# КАЗАН УТЛАРЫ

12.1996



# КИЛӘСЕ САНДА УКЫГЫЗ!

**Хөрмәтле укучыларыбыз!**

**Инде тарихта һәм күңелләрдә генә уелып калачак 1996 елның соңгы көннәре якынлашып килә. Ни генә булмасын, без аның белән: «Хуш, рәхмәт сиңа, Иске ел!»— дип дусларча саубуллашабыз. Алда безне Яңа — 1997 ел көтә. Анысын исә һәркайсыбыз: «Рәхим ит, мәрхәбә!»— дип каршы алабыз.**

**Журналыбызны даими алдырып, андагы роман, повесть-хикәяләрне, шигъри әсәрләрне, тарихи-публицистик язмаларны укып барган әдәбият сөюче дусларга без рәхмәтебезне белдерәбез. Алга таба да бергә булырбыз дигән өметтә калабыз.**

**Журналыбызның алдагы санында басылачак әсәрләр белән дә таныштырып китик.**

Атилла Расих. **«Тыныч еллар күләгәсендә».** *Истәлек-трилогиянең өченче кисәге.* Әдипнең автобиографик әсәреннән соңгы китап.

Фәүзия Бәйрәмова. **Кыска хикәяләр дәфтәреннән.** («Моң», «Боз өстендә...», «Сирень чәчәге»).

Шәриф Хөсәенов. **«Безнең подъезд төбе».** *Драматик хикәят.*

Поэзия сөючеләр Илдар Юзиев, Фәнис Яруллин, Зөлфәт-нең яңа шигырьләре белән таныша алачаклар.

Академик Әбрар Кәримуллин Төркиядә чыгып килгән «Казан» журналына тәфсилле күзәтү ясый.

Журнал ел башыннан «Бүгенге проза турында сөйләшү» башлап җибәрә. Сөйләшүдә күренекле әдипләр, тәнкыйтьчеләр, галимнәр катнашачак.

Әмирхан Еники. **«Шәхес».** *(Бакый Урманченең тууына 100 ел уңаеннан).*

Шулай ук Зыя Ярмәкинең тууына — 110 ел, Мирсәй Әмирнең тууына 90 еллык уңаеннан да истәлекләр биреләчәк.

Һәр сандагыча, иҗтимагый тормыш, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары белән дә танышырсыз.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**12**

**(890)**

**1996**

КАЗАН


## *Бу санда*


ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

М. ӘМИРХАН. Дөя муены. *Сатирик повесть* . . . 3
Р. МИНГАЛИМ. Җизле йөгән, җирән атың... *Шигырьләр* . . . 50
З. ЗӘЙНУЛЛИН. Ат караклары. *Роман* . . . 61
Ф. ӘҺЛИЯ. Йөрәкнең соңгы кылы. *Шигырьләр* . . . 108
Ф. ХАРРАСОВА. Соңгы пәрдә. *Шигырьләр* . . . 111
Р. ГАРИФ. Кыска хикәяләр дәфтәреннән . . . 116
С. МУЛЛА ГАЛИ. Өметемне өзмәдем. *Шигырьләр* . . . 133
Н. ИСЛАМ. Ике йолдыз. *Шигырьләр* . . . 136

НУР ӘХМӘДИЕВКӘ 50 ЯШЬ

Н. ГАМБӘР. Каеннар яктысында . . . 55
Н. ӘХМӘДИЕВ. Кыяр-кыймас кояш байый. *Шигырьләр* . . . 56

ПУБЛИЦИСТИКА

К. НИГЪМӘТҖАНОВ. Мин — укытучы . . . 139

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Х. ӘШРӘФҖАНОВ. Язучы һәм тарих . . . 145

ҺАДИ АТЛАСИНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

С. АЛИШЕВ, Р. ГАЛЛӘМОВ. Ут эчендә калган күгәрчен кебек . . . 157

СИРИННЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Р. МОСТАФИН. «Кыш сайрамый сандугач...» . . . 161

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

М. ШАБАЕВ. Зыя Мансур . . . 165
ЗЫЯ МАНСУР. Гомер юлында. *Шигырьләр* . . . 167

ЗӘКИ НУРИНЫҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ

Л. ИХСАНОВА. Урман шавы . . . 169
Зәки Нури хатлары . . . 175

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Тәлгат Галиуллин**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Булат Солтанбәков**
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**

Безнен адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.



Үзем турында үзем . . . . . . . . . . . . 179
Ә. САФИУЛЛИН. Гаҗәп серләр. *Хикәяләр* 180

Дини бәйрәмнәребез һәм истәлекле көннәр 185
1996 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге . . . . . . . . . . . . . . . . 187
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . 191

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: окончание романа З. ЗАЙНУЛЛИНА «Конокрады», сатирическая повесть М. АМИРХАНА «Верблюжья шея» и рассказы А. САФИУЛЛИНА и Р. ГАРИФА; стихи Р. МИНГАЛИМА, Н. АХМАДЕЕВА, Ф. АХЛИИ, Ф. ХАРРАСОВОЙ, С. МУЛЛА ГАЛИ, Н. ИСЛАМА.
«Публицистика»; статья К. НИГЪМАТЗЯНОВА «Я — педагог».
«Литературная критика»: статья Х. АШРАФЗЯНОВА «Писатель и история».
«К 120-летию Хади Атласи»: статья С. АЛИШЕВА и Р. ГАЛЛЯМОВА «Как голубь в огне».
«К 100-летию Сирина»: статья Р. МУСТАФИНА «Соловей не поет зимой...»
«К 75-летию Заки Нури»: статья Л. ИХСАНОВОЙ «Лесной шум» и письма З. Нури.
Религиозные праздники и памятные дни мусульман.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Шок» — фоторепродукция из картины художника Анвара Сайфутдинова, известный поэт, главный редактор газеты «Мәдәни җомга» Зиннур Мансуров.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Тәүфикъ Әйди.**
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 5.11.96 ел. Басарга кул куелды 5.12.96 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 10 527. Заказ Е-535.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1996 ел.



**Марат Әмирхан**

# ДӨЯ МУЕНЫ

САТИРИК ПОВЕСТЬ

## Беренче баб

Тәрәзә кашагаларына ябышып каткан нәзек боз сөңгеләреннән тып та тып тамчы тама. Абзарда казлар каңгылдаша. Күрәсең, чатлары аерылып җиткән һәм күкәй салырга әзерләнәләр. Чуар тавык та исән-сау бушанды, ахрысы, куанычы эченә сыймыйча кыткылдапмы кыткылдый.

Ишек алдындагы барча кош-корт, һәммә җан иясениндидер ләззәтле дә, тылсымлы да бер тәэссиратта булып, олы куаныч кичерә иде. Фәкать лапас түбәсендәге печән өеме ышыгындагы өтек койрыклы мәченең генә һичнидә гаме юк. Тик йокымсыравын белә. Хәер, мәчебез дә ауда икән ич! Әнә, күрәсезме, ярым ябык күзләре чыр-чулы чыпчыкларга текәлгән. Чыпчыкларның исә зиһеннәре чуалган вакыт. Ник шунда унлаган мәче сагалап тормый, сөешүләре сөешү.

Әбелмәлих, күтәрмә әрәмәсенә сөялгән хәлдә, ишек алдындагы шушы манзараны күзәтеп торды. «Дә-ә»,— дип сузды ул авыз эченнән, яз җитә икән ләбаса!

Тик аның бу хакта уйлыйсы килми иде. Аннан килеп, ишек алдындагы бу ыгы-зыгы да саныйм утыз, була тугыз кебек кенә ич әле. Кар шул килеш диярлек, бераз тыгызланды да өстен элпә каплады. Башка үзгәреш сизелми. Көн уртасында тамчы тамса да, иртә-кич колак очларын чеметтерерлек салкын. Димәк ки, хафаланырга иртәрәк. Бер быел гына килми яз дигәннәре, моңа кадәр дә, аллага шөкер, ким-хур булмадылар...

Әбелмәлих уйларына алай бик тирәнгә керергә ирек бирмәде. Башы болай да әйләнчек бәрәннеке шикелле иде, бу арада чистый түнеп бетте.

Мәгәр типтереп тә карадылар соң! Күрше Кенә Елга арлары да шаккатты хәтта. Элек татарлар, арларда көн дә бәйрәм, көн дә туй, көмешкә генә җиткер, дип көләләр иде, инде үзләре әрәпә-мәрәкә килеп беттеләр.

Һич уйламаганда-көтмәгәндә туздырдылар ич ата-бабалары кырык ел элек корган ояны. Хисап җыелышы үзе болай матур гына башланып

киткән иде. Гадәттәгечә, президиум сайладылар, рәис нотык сөйләде, алдынгыларга бүләк өләштеләр. Шул бүләктән башланды да инде низаг.

— Нибуч,— дип беренчеләрдән каравылчы Муса урыныннан купты. Бүрек асты җылынганда «нибуч»ларны ул шулай капчыклап сибә.

— Тыңлыйбыз, нинди тәкъдимең бар?— диде рәис.

— Нибуч, әйтербез дә, без кемнән ким, әнәтрәк, нишләп миңа бүләк юк?

Җыелышны алып баручы ике арадагы бу чәкәләшүне уенгарак борырга уйлады, күрәсең. «Алайдыр шул, юктыр шул»,— дип елмайгандай итте.

— «Дыр»га чебен дә кунмый, уйлап сөйләш.

Рәиснең нияте барып чыкмады, шуңа күрә:

— Бүләк яхшы эшләгәннәргә, алдынгыларга гына бирелә,— дип җитди генә аңлатырга кереште.— Син, Муса, салмыш баштан тәмәке тартып аз гына фермага кызыл әтәч җибәрмәдең. Ярый әле савымчылар вакытында абайлап алганнар, югыйсә, көле күккә оча иде фермабызның.

Муса да бирешми:

— Яңа заманда яшибез, нибуч, калхуз үзебезнеке, бүләге дә барыбызга да булырга тиеш! Югыйсә, әс-пес, артың кыс, тик утыр да бик утыр. Юк, алай булмый ул, җәмәгать!

Мусаның дуамаллыгын әшнәләре күтәреп алды, мәзәк ясап башкалар да кушылды. Клуб эче бермәлгә базар шау-шуы белән тулды. Һәммәсе сөйли, һәммәсе кычкыра. Рәис көч-хәл белән тәртип урнаштырды.

— Нибуч, гаделлек түгел бу,— дип, янә Муса оран салды.— Сабирдан минем кайсы җирем ким, аңа магнитофон, миңа — шиш. Нибуч, минем дә музыкалар уйнатып культуралы ял итәсем киләдер, бәлкем.

Әтәчләнепме әтәчләнә Муса! Өстереп тә торгач, тәмам тугарылды. Рәис тә сүзен бирми, Сабир кебек эшләп күрсәт башта, аннан магнитофонын да, телевизорын да алырсың, ди. Ләкин җыелышның дилбегәсен кулыннан ычкындырган иде инде ул. Хикмәт Мусада гына түгел. Элекке вакыт булса, графинга каләм кагу да аны урынына сеңдерер иде, ялагай эт кебек күзенә генә карап торыр иде. Заманасы үзгәрде, менә нәрсәдә хикмәт. Сабыр, тыңлаучан, итагатьле авылны йөз сиксән градуска борды да куйды базар дигәннәре. Башкала депутатларының йөгәнсезлеге акрынлап авылны да үз җәтмәсенә чорнап алды.

Ләкин моңа кадәрге шау-шу баласы гына булган икән, мичтә булган икән анасы. Югары дәрәҗәсенә җитеп, инде сүрелә башлаган учакка Әбелмәлих дары сипте! Ул дәррәү кабынып китте. Чөнки аның теленнән иң башкисәр кешеләрнең төшенә дә кереп карамаган зәһәр сүз ычкынды:

— Калхузны таратырга, һәркемгә үз өлешен бүлеп бирергә кирәк,— дип кычкырды ул.

Зал бермәлгә тынып калды. Тыңкыш Мөшәррәфнең арттагы рәттә гыр-гыр йоклавы аерым ачык ишетелеп торды.

— Себер китәрлек сүзләр сөйлисең бит, кода,— дип күршесе Әбелмәлихның чабуыннан тартты. Әмма әйтеләсе сүз әйтелгән иде инде.

Янә тавыш-гауга купты. Инде Әбелмәлих күз өстендәге каш иде, инде халык аның авызына карап тора. Ник дисәң, сүзе колакны ярса да, гамәле мавыктыргыч бит, каһәр. Колхоздан үз өлешеңне алу начар нәрсә түгел лә. Сыер, сарык, умарта, машина, акча — һәммәсе бар ич колхозда. Әллә эчне тишәрме алар?

Хакимияткә килгән Мәскәү демократларының игенчене күмәк хуҗалыктан биздерү сәясәте очраклы рәвештә генә булса да, ерак татар авылында да әнә шулай тәүге шытымын бирде. Моны, һичшиксез, алар җиңү дип бәяләрләр иде. Ә халык минутлык вәсвәсәгә бирелеп, әлеге гамәлнең алдын-артын уйлап тормады. Һәм җыелыш бернинди үгетләүләргә дә карамыйча, «колхозны бүлгәләргә», дигән карар кабул итте. Хәер, нәрсә ул колхоз? Мәңгелеккә дип корылган СССРны да бер төн

эчендә пыран-заран китереп ташладылар лабаса! Беркемнән рөхсәт сорап тормадылар, халык фикере белән дә чутлашмадылар. Монда әле, ничә әйтсәң дә, җыелыш карары бар.

Шулай да күз яшьләре, канлы һәлакәтләр, сөргенгә сөрүләр бәрабәренә оешкан күмәк хуҗалык җиңел генә таралыр дип кем уйлаган? Ихтимал, Мусага бүләк эләккән булса, бу уй халыкның башына да кереп карамаган булыр иде. Ләкин ул шул ук вакытта авыл кешесенең аңында җитди үзгәрешләр башлануы турында сөйли иде.

Их, язмыш, язмыш. «Кызыл көч» колхозына нигез салган Тимербай — актив бу хәлләрне ишетсә, җәннәтен дә ташлап кайтыр иде. Ике дә уйлап тормас, кайтыр иде. Башкаларга сабак булсын дип бер сыер белән бер ат тоткан туганы Салихҗанны да кулакка чыгарган, авылдан сөрдерткән иде бит ул. Туганы да үчен кайтарган анысы. Тегене бөтен халык алдында урам тузанына егып салган да, колагын тешләп өзгән.

Колак сурәтен «Кызыл көч» колхозының эмблемасы итсәң дә, гаделлеккә хилафлык булмас иде. Туган якны өйрәнү музеена менә дигән экспонат. Берәү генә дә түгел, ике колак! Берәве ата большевик колагы, ягъни дә кызыл колак, икенчесе... Хәер, анысының төсен әлегәчә билгели алганнары юк. Кыскасы, колхоз үзенең яшәешен колак өзүдән башлаган иде, һәм дә колак фаҗигасы белән яшәешенең соңгы сәхифәсен ачты.

Мал бүлү комиссиясенә башлык итеп Әбелмәлихны тәкъдим иттеләр, үзең башладың, үзең ахырына да җиткер, диделәр. Һай, авыр эш булды ла ул. Бер кешегә ярап булмый, хәтта хатыны да ул төннәрен аркасын куеп ятты. Хатын-кызның шул булыр инде аның, колхозга кергәндә, «нигә кердең» дип талпынганнар, чыкканда «нигә чыгасыз» дип теңкәгә тияләр. Такташ поэмасында сурәтләнгән Мохтар картның карчыгын гына хәтерегезгә төшерегез. Сафура әле, ярый, аркасы белән генә борылып яткан. Теге бит бабакайны бөтенләй җылы түшәгеннән мәхрүм иткән, ди. Ә Сафура исә ирен, энемә ябык сыер туры килгән, шуны да рәтли алмагач, ни пычагыма буталып йөрисең анда, дип әрләгән, имеш. Туган-тумача, дус-иш турында әйтәсе дә юк, талапмы-талыйлар, җә тегесе туры килми, җә монысы. Бөтен кешегә дә симез сыер кайдан табып бетермәк кирәк?

Муса да тавыш куптарды. Дөрес, башта колхоз абзарыннан бер ат, бер тана, бер дуңгыз җитәкләп алып киткәндә авызы ерылган иде. Өйдәгеләре котырткан, ахры. Кыюлык өчен бераз тамызып, танасын җитәкләп килеп җитмәсенме.

— Нибуч, ирек бирмибез! — дип комиссия өстәленә йодрыгы белән китереп тә сукты бу, — давай миңа кәррәк тана!

Өстәл өстендәге әйберләр биешеп алды, кайсылары бөтенләй аяк астына ук тәгәрәп төште.

— Нәрсә очынасың, кәҗүннәй эш сагындырдымы әллә? — диде Әбелмәлих. Тирә-яктагылар мыек астыннан гына елмаеп куйдылар. Чөнки Нибуч күптән түгел генә әлеге чыкмаган янгын өчен унбиш тәүлек «утырып» район үзәге урамнарын себереп кайткан иде.

— Ирек бирмәбез! — дип кабатлады баягы сүзен Муса.

— Син үзең ферма эшчесе идең ләбаса, нигә симертмәдең соң?

— Долой, — диде Муса, — кемлегеңне бик яхшы беләбез!

Әбелмәлихның да талканы коры. Ләкин комиссия әгъзаларына чыгырдан чыгарга ярамый. Алдан кисәттеләр, эш бик четерекле булачак, диделәр, коткыга бирелмәгез, әшнәлеккә юл куймагыз, сүзен дә әйтә белегез, диделәр.

Мусаны исә шәрә арты белән бозга утыртырга әмәле бар иде. Шуңа күрә Әбелмәлих бу форсатын кулыннан ычкындырмады.

— Әгәренки ошамаса, Муса дус, танаңны хәзер үк абзарга кертеп яп, өйдәге малларыңны да алып кил, кая куярга урын табарбыз.

— Ничек кертеп яп, ничек алып кил?

— Шулай, Муса дус, бабаң Хәмидулла колхозга кәҗә койрыгы тотып кергән, колхозда кәҗә юк хәзер, аның урынына сарык бирербез, бигайбә.

Муса ни әйтергә белми тотлыгып калды. Маңгаендагы сырлары тирәнәйде, күзләре томаланды. Берара күзгә-күз карашып тордылар болар. Аннан соң Муса усал эт шикелле Әбелмәлихка ыргылды. Ыргылды да бәреп тә екты. Тотындылар әүмәкләшергә: әле берсе өскә чыга, әле икенчесе.

Шулчак Әбелмәлих бугазына пычак тигән дуңгыз кебек кычкырып җибәрде. Ә Муса шыпан-шыпан гына торды да, танасын җитәкләп утардан ук чыгып ычкынды.

Әбелмәлихны күтәреп торгыздылар. Шаккатырлык хәл, аның сул колагы тиресендә генә асылынып тора иде. Муса умырып алган. Чаптырып шәфкать туташын китереп бастырдылар. Ул яралыны шундук хастаханәгә алып китте. Аннан Әбелмәлих тегелгән колак белән кайтты.

Сәгыйдуллиннарның үзеннән соң киләчәк буыны «Колак» кушаматын ничек кабул итәр, әмма Әбелмәлихка ул сәгате-минуты белән беректе.

## Икенче баб

Йөрәкне ярып район хакимияте башлыгы бүлмәсендәге кызыл телефон шалтырады.

Туры элемтә! Казан! Үтәгәнев кабаланып урыныннан торып басты да, тәҗрибәсез яшь солдат кебек, шәрә башының чигәсенә кулын куйды. Шалтыратучысы хәтәр бит — Түрә! Әллә кайларга куярсың кулыңны. Бер киртеге туры килмәсә дә, җиде бабаңны хәтереңә төшертә торган кеше. Әгәренки күңеленә ярыйсың икән, җил-яңгыр тигезмәс мәгәр. Шуңа күрә Үтәгәнев Түрәне үзенә карату өчен бите белән җир сөберергә дә әзер. Чөнки сәбәпләре бар. Ул Чаллы якларында совхоз директоры булып эшли иде. Чыгышы белән үзе шушы районныкы, берара авыл хуҗалыгы идарәсен җитәкләп тә алган иде. Тик беренче секретарь өнәп бетермәде. Инде ул карьера, үсү турында уйламый да иде, шушы эшеннән риза-бәхил булып йөри иде. Чокып чыгардылар. Кем булды ул мәрхәмәтле адәм, тәки төбенә төшә алмады, кыек атып туры тигезгәннәрен белмичә калды. Чөнки район Советы җитәкчелеккә читтән китерелгән кешегә ризалык бирмәгән, ашыгыч рәвештә «үз кешене» эзләргә туры килгән. Сәяси уенның андый кагыйдәләре дә бар икән аның.

Югарыдагыларның шәхси коттеджлар белән мавыккан чагы иде. Абруй шуның белән билгеләнә иде. Сауна-мунчаларга кыйммәтле мәрмәр белән тышланган махсус җир асты юлларыннан гына йөри башлаганнар иде. Кемнең люстрасы затлырак, кем ишегенә алтын йөгертелгән тотка куйган, кемнең бассейны тирәнрәк, озынрак, киңрәк — очрашсалар, гәп шул хакта. Бер-берсенең йортларын килеп-килеп карыйлар да, чит-ят нәрсә күрсәләр, инде башкарылган эшне җимертеп яңача кыландыралар. Материаллар чит мәмләкәттән кайтарыла, эмиссарлар әле Төркиягә, әле Германиягә, әле Финляндиягә, әле Америкага оча. Икешәр-өчәр мәртәбә.

Партия камытын салган номенклатура ни кыланганын белми тузынымы-тузына. Бер җирдә берниндн күзәтчелек юк. Өстәгеләргә ярасаң, житкән. Идарәче даирәләр демократияне әнә шулай үзләренчә, йөгәнсезлек дип кабул иттеләр. Хәзер аларны бу юлдан, ай-һай, кубарып булыр микән?

Сессиядәге чыгышында Үтәгәнев ачыктан-ачык әйтте, мин үзгынчы түгел, туган ягыма гомерлеккә кайттым, диде. Элекке башлык яшәгән йортны балалар бакчасына бирәм, үземә йорт салам, диде.

— Афәрин! Афәрин! — дип халык гөрләтеп кул чапты. Димәк, абзыебыз ышанычлы!

Әйткән сүз — аткан ук. Көннәрдән бер көнне Ленин урамының түрендә шаулап утырган паркның агачларын аударырга да тотындылар. Башта халык паркны авыру-черек агачлардан чистарталар дип юраган иде, әмма шырпыдай төз чыршы-наратларга да кул тигезгәч, төшенделәр, димәк, Үтәгәнев йортына урын әзерлиләр. Ветераннар администрация башлыгына делегация юлладылар, кабул итмәде. Ахыр чиктә пикет оештырып, җанлы чылбыр рәвешенә паркны уратып алдылар. Өч көн рәттән. Морадыбызга ирештек, дип уйлады гаделлек сөючеләр. Чөнки агач егучылар башка күренмәде.

Алар төнлә килде. Прожекторлар уты яктысында йорт өчен кирәк булган җирне чистартып та куйдылар.

Көрәш кәгазьгә күчте — газетларга яздылар, шикаятьләр юлладылар. Ләкин туй үткәч, дөмбергә генә иде бу. Аңа карап төзелеш тукталмады. Киресенчә, ул аны тизләтергә генә булышты. Ике-өч ай эчендә өч катлы ташпулатның түбәсен ябып та куйдылар.

Менә шушы дәгъваны башка мәңге калкып чыгалмаслык итеп томалап куярга чамалый Үтәгәнев. Әгәренки Түрә ачык чырай күрсәтә икән, эш пешәчәк. Аннан соң аңа хәтта Берләшкән Милләтләр Оешмасының да теле үтмәячәк. Хәзер, Аллага шөкер, партбилетны алу белән дә янамыйлар, бюро да, чуртым да юк. Сәмән патша хәзер, әшнәлек!

...Трубкада «Кем» дигән калын тавыш яңгырады. Зур түрәләрнең элек-электән килә торган гадәте бу. Исәнлек-саулык сорашу юк, юри генә булса да хәл белешү юк. Хәлбуки, түрә кемгә шалтыратуын бик яхшы белә, бу телефонда башка кешенең булуы мөмкин түгел, алар санаулы гына, һәрберсе исем-фамилияле. Түрәнең үзе башлап кул астындагы кешене сәламләве бу даирәдә вазифалар баскычының тәртибен бозу санала.

— Бу мин, Үтәгәнев иптәш... туест... товарищ Сафин...,— дип ыкмык килде район башлыгы. Аннан көч-хәл белән бар кыюлыгын җыеп, үтә бер тәмлелек белән сүзен башлады, әйтерсең, авызы тулы бал иде.— Хәлләрегез ничек, Хөрмәт Шакирович, Сезне чамасыннан артык эшли, диләр, алны-ялны белми, диләр... Бераз ял итеп тә китәрсез дим...

Түрә иренеп кенә кеткелдәп алды. Сүземне ошатты бит, дип куанды Үтәгәнев.

Сафинның дөрестән дә кәефе килгән иде. Ул үзен эшем кешесе, шөгыль кешесе итеп күрсәтергә ярата. Башкалар аңа шалтыратканда, гадәттә, хатыны, бала-чагасы, кода-кодагые, «Музгарка» исемле эте турында сораштыралар. Янәсе, интим якка сугалар, шәхси якынлыкка өмет итәләр. Кәтегез, кертә ди Хөрмәт үз дөньясына чит кешене. Гайбәткә туп-туры юл булыр иде бу. Үтәгәнев әнә, чебеш кенә булса да, нәкъ кирәк төймәсенә басты. Күрә, димәк ки, көне-төне бил бөккәнен ишетеп тора.

— Киләсе атнада сезнең яклардан урыйм,— диде ул,— эшләрегез белән җентекләбрәк танышырга исәп.

Шул җөмләне әйтте дә шап итеп трубкасын куйды.

Үтәгәнев очлаеп торган тар маңгаена бәреп чыккан тир бөртекләрен учы белән идәнгә сыпырып төшерде дә, аякларын суза төшеп, юан янбашын кәнәфинең эченәрәк шудырды. Күлмәк якасын ычкындырып, галстугын бушатуга, изүеннән пешкән шалкандай аксыл итләч ияге түшенә салынды. Күзләрен йомды, уйга калды. Әлеге халәттә ул шактый вакыт оеп утырды, гүя, йокыга талган.

Юк, йокламый иде бүлмә хуҗасы, ми сырларының һәрберсендә нидер кабара, нидер селкенгәндәй итә: уйлый Үтәгәнев, план кора. Кунакны ул әсир төшерергә тиеш!

Аның кулы телефон трубкасына үрелде.

— Чишмә! Сәгыйтов!

Күп тә үтми, аның бияләй кебек калын иреннәре дерелди башлады, күзләре җеп шикелле генә сызылып калды. Бу аның көлүе. Шулай тавышсыз гына көлә белә Үтәгәнев. Димәк, телефонда Чишмә районы башлыгы Сәгыйтов.

— Карале, син тәҗрибәле кеше. «Теге» киләм дип шалтыратты, киңәшләреңне бир, ә?

Башлыклар үзара Сафинны «Теге» дип йөртәләр. Өстәгеләрнең һәрберсе кушаматлы. «Бабай», «Дәдәй», «Абзый»...

— Иң әүвәле, дустым, курчакның гүзәлен сайла,— диде Сәгыйтов,— кунагың ифрат та нәзберек, пакь кеше. Аннан соң берүк машина утыргычларының япмасын өр-яңадан тектерә күр. Сер итеп кенә әйтәм, күпләр янды бу мәсьәләдә. Түрәбез бөтен нәрсәдән җирәнә, кашыкчәнечкене дә үзе белән йөртә ул.

— Кит аннан, булмас ла...

Үтәгәнев трубканы кулыннан ычкындырмый гына гәүдәсен туп шикелле кәнәфидән читкә ташлады.— Монысы минем башыма да килмәс иде, рәхмәт. Тагын, тагын...

— Тагын, дип, дускай, барысын да чыбык аша сөйләргә ярамый, ышанычлы кешеңне җибәр. Ә япманың зәңгәрсу төслесен сайлагыз. Саранланма!

Шул ук көнне кулланучылар җәмгыяте рәисе Мәскәүгә элдертте. Икенче көнне кичкә урап та кайтты. Өч төрле тукыма алган. Өчесе дә зәңгәр төстә: берсе куерак, икенчесе тонырак, өченчесе ачык зәңгәр.

Районның иң оста тегүчеләре тәүлек эчендә өч япма әзерләделәр. Берсен каршы алганда кидерербез, икенчесен районда йөргәндә, өченчесен — озатканда,— дип хәл итеп куйды Үтәгәнев.

* * *

Менә шулай кызып-кызып җан-фәрманга бик тә мөһим мәшәкатьләр артыннан йөргәндә Үтәгәневнең башына күсәк белән тондырдылар. Тондырсалар да түзәр иде әле, хан малае түгел, авылда аунап үскән, вакытында барысын да татыды, йодрыгын да, күсәген дә. Ә монда аның бәгырен суырып алдылар. Кирәк бит әй, шушындый дәрәҗәле кеше районга киләм дип торганда гына «ЧП» китереп чыгарсыннар әле! Колхоз рәисен әйтер идем, авызы белән чыпчык аулап йөри, борын астында ни-нәрсә майтарганнарын күрми. Дилбегәне кулында тота алмагач, ни пычагыма ыштан төбе туздырып утырырга. Хараплар итте, хайван...

«Кызыл көч»кә барганда әнә шулай эт итеп сүкте Үтәгәнев колхоз рәисен. Проблема арты проблема. Моны Сафиннан яшереп калып буламы, юкмы — бер Алла үзе генә белә. Ничек тә сиздермисе, белдермисе иде бит. Дөрес, колхозларның киләчәк язмышы турында бәхәс күптәннән бирле бара. Рәсәйнең үзендә колхозларга һөҗүм тагын да зуррак. Бездә әлегә күтәрелеп бәрелүче юк. Газеталар, киресенчә, күмәк хуҗалыкны тарату — җинаять, дип язалар. Кичә радиодан бер танылган язучы сөйләде, мин, ди, коммунистларны күралмыйм, әмма да колхозларга карата карашым үзгәрде, ди, безне, ди, шулар туйдыра, аларга тияргә ярамый, ди. Шулай да, ди, аз-маз сипләштереп алганда ярап куяр иде, ди.

Сипләү дигәнен ул язучы әйткәнче үк башлаганнар иде инде. Казаннан галимнәр килеп төштеләр дә ничек итеп колхозларны үзгәртеп корырга өйрәтеп киттеләр. Колхоз дип әйтмәгез, хуҗалыкара берләшмә дип йөртегез, диделәр. Ләкин әле өстән бернинди рәсми күрсәтмә юк. «Кызыл көч»тә исә үз белдекләре белән колхозның тамырына балта белән чапканнар. Бусы инде фетнә дип атала. Ә фетнәне бастыралар!

Үтәгәнев машинасындагы радиотелефоннан прокурорның номерын җыйды да дорфа гына:

— «Кызыл көч»кә тикшерүчеләр җибәрдеңме? — диде.

Прокурор берара ни әйтергә белми тамагын кыргалап торды.

— Димәк, хәлне чуртым да белмисең. «Кызыл көч»тә колхозны тараткannар, аңладыңмы?— дип туздырып ташлады аны Үтәгәнев.

Шул кызу белән Үтәгәнев авылга килеп җитте. Бөтенесен утлы табага бастырды, кычкырды, бакырды, янады, куркытты. Ләкин халыкны җыелышка җыя алмадылар. Чөнки мал-мөлкәт бүленгән иде инде. Әле ярый рәиснең күп санлы туган-тумачаларына, кардәш-ырулары, дус-ишләренә сүзе үтә икән, кодалады тәки.

Үтәгәнев буш кул белән кайтып китмәде, ширкәт оештырдылар. «Кызыл көч» зилзиләдән исән-сау котылды. Болай булгач, Сафин алдында йөзе ак булачак Үтәгәневнең.

## Өченче баб

Дөя муены шикелле бу дөнья, бер төз җире юк. Иртәгә ни көтә сине, берсекөнгә ни көтә — белермен димә. Әмма язмыш дигәнең кайвакыт миһербанланып, ачык чыраен да күрсәткәләп куя икән. Казаннан килгән журналистны күрүгә, Үтәгәнев шундый нәтиҗәгә килде. Әле бер кәлимә сүз сөйләшмәделәр, ханым районга килүенең максатын, морадын да җиткерергә өлгермәде, бер-берсенә карашып кына алдылар, югыйсә. Кала чибәркәенең шушы карашы аңа богау салды да инде. Ул тәнендәге һәр күзәнәкнең, һәр әгъзасының уянуын тойды. Рәхәт иде аңа менә шулай күзгә-күз карашып тору.

— Мин яшьләр гәҗитеннән,— дип, ниһаять, ханым аңа курчакныкы кебек кечкенә нәфис кулларын сузды. Куллар нәфис кенә түгел, йомшак та иде. Үтәгәнев тәмам җебеде.— Сезнең белән танышуыма бик шатмын, ярдәмегездән мәхрүм итмәссез, иншалла.

Ханым, озын ак муенын аз гына уң җилкәсенә янтайтты да, тигез ак тешләрен күрсәтеп елмаеп җибәрде.

— Шту сез, шту сез, әлбәттә...

Үтәгәневкә, мөгаен, ниндидер башка сүзләр әйтергә кирәк иде, ләкин башына ник бер юньле уй килсен, телендә шул «шту сез дә, шту сез», ул аннан әңгәмә буе котыла алмады.

— Мине мәдәният мәсьәләләре борчый, Гали әфәнде,— дип дәвам итте сүзен журналист,— авылларда булырга иде, транспорт белән тәэмин итәрсез, дип уйлыйм. Үзегезнең фикерләрегезне дә беләсе килә, вакыт табарсыз бит?

Шома маңгаена җиңелчә генә җыерчык чыгарып, ханымның кашлары сикергәләп алды, ирен очларына янә күбәләктәй җиңел елмаю кунды.

— Шту сез, шту сез...

— Алайса мин урнаша торыйм, Гали Үтәгәневич, берәр сәгатьтән урап килермен,— диде корреспондент,— килештекме? Минем исемем Миссамира.

Килеш килбәте белән дә, исеме белән дә аңын томалады журналист район башлыгының. Мондый бар яктан да килгән ханымны Үтәгәневнең беренче күрүе иде. Үзе чибәр, үзе көләч, үзе корреспондент. Үтәгәнев ул бүлмәдән чыгып киткәч тә кадакланган шикелле урынында басып торды. Аны бу халәтеннән телефон челтерәве генә арындырды. Районның баш балыкчысы икән.

— Гали Үтәгәневич, кара балык урынына карп ярамасмы, өченче күлгә җиттек, ник берәү эләксен,— диде ул ялварулы тавыш белән.

Үтәгәневнның аскы ирене бүлтәеп алга чыкты, иягенә яңа сыр өстәлде.

— Күлегезне хет күккә асыгыз, ләкин кара балык булырга тиеш!

Сафинны каршы алуга әзерлек яхшы бара, моны Үтәгәнев үзе дә яхшы белә. Кара балыкны, әлбәттә, тотачаклар. Бу шалтырату әлеге

бәндәнең үзен эш кешесе итеп күрсәтергә тырышуы гына. Әгәр шуны башкарып чыга алмаса, муенын борачакларын белә ич ул.

Ләкин бу минутта аның күңеле киң, берәүне дә аяк тибеп, өстәл сугып ачуланасы килми иде. Бүлмәдә әле дә булса теге хур кызының нуры балкып тора. Тиздән ул үзе дә ишек какты.

— Мин сезнең карамакта Мис... миссис туташ...

— Миссис булгач, туташ була инде ул, мистер Гали,— дип чытлыкланды ханым.— Мисс тә түгел, миссис тә түгел, Миссамира! Миңа үз исемем бик тә ошый, зыялы, әйеме, миндә генә ул исем! Бердәнбер!

Миссамира үзенең көчен дә, мөмкинлекләрен дә белә иде. Һәм ул тып-тып басып ишек тарафына юнәлде.

Авылларда моңа кадәр культура дигән сүзнең «к» хәрефен дә ишетергә теләмәгән башлыкның клубларга, китапханәләргә кереп, хәл-әхвәл белешүенә шаккаттылар. Хәер, ул үзе дә икенче дөнья ачты. Баксаң, мәдәният өлкәсендәге мәсьәләләр дә бихисап икән ләбаса!

Чиялек дигән авылда бөтерчек кебек кенә бер китапханәче, автограф язып калдырыгыз, дип теңкәсенә тиде бит. Янәсе, бу тарихи вакыйга, әлегә кадәре монда бер югары түрә дә аяк басмаган.

Автографлар өләшеп йөргәнмени Үтәгәнев, аптырады тәки, бәладән журналист кына коткарды. Имзагызны гына сырлагыз, диде. Ә теге сукыр чебен өзми дә, куймый да, иптәш Үтәгәнев, ди, Сез язучылар, сәнгать әһелләре белән еш очрашасыздыр, Сезгә бигрәк тә кайсы язучылар ошый, ди. Минем үземә, мисал өчен, Аяз Гыйлаҗев якынрак. Сез, бәлкем, ди, аның реализмы катгый диярсез, ләкин дә мин шундый җитди язучыларның әсәрләрен хуп күрәм, ди. Аяз абыйның «Йәгез, бер дога» әсәрен, әлбәттә, укыгансыздыр, фикерегез ничек?

Кулыннан килсә, Үтәгәнев ябышкак кандала кебек кадалган бу хатынны баш бармагы белән сытып изәр иде. Ә ул елмаерга, боргаланырга, гәпләшергә мәҗбүр. Бу салам сыйрак корреспондентын әйтер иде, район үзәгендә генә караштырса ярамаган димени. Чөй дә сыймаган чакта койрык булып йөр инде менә.

Китапханәче үтә беркатлылык белән күзләрен аңа текәгән, йөзе тулган ай кебек якты, әйтерсең лә, каршында пәйгамбәр басып тора. Үтәгәневның исә әдәбият турындагы мәгълүматы моннан унбиш ел элек тәмамлаган мәктәп программасының хәтер иләге өстендә калган кыйпылчыкларыннан гына гыйбарәт. Китапханәче атаган язучыларның әсәрләрен түгел, исемнәрен дә көчкә исенә төшерде. Бәһаләре сукыр бер тиен. Алар сиңа иген игешәме, терлек карашамы? Вакытын кая куярга белми йөргән эшсез кешеләргә генә ул әдәбият дигәннәре, үзенә күрә уен, күңел юаткыч. Каладагылар өчен. Ныклап тикшереп, кызыксынып карасаң, бу китапханәче дә гаиләсез, йортсыз-ихатасыз ялкау бер хатындыр әле. Тәгаен шулай.

Шулаен шулайдыр да, ләкин ничек судан коры чыгарга, җавап кетә бит ул. Казан хатыны алдында сер бирергә ярамый. Әнә ничек сынап карап тора. Һәм каплады Үтәгәнев китапханәченең авызын.

— Мин Тукай белән Пушкинны гына укыйм, башка эбер-чыбыр...

— Юк, юк, сез мине дөрес аңламадыгыз, Гали Үтәгәневич,— дип бүлде аны китапханәче,— бүгенге татар язучылары турындагы фикерегезне беләсем килә, мин аны альбомга язып та куяр идем. Китапханәгә әдәбият сөючеләр генә йөри. Бик зур рәхмәт Сезгә...

— Башка вакытта, сеңлем, хәзергә бәхәс клубы ачмыйк инде, күреп торасыз, без эш кешесе,— дип, Үтәгәнев ишек тоткасына ябышты.

Алар район үзәгенә кайтып җиткәндә караңгы төшеп килә иде инде. Үтәгәнев машинасының яктырткычларын кабызды. Шунда ук ике нур көлтәсе катканак юлга ятты. Сирәк-мирәк кенә кар тәңкәләре төшкәли иде. Машина барган кызуга тәрәзәгә килеп орыналар да, ямьшәеп читкә сибеләләр. Ә бер ишесе барыбер тәрәзә пыяласына сыланырга өлгерә.

Үтәгәнев тәрәзә чистарткычны эшкә җикте. Журналист ханым тын гына шул манзараны күзәтеп бара икән.

— Менә шушы чистарткыч кебек бөтен проблемаларны да берьюлы алып ташлап булса иде,— диде ул бераздан.— Күрегез, ничек ансат.

— Проблемалар бетсә, безгә эш калмас иде,— диде Үтәгәнев эшлекле кыяфәттә. Үзе каш астыннан гына кунакка күз салды. Тегесе йомшак утыргычка чумып утырган, йөзе битараф. Һәрхәлдә, түрәнең олы башын көче итеп үз машинасында озатып йөрүенә карата мөнәсәбәтен белдерергә ашыкканы сизелми. Ләкин Үтәгәнев тә кәҗә катыгы түгел. Аннан соң, хатын-кызның эчендә ни кайнаганын йөзенә карап кына билгеләрмен димә, аның эче тулы хәйлә. Пәйгамбәребез бик дөрес әйткән. Хатын-кыз кәкре кабыргадан яратылган, турайтмакчы булсаң — сындырырсың, дигән ул.

Ике арада ханымның сумкасы. Сумка өстендә мендәр өемендә йокымсыраган мәче кебек ап-ак кул ята. Күрешкәндә ул кулларның йомшаклыгын, сихерен тоемлаган иде инде. Тәвәккәлләргәдер, бәлки? Хан кызы түгел, укасы коелмас. Һәм ул машинаның тизлеген алыштыру сылтавы белән җиңелчә генә ханымның кулына кагылып китте — ничек кабул итәр икән?

Кул урынында калды. Әллә белмәмешкә салышты, әллә сизмәде. Янә тизлекне алыштырды Үтәгәнев. Бу юлы кул елан сыны шикелле урынында гына шуышкандай итте. Үзенә кагылганны сизде, монысы көн кебек ачык. Ләкин ятьмәгә керерме, юкмы? Әлегә билгесез. Инде туктарга ярамый, кизәнгәнсең икән, сук, хатын-кыз һөҗүм иткәнне ярата, диләр. Гомере буе шуңа өметләнеп яши, ди.

Үтәгәнев ат башы чаклы зур, көчле учы белән ханымның кулын кысты. Ике кул да кайнар иде. Икесе дә әллә нинди дуамал хәрәкәтләр ясап биешеп алды. Аннан соң нәфис ак кул җайлап кына әлеге зур учка сыенды...

Юл шундый ук катканак, кар тәңкәләре һаман караңгы бушлыктан атылып килеп чыгалар да, җемелдәшә-җемелдәшә машина тәрәзәсенә килеп бәреләләр. Чистарткыч элеккечә аларны бер селтәнүдә шудырып төшерә, алар урынына икенчеләре, яңалары куна.

Куллар зәлпе тамырыдай чуалышып бетте.

— Проблемаларны уптым-илаһи хәл итүнең юллары бар,— диде Үтәгәнев бая өзелгән сүзне дәвам иттереп,— сезнең бер сүзегез җитә, мисс...

— Миссамира,— дип ярдәмгә килде ханым.

— Гафу, Сез мине бөтенләй телдән яздырдыгыз...

— Үзегез дә джентльмен икәнсез, Гали әфәнде, хатын-кызны болай күккә чөйгән ир-ат сирәк хәзер. Җә, миннән нинди сүз көтәсез?

— Менә хәзер юл чатына килеп җитәбез, нәкъ әкияттәгечә, туры китсәк, салкын кунакханәгә килеп чыгачакбыз, уңга борылсаң — оҗмах көтә. Оҗмахмы, кунакханәме?

— Оҗмах, Гали әфәнде, әлбәттә, оҗмах!

Машина урман эчендәге биек койма белән әйләндереп алынган бер корылмага борылып төртеп туктап калды. Көтеп торганнар, күрәсең, шундук капкасы да ачылды. Эчкә үттеләр. Шыңгырдап торган нарат бүрәнәдән эшләнгән бик күркәм йорт икән. Сагыз, урман исе килеп тора, бер җиргә буяу тимәгән. Бик үзенчәлекле итеп җиһазланган. Калын аяклы өстәл-урындыклар, шундый ук төптән юан шкафлар. Чумып утырырдай күн тышлы дәү кәнәфиләр. Затлы да, таза да.

— Табиевләр дәвереннән соң мондый кунак йортлары бетерелде дип йөри идем,— диде журналист гаҗәпләнүен яшермичә,— ялгышканмын икән.

Үтәгәневнең теленә янә теге чүп сүз сыланды.

— Шту сез... Мис...

— Миссамира. Мис-са-мира! Җә, кабатлагыз әле.

— Мис-са-ми-и-ра!
— Инде сүзегезне дәвам итегез, булдырасыз икән ич.
— Әйе, ни... йортны әйтүем, ул урман хуҗалыгыныкы, без кирәк булганда арендага гына алабыз.
— Бераз тамак ялгап алыгыз да, мунча кереп чыгарсыз,— диде аларны каршы алган ир.

Миссамираның мондый дәрәҗәле мунчага беренче элөгүе иде. Башта музейдагы кебек карап-танышып йөрде. Шалкандай ап-ак юкә бүрәнәләрдән салынган. Биек, киң, иркен. Һавасы саф. Чабыну, юыну, киенү урыннары аерым. Эссе салу өчен генә дә шкаф тулы әйбер: квас, сыра, төрле үлән төнәтмәләре.

Мунчаны ул җайлап, аның бар рәхәтен-ләззәтен мәңгегә тәненә сеңдереп калырга тырышкандай озаклап керде. Берничә тапкыр чабынды. Аннан соң мәтрүшкәле пиннекләрне ләүкәгә җәйде дә, шактый вакыт шулар өстендә сузылып-киерелеп тәмам кәефләнеп ятты.

Дөньяның артына тибә белә түрәләр, дип уйлады ул, шушы юнылмаган бәндә дә нәрсәләр кылана бит, әй. Моннан олыраклары ни майтара икән, күз алдына китерергә хыял көче дә җитми хәтта. Их, шуларның берсенә сукмак салсаң иде, ул да кимен куймас иде. Юк, арыш капчыгы шикелле билсез, муенсыз хатыннары артларыннан тотам да калмый, саклап йөриләр. Хәзер менә шушы авыл мужигы белән компаниягә кер инде. Нишләмәк кирәк, һәркемнең адәм рәтле яшисе килә, акчалы, маллы, дәрәҗәле кешегә сыланмыйча булмый. Хан кызы булып туасы калган да бит, Ходай нигәдер мещан баласы итеп кенә яраткан. Төс биргән, матурлык-чибәрлеген кызганмаган, акыл фарыз кылган, ә байлыктан менә мәхрүм иткән. Мәкалә язып, радиотапшыру эшләп кенә очны-очка ялгау, ай-һай, авыр.

Миссамира көзгедә чагылган үз шәүләсенә телен чыгарып күрсәтте. Бу: «Җитте, кызый!» дигән шартлы билге иде. Шунда ук телевизорны кабызды, анда «Бәхет» ансамбле чыгыш ясый икән. Ярсу музыка, ашкынулы җыр журналистны да үз ритмына тартып кертте, бөгелергә, сыгылырга тотынды. Аерым бер үҗәтлек белән арт санын боргалады, әйтерсең лә, анда нииндидер үче бар иде. Шәрабе дә өстәлдә генә.

Биеде дә биеде, биеде дә биеде...
— Һо, фәрештәбез кайтты, җылы пар белән!— дип, кулына шампан касәсе тотып каршы алды аны хуҗа.

Йөзе килгән иде Үтәгәневнең, кыюлык өчен дип түбәтәй астын да җылытып алган иде. Күзләрендә комсыз бүре касәфәте, корбанын шушы минутта ук ботарлап ташлар иде, шөт. Ләкин бу юлы каршында аның кул салуын зур бәхеткә санап, һәрнәрсәгә әзер торучы хакимиятнең таушалган кызыл иреннәре түгел. Казаннан, башкаланың үзеннән килгән гәҗитче! Шуңа күрә сарык тиресе ябынырга мәҗбүр.

— Өстәл янына рәхим итегез!— диде Үтәгәнев коммунизмга өндәгән Ленин бабай сыны кыяфәтенә кереп,— табын авылчарак инде, анысына гафу.

Миссамираның да шәрабтан соң рәвеше килгән иде, хуҗага хәйләле генә елмаеп бармак янады, артык тыйнаклык күрсәтәсең, янәсе. Аның, билгеле, моннан да нәзакәтлерәк өстәлләргә тап булганы бар. Ул «хуҗа» белән нинди мөнәсәбәттә торуыңа бәйле. Үтәгәнев тә төшеп калганнардан түгел икән. Авыл малае димәссең, җаен китереп маташтыра әй, карышлап-карышлап булса да морадына якынлаша. Үҗәт егет.

— Миңа, зинһар, коньяк сал,— диде ханым сиздерми генә «син»гә күчеп,— шампанны җаным сөйми, үзеңә мулрак тамыз, бу рюмка синең кебек баһадирның кече теленә дә йокмас.

Үтәгәневнең элекке йөгенә тулы фужер да кереп оялагач, бүксәсе тәмам кызды. Башкала корреспондентына ул үзенең эрудицияле, күчеш чоры икъдисадының бөтен нечкәлекләреннән хәбәрдар, киң колачлы житәкче икәнлеген күрсәтәсе килде. Шуңа күрә моннан биш-алты гына

минут элек бөтен җаны-тәне белән омтылган нәҗес теләге дә ничектер сүнеп, арткы планга күчте. Психологлар моны гадәти булмаган ситуация дип йөртәләр. Баксаң, бәгъзе адәмнәр нииндидер көчле кичереш йогынтысында кайчак бернәрсә турында уйлыйлар һәм шул ук мизгелдә аңа капма-каршы гамәл кылып куялар икән. Кеше күңелен борынгылар тикмәгә генә карурманга тиңләмәгәннәрдер, күрәсең.

Үтәгәнев тә шундый халәттә иде. Һәм һич уйламаганда сәясәткә борын тыкты. Аның да югары дәрәҗәсенә.

— Өстәгеләр каешланды,— диде ул,— хаталары бихисап. Безгә монда шуларны шомарткалап, төзәткәләп утырырга туры килә...

Миссамира айнып китте. Ник дисәң, рәсми даирәдә, гадәттә эчендәге тышка чыгарып сипмиләр. Киресенчә, хуҗаларның үзләренә барып ирешмәсме дип, һәр уңайдан аларга мәдхия җырлыйлар. Шалканда да баш, моңарда да баш, күр, курыкмыйча ничек әтисенең сакал-мыегын тарткалап мәтәшә.

— Үзләре һаман мактаныша, без болай да, без тегеләй. Бәйрәм итәләр дә бәйрәм итәләр. Ә халык ярлыланганнан-ярлылана. Ул указмуказларын әйтер идем, аларны үтәү түгел, танышып чыгарга да өлгерә алмыйсың. Яхшыатлы булырга тырышалар. Кыскасы, төтене күп, уты аз, шау-шуы күп, эше аз...

— Ә сиңа нәрсә комачаулый, эшлә соң?

— Анда Шәвәли, монда Шәвәли, тегендә дә шушы кеше әвәли,— дип авызын ерды Үтәгәнев, ниһаять, теле ачылганга куанып.— Ирек юк, юл бирмиләр...

Миссамира, әңгәмәне кеше-фәлән тыңлап тормыймы икән, дип якягына каранды. Өйдә үзләре генә иде, аларны капка ачып каршылаган ир дә юкка чыккан.

Миссамира бер салып, бер киеп азапланган күзлеген, ниһаять, сумкасына салып куйды да, Үтәгәневкә елышыбрак утырды. Тегесе аны шашып үбәргә кереште.

— Ой, син нинди дәртле,— дип пышылдады Миссамира.

Үтәгәнев мәгъшукасын күтәреп алып диванга салды.

— Җанаш, ашыктырма... мин хәзер... үзем...

— Изәм,— дип үкерде Үтәгәнев.

— Изәрсең, җанаш, мин риза, тик сиңа бер үтенечем бар, Гали...

— Синең өчен җирне күккә асарга да риза...

— Җир әлегә үз урынында калсын, Гали,— дип Миссамира аның чәчләреннән сыйпады,— миңа менә шушы кәгазьгә кул куйсаң, җитәр...

— Каләмеңне бир!— дип бүлде аны Үтәгәнев,— тизрәк!!!

* * *

Үтәгәнев фатирына соңлап кайтса да, гадәттәгедән иртәрәк уянды. Башы авыртканга түгел, юк, хәмердән аның башы авыртмый. Йомшара, исерә, анысын инкяр итеп булмый, әмма бер-ике сәгать мендәргә башын салып алуга, барысы да үтә. Бу яктан организмы сынатмый әлегә.

Шомланып уянды ул бүген. Күңеленнән кичәге хәлләрне кино кадрлары кебек кирегә әйләндереп, сүтеп-сүтеп карады. Авылдагы очрашулар, юлдагы әңгәмә — болары тәртиптә, тел-теш тидерерлек түгел. Мунча? Анысы да шома үтте. Гадәттә, ул мәгъшукалары белән бергә чабынырга ярата иде. Монысы яңа кеше бит, кыймады.

Тукта-тукта, нииндидер кәгазьгә имза сырлатты түгелме? Әйе, сырлатты. Нинди кәгазь иде әле ул? Ә-ә, ришвәт, спонсор килешүе, имеш. Язылачак мәкалә өчен бүләк. Фәхишә! Һәммәсе каерырга тора кабахәтләрнең. Ансы ярар ла, каймагын эчте: бушка түгел, димәк ки. Биш миллион кайдан килеп, кая китмәгән. Үз кесәсеннән түләми лә.

Тагын, тагын нәрсә?

Хәтер киносы иң хәвефле кадрда туктап калды. Үтәгәнев урыныннан сикереп торды да тәрәзә форточкасын киереп ачты. Йөзенә, шәрә тәненә салкынча җил китереп бәрде. Әле караңгы иде. Урамда кешеләр күренми диярлек. Шулай да бер өлгере атын җигеп чыккан әле. Их, шул чанага утырасы иде дә, болынга элдертәсе, кар көртләрен ера-ера яңа кибәнне башлап, тирләп-пешеп печән төйисе иде. Онытасы иде барысын да. Ләкин әйтеләсе әйтелгән, ул кино кадры түгел, аны кире әйләндереп булмый. Сүз утыз теш арасыннан чыкса, утыз кешегә җитә, дигәннәр. Үтәгәневне аеруча шул борчый. Әгәр дә кичә такылдаганнар югарыга барып ирешсә, көлен күккә очырачаклар! Изәчәкләр!

Тукта-тукта, ничек барып ирешергә тиеш соң әле ул? Юк, ул берничек тә анда кадәр җитә алмаячак. Ник дисәң, әлеге сүзләрне шаһитлар алдында сөйләмәде ул...

Үтәгәнев шатлыгыннан шап итеп учын-учка бәргәләп алды, вәйт дивана, кайчаннан бирле юкка баш вата бит, әй. Буялган ирен шаһит була алмый. Кыскасы, мунча да, чуртым да юк. Әгәренки авызыннан кирәкмәгән сүз ычкына икән, бу инде яла ягу, ягъни мәсәлән. Ә эш урыныңдагы түрәгә яла ягу би-и-к хәтәр нәрсә. Тиешле урынына шалтыратып әйтәчәк кенә ул. Аннан соң коллектив хат та оештырып җиффәрәсең. И һәм дә тәти кызың тү-түт.

Сөенече иң бөек ноктасына җитте генә дигәндә, Үтәгәневнең йөзе чалшайды, иреннәре иске мендәр шикелле салынып төште. Хәтер кадры янә хәвефле хәбәр китерде: теге салам сыйрак күзлеген бер киде, бер салды. Моның берәр хикмәте булмадымы икән? Әллә бөтенләй сүзләрен магнитофонга ук язып алганмы? Күзлек, бәлкем, сумкадагы магнитофонны кабызу-сүндерү өчен сәбәп кенә булгандыр? Моны, һичшиксез, тикшерергә кирәк.

Ул кискен бер фикергә килеп, Миссамираның телефон номерын җыйды. Бер җыйды, ике, өч. Шуннан соң гына әле йокысыннан айнып бетмәгән хатын-кыз тавышы ишетелде:

— Кем бу, мин әле тормадым...

— Миссамира, мин бу,— диде Үтәгәнев,— чыдар чамам калмады, күрәсем килә...

— Ә-ә, и-и, аю, кичә изеп бетергәнсең...

— Мин хәзер, көт.

Үтәгәнев килеп җиткәндә Миссамира көзге каршында буранлы төннең сикәлтәләрен шомартып азаплана иде. Күз кабаклары җилсенгән, иреннәре бүрткән, муен тиресе йомарланган кәгазь рәвешенә кергән. Ул инде алиһә түгел иде. Тузган чәчле гап-гади хатын. Үтәгәневнең борыны җыерылды. Әмма бу халәтен сиздермәде, тешен кысып булса да, кочаклагандай, үпкәндәй итте.

Чәй әзерләделәр. Ул нәкъ менә шунысын түземсезлек белән көткән иде. Миссамира киенгән арада аның чәшкәсенә ике-өч бөртек сәдәпле дару тондырды. Гафу, чибәркәй, йокы даруы әйбәтрәк булыр иде дә бит, нишлисең, бетеп киткән икән, каһәр, дип уйлады Үтәгәнев, бигайбә. Әле монысының хикмәте булырмы? Һәрхәлдә, ун-унбиш минуттан нәтиҗәсе күренергә тиеш. Чыннан да, матур гына ашап утырганда хатын урыныннан торды да: «Мин хәзер»,— дип патшалар җәяү йөри торган урынга элдертте.

Үтәгәнев рәхәтләнеп киерелеп алды, димәк ки, эше пеште.

Миссамираның өченчеме, дүртенчеме сәяхәтендә Үтәгәнев хатынның сумкасыннан магнитофонны суырып чыгарды да, кассетасын алып кесәсенә шудырды. Килешү кәгазе дә аңа күчте.

— Миссамира, сине урынбасарым озатыр, үземнең киңәшмә үткәрәсем бар,— дип Үтәгәнев урыныннан кузгалды.

— Үзең: «Чыдар чамам юк», дидең...

— Әле күрешеребез...

Шушы кызудан авылдан ук чыгып ычкынды Үтәгәнев. Юлсыз, чокырлы-чакырлы кырда кар ерып бара торгач, куәтле джип елга ярына килеп төртелде. Рульгә башын салып Үтәгәнев шактый озак хәрәкәтсез утырды. Аннан соң зур кырлы стаканга мөлдерәмә итеп коньяк салды да, авызына агызды. Нервылары киеренке чакта ул шулай уптым-илаһи чөмерә. Нервылары исә, чыннан да, скрипка кыллары шикелле тартылган иде, шартлап өзелергә тора. Аның сүзләре язылган кассетамы бу, юкмы — ми күзәнәкләре шушы сорау белән тулган. Әгәр ул булмаса, корреспондентны сатып алырга туры киләчәк. Каерачак ул аннан мәгәр, бик нәфесле, туя торган түгел.

Үтәгәнев сак кына кассетаны магнитофонга урнаштырды, курка-курка гына төймәсенә басты. Кыштыр-кыштыр килеп тасма әйләнә башлады, нәрсәдер сызгыра, чиный, әйтерсең лә, тартмасына тычкан балалары кереп оялаган. Ниһаять, ютәл ишетелде. Эченә җан йөгерде Үтәгәневнең, чөнки ул үзенең тавышын танып алган иде инде. Күп тә үтми, ул көткән сүзләр яңгырады:

— Өстәгеләр каешланды, хаталары бихисап...

Үтәгәневнең калын гәүдәсе күмер капчыгына охшап калды. Бур кеше шикелле як-ягына каранып, магнитофонны туктатты да бүреген арт утыргычка тондырды. Бүрек эче лычма су иде.

Язманы ул тулы килеш тыңлап бетерергә җөрьәт итмәде. Бугазына янә бер стакан коньяк агызды да, кассетаны кульяулыгына төреп, ишекне ачты.

Иң элек туң җиргә кадәр кар көрәде, аннан соң кассета төрелгән чүпрәкне шунда салып, өстенә бензин бөркеде. Ут төртте.

Кассета янып беткәч, көлен җыеп, җилгә очырды.

## Дүртенче баб

Әбелмәлих иске бишмәтен болдыр башына җәеп, шуның өстенә кунаклады. Рәхәт иде аңа. Кышның әле чолгаулары сүтелеп бетмәгән, язның да борын гына төртеп килгән вакыты. Шушы ике фасыл арасында гына була торган ачык, саф, салкынча һава. Ул шифалы бальзам кебек сулыш юлларын ача, тәндәге барлык күзәнәкләргә үтеп кереп, бөтен халәтенә җиңеллек кенә түгел, ниндидер дуамаллык, әтәчлек тә өсти иде.

Әтәчлек дигәннән, ишек алды патшасы үзе дә шушында гына. Әнә, бик эре кыяфәттә әрле-бирле чуалгалап, бикәләрен барлаштырып йөри. Тәкәбберләгән күр, ишек алдында, гүя, аннан да кояз, аннан да кәттә башка җан иясе юк. Хәер, дөресе дә шулай ич. Ул муен, ул күкрәк, ул кәпәчләр — ясап куйган кебек бит, әй! Ходай үзенә матурлыкны мул биргән. Ныклабрак уйлап баксаң, тәңребез ир-ит затын гомумән дә якын итә. Кош-кортмы, җанвар-җәнлекме — һәрберсен үтә бер нәзакәтлелек белән яраткан. Карагыз сез ата күркәгә! Аңа гашыйк булмый мөмкин түгел. Тирә-якны дөмбердәтеп торган арыслан, юлбарыс, киекләр кемнәрне генә сокландырмый. Бәндә дә төшеп калганнардан түгел. Шул ук ир-ат токымын гына алыйк, алар арасында да чабыш атыдай шома елгырлар шактый. Өстәвенә, Ходай үзләренә азмы-күпме хәйлә дә биргән. Күбрәк әнә шуның белән алдыра ул. Әнә, Әбелмәлихнең дә түбәтәй астында чираттагы дуамал уе баш калкатып килә. Бәрәч, тавык шулпасы авыз итмәгәнгә дә биш былтыр икән инде, дип ачынды ул, бозау ите дә, сарык ите — сарык ите дә, бозау ите, кикертә башлады бит, валлаһи! Сафурасы, әлбәттә, теше-тырнагы белән каршы киләчәк, күкәй сала башладылар гына әле, дияр, кул сузасы булма, үземнеке, дияр. Ул шулай хайваннарны, кош-кортларны икегә бүлә: олы мал — Әбелмәлихнеке, кош-корт — аныкы.

Хәер, хатынны болай да чабата башына утыртырга була лабаса. Хатын-кызның чәче озын, акылы кыска, аны саламга сөяү берни дә тормый.

Әбелмәлих, шыпан-шыпан гына басып, лапаска яшергән яртысын алып чыкты да, аның беразын әлүмин савытка агызды. Аракыга ипи кисәкләрен манып җиргә сипте. Сагалап кына торган диярсең, Кызыл Кәпәч килеп тә җитте. Әмма азыкка үрелмәде, кыткылдап хәләл җефетләрен чакыра башлады. Чын ир, чукынчык, иң башта хатыннарын, бала-чагаларын туендыру турында кайгырта. Тегеләре дә күнегеп беткән, очына-тузына сырып та алдылар. Тыгындылар гына. Ә бераздан, син күр дә, мин күр, җыр сузмасыннармы. Хор белән җырлый башладылар. Сикерешәләр, талпыналар, бөтереләләр. Тамаша!

Ул арада Сафура кайтып керде. Чишмә суына барган икән. Әүмәкләшеп йөрүче тавыкларны күргәч, иңсәсеннән көянтәсе төшеп китте, ишек алды су белән тулды.

— Әнекәйгенәм лә, ни булган тавыкларыма?—дип әле берсенә барып тотынды, әле икенчесенә. Аннан билен турайтып иренә акайды.

— Әйттем мин сиңа, җебегән авыз! Ачы болыныннан печән чапма, аксыргаклы диеп. Әнә, алма кебек тавыкларым агуланган, күпме чүпләдем ул аксыргакларны печән өстендә, күпме чүпләдем...

— Соң, әнисе...

— Әнисе, әнисе... Нәмә телеграф баганасы күек катып калдың, хет чалып калыйк ичмаса...

Әбелмәлих мыек астыннан гына елмаеп, келәткә кереп китте, минут эчендә сугым пычагын алып чыкты. Хатыны кулына тоттыра тора, ул чала тора. Ун-унбиш минутта ишек алдында Кызыл Кәпәч япа-ялгызы басып калды. Тамак тәмугка кертә, диләр, хак икән.

Әбелмәлих бу кадәрен башына да китермәгән иде, билгеле. Хәзер менә ай буе тавык шулпасы чөмерергә туры киләчәк иде. Әтәч кызганыч, җарияләреннән башка нишләр инде, мескенем.

Шулай да тавык шулпасы аның борчуларын баса алмады, егәре ике-өч кенә көнгә җитте. Чәчәсе бар ич! Элек бу уйлар Әбелмәлихнең хәбәренә дә кереп чыкмый иде, барысы да үз көе белән бара иде. Кайберәүләр хәтта чәчү, урып-җыю кампанияләренең кайчан башланып, кайчан тәмамланганын да абайламыйча калалар иде. Чөнки бар мәшәкатьне колхоз үз җилкәсенә ала иде. Хәзер менә барысы турында да үзеңә баш ватарга туры килә. Нигә эшкә чыкмыйсың дип тәнкыйтьләүче дә, ачуланучы да юк. Бер чыбыркыга өйрәнгәч, ирек дигәненә күнегүе дә авыр икән, каһәр!

Чәчүлек орлыгы җитәр дә, шәт. Ару гына эләктереп калды. Ләкин ул ашъяулык кебек җиргә бодай чәчеп ни майтарасың? Төшемлерәк культура кирәк. Шулай да иң авыры — техника мәсьәләсе. «Кызыл көч» ярдәм итмәячәк, бик дулашып аерылыштылар. Аерым хуҗалыкларга тигән техниканы сатып акчасын гына бүлделәр. Анысы да күке төкерәге кадәр генә тиде. Кайберәүләр ат белән чәчәбез, дип торалар. Монысы суга батканда саламга ябышу гына, күңелне тынычландырырга тырышу гына. Аты булса, арбасы юк, арбасы булса, аты дигәндәй, ятка яраклы җайланмаларны көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмассың хәзер.

Ә чәчәргә кирәк. Аның артыннан әле башка эшләре дә тезелеп тора, тавык чүпләп тә бетерерлек түгел. Ничек булса да, берәр трактор юнәтергә кирәк, шунсыз хана, төп башына утырачаксың. Ялгызакларга кредит бирәләр икән дип ишеткән иде беркөн, әнә депутатлар да телевизордан төкерек чәчте, хак булса, закон да кабул итмәкчеләр, имеш. Анысы әле, мөгаен, күктәге торна гынадыр. Хәзер ничек тә кредит алып, асыл кошның койрыгыннан эләктереп аласы иде.

Шул ният белән Әбелмәлих район үзәгенә төшеп китте. Исәбе, йомышын тиз генә йомышлап, төшкә әйләнеп кайту иде. Чөнки заманасы башка, демократия килде, кәгазь бетләрен, ниһаять, үз урыннарына

утырткannardыр, дип уйлады. Мәгәр бүреләре улады теге вакытта, эчтеләр халыкның канын. Бюрократларның үз кануннары иде шул. Ниндидер бер кәкре саплы өтер өчен генә дә алар сине әйләнчек сарык кебек атналар буе үз тирәсендә әйләндерәләр иде.

Бюрократ, язмышың кыл өстендә торса да, синең үтенечеңне беренче мөрәҗәгать итүдә генә хәл итмәс. Юк! Ник дисәң, әгәр ул аны үти икән, дөнья кендеге булудан туктый. Башын ташка орса ора, әмма бу хәлгә бервакытта да юл куймый чиновник-бюрократ. Дәрәҗә — аның өчен иң кыйммәтле хәзинә. Аның янында йомышчылар умарта күче шикелле мыж килеп торырга тиеш. Аның кирәклеген һәркем даими сизеп торсын, ул дәүләт механизмының бик тә хаҗәт шөребе! Шуңа күрә аның чабатасы түрдә. Син аңа баш иеп, ярарга тырышып сәлам бирәсең, ә ул битараф, йөзендә ник бер мускул җебе селкенеп карасын. Эшле кеше бит, ишетеп бетермәде, ахры, дип, хәлбуки, ишеткәнен белеп торсаң да, тагын ялагай эт шикелле күзенә текәләсең. Теге ниндидер бер мизгелдә, әрем чәе эчкәндәй, йөзен чытып куя. Моңа, һичшиксез, шатланырга гына кирәк, чөнки үҗәтлегең бушка китмәде, сиңа игътибар иттеләр.

Бәлки, миһербаны килеп, күңеле йомшарып китәр? Ләкин... ләкин... Иблис гөнаһтан курыкмаган кебек, бюрократ та шәфкатьне белми.

Әнисенә пенсия юллаганда боларның барысын да башыннан кичергән иде Әбелмәлих. Туу турындагы таныклыгындагы имзаның койрыгы кителгән өчен ничәмә-ничә кабинетларга кумадылар аны. Бусагаларны таптады таптавын, тик барыбер өтек койрык җиңде. Чөнки ул имзаны сырлаган абзый (шул ук бюрократ токымы!) үзе вафат иде инде. Күрәсең, дөньяга үче калгандыр, мине онытмасыннар, чиyләнсеннәр, дигәндер.

— Җә, нәрсә? — дип, ачулы карашы белән үтәли бораулап алган иде аны мөдир соңгы керүендә, гүя, ул аның яраткан маэмаен дөмектергән.

Әбелмәлихнең тез аслары калтыранып китте, хәтта шушындый олуг кешене бимазалап йөрүенә үкенә үк башлады, тел куәсен югалтты.

Мөдирне күрше бүлмәдә чәй көтә иде. Һәм ул мәшһүр гаскәр башлыгы Наполеон рәвешендә кулын алга сузды. Бу — аудиенция тәмам, ягъни эшең бетте кодагый, дигән сүз иде, янәсе, үзең буш куык, башта гозереңне кешечә аңлатып бирергә өйрән.

Шуннан соң Әбелмәлих бу зур йортның бусагасын таптаудан туктады.

Хәзер, әлбәттә, башкача булырга тиеш. Демократия заманы! Пенсия галәмәтеннән соң учреждениеләр тирәсендә йөргәне юк иде Әбелмәлихнең. Шуңа күрә кирәк җирне табуы читен булыр дип уйлаган иде. Ник дисәң, коммунистлар партиясе яшәүдән туктагач, яңа хакимият әгъзалары аппарат биналарын балалар бакчаларына, яслеләргә бирәчәкләре турында лаф органнар иде. Ул биналарның хаҗәте калмый, янәсе, чөнки аппарат, ягъни дә чиновник-бюрократларның саны бик нык кимиячәк. Митингларда күпме изменәрен изделәр. Әбелмәлих хәтта ул «мескеннәр»не кызгана да башлаган иде, алар да кеше ич!

Административ биналардагы язуларны күргәч, Әбелмәлих өнемме бу, төшемме, дигәндәй, авызын ачып калды. Барысы да исән-сау, барысы да урынында лабаса! Шул ук шыплап тутырылган чиновниклар оясы. Утта янмас, суда батмас тылсымлы адәмнәр икән, йа, ходай! Феникс кошы кебек — яндырсаң, көлеңнән яралырлар, шәт.

Әбелмәлих банкның калын ишеген ачып эчкә үтте. Управляющийга керергә, диделәр. Аңа чират шактый иде. Шунда үзе кебегрәк бер кеше белән гәпләшеп тә алдылар. Аның да ссуда артыннан йөрүе икән.

— Өченче килүем инде,— диде ул, уңган ситса кебек төссезләнеп, калын кашларын җыерып,— һаман кул куймый.

— Нәрсәгә бәйләнәләр?

— Башта фермер икәнлегемне раслап көч түктем, аннан болай финанс мөмкинлекләремне тикшерделәр, түли алырмынмы, янәсе, бөлсәң, ни-нәрсәләр сатарга була.

— Инде...

— Инде...

Фермер әйтергә теләгәнен әйтә алмыйча калды, аны икенче бүлмәгә чакыртып алдылар.

Ниһаять, Әбелмәлихкә дә чират җитте. Секретарь кыз, башына өелгән кызгылт чәч көлтәсен кыйшайтып, аңа сүзсез генә ым какты, янәсе, керергә мөмкин.

Әбелмәлих иң элек бүлмәнең иркенлегенә шаккатты. Авыл клубы чаклы. Түрдә ялтыравыклы өстәл. Өстәл өстендә берничә телефон аппаратыннан башка бернәрсә юк. Идәннән түшәмгә кадәр сузылган биниһая зур тәрәзәләрдән төшкән яктылык әлеге даладай киңлеккә ниндидер өрфә җиңеллек тә өсти иде. Шуңа күрәме, өстәл артында утырган кеше әмерикәлеләрнең мәшһүр «Барби» курчагына охшап тора. Шундый ук ыспай, төз, шома.

Озын-озын итеп телефон челтерәде, бүлмәгә касык астыннан чыккан ясалма, әмма мөлаем калын тавыш яңгырады:

— Тыңлыйм!

Бәрәч, Мөсифуллин ләбаса бу! Әлбәттә. Районда тавышын танылган артист Шәүкәт Биктимеровныкына охшатып сөйләргә тырышучы башка кеше юк иде әле моңарчы.

Әйе, бу Мөсифуллин иде. Ул Әбелмәлихкә яхшылык эшләмәячәк. Моннан берничә ел элек нык кына чәкәләшкәннәр иде.

Ул чакта Әбелмәлих сугарулы көтүлектә су сиптерүче булып эшли иде. Ни хикмәттер, ул елны үлән котырып уңды, маллар күзгә күренеп көрәйде. Сөт җиленнәреннән ташып тора иде. Шуңа күрәдер, мөгаен, монда район семинары уздырдылар. Халык күп җыелган иде: җитәкчеләр, белгечләр, савымчылар. Бик төпченеп йөрделәр, янәсе, сөт фураж исәбенә генә артмыймы?

Семинарда райкомның идеология эшләре белән шөгыльләнүче секретарь Мөсифуллин да катнашты, төкерекләрен чәчеп нотык сөйләде, оештыручыларны күкләргә чөйде. Бигрәк тә Әбелмәлих адресына мактау сүзләре күп яңгырады.

— Карагыз сез аңа,— диде ул, озын нәфис кулын Әбелмәлихкә төбәп,— гап-гади совет кешесе, хәтта партия әгъзасы да түгел икән әле, монысы, билгеле, партия оешмасының зур җитешсезлеге (бу сүзләрне әйткәндә секретарь ым кагып партком секретарен урыныннан торгызды, күрегез, янәсе, Үзәк Комитетның партиягә гади халыкны тарту турындагы күрсәтмәсен үтәмәүче менә шушы инде ул!), ышанып әйтә алам, иптәшләр, Сәгыйдуллин коммунист булган булса, үләне болай гына үсмәс иде, икеләтә-өчләтә мулрак булыр иде. Менә кайда ул резервлар!

Икенче көнне үк Әбелмәлихне партия әгъзасына кандидат итеп алдылар. Ә әгъзалыкка кабул итү җыелышына Мөсифуллин үзе дә килде. Әбелмәлихне ул шәкерте дип саный иде.

Ләкин җыелыш бөтенләй көтелмәгән юнәлеш алды. Авылда үзен чын большевиклар рәтендә йөртүче «Туры Хафиз» кушаматлы карт коммунист бар иде. Сөйләшүнең эзен шул чуалтты. Җыелышны алып баручы мәсьәләне тавышка куям гына дигәндә, кулын күтәрде бу. Төртмәле сорауларны ул шулай юри азакка калдыра. Шуңа күрә аннан куркып, шүрләп торалар. Кибешкән иреннәрен теле белән ялпап алды да, чәрелдек тавышын сузыбрак сөален җиткерде Туры Хафиз:

— Ә-әбелмәлих иптәш, әйтегез әле, закун нигезендә хосусый хуҗалыкка йорт-җир өчен ничә сутый җир тиеш?

Әбелмәлих колак артын кашып торды да икеләнебрәк кенә:

— Егерме биш сутыйдыр инде,— диде.

— Инде түгел, дөресе шул,— дип күтәреп алды карт коммунист,— беләсең икән, маладис.— Ә хәзер әйтеп җибәр, синеке ничә сутый?

Төртмәле сорау иде бу. Чөнки узган ел Әбелмәлих күршесе Вафакамалның өч ел буш торган бакчасын үзенеке белән берләштергән иде.

Карчык инде вафат, бала-чагасы юк. Алабутасын бөтен авылга чәчеп ятты. Моны җыелыштагылар да яхшы белә. Шуңа күрә Әбелмәлих та үзен ышанычлы тотты.

— Үзең беләсең бит инде, Хафиз абый...

— Ступ! Ә закун? — дип урынына утыртты Туры Хафиз Әбелмәлихне.

Мөсифуллинның йөзе кара болыт төсенә керде. Сарык тиресе ябынган бүре икән ләбаса бу Сәгыйдуллин дигәннәре дип уйлады ул, шул кешене мин җүләр партиягә өндәп йөрим. Әле ярый вакытында күзне ачтылар. Халыкка бу турыда ачыктан-ачык әйтергә кирәк.

— Владимир Ильич Ленин, — дип башлады ул сүзен, — крестьяннарны вак буржуаз идеологиягә бирелүчән сыйныф дип билгеләде. Шуның өчен дә күмәк хуҗалыклар оештырдылар. Ләкин искелек калдыклары озакка бара, аларга каршы көрәшергә дә көрәшергә әле. Менә Әбелмәлих иптәш тә шул буржуаз идеология йогынтысына эләккән. Теләпме, теләмиме, әмма эләккән. Бу факт! Мондый кеше, билгеле, партиягә якын килә алмый.

Халык алдында мәсхәрәгә калуыннан Әбелмәлих чөгендер кебек бүртенде. Партиягә алмауларына пошынмады ул, юк. Су сиптерүчегә кызыл билетның ниемә кирәге бар? Аны барыбер урынга куймаячаклар, грамотаң юк, диячәкләр.

— Ә сез... син ришвәтче! — дип кычкырды Әбелмәлих гарьлегеннән.

Мөсифуллин өнсез калды. Күзләре күкәй сала алмаган тавыкныкы кебек бүртенеп чыкты. Дер-дер калтыранырга ук тотынды бу. Үзе нидер әйтергә тели, ләкин теле әйләнми, әйтерсең лә, авызына чүбек тутырганнар.

Көчәнә торгач, ниһаять, аңа сүз куәсе кайтты.

— Ялган, ялган бу, иптәш коммунистлар!

Әбелмәлих упкынга тәгәрәвен дәвам итте.

— Булыр ялган, персидәтел Гафуров абый кушуы буенча бер чиләк аертылган бал, бер түшкә сарык итен үз кулларым белән фатирыгызга илтеп бирдем, — диде. — Гафуров абый монда әнә, сүзен әйтер. Син аңа әйткәнсең, Сәгыйдуллин китерсен, дигәнсең, янәсе, ышанычлы.

— Яла бу, яла, — дип тузынды секретарь, — хакың юк, мин судка бирәм!

Колхоз рәисе артын урындыктан алганчы, партком секретаре тиз генә җыелышны япты.

Әбелмәлихнең эше бер-ике ай асылынып йөрде-йөрде дә онытылды. Срогы чыкты, дип мәсьәләгә кире кайтмадылар.

...Менә шул Мөсифуллин хәзер аның каршында. Банк башлыгы. Кайда ояларга белгән, ярпач. Бүлмә хуҗасы әлегә аны күрми, кызыпкызып телефоннан сөйләшә. Ул аны, әлбәттә, таныячак. Нишләргә? Бәлкем, барысына да кул селтәп чыгып кына китәргәдер. Ул барыбер якты чырай күрсәтмәячәк. Әллә беткән баш беткән дип, тәвәккәлләргәме? Ятып калганчы атып кал, диләр түгелме соң?

Бүлмә хуҗасы телефон трубкасын куеп өлгермәде, Әбәлмәлих өстәл янына килеп баскан иде инде.

— Теге чакта бик дөрес әйттегез, иптәш Мөсифуллин, — дип такылдый да башлады ул, — мин коеп куйган вак буржуй булганмын икән, укымаган кешенең шул наданлык инде аның. Сезнең хак сүзегезгә каршы тартгә тибеп маташтым бит, әй. Гафу үтәнәм. Партиягә алмыйча бик дөрес эшләдегез, ул чакта буржуаз идеология бугаздан алган булган икән. Хәзер гүпчем дә элмәгенә эләктерде, колхоздан чыктым бит мин, иптәш Мөсифуллин, фермер, ягъни дә...

Әбелмәлих Мөсифуллинга сүз кушарга да ирек бирмәде, тәтелдәде дә тәтелдәде. Тегесе бер кызарынды, бер бүртенде, алдындагы папкасын әле алдына шудырды, әле читкә этте. Ручкасы белән өстәл өстен дә төеп карады. Юк, сибә генә Әбелмәлих борчагын.

Ниһаять, бер җаен табып Мөсифуллин:
— Сине монда кем кертте? — диде.
— Кызлар...
Мөсифуллин ыспай гәүдәсен өстәл ягына шудырып сөйләшү җайланмасының бер төймәсенә басты. Шул ук секундта ишек уемында секретарь кыз пәйда булды.
— Минем янга теләсә кемне кертмәгез дип ничә тапкыр кабатларга була? — дип ташланды аңа Мөсифуллин, — соңгы тапкыр кисәтәм!
Кыз йөгереп килеп Әбелмәлихнең җиңеннән тарткалый башлады, тегесе аны читкә төртеп җибәрде дә кәгазьләрен Мөсифуллинның йөзенә бәрде.

## Бишенче баб

Әбелмәлихнең тезгене тәмам ычкынган иде. Йөрәге читлектәге кош кебек бәргәләнә, йөзенә хәтта тимгелләр бәреп чыкты. Кара әле син аны, шул адәмгә ярарга тырышып тасма телләнеп азапланды бит, әй, тьфү, кадалып китсеннәр кредитләре-меридитләре белән, җан биргәнгә җүн бирер әле. Алай бик шашса, өенә «кызыл әтәч» җибәрергә дә күп сорамас. Мәгәр, үрле-кырлы сикерер иде. Байсар бикәсе шикелле кукраеп утыруын күр.
Әбелмәлих авыз эченнән сүгенә-сүгенә атның аркалыгын күтәрде, авызлыгын каптырды. Шунда, мин дә бар әле монда, дигәндәй бәрән сарык аваз салды. Бәйле аяклар белән ятуы уңайсыз иде булса кирәк. Дөнья хәлен белеп булмый, кирәге-мазары чыгып куюы бар дип, чанасына бәйләп салган иде ул аны. Менә кирәге чыкты түгелме?
Әбелмәлихнең чырае яктырып китте. Мөсифуллин үрле-кырлы сикерсен әле. Их-ма!
Әбелмәлих сарыкны күтәреп җилкәсенә салды да, атлыгып кабул итү бүлмәсенә керде. Җәт кенә пәкесе белән бәйләрен кискәләп ташлады, аннан соң управляющий кабинетының ишеген ачып сарыкны шунда кертеп җибәрде. Бу шулкадәр тиз эшләнде ки, көлтә чәчле секретарь кыз куркуыннан ачкан авызын ябарга да өлгермәде.
Аты җитез иде Әбелмәлихнең, сызгырды гына. Әмма үзәк урамга җитәрәк аны яшь кенә бер милиционер туктатты.
— Их, чукынды, каһәр, өлгерә алмый калдым! Беренче булып башына шушы уй кадалды. Ләкин милиционер аны-моны белгәнгә охшамаган иде.
— Абзый, монда ярамый, борыл, — диде ул.
— Миңа «Кызыл көч»кә, — диде Әбелмәлих, — тизрәк кайтасы иде.
— Ярамый дип әйтәләр ич сиңа!
— Нишләргә соң?
— 30—40 минуттан дөнья ишелмәс, атыңны аулаграк урынга кертеп тор. Казаннан ниндидер зур кеше килә, алар үтеп киткәнче хәрәкәт тыела..
— Әмәк йөгергәнгә Шәмәкнең табаны кыза, ди...
— Телеңә салынма, әйткәнне эшлә, — диде милиционер. Әмма Әбелмәлихнең сүзе ошады булса кирәк, мыек очлары селкенгәләп торды.
Әбелмәлих атын якындагы бер тыкрык эченә кертеп бәйләде дә халык җыелган урынга китте. Чыр-чу киләләр. Кайсы кибеткә дип чыккан, эшкә ашыгучылар да хәтсез. Укучы балалар да бар. Беркемне беркая җибәрмиләр. Алай гынамы, кунак утырган машина үткәндә сәламләп, кул болгап калырга кушалар.
— Хакыгыз юк! — дип кычкырды кемдер. Нинди таныш тавыш соң бу дип борылып караса, үз күзләренә үзе ышанмый торды Әбелмәлих. Тавыш иясе авылдашы Муса иде. Колак хәлләреннән соң ул авылдан чыгып качкан иде. Чаллыда, диделәр. Күрешүләр насыйп булган икән

ләбаса! Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына дияләрме әле? Бүген ул үчен кайтарачак! Кулы кычыткан вакытка туры килде. Үпкәләштән булмасын, Нибуч дус, бәйрәм ашы кара каршы.

— Кеше хокукларын бозарга хакыгыз юк,— дип оран салды янә Муса.

— Кара-кара, нинди сүзләр сөйли башлаган бу бушбугаз,— дип аптырап китте Әбелмәлих,— каян килгән Сахаров.

Муса, чыннан да, Чаллыда шау-шулы митингларда йөреп, шактый шомарган иде. Мин — колхоз тараткан кеше, дигәч, күтәреп кенә атмадылар үзен. Митингларда инде аның үз роле бар иде. Митинг кызып, кайнау ноктасына җиткәч, кулына микрофон ала да:

— Бетсен калхуз! — дип акырып җибәрә. Җыелышучылар исә аны бердәм рәвештә: «Бет-сен! Бет-сен! Бет-сен!» — дип күтәреп алалар.

Муса кеше җыелган җирне үзеннән-үзе митинг итеп кабул итә башлаган иде инде. Әле дә автобустан төшүгә, җыелган халыкны күргәч, ярсып килеп җитте дә:

— Бетсен калхуз! — дип кычкырды.

Чаллыдагы кебек, аны җөпләүче булмады. Киресенчә, чандыр гәүдәле бер ир: «Колхозга тел тигезәсе булма, күчән баш, шөрепләреңне таратып ташларга да күп сорамам»,— дип тегенең якасыннан ук эләктереп алды.

— Бу контрның авызын капларга кирәк,— дип шаулашты өлкәнрәкләр. Яшьләр авыз ера, аларга кызык-тамаша.

Милиция Мусага болай да теш кайрап тора иде, халык та ризасызлык күрсәткәч, куллары чишелде. Аны ике яктан култыклап алдылар да бүлекчәгә алып киттеләр.

— Кеше хокукларын бозарга хакыгыз юк,— дип бәргәләнде Муса, тик аны тыңлаучы да, кызганучы да юк иде. Әбелмәлих та кысылмады. Чөнки нәкъ шушы вакытта юлда түбәсендәге кызыллы-сарылы утларын җемелдәтә-җемелдәтә килгән ГАИ машинасы күренде.

— Игътибар, игътибар! Урыннарыгыздан кузгалмагыз!

Шуннан соң күп тә үтми, кара машина күренде. Машинаның тәрәзә пыялаларына коңгырт төс йөгертелгән иде, мең мәшәкатьләр белән юнәткән зәңгәр япманы да, аның өстенә җәелеп утырган Түрәне дә шәйләүче булмады. «Ура» да кычкырмадылар. Кешеләр сүгенә-сүгенә үз юлларына киттеләр. Әбелмәлих берүзе басып калды. «Нәрсә булды соң бу?» — дигән гап-гади сорау иде аның башында. Юл бөтен кеше өчен дә уртак лабаса! Нигә дип халыкны эш-шөгыленнән тыеп, көчләп дигәндәй җыеп тотарга? Машинаң бик гайрәтле икән инде, рәхим итеп узып кит, юл сабу ата-бабадан килә торган изге гамәл. Ну, остардылар, валлаһи, мөгез чыгарырга. Элек тегеләй иткән дә, болай иткән дип, патшаларны сүгә идек. Хәзер һәммәсе патша булмакчы. Мөсифуллинны гына күр, кем булып утырган була бит, ә? Ну, шәп итте ул аны, йөриләр бугай бүлмәдә сарык куып. Тегесе чиста келәмнәргә борчакларын сибә булыр...

— Әй, нәрсә катып калдың, телеграф баганасы түгелдерсең бит!

Борылса, аптырап китте, аркасына терәлеп дигәндәй бер чибәр машина туктаган икән, шоферы ишеген ачып аңа кычкыра.

— Гафу ит, энекәш, теге әкәмәтләрне күреп баш чуалды әле монда,— диде Әбелмәлих.

— Эскортны әйтәсеңме?

— Искуратмы-чуртмы, түлке кыланмышлары тиреләренә сыймый.

— Әйе, хәзер үзләре Алла, үзләре мулла...

— Кая болай юл тотасың, энекәш, машинаң да ялт итеп тора? — дип сорады Әбелмәлих.

— Әй, абзый, бездәге тамашаны күрсәң иде син. Көлеп эчләр катты. Бер мужик управляющий кабинетына сарык кертеп япкан, майлый, янәсе. Вәйт, комедия! Шеф, күземә күрсәтмәгез, дип акыра. Ә сарык аның саен котырына гына. Көчкә тоттык.

— Нишләттегез инде, сарыкны, мәйтәм...
— Шеф әйтә, башыннан бер бөртек чәче дә коелырга тиеш түгел, ди. Буталып бетте, мескен, сарыкның башына каян килсен чәч, аны йон баскан ич. Ха-ха-ха!
Әбелмәлих бүреген чөеп, колак артын кашып куйды.
— Шуннан?
— Шуннанмы, әнә кара!
Машина утыргычында, син күр дә мин күр, аның сарыгы кырын яткан. Чиста шикәр капчыгы кидергәннәр, өстендә бизәкле одеал. Керт-керт итеп нидер күши. Казаннан килгән әлеге түрә кебек. Искурт диме, шунысы гына җитми.
— «Кызыл көч»кә илтәм, хуҗасына. Вәйт, комедия!
Машина кузгалып китте. Әбелмәлих кәефе килеп чанасына ауды. Үчемне кайтардым, әкәмәт яхшы килеп чыкты бу, дип уйлады. Их, карап торасы иде чәбәләнеп йөрүен.
Үч турындагы уйлары Мусаны хәтеренә төшерде. Өтермәгә ябып куйганчы, ул мокытны коткарырга кирәк, дигән фикергә килде. Нинчә әйтсәң дә, алар бер җепкә теркәлгән, колхоздан да бергә-бергә чыктылар. Муса башлады, ул күтәреп алды. Утыз җиденче ел кире кайтса, парлап утыртачаклар мәгәр. Кем уйлаган бит әй, колхоз кадәр колхозны бүлгәләп булыр, дип? Башка сыярлык хәл түгел иде үзе. Авылның яртысы аерым хуҗалык ич хәзер!
Муса милиция бүлекчәсендә дә үзен митингтагыча тота иде, авызында һаман шул бер балык башы: кеше хокукларын бозмагыз!
— Кикригеңне шиңдерерләр, бик очынма,— диде Әбелмәлих,— эш тирәнгә кергәнче табанны ялтыратыйк моннан.
— Әйе, әйе, абый, алып кит әле шуны,— диде урамда танышкан яшь милиционер,— олы түрәләр килгән көнне безгә кешеләрне тоткарларга ярамый. Штраф чәпесәң, яхшы булыр иде анысы.
— Аның акчасы юк,— диде Әбелмәлих,— ул аерым хуҗалык, теле хакында дөрес әйтәсең, бик озынайган, кисәсе булыр.
— Хакыгыз юк кеше хокукларын бозарга,— диде кирегә каткан Муса.
Әбелмәлих аны милиция бүлекчәсеннән көчләп дигәндәй алып чыкты.

* * *

Казаннан килгән түрә карсак гәүдәле, төптән юан бер кеше иде. Читтән караганда ул өреп тутырылган шарны хәтерләтә. Ләкин йөз-кыяфәте күркәм, үзе җиңел дә, кәтүк шикелле тәгәрәп кенә йөри. Вакытында сәхнәләрне иңләгән үзешчән артист. Аны шул артистлыгы хакимият күгенә күтәрде дә инде. Районда баш агроном булып эшли иде. Шулай бервакыт партия өлкә комитетының беренче секретаре килде. Гадәттәгечә, кич елга буенда табын әзерләделәр. Авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы ялда иде. Шуңа күрә аш-су өчен аны җаваплы итеп куйдылар. «Сиңа зур имтихан бу»,— дип кисәтте аны райком секретаре.
Ашадылар-эчтеләр болар, озак кына су коендылар. Кырын-ярын ятып кәрт суктылар. Секретарь бу бертөрлелектән ялыкты булса кирәк, гармун таптыра башлады. Гармун юк иде. Алайса җырлагыз, диде түрә. Райком башлыгы белән райбашкарма җитәкчесе шундук парлап җырлап та җибәрделәр. Секретарь йөзен чытты, егетләрнең тавышы койрыгын кыскан кәҗә тавышына охшый иде.
Шунда кунак учак тирәсендә кайнашкан Хөрмәтне күреп алды да:
— Нинди шпион ул анда? — дип сорады.
— Ышанычлы егет,— дип тынычландырдылар кунакны.

— Алайса монда чакырыгыз! — дип әмер бирде секретарь һәм сырлы стаканга тутырып хәмер салырга кушты.
Хөрмәт ниндидер эчке бер әүлиялек белән үз язмышының менә хәзер хәл ителәчәген һәм аны шушы итләч борынлы, бит тамырлары бүртенгән олы түрә хәл итәчәген бавыры-эчәгеләре белән сиземләп торды. Ләкин моның өчен түрәнең игътибарын үзенә җәлеп итәргә кирәк иде. Шуңа күрә ул Шолохов герое мәшһүр Соколов үрнәгендә аракыдан соң авызына ризык капмады.
Кунакка бу ошады.
— Бу юлпыч корсакларга биеп тә күрсәт инде,— диде секретарь,— аларга тыгынырга гына булсын...
Керешә биергә Хөрмәт, үзе такмаклый, үзе бии, кыска юантык гәүдәсе бөтерчектәй бөтерелә. Тегеләр кул чаба. Әш-мәш килеп беттеләр.
Тагын ике атнадан ул райкомның икенче секретаре иде инде. Бер эштән дә чирканмады, төпкә җигелеп тартты. Тырышты, тырмашты, чәче белән җир генә себермәде фәкать. Дөрес, хакимиятнең югары баскычына күтәрелү, шәхси кушаматка ия булу өчен бу сыйфатлар гына аз. Хәтта бик аз. Иң мөһиме — ярарга кирәк. Һәм ул ярады. Инде үзенә ярарга тырышалар. Үтәгәнев шундыйларның берсе. Ул әле йомыркадан яңа гына тишелеп чыккан сары томшыклы кош баласы кебек кенә, тез буыннары мамыктан да йомшак. Әмма шушы камырдан тугрылыклы вассал әвәләргә бик мөмкин. Йорт сала икән, әйдә, сала бирсен, димәк, кеше төпләнергә уйлый.
Шулар турында уйланды Сафин, ә үзе Үтәгәневне бөтенләй башка яктан тәрттереп кашыды.
— Аңламыйм,— диде ул үз-үзе белән сөйләшкәндәй — житәкчелеккә колхоз күтәргән кешенең шул ук колхозга нинди үче булырга мөмкин?
Үтәгәнев шытырдатып урындыкка ябышты, әйтерсең лә, упкынга тәгәрәүдән шулай котылып була иде. Әйе, ул үзен бу минутта упкынга тәгәрәгәндәй хис итә иде. Чөнки белә, әлеге таш аның бакчасына төбәп ыргытылды. «Кызыл көч» вакыйгасының шунда, үз жирендә генә йомылып калуы өчен күпме энергия сарыф итте ул, бу хакта хәтта район газетасында да хәбәр бастыртмады. Бик теш кыжырап караганнар иде үзе. Өстәлгә бер генә сукты, шып булдылар. Казан чыпчыгы да хәбәрдар түгел иде. Димәк ки, районда аның өстеннән дә күзәтүче көчләр бар. Ә ул мин хужа дип йөргән була.
— «Кызыл көч» колхозы таралмады, Хөрмәт Шакирович,— диде ул,— ширкәт итеп кенә үзгәртелде.
— Беләм,— диде Сафин,— өлгерлек күрсәткәнсең, молодец. Мәскәүлеләр әнә республиканы «Коммунизм утравы», дип мыскыл иткән булалар. Ә без, элекке коммунистлар, демократларга караганда да радикалрак икән ич. Колхозлар да яши, ассоциацияләр дә үсеп чыга. Шәп бит, ә? Барыннан да бигрәк, халыкны контрольдә тотарга кирәк, аның муенында һәрчак муенчак булырга тиеш. Колхозмы, ассоциацияме, хикмәт анда түгел, хикмәт — муенчакта! Кеше минем белән синең кирәкне даими тоеп торсын: килсен, бил бөксен, ялынсын-ялварсын. Халык сөзгәк үгез кебек ул. Иреккә чыгардыңмы, дөньяны туздырып ташларга да күп сорамас. Тузган дөнья, Үтәгәнев, беркемгә дә, шул ук халыкның үзенә дә кирәкми. Халык каты кулларны үз итә. Бу ни-нәрсә дигән сүз? Бу — халык мәнфәгатьләрен кайгырту, дигән сүз. Сәясәтебезнең фәлсәфәсе менә шунда. Ә фәлсәфә, Үтәгәнев, бик катлаулы фән.
— Ну, баш үзегездә,— дип чын күңеленнән соклануын белдерде Үтәгәнев,— күзләр ачылып китте, валлаһи!
Сафин кәткелдәп көлеп алды. Ләкин сүзе бетмәгән иде әле. Сорады:
— Анда фермерларыгыз да бар дип ишеттем, дөресме?
Үтәгәневнең колаклары янә сагайды. Аның һич тә бу мәсьәләнә кабартасы килми иде.
— Бар дип, әле алар рәсмиләшеп житмәгәннәр...

— Берәрсен шәхси игътибарыңа ал,— диде Түрә,— үрнәк итеп әзерлә. Теләсә нинди делегация алдында йөзгә кызыллык килерлек булмасын. Монысы инде, Үтәгәнев, фәлсәфә түгел, сәясәт. Аңладыңмы, сә-я-сәт!

Уф алла, дип хафаланды Үтәгәнев, бу ике көнне ничек кенә исәнимин үткәреп җибәрергә?

— Яратам зәңгәр төсне,— диде Сафин утыргыч япмасын сыйпаштыргалап (бу түрәләр телендә мактау дип атала),— диңгезне хәтерләтә. Мин һәр елны диңгез буенда ял итәм. Кстати, Америкага фермерлар делегациясе җибәрергә торабыз, сине дә исемлеккә кертербездер, мөгаен. Итәк-чабуларыңны җыештырыбрак тор.

* * *

Курыккан-шикләнгән эш хәерле була, диләр, хак икән. Сафинның районга визиты Үтәгәнев көткәннән дә уңышлырак килеп чыкты. Юкка-барга бәйләнер, теңкәгә тияр, дип көткән иде, юк, үзен тыныч тотты, файдалы киңәшләрен бирде, үгет-нәсихәтсез дә калмады, билгеле. Ләкин алар күлмәк аша тешләгән черки кебек кенә иде. Ашау-эчү белән мавыкмады, кыз-кыркынга күз атмады. Бигрәк тә шул мәсьәләдә борчылган иде Үтәгәнев. Ник дисәң, ул кыз-кыркын дигәннәре тәмам бозылды. Элегрәк югары түрә белән кети-мети уйнау үзе зур дәрәҗә санала иде. Хәзер түләү көтәләр. Түләве дә нинди әле, фатир, машина, зиннәтле тун бир аларга. Югыйсә, ризалашмыйлар. Әлбәттә, үзләре атылып торганнары да бар. Ләкин андыйларын абзыйлар ошатмый. Шуңа күрә бик сак эш итәргә туры килә. Гайбәте дә чыкмасын, кунак та риза-бәхил калсын.

Самолет җирдән кубып күккә иңүгә, җилкәсеннән таулар ишелеп төшкәндәй булды Үтәгәневнең, сулышы җиңеләйде, җилкәләре киңәеп китте. Ул үзен янә районның хуҗасы итеп хис итә иде инде.

Беренче эш итеп ул Мөсифуллинны чакыртты. Тегесе ыспай гәүдәсен ишек уемыннан шудырып килеп тә керде, әйтерсең лә, бусагада гына дәшүләрен көтеп торган.

— Тыңлыйм, Гали Үтәгәневич,— дип куеп кесәсеннән блокнотын тартып чыгарды, язарга әзерләнде.

—«Кызыл көч»тән берәр фермер кредит сорап килмәдеме?— дип текәлде аңа Үтәгәнев.

Мөсифуллинның бу көтелмәгән сораудан күзләре әсәреп, җаны авызына килде. Җиткергәннәр, каһәр, дип уйлап алды ул, әле ярый сарыгын өенә илттергән идем. Аның әлҗе-мөлҗе килеп утыруын Үтәгәнев тә сизде.

— Карале, кичә ару тәшергәнсең, ахры, әнә, шифалы су эч, ярдәм итә,— диде ул дустанә кыяфәттә.

Башлыкның ягымлы мөнәсәбәте Мөсифуллинны тынычландырып җибәрде.

— Юк, юк, буламы соң, Гали Үтәгәневич,— дип мыгырданды үзе, хәлбуки, сарык мәрәкәсеннән нервасы кубып, эштән шактый гына кабып кайткан иде.

— Мине «Кызыл көч» кызыксындыра,— дип сүзне башлаган эзенә төшерде Үтәгәнев.

— Мин моны тикшерермен, Гали Үтәгәневич!

— Үз игътибарыңа ал, мөрәҗәгать итүче юк икән, оештыр. Анда тәҗрибә өчен бер үрнәк фермер хуҗалыгы булдырырга кирәк безгә.

— Чарасын күрербез, Гали Үтәгәневич!

Башлыкның сүзе бетмәгән иде әле. Ул башын калкыткан управляющийны кулын изәп урынына утыртты да:

— Мине Әмерикәгә җибәрәләр, бераз доллыр кирәк, Кабмин пагыйна калдырмассың бит инде,— диде.

— Була ул, ләкин ни... Гали Үтәгәневич, бюджетникларга эш хакын бераз кечектерергә туры килер. Ул арада без аны әйләнешкә кертеп, сумма эшләп алырбыз да, процентны долларга алыштырырбыз.

— Мөсифуллин, берүк укытучыларныкына кагылма әле, телләрс озын.

— Ачка үлмәсләр, төп сумма шуларда бит, Гали Үтәгәневич.

Килештеләр.

Үтәгәневнең чит илгә беренче чыгуы иде. Әле кайда диген, Әмерикәгә! Шуңа күрә бик дулкынланды. Җиде төн уртасында уянып китә дә, шул хакта хыялланып ята, хәтта көндез дә бу уй башыннан чыкмый. Баргач, бүләк-мазарын да юнәтергә кирәк булачак бит инде. Тылмачына да төртми булмас, кибетләрдә йөргәндә ярдәм итәр, коры кашык авыз ерта, ди.

— Улым, акчаңны еракка-рак яшер, ул әмерикән дигәннәрең бик үҗәт халык диләр,— дип әнисе дә киңәшләреннән калдырмады.

— Ерак урын кайда соң ул, әнкәй? — дип көлде Үтәгәнев.

— Тешләреңне ыржайтма бер дә,— дип турсайды әнисе.— Әтәң мәрхүм дә шулай авызын ерган иде дә әйткәчтен, бер чистартып кайтаргач, бик тиз акылына килде. Ходай да сакланганны гына саклармын дигән.

— Ничек сакларга соң, әнкәй?

— Бәлеш, ничек дип, трусигыңа кесә тектерәсең, әтәң рәхәтләнгән иде, башка бәла-каза күрмәде, урыны оҗмахта булсын.

Кичен хатыны Үтәгәневнең сатин трусигына ике катлап зур кесә салды.

## Алтынчы баб

Дөресен әйтергә кирәк, Әмерикә дигән мактаулы ил ошамады Үтәгәневка. Күккә ашкан биек ташпулатлар, биниһая киң юллардан ике яклап унар рәт тыз да быз чапкан машиналар, күз явын алырдай якты тәрәзәле кибетләр, рестораннар, кафелар менә-менә таптап-изеп китәрләр төсле тоелды. Шуңа күрә ул автобуска утыруга күзләрен чытырдатып йома да, әллә кайда еракта, бик еракта калган инеш буйларын, андагы болын-әрәмәлекләрне күз алдына китерә. Йөрәге сагыштан чеметеп-чеметеп ала.

Кешеләрнең дә рәтен тапмады. Сөйләшүләре сөйләшү түгел. Авызларына чүбек тутырганнар диярсең, телләрен әйләндерә алмыйлар, эт кебек һау да һау өрәләр.

— Кайчан авылларына алып барырлар икән? — дип сорады ул бүлмәдәшеннән.

Бүлмәдәше какча гәүдәле, күзге чебен шикелле тиктормас телчән бер бәндә иде. Исеме Муллый. Инглизчә дә бераз сукалый бугай. Һәрхәлдә, кулыннан сүзлегән төшерми, һаман нидер ятлый, мыгырдана. Андый ярдәмлек Үтәгәневтә дә бар, Казанда ук биргәннәр иде. Ләкин ул аның берниндн дә файдасын тапмады.

— Тизрәк тәҗрибә алыргамы исәбең? — дип көлде Муллый.

— Бәй, шуның өчен җибәрделәр бит.

— Тәҗрибә качмас, яшьти, әйдә, барга төшик, Җир шарының икенче ягыннан килеп, Әмерикән ледиләренең ботларын да тотып карамасак, аяз көнне яшен сугар үзебезне.

— Сөйләмә юкны, берәрсе күреп калса, ни җавап бирербез? Юк, мин, юк...

Муллый юка иреннәрен бөрештереп алды да сүзсез генә киенә башлады. Үтәгәневнең дә Әмерикә ледиләренең ботларын тотып карыйсы килә, әлбәттә. Ләкин шикләнә. Тел белмәгәч, ничек итеп сүз кушасың ди, тудым-судым гына ботка үрелеп булмый ич инде. Ярый, үрелдең дә ди, риза да булды ди. Умырып акча сораса, нишләрсең? Әле бик күп

әйбер аласы бар. Хатыны ыштыр буе исемлек тоттырып җибәрде әнә. Шулаен ул шулай, билгеле. Ләкин дә, Муллый әйтмешли, мәтәштереп караганда да зыян итмәс иде, истәлеккә калыр иде. Әллә тәвәккәлләргәме соң? Беткән баш беткән...

— Ничек сөйләшергә соң алар белән? — дип риза икәнен белдерде Үтәгәнев.

— Мине бер дә юкка гына шушы талмутны куен кесәсендә йөртә дип уйлыйсыңмы әллә? — диде Муллый.— Юк, яшьти, хатын-кыз белән генә танышырлык рәт бар бездә. Аларга бит ике сүз җитә. Беренчесе — матур, икенчесе — яратам. Сынаганым бар, валлаһи, шушы ике сүз теләсә нинди хатынны ега да сала. Инглизчә ул болайрак яңгырый: файн, лав. Җә, кабатлап кара әле.

— Юк, минем андыйга тел әйләнми, мин сиңа ияреп кенә...

— Ярый, ярый, мин икебез өчен дә сөйләшермен, аның әлегә теше сызлый, диярмен, кхе-кхе-кхе... башкасына бик маһир, диярмен...

Барда халык күп түгел иде. Ишек-тәрәзәләргә калын чаршаулар корылган. Берничә урында тычкан күзе кадәрле генә ут яна. Ярымкараңгы. Буфет ягы гына яктырак. Акрын гына музыка уйнап тора.

Муллый барменга сүз дә әйтеп тормады, ике бармагын гына тырпайтты. Шунда ук алар алдында ике озын стакан пәйда булды. Бармен аларга матур этикеткалы кара шешәдән хәмер агызды, эчләренә салам сабагы шикелле полиэтилен көпшә тыкты. Аннан соң ихтирамлы кыяфәткә кереп:

— Плиз,— диде.

— О'кей,— дип Муллый аның өстәленә вәкарь белән генә тимер акча шудырды. Негрның авызы җигүле ат керерлек булып җәелде.

Шомарган, каһәр, дип көнләшеп куйды бүлмәдәшеннән Үтәгәнев.

Алар почмактагы буш өстәл янына килеп кунакладылар.

— Закуска алмадык ич әле,— дип сүз кыстырды Үтәгәнев, янәсе, ул да төшеп калганнардан түгел.

Муллый аңа карап башын чайкап торды да әйтте:

— Запад бу, Гали әфәнде, цивилизацияле җәмгыять. Монда бер чирек көмешкәне бер чиләк бәрәңге тыгынып чөмермиләр, саламнан гына суыралар.

Цивилизацияле җәмгыятьнең хәмереннән нишләптер Муллый мыскыллап көлгән көмешкә тәме килә иде. Марилар тавык тизәге салып гайрәтләндерә торган көмешкә исе. Үтәгәнев чак кына косып җибәрмәде.

— Агу ич бу, закуска белән дә эчәрлек түгел.

Муллый аның сүзләренә игътибар итмәде, чөнки алар өстәленә таба ымсындыргыч гәүдә-сыннарын боргалап, фәрештә үбеп үстергән ике чибәркәй якынлаша иде. Кигән күлмәкләре бияләйдән зур түгелдер. Шул бармаксыз бияләй кисәген тәннәренә сылаганнар да, зур аеллы каеш белән беркетеп куйганнар. Аякларында уемыннан песи баласы чыгарлык биек үкчәле туфлиләр. Бөтен байлыклары күз алдында.

— Хелло!

— Хелло!

Кызларның рөхсәт соравы да, сәламләүләре дә шушы булды, ахрысы. Буш урындыкларның артына сумкаларын элделәр. Муллый барменга янә ике бармагын тырпайтты. Болар да шушы сасы суны эчәр микәнни, дип уйлады Үтәгәнев. Ә кызлардан, тәнне кытыклап, вәсвәсәле хушбуй ике килә. Ул Муллый өйрәткән сүзләрне хәтеренә төшерергә тырышып карады. Юк, сүзе түгел, авазларын да хәтерли алмады. Хәер, Муллый үзе дә әллә ни майтара алмады бугай. Кызларның берсе аны тыңлап торды торды да, озын керфекләрен сирпеп, саф рус телендә:

— Сез Россиядәнме әллә? — дип сорады.

— Йа-йа, русиш, рашн,— дип такылдавын дәвам итте Муллый.

Кызлар, тәмәке төтененә буылып, ютәлли-ютәлли көлештеләр дә көлештеләр.

— Чуть не влипли,— диде көлеп туйгач, саргылт чәчлесе,— мы думали, янки...

— Янкилардан мең өлеш артык без,— дип, Муллый үзенең какшаган абруен төзәтергә азапланды.

— Вы нищие,— диде аңа әлеге кыз.

— Безнең йөрәкләр кайнар!

— Мы сюда не за любовью приехали, а заработать!

Муллый да үҗәт егет икән. Бер селтәнүдә кесәсеннән яшел купюр суырып чыгарды да, өстәлгә бәрде, янәсе, без дә арыш бете түгел.

Әбелмәлихнең йөрәге өзелеп төшәр хәлгә килде, нишли инде бу җүләр, мондыйлар үзебездә түләүсез-нисез ләбаса, дип офтанды ул.

Саргылт чәчле кыз акчага бер генә күз сирпеп алды да, Муллыйның үзенә шудырды.

— Мимо!

Кызлар стаканнарга кагылмадылар, тордылар да үз юлларына китеп бардылар.

Бу көнне Русия кунакларына Әмерикә ледиләренең ботларын капшау насыйп булмады. Бу көнне генә түгел, гомумән, әлеге хыяллары хыялдагы чәчкә килеш сүнде. Чөнки бу сәяхәтне оештыруны үз кулына алган фермерлар ассоциациясе делегациягә тын алырга да ирек бирмәде. Икенче көнне таң белән аэропортта иделәр инде. Үтәгәнев очкыч тәрәзәсеннән күзен алмады. Аның Әмерикә авылларын күрәсе, бу бай мәмләкәтнең авыл халкына мөнәсәбәтен бик тә беләсе килә иде. Ул мондагы авылларны зур итеп, төзек итеп күз алдына китерә иде. Аныңча, бай илнең авыллары да зур булырга тиеш. Тик ничек кенә чекерәймәсен, икешәр-өчәр чакрымга сузылган авыллар күзенә чалынмады. Ахыры түзмәде, Муллыйның кабыргасына төртте.

— Карале, боларның авыллары кая соң?

Муллый кичә ачудан ледиләргә тиеш стаканнарны да бушаткан иде. Шуңа күрә башы бераз иләс-миләсрәк, йокымсырабрак бара. Алай да күршесенең соравын игътибарсыз калдырмады.

— Салам түбәле җимерек өйләрен күрсәттеләр ди, көт, сизмисеңмени, ничек уратып йөртәләр,— диде.

— Кит аннан, булмаганны, Әмерикәгә салам түбә каян килсен?

— Миңа ышанмасаң, тылмачтан сора.

Муллый күзләрен йомды, Үтәгәнев янә тәгәзәгә капланды, их, күз кырые белән генә булса да әлеге ташландык авылларны күрәсе иде, дип уйлады. Әмерикә булып Әмерикәдә дигең... ә? Юк, бу йолкыш шаярта гынадыр әле, тукта, булмаса, чыннан да, тылмачтан белешим әле.

Ул ян яктагы кәнәфидә утырып баручы тылмачның җилкәсенә орынып алды.

— Карале, ни, ыслушай...

Үтәгәнев Муллыйга карап тотлыгып калды, ул аны авызыңда җыен чүп сүз дип һаман әрли, һаман кисәтә. Алары да, каһәр, ачыган катык кебек үзләреннән-үзләре бүселеп чыгарга гына торалар, сизми дә каласың.

— Мин сезне тыңлыйм,— диде тылмач, укыган гәҗитен тезенә җәеп.— Сорагыз!

— Ни... сездә әллә... теге... авыллар күренми, мәйтәм.

— Һо, мин сезне аңлыйм,— диде тылмач,— Русиядә авыллар күп, зур авыллар, мин күрдем. Әмерикә бу чорны үткәрде инде. Үзәк Әмерикәдә фермерлар гына.

— Калхузлар... ягъни дә... керәстиәннәр кайда яши соң?

— Бездә керәстиәннәр юк, алар булмагач, авыл да юк. Әмерикәдә фермерлар халыкның алты процентын тәшкил итә. Алар бөтен Әмерикәне туйдыра, дөньяны туйдыра.

Үтәгәнев тылмачның сүзләренә ышанмады, борчак сибә дип уйлады. Без дә һәр сыердан 3000-4000 кг сөт савабыз, дип оран салабыз, дип

уйлады, чынлыкта ул ике сыерга туры килә. Капиталистлар да әлләни алдыра алмаганнар, әй, шул ук күз буяу. Алты процент, имеш. Әле монда авыл тулы кеше булып та таманга гына туры килә.

— Үтәгән, Үтәгән, дим, кичә мин өйрәткән тылсымлы сүзләрне онытмадыңмы, җә, әйтеп кара әле,— дип уйларыннан бүлде аны Муллый.

— Нинди сүзләр ул?

— Ай лав ю!

Салонда авызына чүбек тутырган стюардессаның «һай-һау»лы тавышы яңгырады.

— Каешларыңны эләктер, төшә башлыйбыз,— диде Муллый, стюардессадан күзләрен алмыйча,— ну, ботлар, малай, ә?

Аэропортта аларга озак юанырга ирек бирмәделәр, автобуска утыртып, шәһәр читенә алып чыгып киттеләр. Күкәй тәгәрәтерлек тигез юл. Юл читеннән җиде-сигез рәт тимерчыбык тартылган. Унда да, сулда да кукуруз басуы. Кукуруз инде буынга сикергән. Басу өсте такта кебек тип-тигез, әйтерсең лә, җеп сузып кыркып чыкканнар. Кукуруз кыры кайсы ягы беләндер өйрәнчек рәссам ясаган картинаны хәтерләтә. Табигый түгел. Барысы да чамадан тыш тигез, кирәгеннән артык төз, косасыны китерерлек чиста. Күзне арыта, караш бер җиргә төртелми. Юл читендә бәбкә үлән, тукранбаш, ромашка ише үсемлекләре дә булырга тиештер ләбаса инде.

Автобус, тормозларын сызгыртып, бер тимер капка янына килеп туктады. Капканың аргы ягында ак кирпечтән салынган гади генә ике катлы йорт утыра. Кибән хәтле башын ал аякларына салып йокымсыраган бозау кадәре этне исәпкә алмаганда, артык-портык нәрсә күзгә чалынмый. Үтәгәневнең иң сөймәгәне—эт. Ул бу яктан Мөхәммәт пәйгамбәргә охшаган. Кечкенә вакытта бер имансызы тешләгән иде, дошманлык шуннан килә.

— Авыл, авыл дип тылмачның теңкәсенә тигән идең, хәзер менә рәхәтлән инде,— диде Муллый.

— Анда эт,— диде Үтәгәнев,— мин автобуста гына утырам.

Муллый аның чабуыннан тартып туктатты.

Фермер алар арасындагы чыш-пышны ишетеп алган иде инде. Килеп җитте дә, әрчелгән бәрәңге шикелле ап-ак күзләрен киереп:

— Мистерларны ни борчый?—дип сорады.

— Эт, ни... дог,— диде Муллый,— менә бу мистер курка.

— Һо-о, курка, юкка, бу эт карт инде, йоклый да йоклый.

Алай да фермер улына этне оясына ябарга кушты.

Колгасардай озын гәүдәле бу фермер Джон исемле иде. Итлеккә тавык үрчетә икән. Хатыны белән улы ярдәм итә, ди. Бөтен эш автоматлаштырылган. Ферманың ике бинасы бар икән. Зуррагында—тавыклар, кечесендә идарә итү җайланмалары. Чисталык аптекадагыча.

— Безнең эштә иң мөһиме—чисталык,— дип аңлатты Джон үзе дә.—Юл киемнәрегезне салып, менә шушы халатларны, башлыкларны киюегезне үтенәм. Туфлиләрегезне дә алыштырырга туры килер. Инфекция бик яман нәрсә.

Тавыклар тимерчыбыктан үрелгән читлекләрдә ат менгән җайдаклар кебек кукраеп утыралар. Авызлары турында гына конвейер тасмасы уза. Анда азык, су. Үрелеп кенә ашыйлар, үрелеп кенә эчәләр, кузгалмый гына әәй итәләр. Алары да конвейер тасмасына коела. Секунд эчендә юк булалар.

— Бу тавыкларның аяклары юк,— дип эре сирәк тешләрен ыржайтып елмайды Джон. Ләкин аның үзе канәгать калган бу мәзәгеннән берәү дә көлмәде.

— Фашист, ничек интектерә бәгырькәйләрне,— дип күзләреннән ут чәчте Муллый,— шуңа күрә итләреннән агач тәме килә. Чирәмдә чүпләнгән тавыкка җитәме соң?

Ә үзе, парламент кагыйдәләренә туры китереп, хуҗага сораулар яудыра башлады:

— Мистер фермер, әйтегез әле, зинһар, инкубаторыгызның куәте ничек?

— Безнең инкубаторыбыз юк, мистер кунак, без симертү белән генә шөгыльләнәбез.

— Рәхмәт, мистер фермер, мин канәгать. Мөмкин булса, тагын бер мәсьәләгә ачыклык кертеп китик әле, безнең өчен бу бик мөһим. Менә сезнең хуҗалыкны бик җентекләп күзәттем, ләкин азык-төлек склады күземә чалынмады. Моны ничек аңларга?

— Ә-ә,— диде Джон,— без көнлек азык белән генә чикләнәбез. Кулдаш аны һәр көнне иртән сәгать алтыга китереп җиткерә.

— Ә китермәсә, алдаса?

Үтәгәнев авызыннан әлеге сорау очып чыкканын сизми дә калды. Чөнки аның үзенең теңкәсенә тигән нәрсә бу. Ярты гомере әйбер юллап уза. Башта үтенеч кәгазе җибәрәсең, аннан телефоннан ялынып-ялварып сөйләшәсең. Була, диләр, фәлән-фәлән көнгә җибәрәбез, диләр. Бер атна көтәсең, ике, өч. Янә телефонга ябышасың. Сине тагын ышандыралар. Белеп торасың, монысында да сүзләрендә тормаячаклар. Менә шулай тарткалаш та өзгәләш. Ә бу элмәк борын сәгать белән генә сөйләшә...

Джон керфексез күзләрен чет-чет йомгалап, какча җилкәсен җыерып куйды да:

— Ничек инде ул китермәскә мөмкин? Безнең контракт бар ич.

— Яңгыр яуса, әйтик, буран чыкса?—дип Муллый дустына ярдәмгә килде.

— Мин аңламыйм,— диде фермер,— яңгырның монда ни катнашы бар? Без, мәсәлән, ашханәгә һәр көн иртәнге биштә яңа суйган түшкәләр илтәбез.

— Бәйрәм көннәрендәме?

— Бәйрәм көннәрендә дә.

Үтәгәнев, әкият ич бу дип, кулын гына селкеп куйды. Джон аны ышандыра алмады. Бу минутта аны икенче бер бик тә мөһим нәрсә кызыксындыра иде. Экскурсия тәгәлләнеп килгәнгә охшый, дип уйлады ул, гадәттә, мондый чаралардан соң мәҗлесе дә булырга тиеш, боларда да шулайдыр инде ул. Бер-бер яңалык отып кайтып, Казан түрәләренең ушын алганда бик шәп булыр иде, ә?

Кузгалырга дигән әмер яңгырады. Кешеләр этешә-төртешә автобуска тулдылар. Барысының да нәфесе ризык тели иде.

Джон, мич кадәр авызын ерып, кул болгап калды.

Тәрәзәгә күз салмаганда машина бер урында тора сыман. Шома туры юлда тизлекне тоймыйсың да икән. Кәнәфиләр йомшак, тирән, гәүдәң белән чумасың. Рәхәтләнеп черем ит. Ләкин Үтәгәневнең черем итәсе килми. Аның беләсе килә, әйтик, делегация составында 15 кеше. Казанда аларга, сез фермерлар, диделәр, тәҗрибә алырга барасыз, диделәр. Кемнәр алар, кайдан — ләм-мим. Хакимият кешеләренә төпчеңү, гомумән, хилаф гамәл санала. Дөрес, танышбелеш, дус-иш, түрә хатыннары аша сер иртәме-соңмы барыбер тишелеп чыга. Үтәгәневнең исә әлегә Ак йортта таяныр кешесе дә, андый ышанычлы чыганаклары да юк. Әмма аңа карап кызыксынуны йозаклап буламыни? Һәм ул, Тукайның мәшһүр Батыры шикелле, бүрәнә очындагы чәйне кузгату ниятенә керде.

— Карале... әй, гафу, теге...

— Ишан хәзрәтнең төпчек кызы түгелдерсең бит, боргаланмый гына сөйлә,— дип бүлдерде аны Муллый.

— Акчаны көрәп аласыңдыр син, малай, ә?

— Син нәрсә, иске авыздан яңа сүз,— диде Муллый.

— Фермерның маңгаен ару тирләттең, мәйтәм, бу бер галим-голәмәдер инде дип уйлаган идем.

— Рәхмәт инде, би-и-к зурладың.
— Чынлап, син авыл хуҗалыгы институтында эшлисеңме, профиссырмы?
— Мерси, Үтәгән, ләкин син ялгышасың. Мин гап-гади Кияү. Аңладыңмы? Кияү булып эшлим. Кияүләр, Үтәгән, теләсә кайсы делегация сафына керәләр. Алар мөгезсез сыердан да хәтәррәк.
— Авыл хуҗалыгына бөтенләй катнашың юкмыни?
— Монда синнән башка берәүнең дә ашлык үстереп тә, мал асрап та караганы юк. Әнә, теге җирән чәчле әгъзабыз Кода, пләш башлысы Баҗа. Озын буйлы апабыз доктор, түрәләрне дәвалый, журналист та бар, абзыйларны мактап мәкалә яза...
— Ничек инде...
— Чыраеңны киермә, Үтәгән, син үзең дә фермер түгел. Без барыбыз да җилләнеп кайту өчен килгән кешеләр. Билгеле, дәүләт исәбенә. Ә дәүләт безнең бай, аннан гына чите кителмәс.
«Ни-нәмә дип баш ватып торам соң әле мин?» — дип үз-үзен битәрләп алды Үтәгәнев,— булмаган фермерларны кайдан алсыннар, ди. Разнарядка килеп төшкән икән, үтәми хәлең юк, чөнки дә үтәмәсәң, башка вакытта сүз дә кушмаячаклар.
Ул уй дулкынын мәҗлескә күчерде. Автобусның ниндидер аулак урынга, табигать кочагына килеп туктавын көтте. Теге фермер белән чәкештереп эчәчәк, серен алачак әле ул!
Автобус исә, үч иткәндәй, иртән тукталган шәһәрчеккә килеп керде.
— Бераз тамак ялгап алабыз,— диде тылмач.
— Ә мәҗлес? — диде Үтәгәнев,— ягъни дә пикник?
— Безнең программада бернинди пикник та каралмаган,— диде тылмач,— әле тагын бер фермер хуҗалыгына барасыбыз бар.
Авыз-борыннар салынды. Саран тәреләр, дип сүгенеп алды Үтәгәнев, үзебезгә җитәме соң? Үрдәк кебек икән болар, симергән саен артлары йомыла бара икән.
Русия «фермерлар»ына бер чәкән пешкән кукуруз, бер стакан сөт белән канәгатьләнергә туры килде. Кече телләренә дә йокмады. Тик шуңа да карамастан, берсе дә үз акчасына ризык сатып алмады. Күңелләреннән генә Әмерикә капитализмын орыша-орыша автобуста үз урыннарына чумдылар. Кемдер кибет турында сүз чыгарды. Шул сүзләр колагына керүгә, Үтәгәневнең уң кулы чалбарының кашагасына шуышты. Гадәттә, ул бот арасындагы бүртемгә кагыла да, хуҗасын тынычландырып, урынына кайта. Ә бу юлы кул шөбһәләнде, бер капшады, ике, алгы өлешне буеннан-буена сыпыргалап чыкты. Ләкин бүртемне таба алмады.
— Карале, баш бетте, талаганнар! — дип Муллыйны җилтерәтергә тотынды Үтәгәнев.
— Кемне? Кайчан? — дип аңышмый торды тегесе.
— Әллә бәдрәфтә төшеп калды микән? — диде еларга җитешкән Үтәгәнев,— теге сасы кукурузларыннан соң кереп чыккан идем, сөт тә ярамый миңа, эч китә...
— Нәрсә төшеп калган, аңлатыбрак сөйлә!
— Доллырлар,— дип пышылдады Үтәгәнев,— хатын трусикка кесә теккән иде...
Муллый бу гадәттән тыш хәлне тылмачка җиткерде. Биш-алты минут үтеме-юкмы, машина борылып, юл буендагы әлеге кафе янына килеп тә туктады.
Туалетның астын-өскә китерделәр. Ләкин ул көткән нәтиҗәне бирмәде.
— Чалбарыңны сал әле,— диде, ниһаять, Муллый, яхшылап тикшерик әле. Салды, карадылар. Һәм шул ук секундта Муллый Үтәгәневнең шалкан шикелле ап-ак арт шәрефенә лып итеп ботинкасының мөһерен чәпәде.

— Мин... ни... белмәдем, кысылган бит...— дип мыгырданды Үтәгәнев.

Ашыгуданмы, артык саклануданмы, Үтәгәнев трусигының алдын артына киеп куйган икән. Баксаң, кулы бөтенләй башка әйберне капшап барган, тегесе ялгыш сигнал биреп торган.

Әмерикәнең намусына тап төшмәде.

## Җиденче баб

Авылда гайбәт тиз йөри. Югыйсә, телефон да юк, факс-макс та, электрон җайланмалар да. Әмма авызыңнан чыккан сүз ниндидер кодрәти көч белән минуты-секундында таралып өлгерә. Тарала да бөтенләй башка төсмерләр белән баетылып, кайчакта капма-каршы мәгънә алып, өйдән-өйгә иңә.

Әбелмәлихләрнең капка төбенә районнан бик кәттә машина килеп туктавы, аннан шоферның кемнедер күтәреп өйгә алып кереп китүе турында ишеткән-күргәннәр аһ итте. Хәбәр яшен тизлеге белән авылны урады. Имеш-мимешләр төрледән-төрле:

— Әбелмәлих районда ләх булган икән, милиция китереп ташлаган икән. Ябасы да булганнар да, Казан түрәсе рөхсәт бирмәгән, ди.

— Әбелмәлихнең акчасын талаганнар ди, авызы-борыны кан ди. Китереп куючыга бәрән биргән ди, сүз чыгармасын диеп.

— Әбелмәлихне шешәдәшләре бик нык кыйнап, капчыкка салып чокырга ташлаганнар, ди. Эт кенә тапкан, ди.

— Әбелмәлих мафияга кергән икән, таланган әйберләрен бүлешә алмаганнар, ди.

Кыскасы, тетмәсен теттеләр Әбелмәлихнең, юмаган сөяген калдырмадылар. Тыкрык башында җигүле ат пәйда булмаса, ихтимал, гайбәт әле әче катык шикелле кабарган гына булыр иде. Амбар янына җыелган кешеләрнең колаклары үрә торды. Чөнки чанада Әбелмәлих иде. Үзе! Бүрегенең колакчыннарын бәйләмичә куян колаклары шикелле шәлперәйтеп йөрүче авылда шул гына. Җиргә төшкәнче төкерек туңарлык кырлач салкыннарында да изүе ачык булыр, шарф дигән нәрсәне гомеренә берәр мәртәбә муенына салып карадымы икән? Янындагысын да таныдылар. Анысы — Муса!

Күзләрдә янә аптыраш. Дошманнар лабаса! Әбелмәлих аны дөньяда яшәтмим дип күпме янап йөрде.

Төркем янына килеп җитүгә, Әбелмәлих дилбегәсен үзенә таба тартты. Муса да кәефле күренә, авызы ерык. Чанадан сикереп төште дә: «Азатлык!» — дип кычкырып җибәрде.

— Азат-лык!

Кешеләрнең муеннары җимгә үрелгән кош балаларыныкы шикелле алга сузылды да шул халәттә катып калды.

— Таныш булыгыз,— дип көлде Әбелмәлих,— азатлык хәрәкәтенең башлыгы Муса әфәнде Нибуч, митинглар остасы. Телен оныткан, «Азатлык»тан башка бер сүз белми.

Муеннар җыерылып, кире үз урыннарына чумды. Күзләрдә барыбер гаҗәпләнү кимемәде.

— Нәрсә, әллә дөрестән дә митингыга җыелдыгызмы? — диде Әбелмәлих.

— Әбелмәлих, сезнең капка төбендә бер машина тора ие,— диде арадан берәү,— әллә ниткән сүзләр дә йөри...

— Ә-ә, аны әйтәсезмени,— диде Әбелмәлих эре генә,— кышка тәкәне китергәннәрдер, банк башлыгының машинасын сөйләшкән идем, печтердем бит тегене район бүлнисендә, сарыкларга тынгылык бирми башлады, имансыз...

Берьюлы шушы кадәр табышмакны йота ала димени авыл, сорау артыннан сорау китте: ничек, нәрсә, кайчан? Ләкин Әбелмәлих ул сорауларга анықлык кертергә өлгермәде, ат менгән җиназачы малай:

— Хөббетдин бабай вафат,— дип аваз салып узды.

— Бәтәч, әле кичә кич кенә аштан кайтып килә ие,— диде кемдер.

— Килсә сүң, кичә түгел, бүген үлгән ич ул.

Хөббетдин карт авылның иң өлкән кешесе иде. Сугыштан бер кулын өздереп кайтканнан бирле амбардагы күсе ише озын койрыклы хәшәрәтләргә каршы көрәште. Алыштыргысыз гадел каравылчы иде. Шул эштә чәчләренә чал керде, аннан бөтенләй коелып, башы кабакка охшап калды. Әмма никадәр генә тырышса да тегеләрне барыбер бетерә алмады мескен. Агу да сибеп карады, капкын да куйды. Кырылдылар, әлбәттә, әмма алар урынына яшьләре өстәлә торды.

Хәшәрәтләрне бетерә алмаса да, Хөббетдин карт тирә-якта бик абруйлы кеше иде. Мулла вазифаларын башкара иде ул. Аның догалары, вәгазьләре кысасына кергәндерме-юкмы, анысын Алла белсен, авылда аңа бәһа бирерлек гыйлемле кеше юк иде. Йомшак күңелле, ягымлы вә шәфкатьле кеше иде — монысы һәркемгә билгеле. Шуңа күрә аны күрше авылларга да алып китәләр иде. Үлем-китем, аш-су аннан башка үтми иде.

Бу хәбәрне ишеткәч, авыл пошаманга калды. Чөнки якын-тирәдә Хөббетдин мулланы соңгы юлга озатырлык лаеклы дин әһеле юк иде. Алтмышны тутырган абзый-апалар хәтсез анысы. Ләкин алар совет буыны кешеләре. Динне сүгеп, муллалардан көлеп, руханиларны мәсхәрә итеп үскән буын. Телсез, динсез, бәгыре каткан исерек буын.

Ябалак дигән мишәр авылында мулла бар икән барын, тик аны ничек алып килергә? Авыл Советының машинасы юк, «Кызыл көч»нең башлыгы каядыр китеп барган. Колхозны бүлгәләгәннән соң техника урланып-ботарланып беткән иде. Чылбырлы трактор бар анысы. Ләкин ул чылбырлы трактор белән алтмыш чакрым араны урап кайту өчен ике көн вакыт кирәк. Ә мәетне бу кадәр вакыт яткырып буламыни? Авыл мулласын, шулай итеп, догасыз-нисез, «әббәр» итеп кенә ләхеткә төшерергә мәҗбүр булдылар. Ә мәетне Камәр юды. Гадәттәгечә, бер кырлы стакан хәмерне каплап куйды да, тамагын кырып, шөгыленә тотынды.

Бу изге гамәлне Хөббетдин мулла белән бергәләп башкаралар иде алар. Ир-атны Хөббетдин пакьләндерсә, хатын-кыз җәмәгатен Камәр сафландыра. Инде менә ир-ат та Камәр кулына калды. Мулла бабайны юганда да ирләр шөлләде, ник берәрсе булышсын.

Камәрне авылда олысы-кечесе исеме белән генә атап йөртә. Яше берәүне дә кызыксындырмый, хәлбуки, инде сигезенче дистәне ваклаган әби. Үзе көне бүе биләмдә. Озын калын гәүдәсе әле анда, әле монда пәйда була, авылны көненә өч-дүрт тапкыр урый мәгәр.

Камәр үсмер вакытыннан атлы эштә эшләгән. Сугыш вакытында заготзерногa пар ат белән ашлык ташыган. Капчыкларны туп урынына гына уйната иде, дип сөйлиләр. Җыры исә биш чакрымнан ишетелеп торган.

Камәрнең иң яраткан кешесе — Горбачев. Районнан берәр вәкилмазар килеп төштеме, иң беренче соравы шул хакта:

— Апай, анда әле Горбачевны урынына кайтармаганнармы?

Ул Михаил Горбачевның хәмергә каршы көрәше вакытында хәлләнеп калган кеше. Шәһәрдә яшәүче уйнаштан туган кызына йорт житкергән, автомобиль алып биргән. Теге чакта Уфадагы бер туганы аша аракы юнәтеп, шуны биш-алты бәясенә сатып яткан. Өстәвенә, йомышчылардан бөтен эшен эшләтеп калдыра икән. Шатлык-куанычларыннан сәрхүшләр карын көрәгәннәр, тиресен түккәннәр, койма-читәнен рәтләгәннәр.

Демократлар Камәр тегермәненең мөшкәсен яптыралар. Аларны ул күрә алмый, иң төшемле әйберне шалкан бәясенә калдырдылар, ди. Шулай. Хәзер аракыны чат саен саталар, иртәсен дә, кичен дә. Их, заман!

Элек ничек уңай булган икән. Иртән иртүк килеп керерләр иде бәгырькәйләр, йөз генә грамм дип идәндә аунап йөрерләр иде. Бер шешәгә бер сарык алган вакытлары да булды.

Хөббетдин картны җирләгән көнне Камәр Әбелмәлихләр бусагасын атлап керде. Телевизор карап утыралар иде.

— Апай, анда нәмә сүләйләр, Горбачны урынына куймаганнармы? — диде керә-керешкә.

— Безгә нәрсәгә Горбач, үзебезнең патша бар ич,— дип көлде Әбелмәлих,— Татарстан хәзер мөстәкыйль дәүләт.

— Юк, апай, алай димә әле син, Горбач Горбач инде ул. Янә дә куйсалар, ирек алыр идек бер.

— Синең болай да арбаң шәп тәгәри, Камәр. Хәер акчасы да, әнәтрәк, үзеңә генә калырга тора.

Камәрнең тулы иреннәре җәелеп, кыстыбый рәвешенә керде, эчкә баткан керфексез күзләрендә ат тоягы эзләре шәйләнде. Аның күңелендә йомшаклык белән усаллык, шәфкатьлелек белән мәрхәмәтсезлек шулай үзара тату яши иде. Карашы усалланса, авызы җырыла, иреннәре җыелса, күзләренә ат тоягы иңә.

— Бәй, апай, эше дә бик күп бит. Калада минем күекләр умырып ала иде.

Әбелмәлих хатыны күрмәгәндә генә аңа күз кысты, янәсе, әпетит яклары ничегрәк, рәт бар. Камәр борынын җыерды, ул бер эчкәндә бер стаканны аудара да, шуның белән вәссәлам, башка тотмый, хет кыста, хет кыстама.

— Үзең башлагачтын, апай, әйтәем әле, сезгә керүем дә шул чуттан ие,— дип сүзне ялган җибәрде Камәр.

— Әйдә, сөйлә, тыңлыйм.

— Тыңлаем диеп, апай, авылны мулласыз калдырып булмай бит инде. Хәзер, үзең әйтмешләй, ирек. Әллә, мәйтәм, үземә тәвәккәлләргәме икән? Син, апай, афтаритлы кеше, калхузның да әнә бер-ике көндә астын өскә китереп ташладыгыз. Районда да таныш-белешләрең бар бугай, капка төбегездә тәти машина тора ие. Авылны мулласыз калдырсак, гонаһын җыеп бетереп булмас, апай.

— Хатын-кыз затындагы мулла ничегрәк була икән соң ул, Камәр,— дип Әбелмәлих аптырабрак торды,— бер дә ишеткән-белгән нәрсәм түгел.

— Кыз-хатын диеп, апай, без барыбыз да алла бәндәсе, тәгаенләсәләр, ник булмаска?

Мәсьәләне җыенга куйдылар. Камәр белән килешенгәнчә, Әбелмәлих та сүз сорады.

— Сандугач юк елны карга шәп кычкыра,— дип башлады ул нотыгын. Кешеләр бер-беренә карашып елмаештылар, янәсе, көтегез, хәзер тамаша булачак.— Быел карга елы,— дип дәвам итте Әбелмәлих,— күрәсезме дөньяны карга басты...

Халыкның өмете акланды, сүзеннән туктатып, аңа кул чаптылар. Арадан берәү:

— Сакалыгыз бик сары, әллә сез Сафиулла җизниме? — дип җорланып та алды.

— Соң, мәйтәм, бу вазифаны вакытлыча әллә Камәргә тапшырып торабызмы? Сандугачлар килгәнче дим...

Җыен бермәлгә тып-тын калды. Моннан йөз метрлар чамасы арырак урнашкан Хакимият бинасы янындагы тупыл ябалдашларын сырып алган каргаларның карылдавы аерымачык ишетелеп торды. Аннан соң шаркылдап көләргә тотындылар. Көлделәр дә көлделәр, көлделәр дә көлделәр. Мәйдан уртасына Муса атылып чыккач кына тынычлык урнашты.

— Нибуч, Әбелмәлих, динне мыскыл итәргә ирек бирмәбез! — дип кычкырды ул митингларда чарланган тавышы белән,— әгәр хатын-кызга

шул дәрәҗәне бирсәк, аяз көнне яшен сугар. Мөфтияткә мөрәҗәгать итик, мулла җибәрсеннәр!

— Мөрәҗәгать итеп карадык, мулланы үзебезнең авыл яшьләреннән хәзерләргә кушалар, ә укырга теләүче юк,— дип мәсьәләгә ачыклык кертте хакимият башлыгы.— Мулласыз да булмый, уйлашыйк!

— Акча түлисезме соң?—дип сорады кемдер.

— Бездә дин дәүләттән аерылган. Мөфтият үзе куйган әһелләренә түлидер дип беләм. Без анда исәптә тормыйбыз.

— Ырыкныкы кырыкка, кырыкныкы шырыкка икән алайса...

— Әйтүе генә ансат. Мәчет төзик дидек, бер кеше бер тиен акча бирмәде. Йә, кайсыгыз намаз укый белә, кул күтәрегез әле.

Кул күтәрүче табылмады.

— Вәлихан абзый белә,—дип аваз салды Камәр форсаттан файдаланып,— укып күрсәт әле, Вәлихан абзый, безнең авыл наданнарына, тыңласыннар!

Вәлихан каратут йөзле, зур борынлы, калын иренле, карап торуга шактый нык бәдәнле карт иде. Элекке тегермәнче. Тирә-якка даны чыккан адәм. Авыл саен йортка кереп, азып-тузып йөри торгач, ахыры тегермән ташында кулын өздереп, эштән чыгып туктаган иде. Баксаң, дин ягыннан шактый укымышлы икән. Тавышы да моңлы. Коеп куйган рухани. Әйтерсең лә, гомере буе намазлык өстендә утырган, бәлеш төбе белән сыйланып йөргән.

— Менә сезгә әзер мулла,— диде Камәр.— Ул хәзер безнең авылга күченеп килде, бергә торабыз.

Вәйт, хәйләкәр төлке, дип ачынды Әбелмәлих, аның сүзен тыңлаган мин җүләр, күрәләтә утка төртеп кертте бит, ә? Мине эт урынына өстерде дә, үзе, баксаң, инде әллә кайчан чарасын күреп куйган.

Хак икән, сандугач юк елны, чыннан да, карга шәп кычкыра икән. Камәр исә сандугачны да үз кулында тотып калды, карганы да очырмады.

* * *

Икенче көнне Әбелмәлихне районга чакыртып алдылар. Кабул итү бүлмәсендә озак тотмадылар, шундук башлык янына кертеп җибәрделәр. Ике катлы ишек ябылуга, ул куркып-шикләнеп калды, әйтерсең лә, төрмәгә кертеп яптылар.

Каяндыр ерактан: «Бирегә уз»,— дигән тавыш яңгырады. Бу нинди тавыш дигәндәй, Әбелмәлих башын як-якка боргалады. Зур, якты, чиста бүлмә. Мөсифуллинныкыннан да зуррак.

— Бирегә уз!—дип кабатлады баштагы сүзен Үтәгәнев.

Әбәлмәлих аңа күтәрелеп карады. Һәм йөрәге тынычланып тибә башлады, борчылулары онытылды. Бер карауда ошатты ул башлыкны. Үтәгәневнең дә йөзенә елмаю чаткылары сибелде.

— Әйдә, уз, фермер, утыр,— диде ул күптәнге танышын каршылагандай.

Ул инде Әмерикәдә трусигының алдын артына киеп, әбрәкәйдә доллар капшап йөргән мескен керистиән түгел иде. Дәү өстәлнең дәү хуҗасы.

— Карале, Сәгыйдуллин, мин синнән үрнәк фермер ясыйм,— дип Үтәгәнев үгезне мөгезеннән алды,— Әмерикәнең дә тез астына тибәрлек итеп, аңладыңмы?

Балта сораганда шөшле тоттыра, дигәндәй, болар Әбелмәлихнең башына кереп тә караган уйлар түгел иде. Өмете һич тә яктыда түгел иде. Шуңа күрә Үтәгәневнең тәкъдименә ни дип әйтергә дә белмәде. Хәер, башлык аннан җавап та көтми иде булса кирәк, планны алдан корып куйган иде, күрәсең, шулар белән хәзер Әбелмәлихне таныштыра гына иде.

— Инде хуҗалыкның юнәлешен билгелик,— диде ул,— ягъни дә нинәрсә белән шөгыльләнәчәкбез?

Әбелмәлих бу сөйләшүгә әзер түгел иде. Гомумән, ул әле аңына да килеп җитмәгән иде. Шуңа күрә ык-мык итеп торды.

— Җә, җә,— дип ашыктырды аны Үтәгәнев,— нужали бер уең да юк?

— Бар анысы, бик капылт килеп чыкты бит әле бу сөйләшү, диюем...

— Заманы шулай, Сәгыйдуллин, заманы.

— Бәрәңге утыртырбызмы әллә дип тора идек, беразына үлән чәчәргә ие...

Бермәл Үтәгәневнең барча әгъзалары да калтыранып торды. Гадәттәгечә, тавыш чыгармый гына көлә иде ул.

— Татарның шул булыр инде, бәрәңге, комган, юлпыч...

— Суганы табышлы бугай да инде аның, үстереп караган юк бит.

— Монысы ярый, нәкъ мин уйлаганны әйттең, ашханәләр суганны читтән кайтарып азапланалар. Заказга күмәрбез, җитеш кенә. Кредит та бирербез.

— Бирер Мөсифуллин, көт.

Үтәгәнев ниндидер төймәгә басты да, бөер тавышы белән сәркәтибенә боерык бирде: банықны тоташтыр!

— Тыңлыйм, Гали Үтәгәневич, Сезне кайтуыгыз белән тәбриклим, каршыларга төшә алмадым, гафу итегез. Сукыр эчәгегә приступ булды, операция ясадылар. Сез кайтканны ишеткәч, эшкә чыктым, кирәгем чыгуы бар дип уйладым,— дип тезде Мөсифуллин.

— Ә, алаймыни, исәп орышырга иде әле үзеңне. Хәтереңдәме, «Кызыл көч»тәге фермер хуҗалыгы хакында сөйләшкән идек. Кыл да кыймылдатмагансың бит, ә?

— Мин барысын да белештем, тик нигәдер минем ул Сәгыйдуллинга күңел ятып бетми, Гали Үтәгәневич, чәүчәлек адәм диләр, әллә башка кандидатура сайлыйкмы?

— Мәсьәлә хәл ителгән инде. Ул менә минем янда утыра, иртәгә Казанга китә. Бүген үк сөйләшкәнчә хәл ит. Тракторга да, симәнәгә дә, башкасына да җитәрлек булсын!

Мөсифуллин кәнәфиендә бик озак бүртенеп утырды да, бу эшне урынбасарына тапшырып, Үтәгәневне сүгә-сүгә сырхауханәгә укол кададырга китте.

## Сигезенче баб

Казан Әбелмәлихне бик үк мәрхәмәтле каршыламады. Хәер, авызың кыек булгач, көзгегә дә үпкәләргә туры килми шул. Шулай да Такташ хаклы булгандыр, мөгаен.

Казан!
Фахиш шәһәр.
Синең урамыңда
Җанга җылы юктан туңам мин,
Череп беткән мещан мунчасында
Көзге чәчәк кебек сулам мин.

Безнең көннәрдә яшәсә, шагыйрь тагын ничекләр язган булыр иде икән? Ул тасвирлаган нэпманнар хәзерге мафиянең кисеп ташлаган тырнакларына да тормыйлар лабаса! Ленин нэпманнарны бер фәрманы белән тарих мөнбәреннән алып ташлаган. Бездә исә аларга каршы торырлык көч юк. Чөнки дәүләт үзе мафияга хезмәт итә. Кызганыч, хакыйкатьне сәнгати сурәтләргә туры Тукайларыбыз, Такташларыбыз юк.

Хәер, зарланудан ни файда, әйдәгез, Әбелмәлихне күзәтик, ник килгән ул монда, исәбе ни майтару? Ә аны автобустан төшүгә бер кыска итәкле ханым эләктереп алды да:

— Баһадир, башкала җариясенең тәмен татып карыйсың килмиме? — дип пышылдады. — Тиз дә, очсыз да!

Әбелмәлих башта аңышмый торды; нинди җария, нинди тәм? Ханым гөрелди генә:

— Әйдә, баһадир, карышма, гомерең буе сагынып искә алырсың. Авыл кешесенең андыйны күргәне бармыни аның?..

— Туктале, син мине кая өстерисең? — диде, ниһаять, Әбелмәлих.

Шул рәвешле тарткалашып торганда алар каршына шундый ук маймыл кебек буялган, шундый ук таушалган бер хатын килеп басты.

— Әй, син, сөйрәлчек,— дип төртеп җибәрде бу кыска итәкне,— кичә минем клиентны урлаган идең, бүген бу красавчикны үземә алам!

Черелди генә, теле телгә дә йокмый. Киттеләр тарткалашып, киттеләр эткәләшеп, авызларында гел кабәхәт сүз. Шуннан файдаланып, Әбелмәлих алар яныннан табанын ялтыратты. Ерак түгел генә сыраханә бар икән, иң элек шунда сугылды.

— Ике тустаган сыра,— диде ул сатучыга. Һәм түләргә дип кесәсенә тыгылды. Ә анда бумажниктан җилләр искән иде. Әбелмәлих атылып урамга чыкты. Вокзал ягына йөгерде. Кызыл иреннәрне ул бик тиз тапты. Эскәмиядә көлешә-көлешә туңдырма ашап утыралар иде.

— Бумажникны бир, карак, хатын-кыз башың белән кесәгә керәсең,— дип, Әбелмәлих тегене кымтырата башлады. Якында гына бер милиционер йөрештерә иде, хатын аңа кычкырды:

— Иптәш милиционер, баядан бирле менә шушы адәм миңа бәйләнә, башта йокларга өндәде, хәзер бумажник таптыра...

— Мин шаһит,— дип чыелдады дусты.

— Абзый кеше,— диде милиционер,— яхшы чакта тай моннан, югыйсә, сыртыңа сыдырырга да күп сорамам.

Әле ярый, юллык акчаны гына чәлде, дип соңыннан күңелен юатты Әбелмәлих. Документлары, кредит кәгазьләре, төп сумма ышанычлы урынга яшерелгән иде.

Министрлыкта да аны көтеп тормаганнар икән. «Әбәт вакыты, бераз йөрештереп керегез»,— диде дежурный.

— Минем йөрештерерлек урыным юк,— дип ризасызлыгын белдерде Әбелмәлих,— җәтрәк йомышны йомышлыйсы иде.

— Синең йомышчылар монда буа буарлык,— диде дежурный.

Бәхетенә, нәкъ шушы вакытта тышкы ишектән тәгәрәп диярлек туп шикелле бер юан кеше килеп керде. Дежур аны күрүгә аягүрә торып басты, күзләрен очкынландырып Әбелмәлихкә читкәрәк китәргә ым какты. Әбелмәлих исә, киресенчә, авыл кешесенә хас беркатлылык белән керүчегә бакты.

— Иптәш Сафинга юл бир! — дип ысылдарга мәҗбүр булды дежур.

«Һы, шушы да булдымы түрә,— дип уйлады. Әбелмәлих.— Түрә мәһабәт гәүдәле, энәдән-җептән киенгән чибәр кеше булырга тиеш. Бу нәрсә?! Фу...»

Тегесе дежурның сүзләрен ишетеп алган икән.

— Нәрсә, әллә буйсынмыйлармы? — диде көлемсерәп.

— Аңгыра сарык ул кеше хәзер, иптәш Сафин, чыбыркысыз берни дә төшендерә алмыйсың.

— Ну, ну, арттырып җибәрәсең түгелме, Мостафа?

Сафин дигәннәре Әбелмәлих ягына борылды да:

— Сез кайдан, ни йомыш? — дип сорады.

Шуннан соң гына Әбелмәлих бу кешенең Түрә икәнлегенә ышанырга мәҗбүр булды. Ул кыска гына итеп хәлне сөйләп бирде.

Сафинның сессиядән кайтып килеше иде. Анда оппозиция вәкиле авылны «коммунизм утравы», дип тәнкыйтьләде. Фикерен фермерлык

хәрәкәтенең сүнүе белән дәлилләде. Инде күптән яңа фермер хуҗалыклары оешканы юк, элеккеләре таралып бетте, диде. Бу дәреслеккә туры килә иде. Тик оппозициягә факт кына кирәк, әлеге хәлнең сәбәпләре аны кызыксындырмый.

Колгасардай озын буйлы, җирән сакаллы бу депутатка биргән җавабында ул парламентарийларның үз бакчаларына таш очырды.

— Тәнкыйтьне кабул итәбез,— диде,— әмма дә ләкин фермерлык без теләгәнчә җәелсен дисәк, шуңа тәңгәл законнар да зарур. Ә алар юк дәрәҗәсендә. Әйтик, фермер кредит процентларын күтәрә алмый, шуңа бөләләр, таркалалар...

Әбелмәлих белән гәпләшеп торган арада Сафинның башында бинһая зур план да пешеп чыкты. Тиздән Дәүләт Советына сайлаулар. Бу фермер аламасын альтернатив кандидат итеп теркәгәндә, менә дигән спектакль килеп чыгачак бит. Оппозициянең авызын чәп иттереп каплыйсың да куясың. Фермер, әлбәттә, Үтәгәневне җиңә алмаячак, җиңүе кирәкми дә. Тирә-күршеләрдә дә мондый хәлнең булганы юк әле. Шәп идея, каһәр!

Сафин Әбелмәлихның йомышларын яшен тизлеге белән йомышлатты да, Үтәгәневка шалтыратып, күрсәтмәләрен бирде.

Базада гына эш алай тиз бармады. Мондагыларның уены башка иде, күрәсең.

Мөдир ул биргән кәгазьләрне бер читкә сыпырып куйды да:

— Ать әле, гадук, синең катының яшьме, картмы?— дип сорады.

Әбелмәлих ни дип җавап бирергә дә белмәде.

— Ну!

— Бергә-бергә торгач, барыбер түгелмени?— дип Әбелмәлих җилкәләрен сикертеп куйды.

— Юк, гадук, барыбер түгел. Катының яшь булса һәм дә һаман авырып торса бер халь, әгәренки ул карт, шуның өстенә таза да булса, ух-да-ух.

Мөдир алтын тешләрен ыржайтып рәхәтләнеп көлде. Аннан соң шып туктап, без шикелле очлы бәбәген Әбелмәлихкә батырды:

— Иртәгә килерсең, беген вакытым жук,— диде.

Иртәгәсен дә юл уңмады. Әле имзадан гаеп табалар, әле документының срогы чыккан дип бәйләнәләр. Аптырады чистый. Янә мөдирнең ишеген шакыды.

— Һо, гадук,— дип каршы алды аны мишәр,— кыргаяк турысында анекдотны ишеткәнең бармы?

— Анекдот кайгылары юк әле монда,— диде Әбелмәлих. Мөдир аңа карамады, сөйли башлады: «Бөҗәкләр собрание зыйганнар, имеш. Кыргаяк суңарып килген.

— Нәрсәгә суңардың?— дип сораганнар моннан.

— Вакытым аякларымны сөретеп узды. Үзегез ишек катына: «Аязгыгызны сөретеп керегез»,— дип язгансыз ич дигән, ди.»

— Кадалып китсен кыргаягың, миңа трактор кирәк,— дип кычкырды Әбелмәлих.

Мөдирнең елмаерга ачылган иреннәре кире ябылды, күзләре усалланды, кыска юан бармагын ишек ягына тырпайтты.

— Аякларыңны сөртеп кер, надан!

Сарык белән булган мәләкәдән соң алыш-бирешкә баш тыкмам дип ант иткән иде Әбелмәлих. Ләкин антын бозарга туры килде. Чөнки төшендерделәр, монда өстәл артында утыручы һәр хезмәткәрнең үз бәһасе бар икән. Аларның нәфесен канәгатьләндермичә син моннан сыңар тәгәрмәч тә ала алмыйсың. Тракторга салым зурдан икән. Үзе чикерткә кебек кенә, ә көче Алып тауларын ишәрлек.

Мөдир-хезмәткәрләрнең учларын җылыткач, эше майлангандай барды. Менә ул шатланып-куанып капка янына килеп туктады. Каравылчы нәкъ аның борын төбендә тимер капканы шап итеп бикләп куймасынмы.

Әбелмәлих аңа рөхсәт кәгазьләрен сузды, янәсе, барысы да тәртиптә. Тегесе исә башын гына чайкый, бигайбә, чыгара алмыйм, нәчәлстуа кушмады, ди.

Ләкин Әбелмәлих кайчан нинди төймәгә басарга икәнне өйрәнгән иде инде. Каравылчының кулына бер шытырдык кәгазь кыстырган иде, капка үзеннән-үзе ачылып китте.

Әбелмәлихның авызы барыбер колагында иде. Шулай булмыйча, тракторлы булды ич. Кара, нинди уңайлы... Кабинасы җылы, якты, бөтен җире ялтырап тора. Кайтышлый Чаллыда суган орлыгы гына аласы калды. Иншалла, анысы болай ук мәшәкатьле булмастыр.

Трактор чакырым артыннан чакырым саный. Ә Әбелмәлихнең күңеленә сыеша алмаган шатлык җыр булып ургылып тышка чыга:

Тала, тала, тала, тала,
Тала минем беләгем...

Җыр белән мавыгып ул юл чатында торучы милиционер егетнең сыбызгы сызгыртуын да ишетмәде.

Нигә тала, нигә яна
Икән минем йөрәгем?..

Бераздан артыннан төтен алкалары калдырып, тракторны ГАИ машинасы узып китте дә, 10-15 метр алда туктап калды. Аннан яшь кенә бер лейтенант атылып чыкты. Кулындагы түгәрәк нәмәстәсен болгый-болгый ул аңа туктарга кушты.

— Документларыгызны бирегез!

Әбелмәлих шыр җибәрде, кесәсеннән кәгазьләрен чыгара алмыйча азапланды.

Лейтенантның юка иреннәренә мыскыллы елмаю кунды. Ул бу минутта башлыгы майорның төксе йөзен күз алдына китерде. Майор дежурга чыгар алдыннан бөтен команда алдында аңа кисәтү ясады, вак-төяк белән шөгыльләнәсең, Хәтмуллин, эрерәк балык эләктерергә вакыт, диде. Эш күрсәткечләрең түбән, диде. Ул рапортларның җиллесен ярата иде, «Минем дежурлык вакытында берниндн гадәттән тыш хәлләр булмады»,— дигәннәрен ертып кына ташлый.

Әбелмәлих лейтенант табасында кыздырылырга тиешле эре балык булырга тиеш иде. Беренчедән, постта торучының әмерен үтәмәде, икенчедән, салмыш, әнә, куллары калтырап тора. Машинага, документларга килгәндә, алардан гаепне күз йомып та табып була.

— Иптәш лейтенант, минем кайтасы җир ерак, тизрәк җибәрсәгез иде,— диде Әбелмәлих.

— Ашыкма, хәзер медэкспертиза чакыртам, син исерек!

Лейтенант документларны алды да, будкага кереп китте. Анда радиотелефон аша кем беләндер элемтәгә керде. Ләкин тегесе ризалашмый иде, ахры. Озак кына бәхәсләштеләр. Лейтенант хәтта бүреген салып почмакка ыргытты, «ике-өч сәгатьтән булса да килегез, көтәм»,— дип кычкырды.

Милиция — чыгынчы бия кебек, бер тәртәгә типтеме, син аны берничек тә эзенә төшерә алмыйсың. Әбелмәлих та телен еландай боргалады, салпы ягына салам да кыстырып карады, ләкин лейтенант сүзеннән кайтмады.

Ә экспертиза дигәннәре юк та юк. Лейтенант ябык озын муенын сузып әле юлга чыгып баса, әле будкага кереп радиотелефонга тотына. Базга төшкән җанвар кебек чәбәләнә. Әбелмәлих аны кызгана ук башлады, булышасы килә башлады. Милиция булып милициядә дә тәртип булмагач, башкасына нинди чут, дип уйлады, дөньясы бардакка әйләнгән икән, кая борын тыксаң, шунда ертык.

— Син, энекәш, үзең урап кил, сменаң да бетәдер бит инде,— дип Әбелмәлих лейтенантның хәленә кермәкче итте.
— Минем постны ташларга ярамаганны беләсең бит, сволочь,— дип күзләрен генә акайтты тегесе.
Бераздан ул дык-дык басып урамга чыгып китте. Әбелмәлихнең дә бу тынчу эт оясында утырасы килми, ләкин егет рөхсәт итми, телефон төбендә утырырга куша.
Ниһаять, телефонга да җан кергәндәй булды. Әбелмәлих будканың ишеген ачып, лейтенантны чакырды, үзе урамга чыкты.
Монда рәхәт иде. Офык күк читендәге болыт сәламәләренә алсу итәген япкан. Ерактан ул сүнеп барган ялкынны хәтерләтә. Инде төн пәрдәсе төшеп килә. Әнә, аерым машиналар яктырткычларын да кабызганнар. Будка яныннан туктатмасалар ярар иде дип сак кына узып китәләр. Шулай булмыйча, бу бәйләнчекләрдән еракрак йөрүең хәерлерәк.
Әбелмәлих кабинадан азык-төлек салган букчасын алып будкага керде. Лейтенант ятим бала шикелле яңакларын ике учы белән кочкан да бер ноктага текәлеп уйга талган.
— Әйдә, энекәш, иякләрне биетеп алыйк булмаса, ач кеше ачулы, диган борынгылар.
— Иди ты...
Ләкин баягы кебек дорфа сүз әйтүдән ничектер тыелып калды лейтенант.
— Эшләр Хөрти,— дип тынычланыбрак дәвам итте сүзен,— кулалмаш авырган, экспертиза просто алдады, сволочи!
— Син миңа зрә бәйләнәсең, энекәш,— диде Әбелмәлих,— бу тракторны миңа бик зур түрә язуы белән бирделәр. Аннан китереп, инде бер тәүлек авызыма шайтан суы да капканым юк. Юл ерак бит, башыма тай типмәгән лә...
— Алайса нигә кулларың калтырый иде?
— Куркудан, энекәш, без милицияләргә эләгеп йөргәнмени?
— Миңа бу эштән китәргә кирәк,— диде лейтенант,— сиземлегем юк икән.
— Анысы синең эш, энекәш, әйдә, булмаса тамак ялгап алыйк.
Әбелмәлих өстәл өстенә ашамлыкларын тезеп куйды. Сүзсез генә ашадылар. Лейтенант йокларга ятты. Әбелмәлих юлга чыгып басты. Юри генә, сынап кына карамакчы булып, лейтенантның сырлы таягын күтәрде. Үтеп баручы машина шундук туктады.
— Дүкәмитләрең! — диде Әбелмәлих коры гына.
Шофер правосын сузды. Аның эчендә унмеңлек ике купюр ята иде. Алыргамы-юкмы? Әбелмәлих бераз икеләнеп торды. Шулай да алырга карар итте. Акча үзе кесәгә керәм дип сикергәләп торганда нинди икеләнү ди. Кизәнәсең икән — сук!
Машиналар туктый тора, кесәгә акча шуа тора. Бер-ике сәгать эчендә үз роленә шундый күнекте ки, Әбелмәлих, әйтерсең лә, гомере буе шушы эш белән шөгыльләнгән.
Бер шофер таякны күтәргәнче үк туктады.
— Ринат ял итәме, сәлам әйт, Колгадан диген.
— Есть, товарищ командир! — дип Әбелмәлих аңа шаяртып честь бирде. Тегесе дустанә рәвештә кулын болгап китеп барды.
Уеннан уймак чыкмагае, дип Әбелмәлих акча җыюны туктатырга булды. Будкага керде. Лейтенант песи баласы кебек йомарланып беткән. Ул тагын да кечерәеп калган төсле күренә. Әбелмәлих аның бүрткән кесәсенә кагылды. Кесәсе тулы акча иде.
«Юк, лейтенант, син бу эшне ташламаячаксың,— дип уйлады ул,— төшемле шөгыльгә юлыккансың».
Әбелмәлих тракторын кабызды да юлга кузгалды. Ул хәзер ГАИ белән ничек эш итәргә белә иде инде.

Әбелмәлихне депутатлыкка кандидат итеп үз авылларында күрсәттеләр. Авылның колхоз өлешендәгеләр йөзләрен җыерды, билгеле. Әмма өстән килгән әмергә каршы төшеп кара, сытып ташларлар. Бригадир алдан ук кисәтеп куйды. Тәртәгә тибәргә уйлаcагыз, чамалагыз, печән диеп авыз ачасы булмагыз, күзләрегезгә кырып салырлык та тәтемәс, диде. Монысы гарантия өчен иде. Чынлыкта исә, күмәк хуҗалык кысаларында тәрбияләнгән авыл халкы инде күптән сарык көтүенә әйләнеп беткән иде. Кайсы якка кусаң, шунда бара, ни кушсаң, шуны үти. Сайлау булмасын, референдум булмасын, авыл хакимият өчен кирәкле процентны, шалт, Мөхәммәтҗан, эшли дә куя. Менә шулай пролетариат гегемоннан союзникка, крестьян союзниктан гегемонга әверелде дә куйды.

Шулай да кала йогынтысы үзен барыбер сиздермичә калмый. Әлеге җыелышта да чагылды ул. Иң беренче булып Муса атылып чыкты.

— Юк инде, әфәнде вә ханымнар, Әбелмәлих бу мәсләктә намәхрәм зат, чөнки дә ул мафиозник. Әнә, нинди трактор биреп җибәргәннәр үзенә. Долой, мафиоза! Азатлык, азатлык, азатлык!

— Кемне тәкъдим итәсез соң алайса?—дип сорарга мәҗбүр булды җыелышны алып баручы.

— Үземне!—диде Муса.

Халык шыр-шыр көләргә тотынды.

— Сарман көенә бию була бит бу, җәмәгать!

— Тыңламагыз шул ярпачның сүзен.

— Хокукым бар!—дип кычкырды Муса.

Бәхәскә Камәр нокта куйды. Калыбына кертеп диярдәй «бисмилла»сын әйтте, вәкарь белән генә тамагын кырып куйды.

— Бәй, апайлар,—дип башлады ул сүзен,—партия-правительстваның сүзен аяк астына салып таптап торган булсак, оҗмах ишекләре ябылыр безнең каршыбызда, әйе, тәүбә-тәүбә, әстәгъфирулла, Ходаем, үзең ярлыка. Нәмәгә сузып торырга, тавышка куярга кирәк. Әбелмәлих булдыклы җегет, иншалла, Горбачны кире кайтармасмы әле. Мусаны да читкә тибәргә ярамый, аны Әбелмәлихнең ышанычлысы итү мәслихәт булыр. Сайлау чорында андый оран салучылар да бик кирәк.

Әбелмәлих теге вакыттан соң Камәргә ачулы иде. Әмма аның иң кирәк чакта, менә хәзер, ярдәм кулы сузуы, күңелен балавыз кебек йомшартып җибәрде, ирексездән күзләренә яшь элпәсе капланды. Халыкның кайсы кылына басарга белә, каһәр, дип уйлады ул, яман аты чыккан Вәлихан булып Вәлиханны мулла урынына утыртты бит тәки. Хәзер дә үз дигәнен итәчәк.

Ләкин инде эш пеште генә дигәндә, колхоз бригадирының көнчелек өянәге кузгалды. Югыйсә, үзе үк югарыдан килгән әмерне бозмаска өндәп йөргән иде. Хәер, көнләшмәгән татар татар була димени.

— Билгеле, иптәшләр, тавышка куярга кирәк!—диде ул бик белдекле кыяфәттә.—Әбелмәлих кандидатурасы форма өчен генә, беләбез, әнтәрәк, Гали Үтәгәнечка көндәш сыйфатында, ягъни дә. Сайлау альтернатив узды дип әйтү өчен...

Муса мондый сүзләргә түзеп торамы соң? Әле генә сөйләгәннәрен онытып, сәхнәгә сикереп менде дә:

— Әбелмәлихне җиңдермәсәм, исемем Муса булмасын!—дип кычкырды.

* * *

Әбелмәлихне Үтәгәнев очрашуларга үз машинасында гына йөртте. Бергә ашадылар, бергә сыйландылар. Башлыкны Әбелмәлихнең ышанычлысы да канәгатьләндерә иде. Үзе кебек, ни акыл-

лы, ни дурак, кәмит куеп, халыкны көлдереп йөрергә ярый шунда, дип уйлады. Ә аның ышанычлысы Мөсифуллин иде. Сөйләргә оста, кешеләрне авызына гына каратып тота. Ул мактый, мин сиңа әйтим, Үтәгәнев баштагы мәлне чөгендер кебек кызарып чыга иде. Соңыннан күнекте. Кайдан таба чагыштыруларын, исең-акылың китәрлек, валлаһи! Берсендә түбәтәй киеп сәхнәгә чыгып басты да дога укырга кереште Мөсифуллин:

Аллаһу әкбәр!
Әшһәду әл лә иләһә иллəл-даһү!..

Кешеләрнең күзләренә яшь бәреп чыкты. Үтәгәнев үзе дә аздан гына калды. Шундый да моңлы, шундый да мәкамле итеп укыды, чын муллаларың бер якта торсын.

— Җәмәгать, бу доганың мәгънәсен кем аңлатып бирә ала?—дип сорады соңыннан Мөсифуллин.

Җаваплар ык-мык итүдән узмады.

— Азаныбыз булыр бу, җәмәгать. Аллаһу боерса, Гали Үтәгәневичне депутат итеп сайлагач, авылларыбызда мәчетләр төзелә башлар, ул бик инсафлы, динле гаиләдән. Дөрес, кайберәүләр, бигрәк тә район үзәгендә, аңа йорт салу мәсьәләсендә нахак бәла тагалар. Ләкин дә бу дөреслеккә туры килми. Бу җәһәттән, мин үзем дә Гали Үтәгәневичне кискен рәвештә тәнкыйтьләргә тиешмен. Әйе, әйе, иптәшләр, бернәрсәгә карамыйча, без туры сүздән курыкмыйбыз. Ник дисезме? Чөнки әлеге кызыл авызларның базын шунда ук ябарга кирәк иде. Ул исә, ягъни дә Гали Үтәгәневич, артык мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек күрсәтте. Хәер, бәлкем шулай кирәктер дә, ә?

Кешеләр шаулашып алды, бу минутта алар теге кызыл авызларның тетмәсен тетәргә әзер иделәр. Ләкин Мөсифуллинга бу гына аз, ул берьюлы икешәр-өчәр көймәнең койрыгын тотарга күнеккән.

Йөзенә хәйләле елмаю ишарәсе чыгарып, ул залга текәлде. Тып-тын калдылар, тик бу алдавыч тынлык. Тагын берничә секундтан котырынып кул чабачаклар. Әйе, барысы да уйланылганча бара.

...Ләкин бу юлы шартлау булмады. Хәтта кайсыларыдыр хихылдап көлеп тә куйдылар. Чөнки нәкъ шул вакытта бер исерәге урыныннан егылып төште. Паразит, бөтен эффектны бетерде бит бу, дип сүгенде эченнән генә Мөсифуллин, юк, без алай җиңел генә бирелә торганнардан түгел. Ул шушындый көймә комга терәлгән чакларда гына кулланыла торган сыналган алымны эшкә җикте: халыкка елмаеп, артистларча җиңел генә кулын чапкандай итте.

Менә шунда купты инде зал! Колаклар чыңлап торды.

— Рәхмәт,—дип тезеп китте Мөсифуллин, зал тыңлар хәленә кайткач,—пәйгамбәр ул безнең хакимият башлыгы Гали әфәнде. Гали! Мөхәммәт пәйгамбәрнең кияүе дә Гали исемле булган, иптәшләр. Бу һич тә очраклы түгел. Гали Үтәгәневич безнең бәхеткә туган кеше. Бирик без аңа шундый мөмкинлек, итсен ул безне бәхетле!

Пәйгамбәр дигәч шунысын да әйтим, алар бит ялгышмый, җәмәгать! Җу-у-ук! Коръән Кәримдә әйтелгән, пәйгамбәрнең аяклары гына таеп китәргә мөмкин, диелгән. Аллаһу Тәгалә аларны һәрвакыт ярлыкый.

Бу сүзләре белән Мөсифуллин Үтәгәневнең бөтен гөнаһларын юып төшерде. Шул ук вакытта кеше алдында Әбелмәлихне да читкә типмәде, авыл хуҗалыгының киләчәк язмышы фермерлар кулында диде, Сәгыйдуллин да йөрсен менә, әвәләнсен, шомарсын, ихтимал, алга таба район масштабында яңа сәясәтчебез дә туып куймасмы?

Әбелмәлих Мусага күз төшерде. Саргылт керфекле күзләрен челт тә челт йомгалап утыра. Кая инде аңа Мөсифуллинга җиту. Алай да кыяфәтенә караганда, бирешергә исәбе юк кебек. Әбелмәлих шикелле,

Мөсифуллинга мөкиббән китеп утырмый, хәтта блокнотына нидер сызгалап та куя. Аңа карагач, Әбелмәлихнең дә кәефе күтәрелеп китте. Җинүен башлык җинсен, дип уйлады, аңа кирәгрәк. Тик бер тотынгач, безгә дә сер бирергә ярамый, азмы-күпме тавышын да җыясы иде ич, алайдыр, болайдыр, фәләндер, төгәндер, дип кенә йөрергә ярамый.

Пластинка сырларына эләккән патефон энәсе кебек, барысы да бер түгәрәктә әйләнә. Очрашулар, алкышлар, мәҗлесләр. Шул ук тостлар, шул ук мактаулар, шул ук мактанышулар.

Көннәрдән бер көнне уйламаганда-нитмәгәндә Муса бу ялыктыргыч бертөрлелеккә үзгәреш кертте. Үзенең башына килгән идеме бу, өйрәткәннәр идеме, Әбелмәлих белми калды. Ихтимал, авылы шуңа этәргәндер. Әмма тегеләрнең кыңгырауларына үлән тыкты тәки.

Әмәкәй авылы иде бу. Зур, төзек, бердәм авыл. Сугышсалар да бергә, урлашсалар да бергә. Мәгәр авызында кан булса да, төкермәс Әмәкәй кешесе. Кулы сынса, җиң эчендә, аягы сынса, итек эчендә булыр. Дөя муены төз дип әйтә икән, димәк, төз, үлсә үләр, сүзеннән кайтмас.

Сабантуенда алар һәр елны район үзәге кешеләрен тукмап кайталар. Югыйсә, милиция алдан бөтен чарасын күреп куя. Районныкылар үзләре дә ныклап әзерләнә. Барыбер сугыш була, барыбер әмәкәйлеләр җиңә. Кемдер Әмәкәй кешесен кыерсыта икән, шулай ук рәхим-шәфкать көтмә. Өерләре белән барып әлеге авылны пыр туздырып кайталар.

Патша вакытында, дөрес булса, Әмәкәй авылы башында кара багана торган диләр, бу куркыныч дигәнне аңлаткан.

Халкы бердәм генә түгел, үҗәт тә. Колхозлары районда беренче. Кассаларында һәрвакыт акча булыр. Һичюгы, урман кисеп, сал агызып булса да, тамак туйдырырлык рәт чыгарырлар.

Клубта халык шыгырым иде, энә дә төшәрлек түгел. Мөсифуллин монда да оста оратор икәнлеген дәлилләде. Яраттылар. Чират Мусага җитте. Аның шул бер балык башы иде: «Азатлык»та «Бетсен колхоз» — Әбелмәлих шул сүзләрне көтте. Ә ул бернинди кереш сүзсез тотты да Үтәгәневкә үтергеч сорау юллады.

— «Хөрмәтле Гали әфәнде,— диде ул үтә бер әдәплелек белән,— Сезне Мытыйс урманындагы кунак өенә мәгъшукалар алып бара диләр, шул дөресме?

— Провакация бу, минем кандидат андый сорауларга җавап бирми! — дип атылып чыкты Мөсифуллин.

Ләкин таудагы кар ишелә башлаган иде инде, аны хәзер беркем дә туктата алмаячак. Күзләр Үтәгәневкә төбәлгән. Ә ул:

— Хакимиятнең бернинди кунак йорты да юк! — диде дә, балаларча үпкәләп, урыныннан торып залдан чыгып китте. Бу аның зур хатасы иде. Әмәкәйлеләр дә, башкалар да сорашуның нигезле икәнен мыек очына чорнап куйдылар. Дөрес, шул ук көнне Үтәгәнев аренда договорын өзү, хезмәт күрсәтүчеләр штатын кыскарту турында боерык чыгарды. Ләкин бу — туй үткәч, дөмбергә генә иде.

Янә бер зур хата эшләде Үтәгәнев командасы. Бер-ике көннән Мусаны төнлә ашыгыч ярдәм машинасы белән килеп алдылар. Янәсе, хатыны телефоннан шалтыраткан. Шалтыратуы хак иде. Анысы да Мөсифуллин кушуы буенча. Ул аңа әйткән, ирең авыру, дәваларга кирәк, үзем ярдәм итәрмен, дигән. Югыйсә, дигән, гомерең буе сырхау ир белән интегәчәксең, дигән.

Хатын, билгеле, Мусаның кыланышларыннан болай да гарык иде. Рәхмәтләр әйтә-әйтә ризалашты. Ике арадагы килешүне чәчмәскә дә вәгъдә бирде.

Менә шулай, ай-ваена карамастан, Мусаны хастәханәгә китереп салдылар, инфаркт, кузгалырга ярамый дип, янына махсус шәфкать туташы да утырттылар.

Без капчыкта ятамы соң?! Тоталитар режим вакытында меңнәрчә кешеләрдә сыналган бу «үтемле» алым демократия чорында ярамый

икән шул. Әмәкәйлеләргә дә барып ирешә бу хәбәр. Шикләре зур иде. Һәм җиде төн уртасында Мусаны сырхауханәдән урлап алып чыктылар да, күрше районга илтеп тикшерттеләр. Мусада инфаркт та, чурт та тапмадылар.

Бу хәлләрдән соң Муса хатынын сыек чыбык белән ярган дип сөйләделәр. Ярса яргандыр, озак кына күзгә-башка чалынмады, хәзер иренең күзенә генә карап тора.

Бу җәнҗал Әбелмәлихкә җиңү китерде. Депутат булып сайланмагач, Үтәгәневне башлык вазифасыннан азат иттеләр.

Муса сүзендә торды.

## Унынчы баб

Котыр өстенә котыр дигәндәй, кунакханә администрациясенең кылган көч-хәл белән үтеп, ачкыч алыр вакыт җиткәч тә каршылыкка дучар булды әле Әбелмәлих.

— Күк тәрәве түгелдерсең бит, нәрсә терәлеп каттың, юлыңда бул,— дип каршы алды аны җыештыручы.

— Мин инде килеп җиттем, түтәкәй! — диде Әбелмәлих шаяртыбрак.

— Бик кукрайма, монда кат саен милиция.

— Мин бу бүлмәдә торачакмын, түтәкәй, аңладыңмы?

Җыештыручы карашы белән Әбелмәлихнең юлда буялган киемнәрен, җил ашаган төссез кашларын капшап узды. Ләкин игътибарны җәлеп итәрдәй нәрсә тапмады, ахрысы, шунда ук сүнде.

— Яхшы чакта үкчәңне ялтырат, тел кашырга вакытым юк минем.

— Ышанмасаң, менә кәгазьләрем,— дип Әбелмәлих кесәсеннән шәхеснамәсен суырып чыгарды.

— Депутат та түгелме әле? — дип иреннәрен бөрештерде хатын.

— Коеп куйган...

— И хәчтерүш, сөйләп торган була, депутатларның значогы була, алайса кая соң значогың?

— Мин аны кесәмдә генә йөртәм.

— Ышандылар ди, бик беләсең килсә, депутатларның авызыннан затлы коньяк исе генә килеп тора, ә синнән өчсыз сыра исе аңкый. Фу!

— Нәрсә бар монда? — дип алар янына милиционер килеп туктады.

Әбелмәлих аңа кулындагы шәхеснамәсен сузды.

Милиционер документтагы фотосурәтне җентекләп тикшерде, күзләрен чекерәйтеп, бер Әбелмәлихкә, бер шәхеснамәгә текәлде. Гүя, аның каршында чикне бозып, мәмләкәтебезгә үтеп кергән килмешәк басып тора иде.

Ә документлар тәртиптә. Шуңа күрә милиционер кагыйдә нигезендә:

— Хәерле көн, иптәш депутат, рәхим итегез,— дип кулын чигәсенә терәргә мәҗбүр булды.

Җыештыручы бу сүзләрне ишетүгә милиционер артына посты. Аларның икесенең дә депутатка охшамаган депутатны беренче күрүләре иде.

Чит кешеләр генә түгел, ул үзе дә ят вазифага күнегә алмыйча йөдәде. Ләкин аңа озын-озак мыңгырап йөрергә ирек бирмәделәр, әле берсе, әле икенчесе кодалады.

Беркөнне шулай өердән аерылып бер читтә басып тора иде. Янына башына түбәтәй кигән ыспай гәүдәле кеше килеп туктады.

— Җыен эшсез,— диде ул уены-чыны белән, әрле-бирле йөрүче тук депутатларга ымлап,— авылга җибәреп бер-ике атна җигәсе иде үзләрен, ә?

Әбелмәлих көлеп җибәрде. Чөнки ул үзе дә нәкъ шушы хакта уйланып тора иде.

— Милләттәш, мин сине күптәннән күзәтәм,— дип дәвам итте сүзен яңа танышы,— бик битараф тотасың үзеңне, сайлаучыларың гафу итмәс бит мондый фигыльләреңне. Әйдә, берләшик, монда милләт турында кайгыртучы юк дәрәҗәсендә. Күбесе начальник, үз урыннары өчен куркалар. Баштагылар ни әйтсә, шуны үтиләр, халык турында уйламыйлар.

— Мин андый уен-муеннарда катнашмыйм шул, кордаш,— диде Әбелмәлих,— без гади халык, авылдан...

— Вәйт-вәйт,— дип күтәреп алды аны әңгәмәдәше,— менә шунысы бәһале дә инде аның. Бик яхшы булыр иде бу, милләттәш!

Әбелмәлих юк йомышын бар итеп тиз генә туалетка кереп шылды. Сүз өзелде. Шулай да әлеге депутатны күз уңыннан төшермәде. Камил атлы ул. Сәер кеше. Үзе утырыш саен берничә мәртәбә микрофонга ыргыла, үзе нәкъ чираты җиткәч, галстугын рәтләп вакытын уздыра. Шуңа күрә көләләр. Сүзен һич тә үткәрә алмый, бәгырь. Югыйсә, тәкъдимнәре халык мәнфәгатьләренә туры да килә кебек. Әйтик, сессияне чиратлаштырып рус һәм татар телләрендә алып баруның нинди зыяны булыр иде икән? Үзебезнең Татарстаныбызда яшибез ләбаса. Ләкин бәхәс, сүз көрәштерүләр нәтиҗә бирмәде. Татар үз телен үзе буа.

Кичен бу хакта күршесенең дә кылын тартып карады Әбелмәлих. Сөйләшеп, сыйланып утырганда татарлык мәсьәләсендә хәтта Камилне дә уздырып җибәрә монысы. Татар гомере буе кысылып, изелеп яшәде, иреккә чыгарга бик вакыт, ди. Ә үзе гамәлгә килеп җиткәч, нәкъ киресен эшли. Шуның сәбәбен сораган иде, кызыпмы-кызды.

— Яшең кырыкка җитсә дә, сәясәттә бала гына әле син,— диде,— минем менә кешечә яшисем килә, үсәсем килә. Әгәр мин хөкүмәт арбасының тәгәрмәченә таяк тыгып утырсам, Үтәгәнев кебек тире җыярга гына китәсе калачак бит.

Камил бер атнадан соң тагын шул телләр мәсьәләсен өстерәп чыгарды. Тәкъдимемне исемләп тавышка куегыз, нәтиҗәсен матбугатта игълан итү шарты белән, диде. Исемлектән шөлләделәр, ахры, тәкъдимнең бу өлеше шактый яклау тапты. Тавышка куеп карарга булдылар. Бүлмә күршесе бу утырышта катнашмады. Теркәлгәннән соң үзе кебек берничә башлык белән каядыр шылдылар болар, минем өчен дә тавыш бир, дип колагын киртләп китте ул. Ничек дигәч, башлыкка күз төшер, ничек иканен үзең күрерсең, диде.

Чыннан да, мәсьәләне тавышка кую вакыты җиткәч, башлык та бәхәскә кушылды. Микрофоннан аның йомшак тавышы яңгырады. Мәсьәлә бик мөһим, диде, аны өстән-өстән генә карау килешмәс, ныклап әзерләү зарур, диде.

Башлык шулай ара-тирә сүзгә кушыла, аңлатма бирә, ачыклык кертә, фикерен җиткерә иде. Аның сүзләреннән соң Әбелмәлих ничектер тынычланып китә, ышанычы арта. Димәк ки, башлыгыбыз уйлана, яхшы булсынга омтыла. Камил исә моңа каршы, фикерегезне башкаларга көчләп тагасыз, дип бәйләнә. Әбелмәлихкә аның сүзләре дә якын. Ул да тырыша, ләкин аның татарлыгы күпләрнең тешенә сылана булса кирәк, өнәмиләр.

Камил ничек кенә көчәнмәсен, тәкъдим барыбер көн тәртибенә кертелмәде. Барысы өч тавыш җыйды. Шуның икесе — Әбелмәлихнеке. Чөнки күршесенең төймәсен дә үзенекенә кушкан иде.

— Син, абзый, нәрсә маташтырдың анда, дип бәйләнде соңыннан тегесе.

Әбелмәлих белмәмешкә салышты. Иелгән башны кылыч кисмәс, дип уйлады.

— Нәрсә булды, артыңны черки тешләдеме әллә? — дип хәтта сүзне уенга да бормакчы итте. Тегесе аның бу кыланмышыннан бөтенләй дөрләп кабынды.

— Мине җүләргә санама, җәме, синең кебек астан уеп, өстән ямаучыларны күп күргән, тик кара аны, абзый, ут белән шаярасың.

— Аңлатыбрак сөйләле, энем!

— Абзый чакыртып пешерде анда, үз даирәмдә оппозициягә ирек бирмәячәкмен, ди. Әйтеп буламыни аңа, мин түгел, күчән баш Сәгыйдуллин икенче төймәгә баскан, дип.

Әбелмәлихнең иреннәре сизелер-сизелмәс кенә дерелдәп алды. Ни өчендер ул үзеннән-үзе риза иде бу мизгелдә, гүя, ниндидер батырлык эшләгән. Һәм аның бу турыда Камилгә дә сөйлисе килеп китте.

— Син соң,— диде ул кәефе килеп,— Президиумга карап утыр, барысы да аңлашылыр дип кисәттең бит. Мин аннан күземне алмадым. Башлыгыбыз да мәсьәлә бик мөһим дигәч, якларга кирәк икән, дип уйладым.

— Актыгына кадәр тыңларга иде, мәсьәлә әлегә өлгереп җитмәгән дип тә кисәткән ич, Алла колы!

Шушы хәлдән соң күршесе аны ташлап икенче бүлмәгә күчте. Әберничә көннән Әбелмәлихне Сафинга чакырдылар.

Күптәнге дуслар кебек колач җәеп каршылады Сафин. Авызы ерык, әйтерсең лә, улына Әбелмәлихнең кызын ярәшергә җыена.

— Зурайдыгыз, Әбелмәлих Шамилович, депутат булгач, борыныгызны чөйгә элдегез, кермисез, хәл белешмисез, без бит дошманнар түгел, хәтерлисезме?— дип сайрый башлады.

— Хәтерләмичә соң, иптәш Сафин, сез мине тракторлы иттегез, әле дә гөлләр кебек эшли.

Түрә Әбелмәлихне җитәкләп ял бүлмәсенә алып керде. Анда җиңелчә табын әзерләнгән иде.

— Ата-бабаларыбыз дуслашу өчен бер пот тоз ашарга кушканнар, безнең зур тизлекләр чорында аны бер шешә коньяк та алыштыра,— дип сөйләнә-сөйләнә, киң төпле рюмкаларга эчемлек агызды.

Шул арада бер мәзәк тә сөйләп алды.

— Минем кода бар,— диде,— табиб кеше. Үзе болай әйбәт кенә, тел тидермәле түгел. Тик кунакка килгәч, ни ашатырга белми аптырыйбыз. Беренче очрашуда хатын туалетка кереп яшьләрен бушатып та чыкты хәтта. Үземнең дә ачу купты, их, мәйтәм, тегеләй-болай, сине хөрмәтләп табын түренә утыртканнар, ә син монда ризыктан гаеп табып утырасың. Алдына ысланган колбасаны төртеп куйдым моның, ул чакта дефицит иде. Борынын гына җыерды, канцероген, ди, үт куыгына ярамый, ди. Мәйтәм, алайса атланган майдан авыз итегез, авылдан махсус сезнең өчен китерттем, дим. Янә отказ. Атлан майда холестерин күп, ди, инфаркт аласым килми, ди. Мин дә кызып киттем, бирешәсе килми, каһәр. Менә, мәйтәм, гөмбә, холестеринны куып чыгарачак. Аллам сакласын, ди, гастро-энтероколит!

Хатын варенье белән чәй төртә, кода бит, сыйлыйсы килә, әлбәттә. Тегенең йөзеннән төсе үк качты, диабет, ди, кирәкми, ди. Сез дә минем кода кебек түгелдер бит, Әбелмәлих Шамилович!

— Бу профессорлар чире,— диде Әбелмәлих,— без наданнарга кагылмый.

Сафин үз сүзләреннән кәефе килеп, рәхәтләнеп көлде дә шигырь сөйли башлады:

Ассалар да киссәләр дә,
Үлмәдең син калдың тере.
Чукындырган чагында да
Чукынмадың татар теле!

Әбелмәлих күлен танымаган бака хәлендә иде, бу минутта ул үзен арыш бетеннән дә кечкенә итеп тоя иде. Шушы печтик кенә вакыт эчендә ниләр генә иштмәде дә, ниләр генә белмәде, академияләрең бер якта торсын, валлаһи! Ну, баш та бар икән үзеңдә!

— Шәп бит, Әбелмәлих Шамилович, ә?— диде Сафин.

— Шәп булмыйча,— диде Әбелмәлих, ниһаять, телгә килеп.— Моны парламентта сөйлисе иде.

— Ни файда,— дип кулына рюмкасын алды түрә,— сүз боткасы ясап, көн тәртибен раслый алмыйча ярты көнегез үтә.

— Әйе шул, үземнең дә эчем поша...

Сафин сәгатенә карап алды да әйтте:

— Әйттем исә кайттым, парламент эшенә тыгыла диярсез. Ә мин сезне бик мөһим мәсьәлә буенча чакырган идем. Без республикада фермерлар ассоциациясе төзәргә уйлыйбыз. Шул мәсьәлә буенча киңәшергә иде. Хәзер үк димим, уйланыгыз әле, зинһар!

— Була ул, иптәш Сафин!

— Җә инде, Әбелмәлих Шамилович, нигә инде ул андый рәсмилек, без бит дуслар. Киңәш дигәннән, сез ул экстремистлардан сак булыгыз, төпсез арбага утыртулары бар.

Сафин аны Тукай шигырен укып озатып калды:

> Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата;
> Моңланып, хәсрәтләнеп, ялкау гына ак ай бата...

* * *

Әбелмәлих бу сәер әңгәмә турында төне буе уйланып ятты. Уйлана торгач, ниһаять, төбенә дә төшенде: түрәбез мәгълүм әкияттәгечә, тимерчедә телен таптаткан икән ләбаса! Шуңа күрә теле еланны да өненнән чыгарырдай булып татланган. Янәсе, күрегез ул нинди гади, нинди мәгърифәтле. Сусыз юар, җилсез киптерер мәгәр. Шул рәвешле үз тегермененә су койдыртмакчы. Юк, агай-эне, без дә төшеп калганнардан түгел, тәкәнең артыннан, атның алдыннан, ә синең кебек адәмнәрнең һәр ягыннан да әйләнеп үтәргә кирәклеген бик яхшы беләбез.

...Камил икенче көнне дә сессияне чиратлаштырып ике дәүләт телендә: татар һәм рус телләрендә алып бару турындагы тәкъдимен төртеп карады. Үзеннән кала бер генә депутат аны яклап тавыш бирде. Ул Әбелмәлих иде.

## Унберенче баб

Көзге көннең көлүе, көлүе дә елавы. Яңгыры да иште, кары да кимен куймады. Бүген — кар, иртәгә яңгыр, ахыры барыбер — су. Чокыр-чакырларда гына түгел, тип-тигез урыннарда да күлдәвекләр җәйрәп ята башлаган иде инде. Резин итексез ишек алдына да чыгармын димә. Бигрәк тә мал-туар интекте. Дымлы суык сөякләргә кадәр үтеп керә бит ул. Шуңа күрә ашауны да умыралар, житкер генә. Кышлык азык бетә бит инде, кайчан утырыр бу көне, дип зарланды авыл халкы.

Тик никадәр генә озакка сузылмасын, һәрнәрсәнең чиге була. Кемдер, ниһаять, күкнең бирән тишеген борчак саламы белән томалап куйды. Көннәрдән бер көнне йокыдан уянсалар, шаккаттылар. Тирә-як тоташ көзгегә әверелгән. Куанды да соң бала-чага! Атналар буе өйдә сөрсеп яту ялыктырган иде үзләрен, барысы да урамга сибелде. Кәнкие бары кәнкиен таккан, чаналысы чанасын өстерәгән. Малайларның кулында кәшәкә. Чыр-чу киләләр. Үзе бер күңелле манзара.

Шуннан соң табигать яшен агызмады. Хәер, кояшның куянга атланган чагы житкән иде шул инде. Тагын берничә көннән кар яуды, чана юлы төште. Дөрес, кары әлегә мул түгел. Шулай да оеш-оеш катканаклар, кантарлар сөңге шикелле тырпаеп тормый инде, араларына кар кереп тулган.

Күк йөзе чалт аяз. Салкынча һава тирә-якны сафландырып, пакьландырып җибәргән. Урманнар, телефон баганалары, таулар ничектер якынаеп киткәндәй булганнар, кулыңны сузсаң, кул җитәр сыман.

Чанасына кырын яткан юлчы да шушы манзара белән хозурланып бара иде булса кирәк. Күңелендәге моңы әле җыр булып бәреп чыга, әле сызгыруга әйләнә. Аты да шул салмак көйгә җайлап кына атлый. Көр гәүдәле ат. Шәт, юыртып та китәр иде, хуҗасы дилбегәне кысып тоткан. Күрәсең, ашыкмый.

Бәхетле адәм! Өермәдәй бөтерелүче бүгенге зилзиләле тормышта да шундый тыныч, шигъри җанлы кеше бар икән әле. Бәлки ул, чыннан да, шагыйрьдер, иҗатына илһам эзләп йөри-йөри шушы самими гүзәллеккә тап булгандыр? Әллә бөтенләй гамьсез бер затмы? Андыйларга ике чабата бер кием. Хыял, хис тән хаҗәте генә, алар аның җанына кагылмый, уйларын басмый. Ихтимал, рухи омтылышлар бер тиенгә тормаган бу заманда барысы да ихтимал.

Юлаучы чана башыннан шешәсен суырып чыгарды да борыныннан гына бер-ике мәртәбә йотып куйды, кикереп җибәрде. Һәм янында бер фәрештә дә калмады, барысы да качты. Юк, шагыйрь түгел икән. Шагыйрь борыныннан гына кабып хәмер эчәргә мөмкин, чөнки ул романтик, аның һәр гамәле үзгә, табигать шулай яраткан. Ләкин шагыйрь бервакытта да болай ямьсез итеп кикермәс.

Район үзәге ягыннан тагын бер юлчы пәйда булды. Монысы машинада. Машинасы шәп, ахрысы, дымык су өстендәге көймә шикелле орылмыйча-сугылмыйча гына элдертә. Шофер янында эшләпә кигән бер кеше утыра. Фырт түрә, димәк ки, авыл әнә беренче кыраудан ук бүреккә күчте. Алай дисәң, нигә ул йомшак кәнәфигә чумып утырмаган, куып төшермәсәләр ярар иде дигәндәй, кырыена гына чүмәшкән. Ә эшләпә? Җә, кем эшләпәне шулай кия инде, хохол егетләренекедәй бер учма чәче маңгаена чыгып тора.

Ат ичмасам дәрәҗәсен белә икән, нинди ялтыравык машинага да юл сапмады бит, юл уртасыннан баруы бару.

— Кешесе юк, ахры,— диде Эшләпә,— төшеп карыйк әле, бер-бер хәл булмагае.

— Борчылмагыз,— диде шофер,— аты иясенә охшаган.

— Кем соң ул?

— Кем булсын, районда бер генә ул, Үтәгәнев!

— Үтәгәнев?

— Машинаңны туктат,— диде Эшләпә, хәлбуки машина болай да туктап тора иде инде.

— Үтәгән!— дип кычкырды ул машинадан төшә-төшә,— синме бу?

Чанадагы калын түшкә селкенгәндәй итте. Аннан соң ул түшкәдән баш калыкты. Исерек дип булмый иде аны. Кызмача да түгел хәттә. Аракыны күтәрә ала Үтәгәнев.

— Ә-ә, депутат,— диде ул артык исе китмичә генә,— нинди җилләр ташлады бу якларга?

— Иске авыздан яңа сүз, авылга кайтып барышым.

— Сине Казанга күченгән дип ишеткән идем.

Әбелмәлих аңа сынаулы карашын текәде. Ул Үтәгәневтән төшенкелек, битарафлык сыйфатларына ишарә итүче билгеләр эзләде. Тапмады. Килеш-килбәт элеккечә мәһабәт иде. Шундый ук тәкәббер йөз, калын иреннәр, итләч борын, җәелеп киткән ияк. Ләкин ниндидер үзгәреш бар иде. Нинди үзгәреш бу — абайлый алмады.

— Хатын риза булмады, күчә идем мәгәр,— дип көлгәндәй итте Әбелмәлих.

— Җүләр, Тулага үз самаурың белән баралармыни?

— Ужымга керергә рөхсәт сорамыйбыз анысы, Үтәгән. Ә парламентта даими эшләү өчен баш кирәк. Минекенә нишләптер сүс тутырганнар. Сөйлиләр, бәхәсләшәләр, малай, мин һичнәрсә аңламыйм. Тыры-

шып та карыйм үзе, юк, бер колактан керә, икенчесеннән чыгып китә. Күңелдә һаман шул бер балык башы: капка төбен себерделәрме икән, мал-туарны карыйлармы, атны вакытында эчерәләрме... Хәлләр шулай, Үтәгән. Дәрәҗәсе бар анысы, күреп торасың, машина белән озаталар, китереп куялар. Төшкә дә кергән нәрсә түгел иде.

— Аның урынына, фермер!

— Һәй,— дип кулын селтәде Әбелмәлих,— исеме генә инде аның, бөтен республикага бер үзем диярлек калдым бугай инде. Депутат булгач, колхоз минем эшне дә үзенеке белән рәттән эшләттерә. Депутатлар ике сүзнең берендә: «җир, җир»,— дип өзгәләнгән булалар. Ә авылда җиргә ябышырга теләүче юк. Авыл кешесе ата ялкауга әйләнде хәзер. Теге вакытта колхозны тараттык дип күкрәк киереп йөргән малайларның да кикриге шиңде, кире колхозга кайтып беттеләр. Муса булып Муса тынды. Җил-давылның вакыты кыска шул аның.

— Мин болардан гарык, депутат, сөйләмә син аларны миңа,— диде Үтәгәнев.— Булмаса, күрешү хөрмәтенә тамак чылатып алыйк.

— Шофер бар бит, яхшы түгел.

— Җибәр син аны, үзем илтеп куярмын.

Әбелмәлих та буш кул белән түгел иде. Дөресен генә әйткәндә, Үтәгәнев аны шушы дәрәҗәгә күтәрде ләбаса! Фермер итте, трактор бирдерде. Суган сатып шактый тернәкләнеп калды теге вакытта. Ул болай да Үтәгәневне сыйламакчы булып йөри иде. Менә җае туры килде бит.

Биш-алты минут чамасы, хәмер парлары канга кучкән арада алар тавышсыз-тынсыз гына капкалап алдылар. Аннан соң телләр үзеннән-үзе ачылды. Инде күңелләре җыр ноктасына ук килеп җитте. Әбелмәлих үзенең яраткан җырын башлады:

Тала, тала, тала, тала,
Тала ике беләгем...

Үтәгәнев эскерт почмагын чылатып тора иде, кычкырды:

— Минем алда такмак такмаклама, җырны аны, менә болаерак җырлыйлар.

Кара да гынай урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк лә үтәргә...

Әбелмәлих җырны башыннан эшләпәсен салып тыңлады. Үтәгәневнең тавышы шушы мәһабәт җыр кебек үк йомшак, сагышлы, озын вә аһәңле иде. Ул күңелнең иң аулак яткылыкларына кадәр үтеп керә, инде күптән суынган хатирәләрне яңарта, тәүге мәхәббәтенең ярасына тия, өзгәләнә, тарткалана.

Үзгәреш дигәне шушы моң, сагыш иде.

Әбелмәлих йөгереп барып Үтәгәневнең кулларын кысты.

— Тире җыеп йөрергәме соң сиңа, дустым, сәхнәләргә чыксаң, алкышларга күмәчәкләр бит!

Чәркәдәшенең бу сүзләре Үтәгәневкә дә тәэсир итте, зур, авыр җилкәләре калтыранырга тотынды. Ул елый иде. Аңа карап Әбелмәлихнең дә күзләреннән яшьләре сытылып чыкты.

Кочаклашкан килеш алар шактый ара елаштылар. Ихтимал, бу хәл озаккарак та сузылган булыр иде, Үтәгәневнең шөгыле бетмәгән булган икән әле, шөлдериен салкын чеметеп алды.

— Туктале, чалбарны күтәрим,— дип пышылдады ул.

Үтәгәневкә теге вакытта әйбәт кенә эшләр дә тәкъдим итеп карадылар. Нефтебаза директорлыгына ризалашкан да иде, әнкәсе каршы төште. Улым, сиңа анда барыбер көн күрсәтмәячәкләр, иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас, дигән борынгылар. Әткәң кебек тире

жыярга керсәң, кулайрак булмасмы? Бик төшемле эш. Уйлап кара әле, диде.

Үтәгәнев әнкәсенең сүзенә колак салырга булды.

Моңа райондагылар гына түгел, казанлылар да хәйран калды. Үгетләп тә карадылар. Сафин үзе шалтыратты, үзең гаепле, сайлауларны оештыра алмадың, инде безне мыскыл итеп җүләр сатма, диде. Оппозиция болай да эт кебек ябышырга гына тора, синең тартәгә тибеп маташуың алар тегермәненә су агызу ул, җирле органнар белән очраклы кешеләр идарә итә, диячәкләр, кадрларны сайлый белмисез, диячәкләр. Ленин вакытлары үтте, без кухаркаларны идарә даирәсенә кертә алмыйбыз.

Үтәгәнев тискәре кеше иде, үз дигәненнән кайтмады.

— Үтәгән, хәтердән дә чыгып тора, сиңа әманәт бар бит әле,— диде Әбелмәлих.

— Әллә мине дә хәтерләүче бармы?

— Ничек кенә әле, кем дип сора син.

— Кем?

— Бер бик чибәр корреспондент хатын. Менә сиңа бер төенчек тә биреп җибәрде. Кара, истән дә чыгып тора...

— Тукта, тукта! Сал әле берне тутырып, җә йөрәк ярылыр, тизрәк бул, көттермә!

Әбелмәлих аның гозерен үтәде.

— Менә хәзер сөйлә инде, бөртекләп сөйлә, кем, нәрсә, кайда күрдең?

— Бөртекләп дип, аның әллә нәрсәсе юк инде. Сессиядә үзе эзләп тапты, сез шул-шул кешеме, диде. Әйе, дидем, мин шундый-шундый кеше, дидем. Алайса сез Үтәгәневне беләсез инде, диде. Әйе, дидем, Үтәгәневне беләм, дидем, якташым, дидем.

— Дидем, дидем, ниемә дилбегә буена сузасың, сөйлә әле җүнләбрәк.

— Үзең бөртекләп сөйлә дисең бит.

— Минем турындагысын дидем мин, колак! Тагын нәрсәләр сораштырды, сәлам әйттеме, барып чыгам димәдеме?

— Юк, шушы пакетны гына бирергә кушты.

— Ул пленканың бушка да кирәге юк хәзер, шуңа биреп җибәргән ул аны, фахишә! Күчермәсен алгандыр, дип теге вакытта да шикләнгән идем аны. Күңелем белеп өзгәләнгән икән. Күпне күргән нәмәстә, кибәккә генә алдана торганнардан түгел. Мәгәр үткен хатын! Ә мин, җүләр, кассетаны яндырдым дип йөрдем. Саумакчы булган димәк ки... Нинди тәмле хатын иде. Син аның тәннәрен күрсәң... Шул ләззәтләрдән син мәхрүм иттең мине, син! Ишетәсеңме, колак! Шуның өчен мин синнән дөя муены ясыйм...

Үтәгәнев көчле куллары белән Әбелмәлихның изүеннән эләктереп алды да, аны үзенә таба тартып, исән колагына атныкы кебек эре тешләрен батырды...

*6/VII-95.*





## Рөстәм Мингалим

### ҖИЗЛЕ ЙӨГӘН, ҖИРӘН АТЫҢ...

#### Гаярь татар

...Бик күптән,
һай, күптән
безнең татарны
карап торды,
барлап торды Мәскәү.
Сынап торды,
санлап торды Мәскәү.
Булдыклы бит,
җай бит ул татар!
Һай, аның түрәсе,
татарның түрәсе,
әз генә елмаеп,
бер генә үбәсе,—
май бит ул татар!
Сәйяр татар,
гаярь татар!
Онытма, Мәскәү,
татар барын:
— Һәрчак әзер! —
татарларың.
Син:
— «Сыйлыйм!» — дисәң,
кунак булып барачак.
— «Җигәм!» — дисәң,
ул ат булып барачак.
Мылтык бирсәң —
солдат булып барачак.
Син дигәндә, Мәскәү!
Синең өчен, Мәскәү!
Әйтсәң татарга —
кушсаң татарга

энә
    белән
        кое
            чокырга:
— Чукынышлар китим,
булдырам бу эшне! —
дип әйтер дә татар...
Һәм чукынып да.

## Әй, шаян тормыш...

*(Сәяси үзгәрешләр уңаеннан)*

...Сәясәтләрен сатыйм,
аны күп ишеттек.
Искесен ишеттек,
        тыңладык яңасын,
авызларын гына
этләр яласын!
...Килеп җиттек.
Шушында,
гомер ахырында,
калдым төнге юлда.
Дөм-караңгы монда.

Халык кайнаша,
әллә кемнәр
        кыймылдый
            янымда:
Өметен һаман өзмәүчеләр,
Бәхетен эзләүчеләр,
өметсезләр,
алдакчылар,
эчкечеләр,
караклар,
үтерүчеләр,
үлүчеләр...
...Мин урлый алмам,
үтерә алмам.
Качкын бәхетемне
язып табалмам —
дөм-караңгы монда!

Нишлибез, халык?
Юлдашлар?!
Эчкечеләр?!
Караклар?!
Безгә кай тарафка?!
Кай якка узабыз,
бәгырькәйләрем,
үтерүчеләр, үлүчеләр?!

Әй, шаян тормыш,
якамнан
        кулыңны ал әле,
буасың бит, җибәр.
            Җибәр!..

## Алдагы сайлаулардан соң...

Сайлау узды,
туннар тузды, дисәң инде син.
Шулай ул, энем Габдулла,
сайлау дигән мәсьәләнең —
ике ягы була.
Сайлаучылар — сайладылармы?
Сайладылар!
Сайланучылар — сайрадылармы?
Сайрадылар!
Эшлиләр, нәтиҗәсе дә бар —
татар хәлен
шактый җайладылар.
Кибетләргә тулды
затлы туннар.
Тик затлы тун әлегә кемнәргә?
Сайланучыларга
һәм аларга җайланучыларга.
Урамнарны чыелдатып чапкан
затлы машиналар кемнәрнеке?
Сайланучыларныкы
һәм аларга җайланучыларныкы.
Ишегеннән чыккан исе —
сине исертеп егарлык
затлы ресторанnap,
Чәчәк кебек чәчелгән
яңа өйләр,
якын һәм ерак илләрдәге
виллалар,
дыңгычлап доллар тутырылган
сейфлардан ачкычлар,
күкрәк киереп күккә менгән
очкычлар — кемнәрнеке?
Сайланучыларныкы
һәм аларга җайланучыларныкы.
Кыскасы, санаганнарым —
мәсьәләнең беренче ягы.
Аның икенче:
безнең тунга кагылышлы ягы —
сайлаучыларга кәҗә тоягы!
Алдагы сайлаулардан соң,
имеш, кәҗәсе дә була.
...Ни бит,
кәҗәсен нитеп, мин әйтәм,
туннарны ямарбыз,
энем Габдулла.

## Җизле йөгән, җирән атың...

Җизле йөгән, җирән атың,
үз татарың — авылда.
Инде алар синнән ерак,
син калада, син монда.
...Әллә татар каласы бу,
әллә урыс каласы? —

Казан тирән, Казан зур ул,
барасы да барасы...
Очрый калсаң бер татарга,
алдан укы иманың.
Йә Иванга тарса юлың —
иманы юк Иванның.
...Бу хәлеңнән сине Алла
коткарыр да шикелле.
Ул коткарыр шикелле дә,
котылуың — икеле.
Уйлыйсың гел яз качарга,
җәең тота, кышта — соң.
Әле кая хәтлерәк тә
ни рәвешле качасың? —
Юк машинаң,
булмас атың,
аның арба-чанасы:
калдың менә Казаннарда,
ах, анаңның баласы!
Җизле йөгән, җирән атың
булса бүген кулыңда —
Минем сыман
шигырь язып
йөрмәс идең син монда.

## УЙНАБРАК УЙЛАНУ

### I

### Өйләнеп йөргән чакны искә алу

Нинди икән сездә кызлар,
бездә шундый кызлар бар!
Үбешергә иренең бирсәң —
суырып
башыңны йотар...
Шуңа талдай бер билкәйгә
салдым бары кул гына:
— Йотар, йотар,—
дип, шикләндем
һәм...
нәкъ шулай булды да.

### II

### Өйләнгәч тә матур яшәлгән

Ике күкрәк —
килә күкрәп,
изү ачам
яшенәнә:
шактый кыска
буем белән,
шактый озын

яшем белән,
изү ачам
яшененә.

Яшеннәрдә,
күкрәүләрдә—
шомланып та
калыр кеше.
Шомланмыйк ла,
шайтан йоклый,
безнең тормыш—
шайтан төше.

Шайтан төше—
безнең Дөнья:
әмма яшәү—
барыбер рәхәт.
Рәхмәт инде
әткәемә,
мине тапкан
әнкәемә!
Яшен тотып
яшәгәнгә—
үземә дә
бик зур рәхмәт!

III

## Шөкер, бүген дә без бергә

Минем дуслар әйбәт кенә түгел,
әйбәтләрдән әйбәт ир-атлар.
...Ресторанга дисәм?
Ни бит әле,
өйгә чакырырга исәп бар.
Чакырырга кирәк үзләрен бер,
килгәч күңел шундый карарга.
Шәрә туташ кебек шәрә бүлмәм
бик ошарга тиеш аларга...

Чакырырга кирәк үзләрен бер,
зур байлыгым—кызым, алтыным.
...Аннан
һәр дусымның хатынынан
матуррак бит минем хатыным.

Чакырырга кирәк үзләрен бер,
берәр ярты алып һәр дуска.
Шәп закуска алам,
әгәр бер дус—
акча биреп торса бурычка?!



# КАЕННАР ЯКТЫСЫНДА

Азнакайның каен урманнарында булганыгыз бармы Сезнең? Булырга туры килмәсә, мондый мөмкинлекне кулыгыздан ычкындырмаска тырышыгыз! Чөнки, Такташ әйтмешли, «Бер җирдә юк андый ак каеннар»... Шушы сүзләрнең асыл мәгънәсенә төшенергә тырышып, шушы табигать ясаган картинаның сурәтен күзалларга омтылып хәтер төенчекләрендә актарына башлыйм да Азнакай каеннары арасына кереп югалам.

Менә минем алда тоташ каенлык урманы. Үләннәре хәтфәдәй ямь-яшел, куак-чытырманлык та, ауган-корыган агачлар да юк анда, яшь-төз, шәмдәй зифа, озын буйлы, ап-пакъ тәнле каеннар, каеннар гына тезелеп киткән. Ул каеннарның кәүсәләрендә ник бер җыерчык, ботак-санак күренсен, бары унган авыл карты бәйләгән себерке хәтле генә җыйнак-пөхтә ябалдашлары күк гөмбәзен терәп, күтәреп тора сыман.

Табигать белгечләре, Татарстанда 200 дән артык төрдәге каен агачы үсә, диләр. Әмма мондый каеннарны Азнакай урманнарында гына очратырга мөмкиндер, мөгаен.

Марсель Галиев, Илдус Гыйләҗев һәм Нур Әхмәдиевләр әнә шундый якты, сәгадәтле «урманнан чыккан» шагыйрьләр.

Һәр иҗат кешесенең «визит карточкасы»на тиң, аның җанын ачып бирердәй әсәрләре була. Нур Әхмәдиев диденме, җырдагы гади генә, җанга якын моңы белән бергә үрелеп, түбәндәге юллар хәтергә килә:

Каенкайлар, күңелемне  
Һәрвакыт аңладыгыз;  
Нигә инде бу юлы да  
Җибәрми калмадыгыз!

Нигә җибәрсеннәр, ул бит, әнә, журналыбызда урнаштырылган фотосурәттәге кебек туган ягы каеннарына сарылып үскән шагыйрь, ләбаса. Нәкъ менә «Каенкаем — бәгырькәем» шигырендәге кебек:

Йөгерә-йөгерә каршы чыгалар да,  
Үр җитәрәк туктап калалар.  
Үзебезнең якта каеннарым  
Мине шулай каршы алалар.

Дөрес, заманында Нур Әхмәдиев «башка урманнарда» — узгынчы темалар урманында да адашып йөргәләде. Ләкин соңгы дәвер иҗатында да ул каеннар яктылыгына чыга алды, бу бәладән аны хис һәм фикер шигърияте коткарды. Ул — шигъриятта ил язмышын кайгырта алучы ир-егет булып җитлекте.

Ил язмышы — ир язмышы булган,  
Күңме башка казык кагылган.  
Аятлар гына түгел,  
Тарих үзе  
Ирләр каны белән язылган.

Ә көндәлек тормышта ул яшьтән үк җитди, кеше хәленә керә белүчән эшлекле егет иде. Шушы сыйфат-холкын искә алыштыр, бәлкем, аны Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлекчәсенә җитәкче итеп сайлап куйдылар. Ул әле өлкән язучыларының өйләренә барып, аларның хәл-әхвәлләрен белеп кайта, яки язучылар үзләре аның янына кереп утыралар. Гариф Ахунов, Әдип Маликов, Равил Фәйзуллиннар «эстафетасын» кулыннан төшермичә, ул Әлмәт язучылары мәнфәгатен кайгыртып яшәде. Боларына мин үзем дә шаһит. Мөслимдә яшәгән чорымда еш кына Әлмәт бүлекчәсенә барып чыга идем. Шундый көннәрнең берендә ул, Язучылар берлегендә әгъза булмавына бик тә гаҗәпсенеп: «Ничек була инде ул? Мин бит сине күптән язучы-әгъза дип белә идем. Хәзер машина тәгәрмәчен хутка җибәрәбез аны»,— диде дә җиң сызганып эшкә керешә һәм үзе юллама язып, мин бер ай-ай ярым дигәндә секция утырышында «язучылыкка» тәкъдим ителдем.

Боларны шуңа гына әйтәм: Нур Әхмәдиев — кешелекле кеше. Соңгы вакытта ул чордашы һәм хезмәттәше Фәрит Гыйльмине күз карасыдай саклады... Тик адәм баласын күкрәк кесәсенә салып йөртеп булмый шул: Фәрит дустыбыз вакытыннан алда арабыздан китеп барды. Урыны җәннәттә булсын!

Шулай, кызык бу тормыш: әле кайчан гына безнең буын 50 яшьлек агай-апаларга астан өскә карап йөри иде. Баксаң, үзебез дә шул биеклеккә менеп җиткәнбез икән. Әнә ич, ай саен диярлек кырык алты, кырык җиденчеләрнең юбилейлары үтеп һәм китеп тора. Югыйсә, алар авыл саен бармак белән генә санарлык булсалар да. Ләкин:

Туган еллар безнең — кырык алты.
Сугыш күрмәгәнбез дисәк тә.
Авыл саен без бит ничәү генә,
Тарихта без аерым исәптә.

...Җаваплылык шуңа башкалардан
Күбрәк төшә безгә дөньяда.

Рәсемдә Аккош күлендәге ак каенга сөйкәлеп-кочаклашып бер ир-егет басып тора. Илле яшәр Нур Әхмәдиев гел шушы сурәттә күз алдыма килеп баса. Уйчан һәм моңсу булып.

Наис ГАМБӘР.

# Нур Әхмәдиев

КЫЯР-КЫЙМАС
КОЯШ БАЙЫЙ

## Хәзер

Сабый булуларым көлке хәзер,
Чәнечкеле — мин дә керпе хәзер.
Бугазымнан алып селке хәзер,
Ни дә төшмәс, мин дә — төлке хәзер.

Ягылмакчы дөнья кере хәзер,
Сыланмакчы була дөнья чире хәзер.
Тик сер бирмим, мин дә эре хәзер:
Ким дигәндә тешләк бүре хәзер.

## Татарыма

Бабайлар бит шундый гаярь булган,
Ә без нигә куркак җанлылар?
ИНТЕРДУСЛЫК вәгъдә итә-итә,
Телебезне тартып алдылар.
Без дәшмәдек.

Дуслык бакчасында яшь торгач,
Без, татарлар, шундый хушландык,
Берәүләргә туннар өләшкәндә,
Насыйп булды ертык ыштанлык.
Без дәшмәдек.

Урыс сөйдек, сөйдек марҗасын да,
Аерылмаслык булып бәйләндек.
Дөньялыкка урыс үрчетүче
Иң шәп питомникка әйләндек.
Һәм дәшмәдек.

Күзгә кырып салыр татар калды,
Аларын да тарта тегермән.
Сугыш сайлап алган егетләре
Табут булып кайта тегеннән...
Без дәшмибез.

Бүре ыруының горурлыгы
Ахыргача әллә беткәнме:
Яңакларга суккач, рәхмәт әйтеп
Кәтәбез бит артка типкәнне!
Һәм дәшмибез.

Халык инде аермый да бугай:
Нәрсә кимлек, кайда өстенлек.
Рухыбызның газиз түренә үк
Оялаган ИНТЕРМЕСКЕНЛЕК.
Без дәшмибез.

Авыз пешкәч, артык сак булдыкмы —
Үз-үзебезне һәрчак куркыттык.
И татарым, бөтен җир шарында
Синең төсле бүтән мокыт юк.
Син дәшмисең.

## «Туганлык»

Дус дидек тә туган дидек,
Кайдан килгән туганлык?
Үзебезне алдый-алдый,
Шул ялганга куандык.

«Өлкән туган», «кече туган»,
Тормыш — сәхнә,— кыландык.
«Туган»нардан сөяк артса,
Шуны ялап юандык.

«Туганлык»та уйный торгач,
Баш авыртып уяндык.
Мәскәү дә бар, Казан да бар,
Ә кайда соң туганлык?
Ә кайда соң туганлык?

## Без

*Илдус Гыйлаҗевкә*

Сугыштан соң туган асыл буын,
Без окоптан кайткан яралгы.
Шуңадырмы замандашларымның
Туганчы ук җаны яралы.

Тамырларны пуля өзгәләгән,
Чәрдәкләгән мина ярчыгы,
Яраларны юган чагыбызда
Алсу төскә керә таң чыгы.

Сак булыгыз,
Авыр сүз әйтмәгез,
Күтәрүе авыр нахакны.
Аерылырга вакыт, вакыт инде
Гади таштан затлы ахакны,
Акыллыдан — юләр, ахмакны.

Яраланган җаннар булсак та без,
Асылташлар, энҗе затыннан.
Күрмисезме:
Әнә кыйпылчыгы
Җаныбызның — күккә атылган.

Һәм кабынган якты йолдыз булып,
Азмы, күпме — санап карагыз.
Без үлемсез!
Җирдә туабыз да
Мәңгелеккә күчә барабыз.

## Ышанмыйм

Ташлар телсез.
Әгәр телгә килсә,
Сөйләр иде бары дөресен.
Тарихыңны «өлкән туган» язса,
Ничек итеп ялган эресен?

«Өлкән туган» өчен мескен татар
Гомер буе булды вак халык.
Кабер ташы — чиркәү нигезендә,
Башкайлары — бетте тапталып.

Кем ышана андый золымлыкны
Бүтән безгә ул һич кылмас дип?
Киләчәктә минем кабер ташым
Чиркәүләргә нигез булмас дип?

Мин ышанмыйм.
Бармы ышанучы,
Тынгы табыйм ничек җаныма?
Бик тә, бик тә ышанасы килә,
Тынычлана алмый җан гына.

* * *

Атылдым кояшка,
Канатлар
Көйгәнен сизмәгәнмен,
Тиле мин —
Җанның яртысын
Күкләрдән эзләгәнмен.

Көйгән канатларым белә
Егылдым да катыңа.—
Хәзер без икәү очабыз
Сөюнең канатында.

## Язгы ташу

Шушы чыкмаган җанымның
Яз җитүгә ярсуы! —
Гүя минем бу тәнемдә
Кайнап торган кар суы.

Ашкына ерак диңгезгә,
Белмим, ник адарына?
Ышана микән суларның
Шулай гел агарына?

Читтә кояш җылырактыр,
Бәхет тулырак сыман.
Утырам кичке эңгердә
Күзем алалмый судан.

Ага ташу, ургый сулар,
Сылана ярга кубек.
Узышлый гаярь дулкыннар
Китә хәлемне белеп.

Кыяр-кыймас кояш байый,
Юашлана җилләре...
Кар сулары булып ага
Гомернең мизгелләре.

## Бердәнберем

Уйламаган идем, гомер буе
Булырсың дип болай сагынырлык.
Хисләремне ак кәгазьгә салсам,
Шундый кайнар — дөрләп кабынырлык.

Сөюеңне аклар, раслар өчен
Җитәр микән калган бар гомерем.
Гүзәлләрнең дөнья букетында
Син бит, тик син — минем бердәнберем.

Еллар узар, моңсу картлыгыма
Синең белән, бәгырь, мин килермен.
Үлем алдында да пышылдармын:
— Син, Венерам, минем бердәнберем!
Ышан: бердәнберем...

## Өмет

Сөйли белмәгәннәр акыл сата,
Кемдер дәшми оста көенчә.
Мин әйтәсен ләкин кем дә әйтмәс,
Әйтә икән — әйтмәс минемчә.

Төче булыр яки әче булыр,
Фикеремне бозып сөйләрләр.
Дөнья тулы юләр акыллылар,
Һәм акылы алтын юләрләр.

Мин шуларның, белмим, кайсысыдыр,
Белә калганда да ни кылыйм?
Ялгышларым булса, газиз аллам
Ярлыкамый калмас үз колын.

*Әлмәт.*



**Зәки Зәйнуллин**

# АТ КАРАКЛАРЫ

РОМАН

Кырык сигезенче ел яңгырлы килде. Игеннең байтагы яланнарда, колхоз токларында явып әрәм-шәрәм булып бетте. Хезмәт көненә дигән иген җәй көне ашаганны түләргә дә җитмәде. Бер хезмәт көненә 253 грамм иген бирделәр. Сугыштан эшкә зарыгып, колхозны торгызабыз дип кайткан ирләр, шул елны колхоз эшенә салкын карый башлап, урлашуга күчтеләр. Байтагы, чит-ят калаларда яшәгән, бергә сугышып йөргән дусларын хат аша юллап табып, авыллардан китә башлады. Колхозларның эчтән таркала башлавы шул 1948—50 елларга туры килә.

Читкә китү турында уй Хәйдәрнең башына да кермәде. Чөнки, әтисе үлгәннән соң, үзеннән бәләкәй өч энесен карап үстерүне ул үзенең төп бурычы итеп саный. Өлкәнрәк апасы, әтисе исән чакта ук, кырык алтынчы елны укытучылар әзерли торган институтка укырга барып керде. Аларның апасына кадәр әле бер генә кешенең дә андый укуга әләгә алганы юк иде. Апалары укуга кердо керүен. Авылда аның даны да зур булды булуын. Тик әтиләре сугыштан кайтып үз үлеме белән дөнья куйгач, фронтта ятып калган әтиләрнеке кебек апаларына да, малайларга да «файдасы» тимәде. Ире кайту белән Чолык Зәйнәбе барлык налогларны китереп салды аларга. Артыннан әллә кайларга йөри-йөри китерелгән налогларның тик яртылашын гына киметә алдылар. Әтисе исән чакта укырга китте кызлары Фәридә. Киткән чакта:

— Анда аена йөз дә илле сум стипендия бирәләр. Шул җитәчәк миңа, сездән ярдәм кирәк булмаячак,— диде.

Сугыш бетеп, халыкны җиңүче халык дип гәҗит-радиолардан бертуктаусыз мактауга дучар итсәләр дә, авылларда бөтенләй аңлашылмаган хәлләр өстенлек итте. Налоглар, заемнар белән сытылып изелгән авыллар ничек кенә булса да тамак туйдырып, атасыз калган балаларны укытып, «кеше итеп», колхоз эшеннән котылу юлларын эзләделәр. Тик... матур сүзләрдән торган тормыш көчле, мәкерле, котылгысыз иде.

---

Ахыры. Башы 11 нче санда.

Кырык алтынчы елның коры җәендә авыл урамында булган бер вакыйга бик күпләрне тетрәндерде. Камиләнең улы Зөфәрнең йөрәгенә бетмәс җәрәхәт уелып калды ул көнне.

Базар көн, өйлә вакытлары иде. Яздан бирле чат аяз торган күк йөзеннән бер генә тамчы да яңгыр тамганы юк. Кешеләр күңелендә кара шом туган көннәр. Ялан-кырларда кашык буйлы гына, чикерткә башлы игеннәр күккә ялвара-ялвара яңгыр көтеп, тилмереп утыралар. Юл буйларында канатларын салындырып, авызларын ачкан каргалар шәйләнә. Аларның очып китәргә дә хәлләре юк. Юк азыкны эзләп көннәрен уздыралар. Сыер-сарыкларның авыз-борыннары яланнан чучканыкы кебек булып кайта. Үлән юклыктан, алар аның тамырын кимерәләр.

Урам буйлап килгән Зөфәр яңа гына туктаган олауга игътибар итте. Кечкенә, дүрт тәгәрмәчле арбага, бәләкәй генә гәүдәле кызыллы-аклы ала сыер дугалап җигелгән. Камыт-ыңгырчаклары да, хәтта каты юкәдән өчләп үргән эшлиясе дә бар. Тик аларына исе китмәде Зөфәрнең. Ә сыерны җиккән олаучыга карап катты да куйды. Ап-ак сакал-мыеклы, чалбары өстеннән чыгарып кигән, ямаулы ак күлмәкле, салам эшләпәле, буй-буй ыштанлы, тула оеклы, чабаталы карт кына бабай иде олаучы кеше. Тик ак сакал-мыеклы булса да, бабайның гәүдәсе төз, күкрәксыннары җегәрле күренә, йөзе күркәм иде. Зөфәр аны күрүгә танып та алды. Чөнки кечкенә сыер җиккән бабай — Айтуган авылының Арслан исемле, сугышка хәтле булган сабан туйлары батыры иде.

Бабайның исеме генә Арслан түгел, ул үзе дә арысландай горур, мәһабәт гәүдәле иде. Алтмыш белән җитмеш арасындагы юан беләкле, киң күкрәкле, аякларында нык басып торган, нәрсәгә ябышканнан яхшы белгән кеше иде ул. Инде яшәгәненә байтак булса да, бабай тормыш авырлыкларына тиз генә бирешерлек түгел иде әле. Арбасы янында үзенә онытылып карап торган малайга, озын, кара керфекләре арасыннан, кара күзләрен бер генә сирпеп алды да, салам эшләпәсен, киндер алъяпкычын салып, кечкенә арбасы өстенә куйды. Кабаланмый гына, алҗыган сыерын тугарырга тотынды. Сыерның икегә аерылып китә торган камытын салдырганда Зөфәргә тагын бер карап алды да елмаеп дәште:

— Син, улым, каян киләсең болай?

— Килмим, бабай. Мин Югары очка китеп барам. Абый җибәрде, чыбыркы үрергә каеш алып кайтырга, дип.

— Син, Атарбановкада торган Фәйзрахман бабаңны беләсеңме?

— Гәрүчи ташый торган бабайнымы?

— Әйе!

— Беләм.

— Өен дә беләсеңме?

— Беләм. Атарбановка урамына кергәч тә, уң яктан өченче йорт.

— Бик кыен булмаса, шуңа барып кына әйт әле, улым. Айтуганнан Арслан бабай килгән синең йомышыңны үтәп, диген. Сине Таш күпер янында көтә, диген. Үзем барыр идем, шушында каладан кайта торган киленемне көтәм. Шулай сөйләшкән идек. Өйлә вакытына. Аймылыш булырбыз дип куркам.

Көрәшче бабай үзенә йомыш кушканнан малайны шатлык биләп алды. Капар Рәшитенә сөйләсәң, ышанмый бит инде Капар. Зөфәр куанычын яшермичә җаваплады:

— Ә мин бит сине беләм, Арслан бабай. Син бит сугышка хәтлек булган Сабан туйлары батыры. Бөтен яшьләрне тәгәрәтеп салган бабай бит син. Хәзер барып әйтермен.

— Ай, рәхмәт төшкере бала икәнсең! Беләсең дә икән әле мине. Килеп җитсен монда, кереп кенә әйт инде, йәме!

— Ярар, бабай, ярар!

Зөфәр ишек алдында йөгереп йөргән Фәйзрахман бабайга кычкырды:

— Фәйзрахман баба-ай!

— Әү, улым,— диде бабай, эшеннән туктамыйча гына.— Нәстә булды?

— Сине, Айтуганның Керәшче бабай тиз генә Таш күпер янына килеп җитсен әле, ди. Йомышыңны үтәдем, ди.

Җирән сакал-мыеклы Фәйзрахман бабай тузан туздырып ишек алдын себереп йөргән җиреннән бер генә мизгелгә туктады.

— Ә-ә, шулай дисеңме? Рәхмәт, улым, рәхмәт сиңа. Ярар, диген, хәзер килеп җитә, диген. Күрше Гәләветдинне генә чакырам да, хәзер барып җитәбез...

Зөфәр култык астына ике чыбыркылык каеш кыстырып, Ташкүпер янына кире әйләнеп килгәндә анда зур тавыш-гауга бара иде.

Арслан бабайның арбасын байтак халык уратып алган. Алар арба янында барган тавышны зур кызыксыну белән тыңлап, хайран калып басып торалар. Тыңлыйлар һәм... кычкырышырга да ярдәм итәләр. Зөфәр аяк бармагы очларына басып, кеше башлары өстеннән арба ягына карады. Анда, арба янында Арслан бабай, Җирән Фәйзрахман һәм тагын берничә карт күренә. Бар да арбаны аркалары белән каплаганнар да, каршыларында чәрелдәп чыйнап кычкырган Чолык Зәйнәбенә ризасызлыкларын белдереп, каршы торалар. Бабайларның иң алдында басып торган Арслан бабай, Чолык кулларын арбадагы саламга сузган саен, аның куллары сузылган җиргә гәүдәсен куя. Үзе кулларын артына яшергән Арслан бабайга шаулашып картлар ярдәм итәләр. Зәйнәп чәрелди:

— Ач йөгеңне, сбулыч! Барыбер саныйм! Ач, диләр сиңа! Мин хөкүмәт кешесе. Финагент. Кем бирде сиңа право монда килеп, авыл уртасында таргавайт итәргә. Сәүдә ачарга!

Зөфәр алдында басып торган Кырмавык Нәфиганың күлмәк җиңеннән тартты:

— Нәрсә сата ул бабай?

Хатын ялт иттереп артына әйләнеп карады да, сораганның Камилә малае икәнен күргәч, үлеп киткәнче хәбәр итеп өлгерсәм инде дигәндәй, тезеп алып китте:

— И-и иркәм-м, Зефф-фәр! Гарасат монда, гарасат! Теге Айтуганның Керәшче бабай безнең авыл картларының соравы буенча кабер ташлары китергән. Язып, әзерләп. Үлгәч, кабер башына, кыйбла ягына каратып куярга. Алар авылы ягында, теге Яшерган авылы янында, тау тулы шушындый таш бар икән. Шуннан чыгарып, шуларны сатарга китергән. Яшәргә кирәк бит инде, кая бармак кирәк. Безнең авыл бабайлары белән сөйләшеп куйган икән, язып, китереп бирергә. Чолык үтеп бара икән. Инде бәйләнә инде, ташка налук түлә дип бабайга. Мәеттән налук буламыни инде!..

Кырмавык Нәфига тиз генә төкерегән йота, арбага борыла:

— Тукта, тыңлыйк әле. Азактан сөйләп бетереп куярмын. Тик син китә күрмә, ярармы.

Арба янында тик Зәйнәпнең генә тавышы көчәеп, куәт алып бара:

— ... йә, иллешәр сумнан налог түлисең, йә исә мин сине милициягә алып барып яптырам...

Арслан бабай, нинди ярты акыл хатын икән бу, дигәндәй тирә-ягына карап ала да, азрак елмаю чыгара йөзенә.

— Алып барып кара, кулыңнан килерлек булса. Мине, сугыш алдыннан, сезнең авылның иң көчле Даут та ала алмады, син — чикерткә түгел. Бил бөгеп, баш иеп яшәргә күнекмәгән мин. Үземнең хәләл көч белән чыгарган ташларым, үз кулым белән язган язулар. Мин сине белгән кеше дә түгелмен, белергә теләмим дә. Каян килгәнсең, шунда юлыңда бул. Бар, кызым, бар...

— Мин, ни эшләп, синең кызың булыйм, ди, ә? Синең ише кулакка кыз булырга мин, финагент...

Фәйзрахман бабайга нәрсәдер әйтергә дип борыла башлаган көрәшче, кискен хәрәкәт белән Чолыкка борыла. Бабайның күзләрендә очкыннар уйный:

— Бу авылның канын эчеп торган Чолык дигән хатын булдың шикелле син. Бик күп ятимнәрне зар елаткан, яман кеше, диләр иде, хак икән. Минем сугышта өч улым, ике киявем корбан булды. Бер мин ир-аттан аларның ятим балаларын караучы, туендыручы, киендерүче, яшьләрен сөртеп, көн күрсәтүче. Кыздырма каныммы, Чолык. Хатынкызга кул күтәргәнем юк-юклыкка. Шулай да синең моннан китүең хәерлерәк булыр. Дөнья нужасыннан минем болай да күңелем кителгән, йөрәгем урынында түгел...

Арслан бабай башкача Чолык Зәйнәбенә карамыйча сыерын җигә башлады. Арба тирәсендәге кешеләр ничектер үзеннән-үзе килеп чыккан кебегрәк иттереп Чолыкны арбадан читкәрәк аердылар.

— Әйдә, малкай! Кер тәртә арасына! Юлга дип, хәерсез сәгатьтә чыкканбыз, ахрысы. Азагын Ходай үзе хәерле кылсын...

Зәйнәп ачуыннан урыннарыннан чыгардай булып зурайган күзләре белән арбаны уратып алган кешеләр арасыннан кемнедер эзли башлады. Кешеләр аның күзләре белән очрашмаска тырышып, карашларын читкә бордылар. Шулчак ул Зөфәрне күреп алды да, аңарга эндәште:

— Син, Песәй Камиләсенең улы бит әле?

Тик Зөфәр куркуын җиңеп, үзе дә көтмәгән җавапны бирде:

— Булса, ни булган!

— Бар, йөгер милиция йортына. Нәчәлникләренә әйт, финагент налог түләмәгән бер бәндәне тоткан, тиз генә бер милиционерны җибәрсен. Задержаниега, дип әйтте, диген. Бик тиз дип әйтте, диген.

Зөфәр ялан аяклары белән урам тузанында баскалап алды да, арба янындагы кешеләрне көлдереп, җавап бирде:

— Милиция йортының кайда икәнлеген белмим бит әле мин. Үзең генә бар да куй!

— Ничек инде ул, белмисең?!

— Чөнки милициянең миңа кирәге юк. Шунлыктан белмим.

— Яхшылык белән әйтәм: йөгер, тизрәк!

— Хәзер менә йөгердем ди, тот капчыгыңны!

Зәйнәп зәһәрләнеп нәрсәдер әйтергә дип авызын ача башлаган иде, арба янындагы халык гөжләп, Чолыкка кычкыра башладылар:

— Оятсыз, битсез бер нәстә булдың инде!..

— Кешеләрдән оялыр идең ичмасам чак кына.

— Урталай ярсаң, ике кеше чыгарлык. Симерде, хәшәрәт нәстә, кеше хакын ашап.

— Кеше хакы атлатмый ул. Килер әле сиңа да бер, Чолык.

— Яфаланганнарыңны да күрербез әле. Көтик кенә-ә...

Кешеләр артыннан ыргытылган таш Чолыкның дәү түшенә килеп бәрелде. Зәйнәп үзенә ярдәмче эзләп тирә-ягына каранды. Тик аны ачудан нәфрәтләнгән йөзләр, зәһәрләнгән күзләр уратып алганнар иде. Шулчак ул сизеп алды: үзен уратып алган кешеләр боҗрасы акрын гына кысыла башлады. Моны сыерын җигеп болашкан Арслан бабай да сизде. Кулындагы дуганы Фәйзрахман картка тотырды да, ике кулын һавага күтәрде:

— Җәмәгать, дим, җәмәгать! Тынычланыгыз!

Күпне күргән, күпне кичергән ир солтаны, көрәшче Арслан бабайның тавышы тыныч иде.

— Нәрсә эшләргә уйлыйсыз сез, ә? Бук белән бук булып, катыр китәргә итәсезме? Туктагыз!

Зур җитезлек күрсәтеп, артына посып өлгергән Чолыкка борылды. Тавышы тулы җирәнү иде бабайның.

— Бар кит моннан исән чагыңда. Ул-бу булуы бар. Кит. Барып безнең өстән сөйләнеп йөрмә. Яхшылык белән алдан әйтеп, кисәтеп куям.

Сиңа да азрак басылырга вакыттыр. Танауыңа киртләп куй, мин бервакытта да, беркемнән дә куркып яшәмәдем. Кирәк булса сиңа да...

Бабай арба тирәли божра ясап басып торган кешеләргә уң кулын сузды:

— Юл бирегез бу... нәстәгә. Китсен.

Чолык агарган, тирләгән битен күлмәгенең җиңе белән сөртте дә, икегә аерылган кешеләр төркеменнән күпергә табан көч-хәл белән атлап китте.

Игеннәр җыйналып, бәрәңгеләр казылып базларга салынгач, Зәйнәп гаиләсе белән Ташкент ягына күченеп чыгып китте. Аның китkәненә ничәмә ничә дистә еллар үтсә дә, сугыш елларында тол калган, инде әбилектә йөргән хатыннар аны һәрчак исләренә төшкән чакларында каһәрләп телгә алалар...

* * *

Кызы институтка укырга кергәч, гаиләләре белән куандылар. Бигрәк тә кече малайлар. Уен эшмени, апалары укытучы булачак, акчага эшләячәк бит. Тик, татар мәктәбен тәмамлап барган кызга беренче курста стипендия эләкмәде. «Өч»ле алганнарга стипендия тиеш түгел икән шул. Китте инде шуннан соң студентка Фәриданең ачлы-туклы укулары да, авылдан аңарга азык ташулар да. Калага кызына азык җибәрү өчен, анда бара торган кешесен эзләүчеләр алга килеп баса. Ярый әле ул елларда авылдан берничә үткер хатын калага барып, шуннан алып кайтып әйбер белән сату итәләр. Кыйммәтрәк хак белән. Бөтен авылга аларның даны тараттылар — эспикүләннәр. Шулай исем таксалар да, авыл ул хатыннарның кәсебенә бик кирәкле дип карый. Чөнки авыл кибетләрендә бернәрсә юк. Ә хатыннар авыл өчен барлык кирәк-яракны ташыйлар. Аларда шырпы, кер сабыны, әлүмин тәлинкә, чәй калаклары, синке дип йөртелгән әйбер манырга бик тә кулай буяу, арзанлы ситса, бумази әйбер, бала-чагага кара ясый торган порошок, дәфтәр, авыл өчен ел әйләнәсендә киелә торган җылы «куфайка», бүрек, баш яулыгы, тагын-тагын әллә нәрсәләр. Авыл ул хатыннарның барысын да белә: Солтан Заһидәсе, апалы-сеңелле Көрпә Гайшәсе белән Песәй Зөһрәсе, Пиреч Мәрхәбәсе, Кәпәч Хәсбиямалы, Чутый Фәтхиясе, Юкагач Хәдичәсе, Юан Газзә, Чибәр Гыйзелбанат...

Ул хатыннарның барысының да ирләре сугыштан кайта алмаганнар. Кәпәч Хәсбие әйтмешли, үзләре баш, үзләре түш! Һәрберсендә өчәр-дүртәр бала. Ә кайберләрендә, килен кулына калганлыктан, өнсез-тавышсыз биемнәре-кайнаналары да бар өстәвенә. Килен белән телләшеп утырып булмый — бу сиңа улыңның түре түгел, ә килennең эш белән тулган ишек төбе! Ул карчык шунлыктан, киленгә фарыз булмаганлыктан, бөтенләй телсез бер мәхлүккә әйләнеп, өй эчендә артык күзгә чалынмаска тырышып, үзенчә тереклек итә һәм кулыннан килгәнен карусыз эшләп тора. Камилә шул хатыннарның барысы белән дә дус һәм ахирәт. Шуларга ярап, дус булу өчен ул ике нәрсәне файдалана. Беренчедән, юлда йөрергә өчәү-дүртәү бергәләшеп чыгып киткән хатыннарның, каладан кайту көннәрен алдан ук белеп, алар кайтуга мунчасын ягып куя. Самавырын кайнатып, кызарып-пешеп мунчадан чыккан хатыннарны чәй белән сыйлый. Икенчедән, эш сөючән улы Хәйдәрне кушып, шул хатыннарның өен сыларга кызыл балчык китертә җәй көннәрендә. Ком да Камиләдән инде. Шунлыктан «эспикүлән» хатыннар йөз илле чакрымдагы Уфага китә башласалар, Камилә аларның һәрберсенә төен тоттырып җибәрә. Уфада алар үзләренең авылыннан шунда, сугышка кадәр үк күченеп киткән Кидрәчләргә төшәләр. Алып барган майны, йомырканы сатып, кала товарларын җыйганчы шунда торалар, шунда куналар. Кызы Фәридә, авылдаш хатыннарның килер көннәрен чамалап,

шул Кидрәчләргә килгәли. Әнисе җибәргән «күчтигә» өмет итеп. Өмете кайчан аклана, ә кайвакыт — юк шул...

Кырык сигезенче елның иген ура башлаганның беренче көнендә үк Хәйдәр иген урлап төрмәгә эләкте. Унике кило да өч йөз грамм булды урлаган арышы. Арыш урган «Коммунар» комбайнына пар ат җиккән бричка белән аны иген ташырга беркеткәннәр иде. Кичтән ул амбарчы булып эшләгән Мусин Мәҗиттән егерме кычыткан капчык алды. Иртән көтү белән торып, Әҗмәт яланына комбайн арыш урырга төшкән урынга ашыкты. Басу кырындагы чирәмгә ясалган ындыр табагында көлешә-көлешә кызлар белән капчыкларга арыш тутырды. Әҗмәт яланы авылдан өч чакрымнар чамасы гына ераклыкта иде. Шунлыктан ул көненә алты мәртәбә юллады. Кичке сәгать сигезләр тирәсендә соңгы йөк арышны колхоз келәтләре янындагы токка китереп бушатты да, Мәҗит абзый нәрсәдер язып болашканда, зур соскы белән ике рәт батырып алып, бричкадагы бер капчыгына арыш тондырды. Арышлы капчыкны тиз генә башка капчыклар астына тыкты да, өенә кайтып ашап, ялангача куна китәргә исәплән кузгалды. Атларын юыртып, базар почмагын борылуга, аны, колхозда райкомның уполномоченные булып йөрегән Даутов фамилияле, зур гәүдәле кеше туктатты. Аның янында ике милиционер да бар иде...

Хәйдәр ул төнен төрмәнең кандалалы камерасында япа-ялгызы үткәрде. Баш очына, сәке кебек ясалган ятакта, куфайкасын салып, камера караңгылыгына карап ятты ул. Башы тулы тынгысыз йокы бирмәс уйлар иде. Шул уйларның арасында иң авыры: «Утыртып куйсалар, әни бичара япа-ялгыз ул бер өер малайлар белән нәрсә эшләр инде?».

«Песәй Хәйдәр бер йөк арыш урлап тотылган икән. Утыртканнар икән!»— дип, авыл иртәгесен көтү куганда ук гөж килде.

Бер тәүлек ятканнан соң, икенче көнне Хәйдәрдән милиция киемендәге кеше сорау алды. Өстәле алдында, бүлмә уртасында тавыш-тынсыз гына басып торган Хәйдәрне бөтенләй күрмәмешкә салынып, бик тәмләп, өрә-өрә шикәрләп чәй эчте. Шикәрне тешләре белән шартлатып тешләп китеп, чәен шопырдатып эчте. Тешләре ат теше кебек эреләр һәм саргаеп беткәннәр иде. Аннан соң билендәге каешында эленеп торган кобурасыннан шнурлы револьверын алып карады да кире тыкты. Моны-сы күрәсең Хәйдәрне куркыту өчен эшләнде. Шуннан соң гына башын күтәрде дә озак иттереп Хәйдәргә карап утыра башлады. Аның карашыннан Хәйдәр чабаталы аяклары белән идән уртасында берничә мәртәбә баскалап алды да, башын читкә борып, тимер рәшәткәле тәрәзә аша урам якка карады. Шул көенчә башка кузгалмыйча басып тора башлады.

Тәрәзә сирень, шомырт агачлары үскән матур бакчага караган. Тәрәзә төбендә генә үскән, сирень агачында чыпчыклар чыркылдаша. Хәйдәр шул кошларга карап, очып кына китмәсәләр ярар иде дигән теләк белән басып торуын дәвам итте.

— Ну-ну!— диде тикшерүче.— Фамилияң, исемең, атаңның исеме?

— Хөсәенов мин. Хәйдәр. Әтием — Биктимер.

— Ничәнче елгы. Кайда тудың?

— Утызынчы. Шушы авылныкы.

— Әтиең, әниең barлармы?

— Әни бар, әти сугыштан кайткач үлде.

Сөяргулов язгалап утырды да тагын сорау бирде. Ул Хәйдәр өчен көтелмәгән сорау булды:

— Моңа кадәр урлашканың бар идеме?

Хәйдәр эченнән генә уйлап куйды: «Калхузда урламыйча яшәп кара, бар! «Тик җавабын «кирәкчә» бирде:

— Юк, урлаганым юк иде.

— Ә нигә кичә урладың? Әллә берәрсе бирдеме?

— Мин урламадым, алдым. Кем бирсен миңа?

— Син колхоз милегенә кул сузганыңны беләсеңме?

— Беләм. Без үзебез дә калхузныкы инде. Туганнан алып.

— Ала-ай,— диде Сөяргулов.— Димәк, син аңлы рәвештә урлагансың булып чыга.

Шулчак Хәйдәрнең башына бер уй килеп керде, һәм шуңа ябешеп, ул үзен коткарырга талпынды.

— Мин ул арышны атларга ашатырга алдым, үземә түгел.

Үзе сөйләде, үзе үз алдавына ныклап ышана да барды. Тик чәч төпләре тирләп чыкты. «Беткән баш беткән! Нык торырга кирәк! Гел бертөрле генә сөйләргә!»— дигән ныклы карарга килде.

— Ничек инде ул, атларга арыш ашатырга?! Эчләре күпсә?

— Күпми-и! Калхуз атының эче күбә димени! Атның сыерныкы кебек ашказаны юк бит аның. Туры эчәк кенә аңарда. Сыер түгел инде ул эче күбәргә...

— Атларга булгач, нигә сораусыз аласың? Анда бит завток бар.

— Һы-ы, завту-ук! Бирер ул сиңа, бирмини!

Сөяргулов нәрсәдер уйланып, каләме белән өстәлгә азрак тыкылдатып утырды. Сүзләрендә ачу сизелә башлады:

— Син, малай актыгы, алдашма монда. Атларга, имеш. Үзең өчен урлагансың син ул арышны. Һичшиксез, шулай! Дөресме?

Хәйдәр аңарга җавап бирмәде.

— Бар камераңа. Ныклап уйла. Бер сәгатьтән тагын чакыртырмын.

Ишеккә барып кычкырды:

— Гайси-ин!

Аның чакыруына ишектән милиционер Тәмеч килеп керде.

— Син бу малайны алып кереп яп. Кире кергән урынына. Эше шәптән түгел егетнең. Болай киреләнсә, кимендә биш ел булачак. Алып кит.

— Әйдә, Хөсәенов, киттек.

Хәйдәр урыныннан кузгалмады.

— Мин кичә кичтән бирле, монда кергәннән бирле, бернәрсә ашаганым юк. Давай, минем тамакны туендырыгыз.

Сөяргулов аптырагандай иттереп тоткынга карап торды да, өстәл артыннан чыкты. Мыскыллап елмайды.

— Ничек инде ул, синең тамакны туендырырга, ди?

— Теләсә ничекләр итеп. Утырткансыз икән, ашатыгыз, давай! Ашата алмыйсыз икән, чыгарып җибәрегез. Калхузда көн-төн эшләп ачбыз, инде төрмәдә дә ашатмаска булашсыз. Мин монда ач утырырга тиеш түгел. Чыгарыгыз, давай!

Сөяргулов көлеп җибәрде:

— Ну и ну-у! Карап торуга юк кына малай кебексең, ә үзең нахха-ал!

— Көн-төн эшләп йөреп ач утырсаң, син дә булырсың нахал. Ашатыгыз давай!

— Сознаваться итсәң, ашатабыз. Килеш — урладым диген.

— Атка ашатырга алдым мин ул арышны.

— Алып чыгып ябып куй, Гайсин.

— Әйдә, атла, карышма.

Хәйдәр башкача ашарга сорамыйча чыгу ягына юнәлде. Ишек алдын үтеп, төрмә коридорына кергәндә Хәйдәр үзенең артыннан милиционерның пышылдаганын ишетте:

— Атларга алдым дип, шулай нык тор. Аннан синең унсигезең тулмаган әле. Сорау алу пыртакулына минем туган аемны, елымны язып куегыз диген. Шунсыз кул куймыйм диген...

Пышылдаудан туктап акырырга тотынды:

— Йә, атла шәбрәк! Нәрсә киләсең көчкә өстерәлеп.

Сорау алулар икенче көнне көнозын барды. Хәйдәр бик аңлап бетермәсә дә, Сөяргуловның кысуларына каршы торды, барлык сорауларына да бер генә җавап бирде: мин ул арышны атка ашатырга алдым. Ур-

ламадым, алдым гына. Атыма ашатырга. Тагын бер тәүлек үткәч, Хәйдәрне район милициясе начальнигы Мостафин кабинетына алып керделәр.

Зур, мәһабәт гәүдәле майор Мостафин янында кожан кигән, кулына каеш чыбыркы тоткан колхоз рәисен Хамматовны күргәч, Хәйдәрнең эченә җылы йөгерде. Хәйдәр керүгә үк Мостафин Хамматовка эндәште:

— Синең работникмы бу малай?

— Әййе, безнең колхоз члены инде. Иң шәп эшли торган егет ул безнең. Кырык беренче елдан бирле колхоз эшендә чыкмастан эшли.

— Арыш белән эләкте бит, уборканың тәүге көнендә үк. Менә тикшерү бара инде хәзер.

— Соң, Мостафин иптәш, сөйләштек бит инде сезнең белән. Атларына алган бит ул арышны. Мин аларга һәрчак әйтә киләм, атларыгыз ашатылган булсын, каралган булсын дип. Миңа уборканы җиңеп чыгарга кирәк. Ә төп көч шушы малайлар белән атлар. Тик ул бер ялгышлык эшләгән, арышны алып кайтып киткән. Атыгызны токта гына ашатыгыз дип әйтергә минем дә башка килмәгән. Бүгеннән соң бик тә стругы карармын үзем дә.

Мостафин рәисне бүлмичә генә тыңлап утыра бирде.

— Әйдә, бергәләшеп без болай итик. Сез бу егетне миңа биреп чыгарыгыз. Мин игенчеләрне җыйнап, шулар алдында бик шәпләп иттереп аны абрабутать итәрмен. Әгәр инде шуннан соң да берәрсе... э-э, ялгышмы, чынмы дигәндәй инде... э-э... эләксә, аннан соң инде башкача карарсыз. Аннан соң бу малайга унсигезе дә тулмаган, гәүдәгә генә шулай зур күренә ул...

Хамматовның сөйләгәнен тыңлап, Хәйдәрнең күңеле тула башлады. Җылап җибәрмәс өчен аскы иренен тешләп, тавыш-тынсыз гына басып тора бирде. Мостафин бер Хамматовка, бер Хәйдәргә караштыргалап утырды да, рәис туктагач, карарга килде:

— Ярар алайса! Без эшне болай иттереп бетерик инде. Алып кит син бу арыш... ны атларына алган малайны. Тик «дело»сын мин архивка салып куярга кушармын. Алай-болай икенчегә килеп эләксә, монысын да шунда кушып куярбыз.

Каты күз карашы белән Хәйдәрне сөзеп карады:

— Син, малай актыгы, кара аны, башкача кабатлама андый эшеңне. Аңладыңмы?

Хәйдәрнең сүз әйтергә хәле юк иде, ул баш кына какты.

Мостафин өстәлдәге төймәгә басты. Ишектән Тәмеч күренде.

— Тыңлыйм сезне, иптәш майор.

— Иптәш сержант, сез бу Хөсәеновны азат итеп, бинадан чыгарып җибәрегез. Шуннан соң Сөяргуловка минем янга керергә боерыгыз.

— Тыңлыйм, иптәш майор!

Хәйдәрнең җилкәсеннән тотып, ишек ягына этте:

— Әйдә, энем, чык дигәндә, чыгып котыл. Монда азаккы килүең булсын.

Баскычтан төшеп җиргә баскач, акрын гына әйтте:

— Берне җиппәрер идем инде, озынсың, буй җитми.

Чын исеме Сәлимгәрәй булса да, авыл аны ни өчендер Тәмеч дип йөртә иде.

— Рәхмәт инде, Сәлимгәрәй абзый, ярдәмең өчен.

— Мин нәрсә инде, тик Хамматовка барып кына әйттем, арышны атларына ашатырга гына алган ул, дип. Дапруста да шулай дип белдерде үзе, дип. Вәт Хамматовка әйт син рәхмәтеңне. Асыл кеше икән прсидәтелегез, асыл кеше. Ул булмаса, киткән иде газиз башкайларың иң кимендә биш елга. Аннан инде син кеше булып чыга алмый идең. Әтермә бетерә ул кешене. Бетереп бетерә. Асубинны синең кебек яшьләрне.

Ачык капкага күрсәтте.

— Бар, энем, ычкын моннан. Капканың теге ягына чыкканнан алып, кайтып җиткәнче бөтен белгән догаларыңны укы. Тик син Хамматовның чыкканын көт инде. Башкача эләкмәскә тырыш, алдыңны-артыңны җыйнап йөре...

Сәлимгәрәй абзый, урлашма бүтән, дип әйтмәде. Чөнки колхозның барлык эше урлашуга корылганны милиция башы белән ул да аңлый иде. Шул очрактан соң, Хәйдәр чын-чынлап алдын-артын карап эш итәргә ныклап өйрәнә башлады...

* * *

Гомере колхозда узды Хәйдәрнең. Үсеп көч утырта барган саен дөнья күтәргә өйрәнде. Ел әйләнәсенә кара эштән башы чыкмаса да, күләч йөзле, шат күңелле булып үсте. Һәм шулай иттереп яшәде дә. Колхозда эшләгән барлык яшүсмерләр кебек кичләрен аулак өйләргә йөреде. Үзе кебек укымаган, колхоз эшендә гомерләрен үткәреп йөргән кызларны тоткаларга, алар белән кунарга өйрәнде. Тик җырга, биюгә, җор сүзгә осталыгы юк иде Хәйдәрнең. Шунлыктан ул, кич булса, мич башына үрелеп, басудан энесе Зөфәр белән Хәлим урлап ташыган көнбагыш белән фуфайкасының ике кесәсен тутыра да китә чыгып аулакка. Аулак өйнең, ишекне кергәч тә йә сул яктагы, яисә уң яктагы өй мөеше аныкы. Кызларга да бирә, көнбагышны, үзе дә чиртә. «Йөзек салыш», «фант», «почта килде» уеннарында катнаша. Тик штраф чыкса җырлый, бии белми. Шунлыктан чыгып яисә утын ярып керә аулак өй хуҗасына, яисә үзе өчен берәр кызны яллап биетә. Тәүге елларда аңардан көлгәлиләр иде, тора-бара тукталдылар. Бераз вакыт Җырсыз Чижук дип тә үртәп алдылар үзен, тик озакка бармады, тукталдылар.

Хәйдәрне бер дә җырламый дип әйтеп булмый инде. Атлы арбага утырып йөргән кеше, юл озынына, арбаның келтерәп бер генә моң чыгарып баруына, атның теркелдәп кенә бер уңайга юыртуына, тирә-яктагы туган-үскән җирләрнең матурлыгына карап, тавыш-тынсыз гына бара алмый. Сискәнеп китеп, арбада утырып барган җиреннән ул кемнеңдер моңланып, сүзсез генә җыр чыгарып барганын ишеткән кебек була. Дилбегәсен яхшылап тотып кем булыр икән бу, дип тыңлап карый. Һәм... арбада утырып барган җиреннән үзенең моңаеп килгәнен ишетеп, исләре китә. Шулай булганын ачыкласа да... сүзсез җырын туктатмый. Чөнки яшәешендә ишеткән җырлар арасында бу җыр, үзе башкарганы — аның өчен иң-иң матур җыр. Сүзләре юкмы? Булмаса ни! Булмасын. Сүзләргә ияреп, моңны кем дә башкара ул, менә син сүзсез моңаеп кара. Һәркем инде сүзсез моңаюны булдыра алмый!

Хәйдәр дә кеше колагы ишетмәгән җирләрдә генә җырлаштыра. Үзе өчен генә дә, атлары өчен. Тик ул озак җырлый алмый шул. Үзе җырлаганга күңеле тулып, туктый Хәйдәр. Аңлап бетерә алмый бер нәрсәне: нигә генә дип, адәм баласын шушы хәтлекләр иттереп нужа белән басты икән? Кисәң — юньле кием юк, ашарга дисәң — ашарга юк. Колхоз эшләгәнгә бирми, үскән игенне хөкүмәт тоташы белән алып китә. Ә колхозларның бурычы арткаңнан арта гына бара. Барлык карап торганың әнә шул бакчадагы бәрәңге дә, чит-ят күзләр күрмәгәндә урлаштырып алып кайткан аз-маз бөртек. Берничә көн утырып, кәбестә суы эчеп чыкканнан соң, колхоз токларыннан, иген кырларыннан, комбайн яннарыннан урлашуны Хәйдәр уйлап, җиренә җиткереп, эзен калдырмыйча башкарырга өйрәнде. Көндезләрен өенә кайткан чакларда, аның арбасында грамм ашлык табам димә. Келәтендә дә юк иген. Шулай да ул гаиләсе белән ипи, токмач ашарлык ашлыкны кышка җитәрлек иттереп әзерли белә. Энеләре ашауга барысы да тазалар. Җимертеп ашыйлар, җимертеп эшлиләр һәм шәп булып, таза булып үсеп тә килләр. Тик менә калада, институтта укыган апасына җибәреп тә, ташып та

житкерерлек түгел. Төпсез чиләккә су тутырган кебек — житми дә, тулмый да. Апасының октябрь аенда каникулга кайтканын энисе көтеп тә, куркып та каршы ала. Киенергә бик тә ярата апалары. Шунлыктан кайтып кергән көненнән алып, кире Уфасына чыгып киткәнче авызында сүзләр тик кием турында гына. Кайсы студент кыз нинди күлмәк тектергән, ниндирәк түфлиләр сатып алган, пальтосының әйбере драп икән дә, якасы әллә нәрсә дигән җәнлек тиресеннән икән. Бәйрәмгә кызлар ниндирәк күлмәкләр тектергәннәр, нинди костюмнар алганнар...

Шуңа күрә кайтып кергән көненнән алып киткәнче ананың җаны өшеп бетә. Икенче яктан, үз балаң, үз каның. Кеше арасында кыз баланы әйбәтләр иттереп йөретәсе дә килә бит әле ул...

Октябрь бәйрәме алдыннан авылга каникулга дип кайтып, бәйрәмне үткәреп, өч энесенә киез итекләр бастырырга дип ике ел буена җыйган ундүрт кадак сарык йонын энисеннән базарга чыгарып саттырып, акчага әйләндереп алып киткәч, Хәйдәрнең түземлеге бетте.

— Нинди бер бетмәгән акча, ди ул аңарга. Нигә, безгә генә чабатадан йөрергә дигәнмени? Йортка бер файдасы тими. Хет бәрәңге утаткүмәр иде. Гелән киенеп, ясанып тырт-фырт кына йөрергә дигәнмени аңарга?! Без көн-төн эшләп яшь торган кешеләрбез. Малайларга мәктәпкә йөрергә пима кирәк. Ә ул монда кайтып ирен кызартып йөри. Оят кирәк. Узындырасың кызыңны!..

Һәрвакыт сабыр холыклы әнисе кабынып китте:

— Тый телеңне! Киенсен-ясансын! Ичмасам ул кеше булмасмы? Укыган кешеләр арасында шулай тиеш ул. Иншалла, укып чыкса, ярдәме тияр аннан соң. Үзе дә шулай дип тора бит әнә. Зөфәрне институтка кертеп укытам, ди. Шулай бер-береңне карамасаң, дөнья ничек барсын да, ничек көн күрергә кирәк, ди. Түз!

— Түз, имеш! Минем дә чүчинкалар, пималар киясем килә кеше арасында. Көн-төн эшләп, әллә мин чабатада гына яшәргә тиешменме? Әле дә аякта әтидән калган төпле пима. Ул да тузып бетте инде...

— Институт хәтле институтта уку җиңел түгел инде. Менә эстипинди ала башлар. Алла боерса. Без бит, балам, авылда ирләр эшли алмаганны эшлибез. Апаңны институтта укытабыз! Шулай дип әйтүләре генә дә ни тора кеше арасында...

Хәйдәр шуның белән туктый, артык сүз озайтмый. Алдындагы балчыктан ясаган тирән савыттагы умачка күп иттереп катык ката да, шуны тавыш-тынсыз гына ашап бетергәч, киенеп чыгып китә. Әнисенең чәй әзер, эч инде, дигәненә дә җавап бирми. Чөнки аның апасы Фәридәгә дә, әнисенә дә хәтере калган иде.

Сугыш бетте, инде азрак хәл алырбыз, тамагыбыз ипигә туяр, дип яшәгән халыкның өметләре юкка булды. Налог белән кысканнан өстенә, малга ашатырга печән әзерләү сугыш беткәннән соң бик авырга әйләнде. Сугыш елларында җирләрне сөрергә трактор да, ат көче дә җитмәгәннән сөрелмичә, чәчелмичә ятып калган җирләр күп иде. Анда, җәйге искән җилдә дулкынланып-дулкынланып печән үсте. Шунлыктан, сугыш беткәннән соң да, печән әзерләү авыл халкы өчен бик гади чишелә иде. Колхозга печәнне көндез чабасың, ә кичләрен үзеңә әзерлисең. Киң яланны колхоз ат чапкычлары кертеп чаптыра, җыйдырта. Колхоз яланнарын тутырып эскерт-кибәннәр куйдырта. Ә инде урман буйлары, чокыр-чакырлар, урман акланнары халыкка кала. Сугыш елларында ирләрчә селтәнеп чалгы белән йөрергә өйрәнгән хатын-кыз ай үтәр үтмәстә бала-чагалары белән берлектә малларына кышлык печәнне әзерли алалар иде. Шул печән вакытларына инде, арт йоннары коелып, күкәй салудан тукталган өч-дүрт тавык пычак астына эләгә. Печән чабарга ирсез хатын унөч-унбиш яшьлек энеләрен, барлык балаларын җыеп алып бара. Барысы да тырышалар кышкылыкка печәнле, сөтле булырга.

Тик, сугыш бетеп берничә ел узгач, үләнле яланнар сөрелеп, яңадан иген басуларына әйләндерелде. Печәнлекләр кысылып, колхоз малына да

житмəслек дəрəҗəгə килеп терəлде. Шунлыктан, колхоз малларына печəн əзерлəнеп бетмичə, колхозчыларга үз маллары өчен печəн чабу тыела башлады. Ул күрсəтмə райкомнан чыгып, авыл урамнарына таралды. Шул карарны җиренə җиткереп үтəр өчен, һəр колхозга «палнамучый» дигəн иксез-чиксез «правалар» бирелгəн, урында эшлəгəн кешелəр тəгаенлəп куелдылар. Иң беренче иттереп печəнне колхоз маллары өчен əзерлəргə!

Күрсəтмəлəрнең нəтиҗəсен Хəйдəр үз җилкəсендə бик тиз татыды. Кайда житте шунда чабып, кайда тал арасында, кайда чокыр-чакырда, урман эчлəрендə чабып, абзар кыегы астына кертеп өйгəн, ике арбага якын печəнне, идарə карарына таянып, төяп алып чыгып киткəннəр дə, колхозның ат сарае янына илтеп аударганнар. Кич Хəйдəр эштəн кайтканда капка төбендə аны энелəре Зөфəр белəн Хəлим каршы алдылар.

— Абый!— диде Зөфəр.— Абзар кыегы астындагы печəнне төяп алып киттелəр.

— Кем?

— Зампред Əхмəт Тəкəч карап торды, Ялман Хəйбере белəн Трай Таһиры төяп алдылар. Ике ат белəн килгəннəр...

— Ни хаклары бар аларның кеше абзарына кереп, печəнен төяп алып китəргə?

— Тəкəч əйтə, колхоз җилкəсен кимереп яшəргə мин сезгə ирек бирмəячəкмен, ди.,..

— Əни өйдə юк идемени?

— Өйдəе. Тик Əхмəт Тəкəч аны ишегалдына чыгармады да. Тəрткəлəп кире өйгə кертеп җибəрде. Тагын чыксаң, өтермəгə илтеп ябарга да күп сорамам мин, ди. Малаең бур тагын бурлар үстереп ятасың өең тулы, ди Тəкəч...

Атын энелəренə тоттырды да, ишек алдына кереп тə тормыйча, Хəйдəр колхоз идарəсенə китте. Ул анда барып кергəндə яңа рəис Басыйр, Əхмəт Тəкəч, тагын өч бригадир кызып-кызып нəрсəдер турысында сөйлəшеп утыралар иде.

Тəкəч Əхмəт Хəйдəрне күргəн уңайга ук телгə килде:

— Озын гомерле булыр əле, көттермичə килеп тə җиткəн. Кем чакырды монда сине?

Хəйдəр аңарга җавап бирүне кирəк дип тə тапмыйча, рəискə карады.

— Утыр, энем, əнə тегелəйгə узып,— диде Басыйр, бөдрə башын кəгазьлəрдəн күтəреп.

— Ярар, басып торсак та. Мин сезгə бер сорау белəн генə килдем.

— Əйтеп кара, энем.

— Без хəзер, Басыйр абзый, ничеклəр иттереп яшəргə тиешбез инде? Əнидə биш бала, эшкə яраганнардан бер мин. Балаларны ашатырга кирəк, укытырга, киендерергə. Утын кирəк, үзебезгə азык, малларга курмы. Бөтен карап торганыбыз — бакчадагы унбиш сутый җир, сыер, өч баш сарык, бер бозау. Инде шул малларга, көн-төн калхузда эшлəп, безгə печəн əзерлəргə дə ярамыймыни? Калхузда эшлəп, без печəнне каян хəстəрлəргə тиешбез инде? Үзебезнең җирдə чапмыйча, кала урамына барып чабып булмый лабаса. Давай, миңа җавап бир, Басыйр абзый. Миңа энекəшлəрне ничек ашатырга хəзер? Əтинең кая киткəнен үзең яхшы белəсең. Сугышка киткəннəн имгəнеп кайтып, үлде ул...

Рəис сүз əйтə башлаганчы, Əхмəт Тəкəчнең чүлмəк кебек зур авызыннан, əшəке иттереп сүгенү белəн бергə, Хəйдəрне куркытырга уйлаган сүзлəр коелды:

— Син монда, инəңнең... права эзлəп киллеңмени əле! Ə? Закон бозып, колхоз яланыннан урлап печəн əзерлəгəнсең. Бер урлашып, кəчкə котылганыңны бел! Күтеңне кысып кына йөрисе урынга, калхуз печəнен урлап чабасың. Бар чыгып ычкын моннан, лепкəңə берне менеп төшмəс борын. Сəплəк нəстə!

Хәйдәр Тәкәч ягына әйләнеп тә карамады. Аның мөлдерәмә яшь тулган күзләре Басыйрда иде. Рәис, кулларын кая куярга белмичә, берберсенә тоткалап, кыскалап алды. Алдындагы кәгазьләрне кузгаткалап куйды. Шуннан соң гына сорады:

— Күпме тирәсе иде печәнең?

— Энекәшләр кул арбасы белән ташыган печән инде. Зөфәр әйтә, ике фурман төяп алдылар, ди.

— Райком кушуы буенча, райисполкомның карары бар бит. Колхозга әзерләп бетмичә, колхозникка печән әзерләү тыела.

— Бардыр андый карарлар, миңа караңгы алары. Син минем сорауга җавап бир, Басыйр абзый: ничек яшәргә безгә? Нәрсә исәбенә көн күрергә? Әти юк, әни ялгыз. Ул бала-чаганы мин туендырырга тиешме? Тиеш! Чөнки абзый кеше мин. Ундүрт яшьлек энем Зөфәр ачлы-туклы килеш, тал арасыннан урак белән урып әзерләгән печән бит ул. Зөфәр ура, Хәлиме кочаклап ташый арбага. Балалар көче бит ул.

Әхмәт Тәкәч түзә алмыйча тагын килеп кысылды:

— Алдык, алачакбыз. Райком шулай куша...

— Дәшмичә түзәрлек түгел. Әйткәч әйтим инде. Синең бу Тәкәчеңә авылда әллә закун юкмы? Үзенә булса, ат косилкасы белән чаптырып, сгрибалка белән җыйдырып, малайлардан ташыта. Ә безгә...

Әхмәт Тәкәч урыныннан ук сикереп торды:

— Миңа нахакка бәла якканың өчен белермен мин синениләр эшләтергә, пнимаешь! Мин сезне фашистлардан кан коеп коткарып кайткан кеше!

— Төрмәдә надзиратель булган кеше син, Тәкәч. Тик син кеше каны эчеп төрмә ачкычлары күтәреп йөргән вакытта, мин ашаттым сине калхузда җир сөреп, иген чәчеп. Сугыш башланганнан бирле, тамагым туйганчы ипи ашаганым юк минем. Балачагым уенсыз үтте. Инде син изәсең безне, Тәкәч. Күзеңне ачып кара, без дә көч-гайрәт алып үсеп киләбез. Синә гына җитәрлек көч табарбыз.

Ул янә Басыйрга таба борылды:

— Син хуҗа безнең өстән, Басыйр абзый! Үзебез кул күтәреп сине сайлап куйдык. Җавап бир. Нигә геләннәр генә безгә бу нужа дигән нәрсәләр? Иртәгәләргә нәрсә эшләтергә уйлыйсың безне? Ул балаларны иртәгә капчык күтәртеп, авыллар буена мин хәер сорарга чыгарып җибәримени инде? Давай миңа җавап. Тик үзең бир җавапны. Тәкәчне сөйләтмә!

— Ярар, Хәйдәр энем, тыңладым сине, аңладым. Син бар кайт, без монда уйлашырбыз. Кышкылыкка курмысыз калдырмабыз синең кебекләрне. Эшләгән егетләрне, диюем. Тик, райком карарын бозып, без дә берни кыла алмыйбыз бит. Өстән бирелгән күрсәтмәләрне без үтәргә тиешбез. Тәртип кирәк. Һәркем колхоз яланыннан, кайдан теләсә, шуннан чаба башласа, нәрсә булып бетәсен үзең үк беләсең бит.

— Мин, Басыйр абзый, теләсә кем дә, һәркем дә түгелмен. Мин ун яшьтән калхуз эшеннән туктамастан эшләгән кешемен. Инде малайлыктан чыгып, егет кыяфәтенә кереп киләм. Дауай, минем кебекләргә яшәргә ирек аз гына. Без калхуз эшендәбез, һәм калхузда тамак туйдырырга тиешбез. Укымаган, кара акылым белән мин шулай дип уйлыймын. Һәм дөрес уйлыймдыр...

Хәйдәр башындагы каралып, майланып каткан кепкасын әйбәтләп кигәндәй иттереп төзәткәләде дә хушлашмыйча һәм ишекне дә япмыйча чыгып китте. Ул чыгып киткәч, Әхмәт Тәкәч нәрсәдер әйтергә дип авызын ача башлаган иде, бишенче бригада бригадиры Сәвәләй Бакыйры аны туктатты:

— Син, Әхмәт, шушы кирәксә-кирәкмәсә дә матлап акырынып, җикеренүләреңне туктат берүк. Бу егетләр берәр көнне сине әпәләп тукмарлар дип уйлыйм мин...

Басыйрга борылды.

— Энем Басыйр, мин болайрак итеп уйлыйм. Инде бүгенге көнгә алынган печәнне кире бирмик. Райком, райисполком тирәсеннән килгәннәргә күрсәтергә торсын. Тик киртләп алырга кирәк. Ә инде халыкны тентеп, сарай эчләренә кереп йөрүне туктатыйк, яхшы түгел. Инде сарай башларында күренеп торса, кемнеке икәненнән чыгып, уйлашырбыз. Ярамый болайлар иттереп, көн-төн эштә йөргән кешенең гайрәтен чигерү. Ярамый. Хәйдәр бик уңган малай, андыйларны саклап, иплэп эшләтә белергә кирәк безгә. Туктатыйк без бу эшне. Килгән палнамучыннарга күрсәтерлек җыйналган — җитте!

Бу сүзләргә каршы Әхмәт Тәкәч тә каршы әйтеп тормады, кепкасын киде дә чыгу ягын карады.

Шул елны байтак кешеләр үз малларына җитәрлек печән әзерли алмадылар. Басыйр рәиснең «курмысыз калмассыз» дигәне берничә йөк салам булды. Ярты кыш җиткәндә, әйбәт кенә саудырып килгән сыерның сөте кимегәннән-кимеп тәүлегенә ярты чиләктән артмый иде. Табигате белән дә ябык булган ала сыер сөяк белән тирегә генә калды.

Яңа ел җитәр алдыннан Хәйдәр кичләтеп кенә идарәгә барды да, почмакта тәмәке пыскытып, «нәрәт бирү» беткәнне көтеп утырды. Кичке киңәшмәдән бригадир Тимеркәй белән бергә чыкты. Бригадир борыласы тыкрык чатына җиткәч, атнадан артык башында йөреткән уйны әйтте аңарга:

— Син, Тимергали абзый, мине фермага печән ташырга билгелә инде. Малларга ашатырга курмы бетеп бара минем. Бу бару белән барса, сыерның сөте вич бетәчәк.

— Шулай дисеңме?

— Шулай, Тимергали абзый.

— Ярар, иртәгә мин Басыйр абзый белән сөйләшермен.

— Сөйләшүен сөйләш син. Тәкәч юкта гына сөйләш. Ул белеп калмасын.

— Белмәс. Иртәгә иртүк айгырны җигеп, калага китә ул. Өч-дүрт көнсез кайтмас әле. Тик син эшли башлаган көнеңнән үк, чана эченә бик күп салып алып кайтма. Ишетсен колагың. Синең арттан күзәтү куйгандыр ул. Бик үчле бәндә бит. Юкка сабачиться итәсең син аның белән.

Елмайган күзләре ай яктысында шәфкатьле елтырый иде.

— Миңа берәр чүлди куярсың инде, мәгәричкә.

— Әбизәтелне.

— Ярар исән булып тор. Төшер бүрегең колакчынын. Туңдырырсың колакларыңны. Аннан барырсың Мәһирә янына кабартма колак булып, та, кунганда тик түшәмгә генә карап ятарга туры килер... кочаклаша алмыйча...

* * *

Илленче елны июль аенда Хәйдәрне солдатка алдылар. Монголиянең 74 разъездында, танкларга нярәп, автомат тотып, өч ел буена шундагы сопкаларга атакага йөреде егет. Солдат хезмәте аның өчен колхоз эшеннән авыр булмады. Өстәвенә, бушка ашаталар иде. Тик авылдан килгән хатлар гына аны борчый һәм җанын телгәли иде. Бигрәк тә, хезмәт иткәндә, яңа ел үткәч, Зөфәр язган бер хатны уку аның өчен аерата авыр булды. Үзләреннән, агай-энеләрдән, күрше-тирәләрдән сәламнәр язып бетергәч, хатта авыр яңалыклар бар иде.

*«...Апа миңа институтын бетереп кайтканда, җәйге ике айлык стипендия акчасын алып кайтырга тиеш иде. Мин шул акчага тарихка укырга китәрмен дигән идем. Ул укыган институтка. Акчам юк, дип бирмәде. Әни моңарчы сиңа язарга кушмады ул турыда. Аның рөхсәтеннән башка гына язам инде. Син белгертә күрмә. Апа күрше авылда укыта. Тик,*

*үзебезнең Фатыйма җиңги, әнигә ишеттергән, кызың каладан авырлы булып кайткан икән, дип. Әни елый да елый, кешегә күрсәтми генә. Аптыраганнандыр инде, миңа гына әйтте. Шуннан соң яңа ел үткәнче апа базар көннәрендә кайтып йөремәде. Яңа ел каникулы узгач кына кайтты. Апа кайтып ике көн торгач, бер башкорт егете килде безгә. Апаның корсагы зур булып үскән. Шул башкорт — апаның ире икән. Апа белән бергә укыган икән институтта. Барып, загыста язылышып кайтканнар. Апаның язга бәбие була инде. Мин элегрәк яза алмадым. Әни рөхсәт итмәде.*

*Үзем колхозда эшлим. Химия укытучысы Зәйнәп апа урамда очратып мине әрләп китте. «Оялмыйча ун класс белем белән колхоз эшендә йөрисең»— ди миңа. Әрләсә әрли инде, каршы бер нәрсә дә әйтеп булмый. Укытучы апа бит.*

*Курмы ягы әйбәт. Синең эшләгән трудларга өч йөз граммнан иген бирделәр. Яртысы солы. Шулай булса да куанабыз инде. Аннан яңа ел алдыннан тагын дүртәр йөз граммнан бирделәр. Трудка күпләп биргән өчен Басыйр абыйны райкомга чакырып партийный выговор биргәннәр. Тик, кире җыеп ала алмыйлар бит инде.*

*Сыер бозауламады әле. Сөте бар, саудыра. Үзебезгә — ашарга, малларга курмы бар. Тик өскә кияргә генә юк. Бригадта атлар җитешми. Малайлар үгез җигәләр. Кола бия колынлады. Колыны айгыр колын. Тышта түгел, двур өендә тора. Хирахау Мәҗит бабайга куаныч колыны. Хәйдәр кайтканчы менеп йөрерлек була, ди. Сиңа сәлам әйтте. Безгә тап төшермәсен, әйбәт иттереп хезмәт итсен, ди сине.*

*Син солдатка киткәнче йөргән Мәһирә апа Таракан Фәритенә кияүгә чыга, диләр. Чын, ахрысы, мине күрдисә, тиз генә үтеп китәргә тырыша. Синнән хат бармы, дип тә сорамый, элекке кебекләр иттереп. Моны язганга ачуланма, сине белеп торсын дидем. Кызларга ышаныч юк икән ул, кияүгә чыгуны гына күзләп торалар.*

*Лампаның керәчине бетә. Күп язылды, туктыйм инде. Сине бик сагынабыз, абый. Тизрәк кайта алмыйсыңмы?*

*Хат язучы энең Зөфәр. 16 январь, 1951 ел.»*

Хат килгәннән соң берничә көн Хәйдәр үзенә урын таба алмыйча яшәде. Ашады, автоматын тазартты, нарядларга йөреде, сафларда атлады. Кайтканыңны көтәм!»— дип калган Мәһирәсе Таракан Фәритенеке! Чыннан да ышаныч юк, ахрысы, кызларга!

Өч елын тутырып Хәйдәр авылга кайтып тагын колхоз эшенә чумды. Мәһирәсе башкага чыкты дип тормады, солдаттан кайтканына ел тулып үтүгә, күрше башкорт авылыннан төскә дә чибәр, эшкә дә үзе кебек уңган бер йомры гына гәүдәле башкорт кызын башкодалап, туйлап алдылар. Хәйдәр үзе дә уңды хатыннан, әнисе дә уңды киленнән...

* * *

Дүрт ат югалган көзне авыл үзенең көннәрен күңелсез уздырды. Көзге сугымнар үтә торган күңеллелек ул елны булмады авылда. Берьюлы дүрт ат югалу вакыйгасы авыл халкы күңеленә шом һәм курку салды. Шунлыктан сыер-башмак, ат симертеп сугымлыкка дип әзерләп йөргәннәр, кышкы беренче суыклар башлану белән үк ул малларны пычак астына тыктылар. Авылның көзге күңеле бик ныклап кителгән иде. Элекке еллардагы кебек күңелле иттереп мал суйган көнне кулламага йөрүләр дә булмады бу ел. Күпмерәк мае чыкты, иткә симез булдымы сугымнарың, дип сорашулар да булмады. Урамда очрашканда да сөйләшүләр үзара кыска бара һәм күбесенчә әлеге дә баягы, күбрәк шул югалган атлар тирәсендәрәк чуала иде.

— Милиция нәрсә ди икән соң инде? Табылырга өмет бармы икән соң? Теге атларны әйтәм.

— И-и, яшьти дус, яшьти ду-ус! Ул, Исмәгыйль, фуражкасын кырын салып, урам таптаудан бүтәнгә ярамый бит ул! Шул, безнең кебек калхузда изелмәс өчен милициягә барып тыгылды бит инде. Солдаттан кайткач ук. Берничә мәртәбә укырга барган булып йөреде шунда. Үзегез юк иткәнсездер әле, дип, ат хуҗаларына бәйләнмәк була икән. Ул хәтлек дүрт баш атны юк итәргә кемнең йөрәге житсен? Бар сөйләш син аның белән. Чижук кем инде аңарга! Көрпә Зарифы кем? Әгәр инде берәр зур урында эшләгән кешенең сарык бәрәне генә югалсын — тирә-якны актарып эзләтер иде.

— И-и, аларныкы югаламы соң? Начанстваның кайсысының мал тотканын күргәнең бар! Зур урында эшләгәннәрнең маллары барысыныкы да калхуз көтүендә. Алып кайтып азрак симертә дә — вәссәлам!

Икесе дә дәшми генә тәмәке көйрәтәләр. Бераз торгач, икенче яшьти сүзне йомгаклап куя:

— Калхуз малы көтүләрендә житәрлек. Элекке еллардагы кебек, буклы күтле бәрәненә хәтлек исәп юк хәзер. Бетте. Сайлап алып кайтып суя да куя. Начанстваның барысы да бер калыптан сугылганнар — харам ашарга өйрәнделәр. Алар хәзер ат каракларыннан да яманнар! Эзләми инде ул, ни эшләп, эзләп торсын ул югалган атларны...

Урланган дүрт ат хуҗалары яңа ел житкәнче милиция идарәсенә еш йөределәр. Тик милиция начальнигы Хәмитов атналар, айлар үткән саен ат хуҗаларына бер генә дә өметле сүз әйтмәде. Киресенчә, ат хуҗаларын күргән саен, йөзен каралтканнан-каралта барды. Яңа ел алдыннан ул аларны үзе утырган кабинеты эченә кертүне кирәк дип тә тапмады.

— Сез, агай-эне, кирәксә-кирәкмәсә дә, монда бертуктаусыз килеп йөрүегезне кыскартыгыз. Кирәк булсагыз, үзем чакыртып алырмын. Атларыгыз турында хәзергә бернәрсә дә ишетелми...

Бүлмәнең ишегендәге йозакны шалтыратып җиз ачкычы белән ачты да артында, ишек төбендә басып торганнарга карап та тормыйча, кереп китте.

Ат хуҗаларының өчесе башларыннан салган йөнтәс бүрекләрен кулларында әүмәләп, ишеккә юнәлделәр. Бүлмәсенә кереп бетә язган Хәмитовка бер ялгызы Чижук Хәйдәр генә иярде. Майор ишек төбендә туктады да ачуланып карады:

— Сезне монда керегез дип чакырмадым мин. Хөсәинов. Кая тыкшынасың әле син? Бар, эшеңдә бул. Минем вакытым юк синең белән сөйләшергә.

«Сез» белән «син»не ботап сөйләште. Хәйдәрнең юк кеше икәнлеген күрсәтер өчен.

— Син миннән вакытым юк дип кенә котыла алмассың. Булмаса табарсың. Мин сиңа ирекледән килмим монда, нужа бабай китертә. Син, минем югалган малларны эзләсен дип, гомерем буена налуклар түләдем. Мине моннан куарга синең хакың юк. Сталин бабай заманы түгел хәзер, курыкмыйбыз синнән.

— Бар, бар юлыңда бул. Кирәк булса, синең өчен генә мин монда Сталин чорын тиз оештырып алырмын. Бер дә булмаса, сине утырта торган Законны мин үзем дә язып ташлармын. Утырырсың аннан соң кәбестә суында. Син теге елны колхоз мөлкәтенә кул салып, утырып чыкканыңны онытма!

— Утырса, утырганмындыр, анда эшең булмасын! Ул төрмә дигән нәрсәләрдә без генә түгел, Лилин бабай да утырган. Язмыш, диләр аны. Агач башыннан йөреми, адәм башыннан йөри ул, язмыш.

— Шулайдыр бик! Колхоз малын урлау да язмыштыр!

— Ул да язмыш шул менә. Урласам, мин аны ач булганнан, бирмәгәннән, үзем үстергән ашлыкны алдым. Урлау түгел ул.

— Нәрсә инде алайса?

— Бирмәгәннән, үзебезгә тиешлене алу. Үзебез үстергәнне.

Хәмитов сүзнең зурга китә башлавын сизде. Бүлмәсенә кереп китте дә ишеген эчтән бикләп куйды. Хәйдәр, борыны төбендә ябылган, кара дермонтин ишеккә карап сөйләнде:

— Кереп китеп, ишек бикләп кенә котыла алмассың миннән. Синең өстән дә бар начанствалар. Юлын табарбыз...

Икенче көнне, иртәнге уннар тирәсендә авыл урамы буйлап Хәйдәрне ике милиция идарәләренә табан алып китеп бара иде. Каршы очраган берәү сорады:

— Кая алып киттеләр бу фиргәвеннәр сине?

— Теге югалган атларны тапканнар шикелле, шуларның берсен миңа кайтарып бирергә дип, милиция нәчәлниге чакырткан...

Хәмитов алдында яткан берничә кәгазьне урыннарыннан күчергәләп куйды да, башын күтәрде.

— Кичә, ишек аркылы, нинди юл табу турында ләпелди идең син, ә?

— Мин ләпелди торган кеше түгел.

— Нинди начальство турында сөйләндегез?

— Сөйләнмәдем. Син, давай минем атымны эзләт. Миңа бәйләнмә.

— Мин сезгә бәйләнмим. Тик монда килеп, начальник милициягә грозить итеп йөрергә бирмәм мин сезгә.

— Синең алдыңда хәзер минем атны урлаган кеше басып торырга тиеш. Аны табарга кулыңнан килми, ә үзең атларны тап дип килгәннәрне куркытырга болашасың. Юк эш ул. Курыкмыйм мин синнән.

— Шулаймы?

— Шулай.

— Кырык сигезенче елны син эләктеңме унбиш кило солы белән.

— Белмим шул, мин микән, түгел микән. Солы микән, арыш микән. Шул чактагы милициялардән сора инде син ул турыда.

— Менә архивта саклланган, синнән сорау алу протоколы минем алда. Синнән алганнар сорауны, миннән түгел...

Хәйдәр эченә йөгергән курку салкынын йөзенә чыгармаска тырышып, өстәлгә үрелеп карады. Һәм... өстәлдә яткан, картаюны белмәгән кәгазь кисәген танып алды.

— Имзасы синекеме?— дип сорады Хәмитов, тантаналы тавыш белән.

— Белмим шул, кемнеке икән.

— Синеке, синеке. Белмәгән булып маташма.

— Ул эшләргә инде утыз елдан артык вакыт үтеп киткән. Кемнәр генә дә, нәрсәләр генә урламадылар шул узган гомердә. Син үзең дә яхшы беләсең ул елларны.

— Белсәм, беләмдер. Тик минем урлыкта йөрегәнем булмады.

— Шулай дисең инде?

— Шулай дим.

Хәйдәр бераз вакыт дәшмичә утырды да, карарга килде:

— Атларны эзләүдән туктавың шушыдыр инде синең. Мине куркытырга чакырттың инде син. Болай булгач, ат каракларының борчагы пеште-е. Бераз дәшми торгач, сүзен дәвам итте.— Ә без нәрсә? Шул кара эш белән гомерләре уза торган бер калхуз мәхлүкләре инде без. Юньле аш, юньле кием, юньле мөнәсәбәт күргән юк. Этү төртү дә, мат, перемат. Иртә таңнан караңгы төнгәчә кара эш безгә. Анысы вуле—эшлә. Синең белән чәкәләшергә белем юк. Ул кырык ел элек булган унике килограмм арыш сиңа нәрсәгә инде? Шул мине куркытып дәшмәс итәргә. Чөнки эшләвеңнең рәте-чираты юк. Бар эшең урамнарда гәләфи чалбар белән хром итек киеп йөрү синең. Ярар, хуш! Син минем кебек кара крәстиян кайгысын аңлаудан әллә кайчан үткәнсең инде. Әйтәләр иде аны, милиция Исмәгыйльгә көнең калмасын дип—дөрес икән шул.— Ишеккә юнәлде.— Килмәм мин башкача сиңа. Чакыртып та болашма. Анысына да килмәм. Хуш! Ходай үзе ярлыкасын сине!

Ул бүреген кимичә кабинеттан чыгып китте. Шул көннән соң башкача милицияләргә килеп йөремәде. Атын эзләүдән дә туктады.

* * *

**1968** елның кыш башы иде.

Эстәрлетамак вокзалына «Уфа-Ишембай» пассажир поезды Уфа ягыннан килеп туктады. Дүртенче вагоннан таза гәүдәле — өстенә шинель, башына — бүрек, аякларына яшел чалбары астыннан ялтырап күренеп торган ботинкалар кигән майор төште. Кулындагы чемоданын җайлап тотты да, вагон ишеге төбендә калган олы яшьләрдәге проводница хатынга рәхмәт әйтеп, вокзал бинасына юнәлде.

— Исән-саулар йөре, туганым! Ходай ташламасын!— дип, татарчалап изге теләк теләп калды вагон хуҗабикәсе.

Офицер, инде хезмәт итеп тырыша-тырыша майор дәрәҗәсенә җиткән Чижук Хәйдәрнең бертуган энесе Зөфәр иде. Ул Эстәрлетамак вокзалына кереп, тирә-ягына карана гына башлаган иде, аңарга урысчалап дәштеләр:

— А-а, привет будущему генералу, сегодня... пока майору! Поедем?!

— Исәнме, дядя Николай,— диде Зөфәр татарчалап.— Тормышлар ничек?

Николай Иванович та, инде йоласын үткәреп, үземнең урыс икәнемне күрсәттем, шуның белән җитте дигәндәй, татарчага күчте:

— Эштән туктасам, үләм мин. Ике көндә үк. Бер көне эштән туктаганны аңларга китә, икенче көнне каберлеккә урын алу өчен мотаться итеп йөрергә кала. Бетте-китте шуның белән Николай Иванович! Вәсәләм! Прощай! Аннан соң минем илләмә дә җиде генә ел тулып үтте бит. Әнә Маршал Гречко алтмыш биш яшендә генә, ә үзе Оборона Министры. Синең начальник өстәвенә. Так что... Син нәрсә, ялгамы?

— Мәскәүгә килгән идем, командировкага. Бер атнага якын котәргә куштылар. Нәрсәләредер әзер түгел бугай. Кайтып килергә булдым, рөхсәт алып. Авылдагыларның хәлен белеп китим, дидем.

— Әйдә илтеп куям. Майор булгач, акчаң бардыр инде. Син лейтенант чагында да саран түгел идең лә.ул...

Икәүләшеп көлештеләр.

— Сез, урыслар әйтмешли, намек понял. Җый пассажирларыңны. Мин егермене бирермен.

Николай Иванович авызын ерды:

— Ун елдан артык йөретәм сине. Лейтенанттан майорга кадәр үстердем инде. Йөретеп калыйм әле. Сиңа генерал булырга да күп калмады инде. Генерал булгач, аннан соң танымассың да дядя Николайны.

— Белмим инде, булып булырмы икән. Татарларны бик сирәк күтәрәләр генерал дәрәҗәсенә...

Николай Иванович җаваплап тормады, өстәмә пассажирлар эзләргә китте...

Абыйсы белән җиңгәсе иртән эшкә киткәч, Зөфәр өйлә җиткәнче әнисе белән сөйләшеп утырды. Авыл хәлләрен, авылдагы агай-энеләрне, күрше-тирәләрне сөйләшеп беткәч, әнисе башка авыллардагы агай-энеләргә күчте:

— ...Акбаш авылындагы, әнисе минем әти белән бертуган Фәнзия апаң үлеп китте бит быел җәй. Тугыз баласы калды бичараның. Иң олысына егерме бер, иң бәләкәенә өч яшь тулып үтте. Әй тулы аяксыз да күтсез бер өер бала. Өелделәр дә калдылар бичаралар әнкәләреннән. Үләренә өч ай кала абзаң ат җигеп алып барган иде авылларына. Күреп калдым шунда. И-и-и, беткәние инде бичара. Бавырында рак, диделәр.

— Яшь иде бит әле ул?!

— Җәй көне кырык яше тулып кына узганые. Мин баргач бусагаларына чыгарып, паласлар җәеп, мендәрләр белән терәп, кояшка чыгарып утырттылар балалары җитәкләп алып чыгып. Кояшта утырдык шунда сөйләшеп. Озаклар иттереп. Сөйләшмәгән сүз калмады. Үзе бик туган җанлы иде бичара. Сине дә сорашты. Җәлләп тә алды сине, чит-ят җирләрдә, туганнардан еракта үтә гомере, дип. Яткан җиреннән йоклагандай иттереп онытылып та киткәли иде. Өч айдан гүр иясе булды.

Ныклап картая барган әнисе, тәсбих төймәләрен тарта-тарта, авыз эченнән генә догаларын укыштырып, сөйләде дә сөйләде:

— Әнисе, Хәтимә түти — абыстакай дип әйттерә иде үзенә — әти мәрхүм белән бер туган, төпчекләре иде. Әти, мәрхүм, зурлары, аннан соң Сәхибҗамал түти, аннан соң Хәтимә түти инде. Шушы үлгән Фәнзиянең әнисе. Әле дә исән-сау. Карт инде үзе. Яшь чагында, үскәндә, Миңлекамал дип йөртәләр иде үзен. Кулында, тәнендә миңнәре күп булганга. Өшкертеп, күкертле майлар сөртеп, бака сөяген киптереп, шуны төеп, кайнатып эчереп кенә бетерделәр миңнәрен. Шуннан соң тагын үз исеменә — Хәтимәгә кайтты. Акбашка Фазулла исемле кешегә кияүгә бирделәр...

— Ул бер өер бала белән езни нәрсәләр генә эшли икән инде? Барып хәлен белеп кайтырга кирәк әле, киткәнче.

Әнисенең йөзе караңгыланды.

— Барма, йөремә, ризалыгым юк.

— Нигә тагын?

— Апаң өстеннән туктамастан йөреде, уйнаш итте. Шуңа көенеп аның эчкәненә кайгырып авырды да инде Фәнзия. Үлгәненә биш көн дигәндә, өенә яңа бикәч алып кайтты. Киңәш юк, уңаш юк дигәндәй, илаһым. Авыллары тулы Фәнзиянең туганнары, агай-энесе. Монда — без. Бер балалы, үзеннән ике яшькә зур, Фәнзия өстеннән йөрегән эстерәпкәсен алган, диделәр. Белгән кешеләр әйтүе инде. Гайрәтле, би-ик зәһәр хатын, диләр. Рәхим кияүгә ачуым да, үпкәм дә бик зур...

— Балалары бик күп бит, аннан соң бик ваклар да инде...

— Анысы шулай ла ул шулайлыкка, тик оят кирәк бит. Өй эчендә Фәнзиянең...

Сөйләгәнен бүлеп, байтак кына күзләрен, борынын яулык очы белән сөрткәләп, мышкылдап елап алды.

— Әле син кайтыр алдыннан гына зур кызы Флүзәсе килгәние. Өстендә кышкы киеме юк, бичараның. Юка гына җәйге пәлтә кигән. Аяк-кулларда — ни җылы оек, ни бияләе юк. Үзе ябык бичаракай. Туңган, өшегән безгә килеп кергәндә. Пич янында җылына алмыйча әллә ничаклы торды басып. Шулай йөресә, ул балада нинди сәламәтлек кала инде?! Ана буласы кыз бала бит ул. Ярый әле абыең белән киленемә рәхмәтләр яусын. Абзаң чыгып китеп, өстенә җылы бишмәт сатып алып кайткан, аягына — җылы ботинкалар. Оекбаш, бияләйләр бәйләп кидердем. Үгәй-үгәй инде ул. Унҗидесе тулып кына үткән бичараның. Унны бетергән икән шушы елның җәендә. Салават каласына, әнисе белән бертуган Галиулланы эзләп китеп бара икән. Тегесе хат язган: «Кил, туганым! Забутка эшкә кертермен, убшежитиеда урын бирдерермен» — дигән. Ул баланы анда убшыга тыгып, хәзер кулдан-кулга китәчәк бит җыен эчкән егетләр арасында. Киңәш биреп җибәрдем. Галиулла үзләрендә тотсын, син кияүгә чыкканчы, дип. Анысының хатыны марҗа. Үз милләте булмагач, ничекләр генә иттереп каршы алыр икән инде, белмим.

— Берәр җиргә укырга керсә дә, соң бит инде.

— И-и бала-ам! Нинди уку ди инде ул аңарга! Забут инде аларга, кара эш. Шулай да марҗасын мактый торган иде Фәнзия. Галиуллага рәхмәт төшсен инде, үзе чакырткан бит әле ул.

Тыңлар кеше булганга, кулыннан көче китеп, үзе кеше кулына кала башлаган ана бик озак утырды улына кайгы-хәсрәтләрен, үзен борчыган уйларын сөйләп...

Икенче көнне Зөфәр күрше урамга чыкты да, шуның белән авыл уртасына атлады. Бераз баргач, артыннан исемен әйтеп кычкырдылар. Урам буйлап, кичә сөйләгән Фәнзия апасының ире, Зөфәргә езни тиешле Рәхим, күлмәкчән генә, башына да кимичә йөгерә иде. Хәле-тыны бетеп йөгереп килеп җитте дә күңелле иттереп, ике куллап күреште.

— Кайниш, нихәл, әй?! Исән-иминме? Әллә маюр булгансың инде? Мин солдат хезмәтендә булмагач, белеп тә бетермим инде, гафу ит.

— Майор.

— Мин кичә кичтән килеп кунган идем монда. Бүген дә кайтып булмас, ахрысы, эш чыгып тора. Әйдә керик әле, сөйләшеп утырыйк. Бик күптән күргән юк бит сине. Ишеткәнсеңдер инде, апаң да китеп барды бу ел җәй.

— Ишеттем, езни. Кайгың зурдан булган инде. Керик дисең дә, кемгә керергә соң?

— Менә монда, Ярмөхәммәт абзыйларга. Хатыны — Бибиямал апа. Беләсеңдер инде?

— Соң, белмичә тагын! Үзебезнең авылның кешеләрен белмәскә!

— Әйдә, әйдә. Бер утыру — бер гомер, ди картлар. Апаңны искә алырбыз. Сине бик ярата торган иде... мәрхүмә була инде хәзер.

Зөфәр китеп барган ягына карап алды.

— Мин Югары очка, укытучыларымның хәлен белергә китеп бара идем бит әле.

— Ярар, барырсың әле. Иртәгәләргә. Апаң үлгәч, сезнең нәсел-нәкеләр бар да читләшеп бетте миннән. Бер абыең калды... Әйдә инде, ялындырма.

Езнәсенең тавышында өмет катыш ялвару ишетелә иде.

Рәхимнең кемне туктатканын Бибиямал апа тәрәзәдән күреп таныган, ахрысы. Ачык йөз белән каршы алды.

— Әйдүк, Зөфәр, әйдүк. Чишен, түрдән үт. Батинкаларыңны салып торма — карның пычрагы юк аның. Үт.

Зөфәр утыра башлаган арада езнәсе сәке астына үрелеп, бер кычыткан капчык тартып чыгарды. Капчык авызын бәйләгән сүс бауны чиште дә, бик тонык булган сыеклык тутырылган чирекле шешә, ысланган зур бер балык, чүпрәккә төргән, башланган түгәрәк ипи чыгарып өстәлгә тезә барды. Тагын нәрсәдер кирәк иде, ахрысы, капчык эчендә зур куллары белән эзләнә башлады. Капчыгыннан чыгармыйча гына аның эчендәге әйберләрне бер урыннан икенче урынга шул капчык эчендә генә күчереп эзләде.

— Нәрсә эзлисең инде тагын?— диде Зөфәр.— Җиткән бары, тукта.

— Бик шәп бер балык консирвасы бар иде. Табып булмый каһәрне.

Рәхимнең юан бармаклары капчык төбеннән тартып чыгарып яхшы иттереп урап бәйләгән сүз арканны идәнгә салды. Арканны алгач, башы күн савытка тыгылган, кыска саплы уртача зурлыктагы балта күренде. Барысы бергә бәйләнгән дүрт зур пычак, озын кайрак та бар иде капчыкта. Зөфәр боларның барысын да, езнәсе эзләгән консерва банкасы күренмәсме дип караганда, күреп өлгерде. Консерваны капчыкның бер почмагыннан табып алды Рәхим. Зөфәр алдын-артын уйлап бетермичә әйтеп ташлады:

— Син балталар, пычаклар, кайраклар белән безнең авылга әллә берәрсенә мал суярга дип килдеңме?

Рәхимнең тынгысызланган күзләре астан өскә Зөфәргә өздереп карап алды. Ул караашта сагайганлык та, усаллык та чагылып китте сыман. Тик шунда ук тонык кына элпә белән капландылар күзләр һәм үзләренең төсен югалттылар. Ул үзгәрү шулхәтлек тиз булды ки, хәтта Зөфәр эчтән генә нигәдер тетрәнеп алды.

Иданнән алып арканны тиз генә капчыкка тыкты. Балта-пычакларны каплап куйды аркан белән.

— Юк ла-а, нинди мал сую, ди инде монда-а.

Тавышында ниндидер табигый булмаган киеренкелек яңгырый иде.— Кирәк булмасмы дип алган идем дә, кирәкмәс, ахрысы...

Капчыкның авызын бәйләп, аягы белән аны сәке астына этте. Өстәл янына урындык куеп утырды. Өстәлдәге әйберләрне барлап, кечкенә табын әзерли башлады. Сүзсез генә карап утырган Зөфәр езнәсенең кул бармакларының калтыранганнарын күреп калды. Юан, көчле бармаклар вак-вак кына итеп дерелдиләр иде. Зөфәр күзен читкә алды: нәрсәгә дулкынлана бу езни? Рәхим дә үзенең куллары калтыраганны сизде. Ике куллап чирекле шешәгә ябеште:

— Самагун бу. Бик шәбе, первачы инде. Җибәрик азрак, апаңны искә алыйк!

— Сал!— диде Зөфәр, үзе балта, пычаклар, аркан һәм калтыраган бармаклар турында һаман башыннан чыгара алмыйча. Езнәсенә карамаска тырышып кабатлады.— Сал, әйдә самогоныңны! — Елмаерга тырышып өстәде: — Ул төнлә туганны капкан юк иде әле, эчеп карыйк нинди була икән.

Езнәсе киеренкелеге бетеп җитмәгән тавышы белән сөйләп, көлгәндәй итте:

— Кирәк инде анысы да. Замана урысча китте бит инде хәзер, кая бармак кирәк.

Ике сәгатькә якын утырдылар. Самогон күп, ашарга бар. Тагын нәрсә кирәк инде бик озак күрешмәгән езни белән кайнишкә. Азрак сасы исе булса да, самогоны чыннан да шәп, гайрәтле иде. Тик сөйләшү генә барып чыкмады. Рәхимнең күңел тыңгылыгы юк иде, сөйләшкән сүзнең барышын югалткалады. Яхшы гына иттереп утырганнан соң, Рәхимнең ай-ваена карамыйча Зөфәр китәргә җыенды. Шулчак сөйләшкәндә әйтәсе сүзнең иң кирәген әйтеп калырга булды Рәхим.

— Әбигә, әниеңә диюем инде, син, Зөфәр, әйтеп кит инде. Фәнзия юк дип, мине читкә какмагыз. Ул балалар сезгә дә туганнар бит, сезнең кан да ага бит аларда, минеке генә түгел. Бер ялгызым ул хәтлек баланы ничекләр генә иттереп үстерим, ди инде мин. Ярдәм кирәк бит...

— Мин аңлыйм, езни барысын да. Шуңа кердем дә инде син чакыргач...

— Рәхмәт, рәхмәт, кайниш! Рәхмәт!..

* * *

1978 елда Зөфәр Ырымбурда хезмәт итә иде. Шулчакта Фәнзия апасының иң зур улы Фәиз йөк машинасы белән Ырымбурга килеп чыкты да, Зөфәрләрдә кунарга туктады. Заводларына запчастьләр алырга килгән икән. Зөфәр эшеннән кайтканда ул инде марҗа хатыны белән аларның фатирында утыра иде.

Кич байтак сөйләшеп утырдылар. Фәизнең шунда, уйлап бетермичә сөйләгәннәре, Зөфәргә 1968 елның декабрендә, авылда, Бибиямал апаларда езнисе Рәхим белән очрашуны һәм аның капчык эчендәге балта-пычакларны, сүс арканны исенә төшерделәр.

— ...Миңа унбер яшьләр чамасы иде ул чакта. Әти мине кичләтеп җылы гына иттереп киендерде дә, төнгә каршы каядыр алып чыгып китәргә итә. Әни чыга торган ишеккә аркылы басты килеп, кулларын җәйгән, чәче тузылган. Әтигә әйтә: «Бирмим баламны ул эшеңә. Шушында бусагада суй, Рәхим, риза түгелмен. Барыбер бирмим улымны ул юлга алып кереп китәргә!»— ди. Өй тулы балалар елаша. Аларга ияреп мин дә тотындым шыңшырга. Урамда җигүле ат белән әтинең әтисенең энесе Хикмәтулла бабакай көтеп утыра без чыкканны. Әни җибәрмичә

алып калды мине шунда. Кая алып барырга иткәннәрдер инде, әле дә белмим...

Белмим дип эчкән баштан сөйләнеп утырса да, белгәнлеген күзләреннән чамалап була кебек иде.

— Кайсы Хикмәт ул?

— Әйтеп торам бит инде, минем картәтинең бертуган энесе, дип. Беләсең син аны. Йортлары безнең йортка терәлеп тора. Чатан ул, сул аягы тездән юк. Авылда Агач аяк Хикмәт дип йөртәләр аны.

— Ә-ә!— дип исенә төшерде Зөфәр! Аның аягы теге, Герман сугышында яралангандыр инде? Тот әйдә!

— Юу-у-ук шу-ул!— диде Фәиз, аракы тулы рюмкага үрелеп.— Үзе теләп кистергән ул аны. Уналтынчы елны.

Зөфәр айнып ук китте:

— Ничек инде ул, үзе теләп кистергән?

— Әйдә җибәрик моны, абзый кеше. Шуннан сөйләрмен.

Голтылдатып эчеп бетерде дә, шатырдатып тозлы кыяр капты.

— Яшь чагында ат караклары белән буталган ул. Уналтынчы елны Герман сугышына китәргә чират җиткән моңа. Иптәшләре карар кылганнар: Бармаска! Бер литр чуаш самогонын эчеп, лаякыл исереп тәгәрәгән. Ике иптәше пычаклар белән тездән сул аягын кисеп ташлаганнар. Сеңерләрен кискәннәр дә, тездән түбән аягын алып ташлаганнар...

— И-и, менә сиңа-а! —дип исе китеп утыра Зөфәр.

— Шула-ай!— ди Фәиз. Абыйсы Зөфәрнең исе китеп тыңлаганга кәефе килеп. Колхозлар чыкканчы ук, ат каракларын ата башлагач кына, ташлаган ул атлар урлавын. Хәзер колхозда читават булып эшли бит инде. Тыныч эше...

— Аяксыз, ничекләр итеп урлаша алган инде ул?

— Атка атланып барган ул.

— Атка атланыпмы?

— Әйиеме! Биленнән, кулбашларыннан кысып бәйли торган каешы бар аның. Ат эшлиясе кебекләр иттереп ясаган үзе. Ат корсагы астыннан икенче яктан китереп чыгара да, теге тездән юк аякны шул каеш белән ныгытып бәйләп куя. Прәжкәләр ярдәмендә. Шуннан тора да чаба, куып та җитеп булмый.

— Әллә күргәнең дә бармы?

— Бар. Теге элекке байлар җирендәге совхозда дус казакъ кешесе бар. Шунда еш кына баргалый ул...

* * *

Өстәл янында аз-маз эчкәләп утырганда сөйләшкәннәрнең күбесе онытыла бара бит инде. Читтә йөреп авыл тирәсендә нәрсәләр булганын ишетсә, сөйләшсә дә, Зөфәр оныткан кебек иде. Тик 1984 елны җәйге ялга кайткач, энесе Фәизнең сөйләгәннәре аның исенә үзеннән-үзе килеп төште. Сочида ял иткәннән соң, ялының ун көн чамасы вакыты калганга азрак урау булса да авылына кереп, туганнарын, ялан-кырларны күреп, сагынуларны азрак басып китү иде максаты. Аннан инде картая барган әнисенә шатлык ясап, азга гына булса да күренеп китү иде исәбе.

Бу юлысы авылда атна яшәгәч, китәсе итте. Соңгы ике кичне әбиләрендә кунды. Әйберләрен җыйнап, авыз эченнән генә көйләп уйларына чумган җиреннән аны хатынының әнисе айнытып җибәрде.

— Рәхмәтләр төшсен инде сиңа, кияү. Бик игелекле кешесең син. Ярдәмең үзеңнекеләргә дә җитә, безгә дә өлгерәсең. Син булмасаң, бу хәтлек күп бала-чаганы без бабаң белән генә аякка бастырып бетерә алмас идек...

Мондый рәхмәтләрен әбисе киявенә кайткан саен укый, аңарга исәнлекләр тели. Зөфәр инде ул сүзләренә өйрәнеп беткән, башын селкеп елмая гына.

— Менә икене бездә дә куныш, күңелебезне күрдең тагын. Абыеңа да, кодагыйга да рәхмәтләр яусын. Ходай синең исәнлегеңне бирсен инде...

— Амин әби, шулай булсын!

Әбисе, тагын нидер әйтәсе килгәндәй, тамак кыргалады:

— Кияү! Сиңа гына сөйли торган бик тә сикритний сүзем бар. Тик монда, өй эчендә сөйләргә ярамастыр. Берәрсенең тыңлап торуы бар.

Зөфәр көлеп җибәрде.

— Нинди сикрит икән инде ул синдә шул хәтле? Үз өеңдә сөйләргә курка торган. Әллә бабай турындамы?

Әбисе дә елмайды.

— Юк ла инде. Бабаңның сикрит җирләре бетте инде аның. Вчу. Ул әйбәт хәзер. Яшьрәк чакта кытыр-мытырлары булгалаганые. Бигрәк тә сугыштан җиңеп кайткач. Хәзер бетте... Минем сөйли торган, чыннан да бик тә хәтәр эш турында ул, кияү. Сөйлисе кеше тик син генә. Башкача юк. Сиңа да сөйли алмасам, ул серенең йөрәгемне кысып шартлатуы бик ихтимал.

Зөфәргә кызык була башлады.

— Сине шундый хәлгә җиткерерлек булгач, сөйлә алайса. Тыңлап карыйк.

— Мин, кияү, ишек алдына мунча стенасы янына ике урындык куйдым. Мунча эчендә кеше юк. Үзем тикшереп, тыштан ишеген бикләп алдым. Ачкычы менә үзем белән.

Әбисе чуар чүпрәк бәйләнгән зур гына ачкыч күрсәтте.

— Әйдә без шунда чыгып утырыйк. Анда аулак.

— Әйдә соң. Син, әби, шпионнар турында кинолар карарга яратасың. Шуның шаукымыдыр инде бу «сикритең»нең килеп чыгуы.

— Әйтмә инде, кияү. Бу дөньяда яши-яши мин дә Эштирлис булып беттем бугай инде.

Мунча янына чыгып утырдылар. Әбисе ярым пышылдап сөйли башлады:

— Син, кияү, көлмә дә, ачуланма да. Сабыр гына тыңла инде. Чит-кара ишетеп калса, мин сөйләгәнне — икебезнең дә башын юк итәрләр... Минем сөйләгәннәрне тыңлагач, син берәр хәл кылырсың дип уйлыйм мин. Тик мин сөйләгәннәрнең күбесе фактылар түгел...

Карчык каян башларга дип уйлап алды һа, ниһаять тапты бугай.

— Син үзең белән башлангыч классларда укыган Әхмине хәтерлисеңдер бит?

— Кайсы, теге Черки Әхмәдулланымы?

— Ие, шуны.

— Соң хәтерләмичә тагын. Буе бәләкәй булган өчен без куштык бит аңарга «Черки» дигән исемне.

— Ярар, урыс әйтмешли, анысы ниважный. Шул Черкинең башы гомере буена калхуз эшеннән чыкмады. Үзе бичара ни юньле аш, ни юньле кием күрмәде.

— Әтисе сугышта ятып калды бит. Әниләре биш бала белән торып калды иреннән.

— Анысы шулай ла ул аның. Мин бит сиңа бүтән нәстә сөйләмәкче булам әле. Шул Черки сезгә кода тиешле бит инде.

— Әййе. Акбаш авылы Рәхим езнинең бер малае Черкинең Җәмилә исемле кызына өйләнгән бит.

— Шул, шул менә. Черки кызын синең езнәңнең малаена биргәч,— әбисе тирә-ягына карап алды да, пышылдауга күчте: — китте баеп, китте баеп. Баюының ушы юк, мин сиңа әйти-им. Соңгы өч ел эчендә өенең

түбәсен калай белән яптырды. Үзенә өр-яңа лигкавай автамабиль алды. Әрмиядән кайткан улына матай алып бирде, Киявенә, ягъни синең энеңә йорт салдырды. Кенижкәсендә кырык ике мең акчасы да бар, диләр...

Зөфәр көлемсерәп сорады:

— Анысын син каян беләсең инде?

— Беләм инде, кияү, тучны беләм. Тик син миннән төпченмә каян белгәннәрне. Авыл бит монда, сердәшләр җитәрлек.

— Син нәрсә әйтергә телисең соң әле, әби?

— Син тыңлап бетер инде, кияү. Тагын бер нәрсә калды.

— Сөйлә, әби.

— Черкинең кияве, синең Сибгат исемле энең инде, бик боталана хатыны өстеннән бер чит нәстәкәй белән. Башка авылдан килгән хатын ул. Мукшы хатыны. Энең шуфыйр булып эшли. Даружныйда. Машинасына утыртып алып чыга да китә икән теге хатынны. Черкинең малае, солдаттан кайткач, апасы котыртуы буенча, бик кузгалып караган езнәсенә каршы. Барып чыкмады. Черки үз малаен гурыткa, икенче апасы янына тиз генә озатмасынмы. Сибгат минем улыма, ул да шуфыйр бит, бергә эшлиләр, мин Черкине менә кайда тотам дип, йомарлаган йодрыгын күрсәтә икән. Мин кушканча гына безелди Черки, мин кушмасам, кунган җирендә генә утыра тавышсыз, ди икән...

Зөфәр утырган җиреннән кузгалып куйды.

— Син, әби, бик тә серле иттереп сөйлисең. Ә иң мөһимен әйтеп бетерә алмыйсың шикелле. Әйт шунысын да.

— Әйт дисеңме?

— Әйт шул.

— Черки Әхми кызын синең езнәңнең малаена биргәннән соң, китте баеп, китте баеп. Капылт кына, бик тә тиз һәм шәп иттереп. Соңгы ун ел бардыр инде, йорт саен кереп йөреп сөт җыйды. Аена шуңарга илле-алтмыш тәңкә чыга инде. Ярар, сөт белән әвеш-түеш китереп, су кушыр, алдап үлчәп тагын, үтә китсә йөзне чыгарсын да ди инде. Ай саен. Тик алай булмый ул. Ярар, булсын да ди инде. Аңарга бит биш елда, биш ел юкта әле ул, яңа йортлар салып, машина, матайлар алып, ике йортның башын калай белән ябып булмый бит... Син теләсәң нәстә уйла, теләсәң нәстә әйт, кияү, синең езнәң Рәхим, мал урлаучыларның, ат каракларының башлыгы!

— Нәрсә сөйлисең син, әби?!

— Тыңлап бетер. Инде миңа җитмеш ике яшь тулды. Исәнлегем бик начар, кияү. Дөнья хәлен белеп булмый, мин белгәнне син белеп тор. Башка берәүгә дә чишмәдем мин бу серне.

Әбисе азрак уйлангандай утырды да, дәвам итте:

— Безнең елгага караган тәрәзәдән Черкинең капка төбе дә, ишек алды да яхшы күренә. Ерак түгел, инеш аша гына бит. Берәр олы мал — сыер, башмак, берничә сарык югалыр алдыннан синең езнәң Черкигә матай белән килеп җитә. Авылы Акбаштан килеп төшә. Кунган чаклары би-ик сирәк була. Икенче көнне Черки өйләдән соң юк була. Сөтне хатыны җыя. Черкине күбрәк вакытта авырып ята дип ялганлый. Олы мал югалгач, Черки ике көннән кайта.

Синең абзаңнан аты белән тагын өч ат югалган чорда, Черки дә ике көн юк булып торды. Шул атларны урнаштырып йөргәндер дим. Мин ике рәт бардым, сөт өчен акча сораган булып. Хатыны, авырып калага чыгып китте, диде. Кайсы калага? — дип сорагач, тәки әйттереп булмады шунысын. Сүзне икенчегә борды.

— Син әби, әллә нәрсәләр казып чыгарырга булашасың бит. Ай-һа-ай, болар чын булса би-ит...

— Чын, кияү. Черкинең кияве аны кешегә дә санамый. Кеше бар дип тормый, юк дип тормый — бер җикерә бабасына, тегесе түзә. Үзең дә беләсең, Черкинең карахтиры түзә торганнардан түгел бит. Бу эшләр

юньле булып бетмәсләр инде алар, кияү. Сиңа сөйләдем-сөйләвен дә, тик син дә сак була күр. Тәккә генә ычкындыра күрмә берүк.

Әбисе тынгысыз күзләре белән киявенә карап ала да, өмет тулы сүзләрен сөйли:

— Ходай кушып, ялгышкан булсам ярар иде дә бит. Минем сөйләгәннәр ялгышка ошаганнармы соң, кияү?

— Мин уйлыйм әле, әби. Әхминең тиз баюлары, маллар югалган чакларда берничә көннәр юк булып торулары — бик тә хәтәр фактлар инде. Бәлки, берәр туганы ярдәм итәдер, ә?

— И-и, кеме итсен инде. Бар да кул көче белән яши. Аннан, туганнары бөтенесе кызлар бит. Каян артсын инде хатын-кыздан. Бик сак булыйк, кияү. Мин ярар инде, яшисен яшәгән, дигәндәй. Алар, сизеп калсалар, кешене юк итүдән дә тартынып тормаслар. Сарык, сыер малыннан җылкыга күчтеләр бит. Халыкта ат күбәйде хәзер. Мин әле бәләкәй чакларда бу тирәләрдә күп иде ат караклары. Тотсалар, урамда йөртеп, кыйнап үтерәләр иде. Бер елны Әбрәнең атларын урлаган өчен Гыйльван башкортны ике иптәше белән урамда, арканнар белән бәйләп йөртеп, кыйнап үтерделәр. Күсәкләр белән. Әхмәт байның кибете артында кыш көне, бер атна яттылар. Кешеләр барып-барып карыйлар иде шуннан. Күлмәк-ыштаннан гына калдырып кыйнап үтерделәр.

— Үзең күрдеңме кыйнаганнарын, әби?

— Үзе-ем, кияү, үзем! Кыйнадылар, кыйнадылар да кайтып өйләне ашап килделәр. Шуннан соң тагын кыйнадылар. Инде теге мескеннәр атлый алмый башладылар кыйналганнан. Шуннан картлардан берсе әйтә, Ходайга тапшырып, бетереп куйыйк инде бу эшне, ди. Шуннан башларына күсәкләр белән сугып бетереп куйдылар тегеләрне.

Йә, Хода-ай! Үзең ярлыкагыл гонаһлы бәндәләрне!

Икенче көнне беркемгә дә, бернәрсә дә сөйләмичә, әбисе сөйләгәннәрне әле башына сыйдыра да алмыйча, Зөфәр авылдан Мәскәүгә чыгып китте. Йортыннан тик капка төбенә генә чыгып утырып, беркая барып йөремәгән карчык, район милициясе булдыра алмаган эшнең нигезен аңлап, шуны киявенә җиткергән иде...

* * *

Рәхим мал урлашу кәсебенә Агач аяк Хикмәт бабакаена ияреп ундүрт яшендә тотынды. 1942 елның февралендә трудәрмиягә алынган әтисеннән хатлар килүдән туктаган чак иде. Аннан соң Тәтербаш авылы чуашы язган хат белән әтисенең үлгән хәбәре килде. Йөзе кара янып чыккан әнисе ике тәүлек тормастан урын өстендә ятты. Ике яшьлек энесен Рәхим үзе карады. Кәчек кебек артыннан ияреп йөргән энесенә кәҗә сөтен савып эчерде. Бәрәңге пешереп ашатты. Үз янында йоклатты.

Әнисе аякларына басып йөри башлаганга атна тирәсе үткәч, күршедә генә торган Хикмәт бабакае кичләтеп кенә аларга килеп керде. Исәнлек-саулык сорашкач, кечкенә капчыкка салган ун кадак чамаларындагы онны бирде.

— Менә, җиңги, азрак арыш оны сиңа. Балаларга төче күмәч пешер. Рәхимне кичкелеккә алып чыгып китәм мин. Бик ашыгыч эш килеп чыкты.

«Ашыгыч эш»нең нәрсә икәнен җиңгәсе яхшы белә иде. Чөнки ире белән энесе Хикмәт гомерләре буена ул «ашыгыч эш» белән төннәр буена мавыгалар иде. Иренең ычкындырганнарын хатын белә, аларның нәселе борын-борыннан ук атаклы ат карагы Ишмораттан ук килә. Бүре кан эчмичә, аяклы малны егып ашамыйча көн күрә алмаган кебек, боларның нәселе дә тере мал янында кәсеп итмичә яши алмый инде.

Хатын янагаеның сүзләренә актан да карадан да дәшмәде. Чөнки иренең үле хәбәре килгәннән соң, нәселләрендә ирләрдән иң олысы булып Хикмәтулла калды. Андый әйтелгән сүз, ирләр сүзе, хатын кешегәмени инде, каршы төшеп торырга. Кичен чыгып китәргә дип киенә башлаган ундүрт яшьлек улына күпне күргән, күпне белгән күзләре белән карап әйтте:

— Бу авыр чикмәнне сал, улым. Әнә теге иске куфайканы ки — җиңел булсын... эшләргә дә... йөгерергә дә. Биленне атаңның билбавы белән бу. Кирәге чыкса, аны мал мөгезенә дә, муенына да салырга, бәйләргә була. Аягыңа искерәктән, тапа ганнан чабата ки. Аякларың таеп китмәсеннәр. Бар нәрсәдә бабакаеңны тыңлап кына йөре. Аллага тапшырдык, улым! Бар!

Юллары, егерменче елларда алпавыт Гапкадыйр Тукаев җиренә салынган «Байрак» совхозына, шул елларда авылларыннан күченеп утырган Хисаметдин картка булды. Караңгы төшеп, күз бәйләгәч барып керделәр таныш картка. Җигүле ат белән, Хисаметдин карт авырсынып тора икән. Кәефе чамалы булып, тунын, бүреген, пималарын киеп, сәкесендә, мичкә аркасын терәп ята иде.

Килеп кереп сәлам биргәч, Хикмәт агач аягы белән так та ток килеп карт янына үтте дә, сәкегә утырып дога кылды. Аннан соң гына исәнләген сорады:

— Син нәрсә, кордаш абзый?! Авырып алырга чамаладыңмыни әле?

— Шулайрак булып тора әле, Хикмәт энем. Бөер яныннан китереп кысты, тын алыр әмәл юк. Инде билдән югары үрмәли-үрмәли, җилкәгә менеп, кәкерәйтеп куйды. Тураеп булмый.

— Ала-ай! Без менә энекәш белән калага узып барышлый кергән идек. Кунып китү... исәб-бе белән. Нишләрбез икән, алайса?

Хисаметдин карт авыр иттереп ыңгырашты да, үзенең зарын сөйләп китте.

— Би-икләр дә яфаланам шул. Зөһрә карчык кичә дә, бүген дә килеп өшкереп киткән иде дә китүен. Әрекмән белән бака яфрагы да ябып карадык. Юк кына бит, алалмыйлар. Алла-а, Алла-а-а...

Тын алуы да гыжлап чыгып, авыр бара иде шул.

— Атаң мәрхүм исән булса, мунчага алып кереп сылар иде дә, аннан соң аркага менеп таптар иде. Торыр идем мин. Куллары катырак булса да, кайсы җирне басарга, кайсы җирне сылап сыйпарга белә торган иде ул.

Хикмәт Агач аяк аның зарланганын азрак башын иебрәк тыңлап утырды. Кузгала бирде аннан соң.

— Алайга киткәч, без калага бару юлын туктатыйк. Туктатыйк шушында. Иртәгә иртүк мунча ягып, тәүгесенә икәүләшеп керербез. Ул сылау-таптауның әллә нәстәсе юк аның. Беләм мин аны. Әти мәрхүм дә ах-ух килеп кайтып керә торганые. Төрле кәсепләреннән. Кенендә мунча яктырып, өчәр-дүртәр сәгать ята торганые билен җылытып. Мин малай чактан ук биленә ике аяклап менеп таптый торган идем. Аннан кул белән сылый торганыем...

— И-и Хикмәтулла! — дип куанды карт. — Болай булгач, Ходай тәгалә сине үзе җибәргән бит инде миңе терелтергә. Таңнан торып мунча ягарбыз, иншалла.

— Ярар, шулай итәрбез. Әнә Рәхим белән ягарбыз.

— Ай, Алла-ам! Рәхмәтләр яугыры җан икәнсең! Ходай уйламаган җиреңнән китереп бирсен инде... Сиңа да, миңа да... Әййе...

Таң белән ягылган мунчага, төнен башкарган кәсеп эшләреннән өнсез калган Рәхимне керттеләр. Беренче парга.

Әмма Рәхимнең уенда мунчада парлану, юыну түгел иде әле. Тик тулганды да, тулганды мунча эчендә тас, себерке күтәреп. Аның күз алдыннан төнлә булган хәлләр китмәделәр...

Төн икенче яртыга авышкач, атны җигеп, тавыш-тынсыз гына «Байрак» совхозы ягына юл тоттылар. «Биле авырткан» Хисам карт догаларын укый-укый такта капкасын ябып, өенә кереп китте. Инде курку йөрәгеннән башына күчә башлаган Рәхим үзендә арбадан төшеп, авыл ягына йөгереп кайтып китү теләгән көчкә генә җиңеп, басып килә. Белгән догаларын укый...

Киртә эчендә совхозның берничә йөз сарыгы ябып куелган. Төнге каравылда торучы казакъ зур гәүдәле ике этен «ирекә чыгарган» да, үзе, күрәсең инде, каравыл өенә кереп йокларга яткан. Күренми бер җирдә дә. Сарыклар торган киртәгә ярты чакрым тирәсе җиргүле атны зур гына тал куагы төбендә туктаттылар. Хикмәтулла бабакае, түгәрәк, калын табанлы иттереп ясаган «чабатаны» агач аягына киде. Арба эченә салынган печән астыннан кечкенә киндер капчык тартып чыгарды да, капчык эченнән кәкере сыер мөгез алды.

— Нәрсәгә алар, бабакай? — дип сорады калтырануын баса алмыйча Рәхим.

— Эченә эретеп туңмай агызылган аларның. Караулга куелган этләргә азык. Мөгез каты, ә эчендә май бар. Этләргә бирәбез шул мөгезләрне. Кимереп төне буена яталар алар хәзер. Тик өрдерми генә биреп өлгерергә кирәк. Миңа ияреп барганда аягыңны тач минем кебек иттереп, җиргә терәп шудырып кына бар. Күтәрмә җирдән. Адымнарың вак кына булсын. Чабата озынлыгы гына. Этләре каравыл өе янында булыр.

Сыер мөгезләрен куеныга тыкты да, капчыкны сул кулына алды.

— Биш йөзсә алты сарык безнеке булырга тиеш. Курыкма, каравылчы казакъ чыкмаячак өеннән.

— Ә капчык нәрсәгә?

— Баргач күрерсең...

Рәхимнең йөрәге күкрәгеннән атылып чыгарлык булып тибә башлады. Кан сулкылдап баш миенә бәрә иде. Курыкканын бабасына сиздермәскә тырышып, аңарга иярде. Кузгалганда бабасы төн караңгылыгына кулы белән төртте:

— Әнә, сукмак килә, күрәсең?

— Йу-ук, күренми бер нәрсә дә...

— Тал куагын күрәсеңме?

— Биек булып тора, шулмы?

— Әййе. Шул тал куагын урап сукмак уза. Тал янына җиткәч, акрын гына сызгыр. Менә болайрак иттереп...

Бабакаеның иреннәре арасыннан нечкә генә, бик тә акрын сызгыру килеп чыкты.

— Аннан соң инде киртәгә кил. Тик сакланып кына, мин өйрәткәнчә генә атла. Аңладыңмы?

— Ә син?

— Мин этләргә мөгез ташларга тиешмен башта. Мин кузгалгач, син кабаланмый гына йөзгә хәтлек сана да, аннан кит теге сукмакка табан. Яме!

— Яр-ар-ар!

— Курыкма, улым! Син бит атаклы Ишморат, Рәвил нәселеннән. Алар бернәрсәдән дә, беркемнән дә курыкмаганнар. Без егетләрнең асыллары, кирәк булса, арыш чумары ашап кына да яши беләбез. Кирәк чагында, дию ем. Ходайга тапшырдык!

Агач аяк Хикмәтулла авыз эченнән генә «бисмилласын» әйтеп, караңгылыкка кереп югалды. Аның аягы астында бер генә «чылт» иткән тавыш та ишетелмәде. Китте дә, һавада эрегән кебек юк та булды...

Рәхим куркуыннан калтырана-калтырана, йөзгә кадәр санады да, камырга әйләнеп, бөгелеп-сыгылып торган аяклары белән караңгылыкта, күк йөзе яктылыгында чамаланып күренеп торган тал куаклыгына карап атлады. Үзе Аллага ялварды: «Әй, Ходаем! Әгәр шушы, бүгенге куркыныч... баш китә торган... эштән исән-сау котылсам, башкача бер-

кайчан да йөремәс идем мондый... кәсепкә. Зинһар мине коткара күр инде, милициядән дә, өтермәдән дә...»

Догалар укый-укый Ходаена ялынса да, эшен онытмады. Тал куагы янындагы сукмакны табып баскач, иреннәре арасыннан тыныч өреп сызгырып болашты. Тик сызгыру урынына ниндидер ысылдау гына килеп чыкты. Азрак «сызгыргалап» торды да, бабакае кушканча, сарыклар ябылган читән абзар ягына курка-курка гына атлады. Абзарның капкасыннан сарыкның ике ботыннан тотып, аны арткы аяклары белән атлатып, Хикмәтулла бабакае килеп чыкты.

— Тот аякларыннан да, алып кит арбага табан. Мин икенчесен алып чыгам хәзер.

— Курка-ам ми-ин!—диде Рәхим, аның тешләре бер-берсенә шыкшык бәрелә иде.— Тотса-ала-ар!

Бабакае ачуланмады. Пышылдады:

— Әти мәрхүм белән тәүге барганда, мин арт яктан җиппәргән ием куркудан. Беренче мәртәбә шулай була ул. Тот!

Сүзләрендә елмаю төсмере сизелә иде.

Йөгертә-атлата биш сарыкны арба янына ташыдылар. Алып килгән сарыкларны аякларыннан бәйләп, арбага төйи бардылар. Сарыкларны төягәндә Рәхим сарык башында атка кидерә торган кечкенә нукта кебек нәрсәне шәйләде. Сарыкларны төяп бетергәч, азрак хәл керә башлады Рәхимгә.

— Нукта нәрсәгә сарыкка?

— Авызларына ипи дә тыгылган әле аларның. Шул инде, тавыш чыкмасын өчен.

Төялгән сарыкларны тиз генә арбага беркетеп аркан белән бәйләп чыктылар. Аркан озын һәм сүстән өчәрләп ишелгән иде. Дилбегәгә бабакае үзе тотынды.

— Тапшырдык Ходайга! Бисмиллаһир-рахманир рахи-им...

Бераз баргач, туктадылар да кочагы белән эскерттән салам алып килеп, сарыклар өстенә салдылар. Тавыш-тынсыз гына, каршыларына бер генә кешене дә очратмыйча, төн икенче яртысына авышкан бер чакта Хисаметдин картка кайтып керделәр. Атлы арба йорт янына килеп җитүгә, зур такта капка тавыш-тынсыз гына ачылып китте. Караңгыда Хисаметдиннең акрын гына әйтелгән тавышы ишетелде:

— Аллага мең шөкер! Исән-иминсез икән...

Ишек алдына кергән уңайга ук арба капкаларын киң иттереп ачылып куелган сарай эченә кереп китте.

Биш сарыкны өч сәгать чамасы вакыт үтүгә суеп, тунап, эшкәртеп эшен бетерделәр.

Таң атар вакыт җитәргә бер сәгать чамасы вакыт калганда Хисаметдин абзый бакчасының басуга караган ягында пар ат җигелгән бричка килеп туктады. Бричкадан төшкән, урта гәүдәдән кайтышлы, аркасында уасы чыгып торган, үзе таза ир кеше, исәнләшеп баш кына какты да, сарык түшкәләре эленеп торган сарайга атлады. Бричка төбенә җәелгән зур брезентка биш сарык түшкәсен тезеп салдылар. Брезент белән төрделәр дә, салам белән каплап, бәйләп тә куйдылар. Уалы кеше кожанын киеп, аның башлыгы белән йөзен бөтенләй күренмәслек иттереп башын каплады да, бричкасына үрмәләде. Кожанының зурлыгыннан аркасы бөкрелеге бөтенләй сизелми иде. Дилбегәсен кулына алып, атларын кузгатты да, кала юлына чыгып та китте. Хисам абзый агач тырма белән бричкадан төшкән саламнарны тырмалап җыйды. Ә Хикмәт белән Рәхим тырмага эләкмичә калган саламнарны берәмтекләп чүпләп алдылар...

Яктыруга, өлгергән кара мунчага кордашының улы Хикмәтулла Хисаметдин абзыйсын зур чүпрәк паласка салып, Рәхим белән бергә паласның дүрт почмагыннан тотып, күтәреп алып киттеләр. Алар атлаган уңайга, урамда да ишетелерлек итеп Хисаметдин карт каты иттереп ыңгыраша иде...

Рәхим мунча эчендә бер чабынып, бер юынып ялгызы вакыт үткәрде. Ә Хисаметдин бабай белән Хикмәт бабакае мунчаның алдында, чишенеп, күлмәк-ыштаннан гына, мунчадан чыккан җылыда изерәп, җиз самавыр борыныннан агызып, ачы бал чөмерәләр иде. Хисаметдин карт яртылаш тешсез калган авызы белән сарыкның йомшак иттереп пешерелгән бавырын авызында әүмәли-әүмәли чәйнәп болашкан җиреннән, мунча эченә ымлады:

— Сарык төягәндәге курыкканнарын каен себеркесе белән куа инде бу егет. Ничегрәк булырга охшаган соң, беренче чыгуда?

Хикмәт голтылдатып балны эчте дә, стаканын янә картка сузды:

— Сал, тутырып! Миннән шәпкәрәк чыгар дип уйлыйм мин Рәхимне. Курыкса да, каушап калмады. Аллага шөкер, алмаш бар, болай булгач. Бетми әле безнең нәселнең... ат караклары. Еллар иминләнер, ташларбыз сарык урлап йөрүләрне. Сугышлар бетәр, колхозлар таралыр, атлар үрчер, Иншалла!

— Амин, шулай булсын! Тоттык!

1943 елның язы каты ачлык алып килде. Алынасы ирләр сугышка, трудармиягә алынып беттеләр. Ундүрт, унбиш яшьлек малайларны, кызларны ФЗУ[1] га җыйнап озата башладылар. Завод-фабрикаларда сугыш өчен корал ясарга эшче куллар күп кирәк иде.

Хикмәтулла бабакае белән биш сарыкны ит итеп калага озаткач, шул ит акчага әйләнеп кире кайтты. Бабакае Рәхимнең өстенә барысы да солдатныкы булган киемнәр алып кидерде: яшел солдат бушлаты, яшел чалбар, башына солдат бүреге. Эчтән кияргә ак бәстән күлмәк-ыштан.

— Кәсеп акчасы бу. Монысы әниеңә күлмәклек.

Ак бәскә төргән кечкенә төенчек тоттырды.

— Тегүен тексен, тик кеше арасына киенеп чыгып йөремәсен. Җәйгә кияр. Каян алдыгыз дип сораганнарга, ранный солдат сатып бирде, арзан гына хакка диегез.

Өстенә киемнәр дә килеп кергәч, әнисенә күлмәклек тә булгач, Рәхим беренче мәртәбә сарыклар урлаганда куркып, исән-имин калсам, башкача урлашмас идем дигән сүзләрен оныта башлады. Алама-сәләмә киенгән иптәшләре арасында, бушлат белән бүрек тә, солдат чалбары да бик шәпләр иде.

Бабакае ачлык елларын күп күргән, күп кичергән кеше иде. Ул шунлыктан яхшы белә бер нәрсәне. Ачлык елны кайда ничекләр иттереп ашарга пешерү. Чөнки мич эчендә пешерәсеңме, казандамы — пешкән ашның, бигрәк тә итнең исе урамга чыга һәм ач авыл өстенә тарала. Урамда җилле, буранлы-яңгырлы төннәр алар инде әнә шул урланган малның итен пешерергә тәгаенләнгәннәр. Җилле-буранлы урамда кемнең пешергәнен, иснең каян килгәнен белеп булмый. Буранлы, яңгырлы төннәр озак булмый торсалар, итне, төче күмәчне урмандагы тирән чокыр төбендә салынган мичтә пешереп алып кайта Хикмәтулла. Ул чокыр эчендәге мичне үзеннән башка беркем дә белми.

1943 елның ноябрь урталарында Рәхимне авыл советына чакырдылар. 1918—19 елларда Бояр урманындагы партизан отрядында сугышып йөргән Мотыйгулла иде авыл советы рәисе. Ул Рәхим белән кыска гына сөйләшү үткәрде.

— Энем, яшең җитте. Унбишең тулып үтте бу ел җәй. Чиләбе каласына, фызуыга җибәрәбез сине. Анда ашаталар, киендерәләр. Бер атнадан районга китәргә. Алты егет, дүрт кыз кирәк диелгән разнарядкада.

— Әни авыру безнең. Бәләкәч энекәш бар. Кем карый аларны?

— Совет влачы карар, энем.

— Язын чак кына үлмәдек бит ачлыктан.

---

[1] ФЗУ — фабрика-завод училищесы.

— Син монда контр сүзләр сөйләмә. Белдеңме? Колхоз идарәсенә кереп язу ал. Ун кадак бодай оны тиеш сиңа. Әниеңнән төче күмәч пешерт. Юлга ашарга. Тик кара аны, аяк-кулың, башка җирләрең урыннарында булсын. Зыян саласы булма, югыйсә...

Кайтышлый ук Хикмәтулла бабакае янына, колхоз идарәсенә керде. Бабакае колхозда хисапчы булып эшли иде. Рәхимнең сөйли башлаганын тыңлап та бетермәде, туктатты һәм өстәл янына диварга сөяп куйган агач аягын үрелеп алды. Кия башлады. Җентекләп, ике пар каеш белән юан ботына тарттырып бәйләп куйды да урыныннан торды:

— Әйдә, Мотыйкка керик әле.

Тик, идарәдән чыгуга ук, биек баскычлы бусагага менеп килүче, Күпер төбе Фазулланың Фәнзия исемле төпчек кызына тап булдылар. Түгәрәк йөзен матур иттереп вак кына көрән сипкелләр баскан, тулышып килгән түгәрәк гәүдәле иде кыз.

— Кызым , бар да өйлә ашына таралдылар. Йомышың булса, берәр сәгатьтән кил, яме! — диде Хикмәтулла агач аягы белән баскыч такталарына тыкылдатып баса-баса. Тик баскычтан төшеп бетмәде, нәрсәдер сизенеп туктады. Фәнзиягә текәлеп карады:

— Йомышың ни иде, кызым?

— Фызуыга җибәрергә итәләр. Ун кадак бодай онына дип кыягаз язып бирделәр. Шуңарга дип килә идем.

— Ал-лай! Сине дә алалармыни инде?

— Алалар.

— Әти-әниең нәрсә диләр инде?

— Әни елый. Әти әйтә, хөкүмәт кушкач, китәргә кирәк, ди. Биргән чакта барып оннарын ал, ди.

Кыз азрак кызара биреп сорады:

— Әни өйдә елый да елый. Мин кәнсәләргә кереп утырып көтим әле, килгәннәрен. Өйгә кайтасы килми, күңелсез анда...

— Бар, кызым, бар! Кер, көт. Менә безнең Рәхимне дә алалар бит әле...

Кызның үзенең хәле хәл иде, күтәрелеп карамады. Кереп китте.

Икәүләшеп йортларның читәннәре яныннан атладылар. Хикмәтулла җәен-кышын башыннан салмыйча кигән бүреген маңгаена этәрде дә туктап калды. Рәхим аңарга бәреләязды.

— Инәңнең... карап киләсеңмени, чучка борын? — диде бабакае күңелләнгән тавыш белән. — Кунганың бармы бу кыз белән?

— Кайсы кыз?

— Әле, кәнсәләр баскычында очраган сипкелле кыз белән?

— Юу-ук, Барый белән йөри бит ул.

— Кайсы Барый ул тагын?

— Сыерчык Бәдретдин малае, Барый.

— Ә-ә, шуныкымыни?

Тиз генә Рәхимгә карап алды:

— Кунарга кирәк ул кыз белән.

Рәхим кып-кызыл булды. Тик сер бирәсе килмәде, эре генә иттереп җаваплады:

— Бүтәннәр белән кунып йөрегән кызлардан башка да җитәрлек миңа. Аннан юан бит ул.

— Юан, имеш! Димәк ки ашарларына бар. Калхузлар чыкканга кадәр аның атасы пар ат җигеп, авылга тавар ташып, кибет тоткан сәүдәгәр иде.

Уйлап килгән уйларының очына чыгарга болашып, сорау бирде:

— Бүген аулагыгыз кайда була?

— Мәчтүрәләрдә.

— Иртәгә?

— Әллә, белмим әле...

— Ярар, белмәсәң, бар, кайт. Өйләдән соң кил он алырга. Калхуз рәисе кул куйганнан соң, миңа бирерсең әле авыл советы биргән кыягазыңны.

— Ния тагын?

— Күпне белсәң, тиз картаерсың. Бар, юлыңда бул.

Уйлап бетергәннең билгесе иттереп, башындагы бүреген арткарак этте дә, өч урам бергә килеп кушылган урынга, Күпер төбе Фазуллага төшеп китте.

Кичен Рәхимне үзләренең мунчасына алып кереп, көне буена уйлап йөргән серен ачты:

— Фызуыга бармыйсың. Өйләндерәм мин сине. Өйләнгәнне фызуыга алмыйлар. Өйләнгәч, сезне гаилә, диләр. Иртәгә аулак беткәч, Фәнзияне урлыйбыз. Чаптар Гаптериләрнең абзары артында качып торабыз да, ат белән, авызы-башын томалап, салабыз да алып китәбез...

Рәхим нәрсә дип әйтергә белмичә, бабакаена карап, тик кенә утыра иде.

— Безгә алып кайтабыз да, бездә кунасыз...

«Кияү» буласы унбиш яшьлек малай телгә килде:

— Алып кайтып, нәстә эшлим мин аның белән?

Бабакае кулларын күңелле иттереп күтәреп селтәде:

— Чишенеп, бергә яткач, кирәге үзеннән-үзе килеп чыга аның. Хатын белән йоклау, ат урлау түгел. Анда баш белән эш итәсе юк. Теләк кирәк тә, теге, нием... кирәк аннан соң.

«Кияүнең» бирешәсе килми иде.

— Кирәкми ул миңа. Барый белән йөриләр бит алар.

— Харап булган икән. Йөриләр икән. Ә үзең ничә кыз белән йөрдең?—Ул куе кашлары астыннан ачулы күз карашын ташлап алды.— Син минем белән шаярма, энем. Син хәзер авылдан чыгып китсәң ул фызуыга, кире әйләнеп кайтмыйсың. Кем алып бара безнең нәселнең кәсебен? Так чту...

— Фәнзия кирәкми миңа. Мин бит Бану белән йөрим. Әйдә алайсак Бануны урлыйк.

Хикмәтулла бүреген маңгаена табан шудырып, азрак уйланып утырды.

— Юк!—диде ул. Нәселләре бик тә усаллар. Сине кәсептән туктатачаклар алар. Ә Фәнзия юаш. Син аны ничек телисең, шулай бора алачаксың. «Ых», дигән тавышы да чыкмаячак. Бел шуны син, тукранбаш.

Рәхим өметле тавыш белән сорады:

— Әгәр Фәнзия Барый белән кунарга калса?

— Калмый. Барый иртүк калага китә. Ике көнсез кайтмый ул.

«Кияү» буласы малай ризалашты.

* * *

Кыз урлау, ат урлауга караганда да шәбрәк килеп чыкты. Йорт почмагыннан, чыркылдашып, атлый-йөгерә кайту ягына ашыккан ике кызның гәүдәгә тәбәнәгрәген толып белән каплап алдылар да крандаска китереп салдылар. Туң юлдан чаптырып алып та киттеләр. Кызның, курыкканлыктандыр инде, кычкырырга көче дә, тавышы да табылмады. Өй почмагында басып торып калган икенче кыз, крандас күздән югалганчы карап торды да, көнчелеге бәреп торган сүзләрне тезде баштарак:

— И-и иллаһһ-һым! Бәхетле кызларны үсеп бетмәс борын ук урлыйлар! Сугыш бара дип тормыйлар! Мине дә шулай берәрсенә урласыннарые. Бер тавышымны да чыгармасыем шулай. Инде унтугыз белән киттем бит...

Зарлануыннан тукталды да буш урамга карап алды. Чәрелдәп кычкыра-кычкыра кире якка, әле генә икәүләшеп чыккан аулак өйгә карап йөгерергә тотынды:

— Кар-рравыл! Фәнзияне-е урладылар-ар! Ярдәм итеге-гез! Карра-выл!

* * *

Рәхим белән Фәнзия, икесе дә балалыктан чыгып бетмәгән унбиш яшьлек малай белән кыз гына булсалар да, гаилә кебегрәк нәрсә оештырып, яшәп киттеләр. Ике ел Рәхимнең әнисе белән бергә яшәделәр. Тапкан-табынганны бергә тотып, юаш бием белән юаш килен бергә киңәшләшеп, Рәхимне бергә тыңлатырга тырышып, бик тату дөнья көттеләр.

Яши башлаганнарына берничә ел үтмичә Фәнзия иренең «кәсебе» турында башына да китермәде. Тыныч кына иттереп дөнья көтте. Иренә ияреп чыгып китеп, колхоз эшендә йөреде. Эшләде, мал табып мул яшәргә омтылды. Кул көче белән.

1945 елның май башында сул кулын беләзектән госпитальдә калдырып, Рәхимнең абыйсы кайтып төште. Кайтканына атна үтүгә, үзе белән алып кайткан консерваларын, чучка майларын табынга куеп, «кайту шатлыгы» кичәсен уздырды. Ике орден, берничә медаль таккан солдат гимнастеркасын киеп, өстәл башында утырган килеш, кунакларны сыйлый-сыйлый күңелләрен күрде. Икенче көнне әнисен, Рәхим белән аның хатынын сәкедә, шаулап торган самавыр янында җыйды да сүзен әйтте:

— Сез, Рәхим белән Фәнзия, башка чыгыгыз. Чөнки йорт төпчеккә тиеш. Мин хәзергә монда калам. Күреп торасыз үзегез кул югын. Шунлыктан районда сөйләшеп кайттым, мин авылда йон, күкәй, тире җыярга тотынам. Агент по заготовкам, диләр аны...

Тавыш-тынсыз гына үзен тыңлап утырганнарга карап чыкты. Каршы әйтүче юк иде.

— Энекәшне үстерешергә ярдәм итәрсез. Мин Бикмулла бабай белән сөйләшеп килештем. Хикмәтулла бабакай эргәсендәге, кырык өчтә ачлыктан үлгән сеңлесенең өен сата безгә. Акчасын мин түләдем инде. Кичә кич Хикмәтулла бабакай белән өй хакын т ләп, мәгәричен дә эчеп чыктык. Ул йортны сатып алу бабакайның уе.

— Акча каян таптыгыз?—дип сорады Рәхим.

— Таптык инде. Акча бездә бер букча!—диде абыйсы елмаеп.— Йорты әйбәт кенә. Юыгыз, тазартыгыз, күченегез! Тәрәзә пыялаларын куегыз да...

Фәнзия бер нәрсә дә күрмичә, белмичә яшәгән кебек иде. Тик алай булмаган икән шул.

Урланган малларны эшкәртеп, акчага әйләндергәч, Хикмәтулла Рәхимгә, бик күптән булмаса да, өлешен чыгара иде. Хатыны Сәгыйдә, килендәше, Фәнзиягә итләтә дә, онлата да, ярмалата да нык ярдәм итә иде. Туганлык хисе иттереп карады Фәнзия андый ярдәмгә. Туры килгән чакларында үзе дә буш итмәде, җавапсыз, күчтәнәчсез калмады.

Рәхим хатынын бернәрсә дә белми дип яшәп караган иде. Тик бик нык ялгышкан булып чыкты. «Юаштан юан чыгар!»—диләр. Фәнзия кебек акыллы юашлар турында әйтелгән мәкальдер ул.

Зур уллары Рифкә ун яшь тулгач, Рәхим, Хикмәтулла бабакае кушуы буенча, улын төнге кәсепкә алып чыгарга булды. Суык булмаса да, өстенә җылы куфайка, башына бүрек киерде. Мич янында эреле-ваклы тагын өч малай белән кайнашкан Фәнзия иренең әзерлек алып барганын тавыш-тынсыз гына күзәткәләп, янындагы балалары белән мәш килә иде. Киенеп беткәч, сәке астына тыгылып, киндер капчыгын кулына алды да, Рәхим сул кулы белән улын ишеккә этте:

— Киттек, улым!

Ана яшен тизлеге белән ишеккә ташланды. Бөркет коштай кулларын җәеп, ишекнең ике кәчәгенә ябеште. Арты белән эткәнгә ишек киң иттереп ачылып китте. Хатынның ике күзе дә тәвәккәллек белән тулган, аларда ачу, каршы торучанлык бик көчле иде. Ундүрт ел буена бергә яшәп, хатыныннан бер генә каршы сүз дә ишетмәгән Рәхим азрак аптырый биреп, туктап калды. Чөнки хатынның күзендә куркуның әсәре дә юк иде.

— Си-ин... нәрсә-ә?!! — диде Рәхим, тамагыннан кысылып чыккан, гаҗәпләнгән тавыш белән.— Ки-ит ишектән!

— Кит-ми-им! — дип җаны белән ачыргаланып пышылдады ана,— бирмим баламны-ы!

— Ки-ит, дим мин сиңа, яхшылык белән! Ки-ит!

— Ю-у-ук, китмим! Үтер! Сук! Кис! Бусагага салып, капчыктан балта-пычакларыңны алып чапкала, кискәлә! Бирми-им улымны-ы!

Рәхим капчыгын идәнгә куя башлады:

— Чыгарма ачуымны! Кит!

— Бирмим баламны! Бирмим! Үзем исән чакта бетертәм мин синең ул кәсебеңне! Бетертә-әм. Бел шуны!

Капчык шакылдап идәнгә төште. Рәхим кулын сузып, хатынына атлый гына башлаган иде, өй эчендә һич көтелмәгән хәл килеп чыкты. Мич янындагы өч бала чәрелдәшеп, кычкырып елашып, йөгерешеп килделәр дә әниләрен сырып, кочаклап алдылар. Төрлесе төрле яктан әниләрен кочакладылар. Барысы да бергә үкереп елыйлар иде. Рәхимнең янында басып торган зур улы бер адым атлагандай итте дә туктап әтисенә карады. Бер генә сүз дә әйтеп тормады, әнисенә ташланды да аны якларга тырышкандай алдына барып, әтисенә йөзе белән борылып басты. Аның кечкенә гәүдәсендә әтисенә каршы тору көче ташып тора иде. Ике як күз карашларын чәкәштерделәр.

Рәхим идәннән капчыгын иелеп алды да, хатынын, балаларын читкә селтәп ташлап, өеннән чыгып китте...

Өч көн өенә кайтмады. Сакал-мыегы җиткән хәлдә, нык таушалып, ябыгып кайтып керде. Иртән иртүк мунча яктырып, бик озаклап мунча керде. Тәненең бик күп урыннары кыйналып күгәргән иде. Озак иттереп чабынды, әрекмәнле-әремле эссе су белән күгәргән җирләрен юды. Сыер мае белән сөртеп, бөтен тәнен сылады. Хикмәтулла бабакае исә Рәхим кайтканнан соң, тагын дүрт көн узгач кына күренде. Анысы да ару гына кыйналган иде...

Ире кайтканга берничә көн узгач, Фәнзия, кичен йокларга яткач, җылысы бөтенләй беткән сүзләр белән, үзенең еллар буена җыйналган уй-хәсрәтләрен чыгарып салды:

— ...инде ничәмә-ничә еллар эчәсең. Түздем. Чит-ят хатыннар белән чуалдың. Түздем. Уйнашыңа да. Бала-чага хакына түздем. Урлашып, тирә-як авылларның ятим хатыннарына кадәр зар елаттың...

— Син нәстә-ә монда...

Рәхим яткан урныннан күтәрелергә омтыла. Тик күкрәгеннән кочаклаган, йомшак, ләкин көчле куллар аңарга торырга ирек бирми.

— Син, Рәхимҗан, тыңлап бетер мине. Бу хакта мин башкача синең җаныңны бимазалап сүз кузгатмам. Моңа кадәр кешегә дә чыгарганым юк...

— Минем урлашканым юк...

— И-и, Рәх-хим! Хикмәтулла бабакаең белән син бергә урлашкан малны бер урынга җыйсаң, авыл көтүеннән күп була, зур була...

Хатын азрак уйлагандай итеп ятты да, тагын телгә килде:

— Минем кебек исәнтәй дөнья йөзендә юк ул. Ач яшәгәнем юк — Аллага шөкер! Ипекәй вүле, ит-май җитәрлек. Бәрәңгене, аны инде әйткән дә юк. Кием ягы да кешенекеннән әйбәтрәк инде. Синең теге тегермән тарта торган дбижукта эшләгәнеңнән күрә идем тәүге елларда.

Ә синең кәсеп бөтенләй башка икән. Бездә бер ел яшәгән Әндри дәдә ачты иң башта минем күзне. «Фая, смотри за Рахимом. Он на руки нечист» — диде. Мин ул «нечист», дигән сүзне аңламадым да, белмим дә. Сорадым нәрсә була ул, дип. «На воровство уходят по ночам»,— диде. Көлдем башта, кулымны селтәп. Шуннан дәдә Әндри эшен калдырып кайтып киткәч, уйлана башладым. Сезнең угрылыктан куркып киткән дип уйлыйм мин аны...

Фәнзия калтыравын баса алмыйча урынында торып утырды. Кискен, азрак боерыклы тавыш белән әйтте:

— Угрылыктан туктыйсың. Бүгеннән үк. Әгәр туктамасаң, үзем барып сөйлим милицияләргә еллар буена угрылыкта йөрегәнеңне. Беткән баш беткән. Бур балалар үстерәсем килми дә, үстермәячәкмен дә!

Рәхим тетрәнеп китте. Елыйсы урынга, Фәнзия елмая иде. Терәлә биреп иренә сыенып ятты да, пышылдап ыграк кысылып елыша башлады:

— Соңгысы булуы да мөмкин. Кил бер назлыйм әле үзеңне. Әгәр инде кәсебеңне ташламасаң, чыннан да бу соңгысы булыр. Иллә чыпчык үлми — яшәрбез әле. Иншалла, балалар үсеп киләләр. Абыйларым бар...

* * *

Шул төннән соң басылды Рәхим. Кәсебен ташлап, ныклап колхоз эшенә тотынды. Тегермәндә онга манчылып байтак еллар эшләде дә, аннан соң он-тузаннан йөткергәли башлагач, колхоз мастерскоена күченеп, токарьлыкка кереште. Тумыштан куллары оста булганнан, нәрсәгә тотынса, шуны булдыра белә иде.

Рәхим «кәсебен» ташлагач, иң авыры картаеп килгән бабакае Хикмәтуллага булды. Балалары кайсысы кая таралып беттеләр. Тик «кәсеп» ягыннан өч малаеның берсе дә булдыра алмадылар. Каннары куркаклыклары белән хатыны ягына тартканнар иде шул. Йортта төпчек малае Минхан исемле улы белән калды Хикмәт карт. Тик малайдан бер генә тамчы да уңмады. Үзе генә түгел, бөтен авыл белән шулай уйлыйлар. Ни бер яктан укып белем ала алмады. Киреле-күтле җидене бетерде дә, башкача укымады. Шуның белән, вәссәлам! Колхоз эшенә дә күңелен салып эшләмәде. Ат белән дә, трактор-машина тирәсендә дә үзенә ямь тапмады. «Кәсепкә» дә алып чыгып карады әтисе улын. Икесенә чыкты. Өченчегә киендерә башлагач, әнисенең ике ботыннан барып кочаклады да, өй эчен яңгыратып, урамга ишетелерлек иттереп сөрән салды:

— Бармый-йм! Курка-ам ми-ин! Бармый-йим!

Кыйнап та, үгетләп тә карады. Файдасы тимәде, уңышка ирешә алмады Агач аяк Хикмәт уллары ягыннан.

Үзе янына, колхоз идарәсенә хисап эшенә урнаштырды. Шунда эшләр-эшләмәс көннәрен уздырды, җайлап-җайлап эчкегә салыша башлады. Инде соңгы елларында эшен бөтенләй ташлап, ата-әнкәсен, туганнарын, өч бала тапкан хатынын да тыңламыйча, авылның өеннән-өенә кереп йөреп... буш, аракыдан калган шешәләр сорашып җыеп, шуны кибеттә аракыга алмаштырып көннәрен үткәрде. Шулай иттереп, эчке томанында йөрде-йөрде дә, күпер астына төшеп, муенына элмәк салды.

Алкашка әйләнгән улыннан да калгач, Хикмәт карт тиз бирешге, тиз бетеренде. Рәхим «кәсептән» туктаганнан соң, картның яшисе килгәннән битәр, тормыштан туйган көннәре күбрәк булдылар. Бердәнбер юанычы — Рәхимнең балалары, үзенең оныклары иде. Ул кичен ир балаларны үз янына җыеп ята да, агач аягын чишеп, диварга сөяп куйганнан соң, оныкларына төрле әкиятләр, хикәяләр сөйләргә тотына. Әкият сөйләгән жиреннән туктап, өе яныннан гына, тыкрыктан шагыр-шогыр килеп узып барган арбаларны тыңлап кала. Ул арбаларның кемнеке булганын, кая

китеп барганын яисә каян кайтып килгәнен янында, әкият көтеп яткан, «ат караклары нәселеннән килгән»,эреле-ваклы малайларга ачыклый:

— Әнә, авылның иң очына, тугайга зу-ур йорт салып куйган Садыйк малае Шадра Хәбир кайтып бара бу арба белән. Ул, ялангагы төнге камбайнда караулда торган санала инде. Төягән тек төягән инде бу бодайны. Арбасының ыңгырашуын гына тыңла, никадәр салган бит бу. Ай-һа-ай! Хәзер бер сәгатьтән кире китә инде ул...

Авыр иттереп көрсенеп куя да, бурлык сагышын моң урынына сүзгә күчереп, бетереп куя:

— ...бар әле ул дөньяда бәхетле... кешеләр...

Бик тә «бәхетле бурлар» диясе килә инде аның. Тик бала-чага әкият көтә бит...

Шадра Хәбир үтеп китеп, арба тавышы тынып та өлгерми, әле генә ул киткән яктан даңгор-доңгыр килеп шалтыраган буш арба тавышы ишетелә. Шартлатып чыбыркы белән атын яргалап, кабаланып чаба арбага утырган тавышсыз кеше. Бер генә кеше дә ишетмәсен дип, тавышын чыгармый бу кеше. Тик...

— Монысы инде Юан Гайшә малае Аксак Рәвил була. Йорт тәрәзәсеннән утын яндырмый гына Шадраның үтеп киткәнен карап ятты инде ул. Ат җигүле, арба майланган, үзе дә, хатыны да киенгәннәр. Хатыны йоклый — вакыт әрәм итми. Барып төйи инде ул хәзер 12—14 капчык бодайны-ы. Кырчын үрен төшкәч тә, тал арасына кереп поса да, ялангa ашыккан Шадра Хәбирне уздырып җибәрә. Таң караңгысына кайтып җитә инде...

Озак кына сүзсез үзенең уйларына бирелеп ята. Сорый:

— Йокламадыгызмы әле?

— Йу-ук! — дип беравыздан сузалар малайлар. Икесе ике яктан аңа сыеналар. Читтәрәк яткан икесе кулары белән сузылып, бабакайларын кочаклыйлар. Яраталар малайлар Агач аяк Хикмәт бабаларын. Чөнки аның кебек авылда башкача бер генә кеше дә кызыклы иттереп әкият сөйли белми. Ул гына, аларның Хикмәт бабакайлары гына...

— Тагын сөйләле, бабакай, Шадра Хәбир турында әкият. Аннан соң Таз турында?

Бите буйлап аккан күз яшьләрен каткан бармак битләре белән сөртеп ала да, теге Герман сугышына бармас өчен тездән кистергән сул аягының баш бармагы сызлый башлаганын дога укып басарга тырышып карый. Тик бармакның сызлаганы көчәйгәннән-көчәя генә бара. Онытылып булмасмы дип, янә әкият сөйләргә тотына:

— Борын-борын заманда Шадра Хәбир шома булганда, Озын Гәйфи кыска булганда, Танау Фәрите алдый белмәгәндә, Песнәк Зәйнетдин песәй булганда яшәгән, ди бер Таз. Тик ул башка малайлар кебек гади Таз булмаган, ди, ә атлар урлый торган караклар нәселеннән булган, ди...

Малайларның иң кечкенәсе, дүрт яшьлеге бабакаена тагын да ныграк сыена да, Агач аяк һич көтмәгән сорауны бирә:

— Ул ат карагы Тазның ике аягы да булганмы, бабакай?

Тигез җирдән сөрлегеп киткән ат кебек, Хикмәт карт сөйләгән әкиятенең сүзләрендә тотлыгып китә. Малайның аркасыннан сакланып кына иркәләп кага:

— Булган, улым, ул Тазның ике аягы да булган. Ике кулы, ике колагы, ике күзе, ике борын тишеге булган. Тик башында чәче генә булмаган Тазның.

Менә бервакыт Таз кәсебеннән кайтып килә икән. Юл читендә би-ик карт бер бабайны күргән Таз. Ап-ак сакаллы, ертык бишмәт кигән, чабаталары тишек икән дә, бүрегенең бер колагы ертылып төшәр дәрәҗәгә килеп җиткән булган. Хәле-тыны бетеп җәйге эссе кояш астында утыра икән теге бабай. Таз атын туктаткан, сикереп төшкән атыннан да,

юл читендә утырган бабай янына чүгәләгән. Хәл-әхвәлен сораган, кымыз эчергән бабайга, казылык белән ипи биргән. Бабайга әйткән:

— Кирәк дисәң, менә атымны да бирәм. Бик ярлы күренәсең, бабай. Тот тезгенен! — дип, атының тезгенен бабайга сузган.

Карт ашаган-эчкән Таз биргән ризыктан. Тик атын алмаган. Янындагы ямаулы капчыктан чыгарып, Тазга бер каеш йөгән белән бер каеш камчы биргән. «Күңелең киң синең, рәхмәт шуның өчен. Кәсебең җан белән бәйләнгән синең. Көч, гайрәт вә тәвәккәллек белән. Мин, заманында синең кәсеп белән йөргән, ат каракларының иң курыкмасы, атаклы ат карагы Рәвилнең җаны булам. Шушы каеш йөгән белән каеш камчы сиңа миннән бүләк булсыннар. Рәхмәт сиңа, безнең кәсепне бетермичә саклап алып барганың өчен. Бу йөгәнне атка кидерсәң, ат күренмәс була. Шул атка атлансаң, үзең дә күренмәс буласың. Камчы белән койма, дивар, капкаларга суксаң, менгән атлы үтәрлек булып барысы да җимереләчәкләр. Куркуны белмәс булсаң, камчы да, йөгән дә шушы сихри көчләрен югалтмаячаклар. Сиңа тугры хезмәт итәчәкләр. Әгәр инде үз гомереңдә бер генә мәртәбә булса да курыксаң...

Хикмәтулла карт, юк аягының баш бармагы сызлаудан туктаганга куанып, малайларның тын алуына колак сала. Йоклаганнар сабыйлар. Уйларын телгә чыгармыйча, үзенә-үзе эчтән генә әйтеп куя:

— Тагын бер генә тапкыр, иң соңгы тапкыр гына чын бер ат урларга насыйп булсачы. И-э-эх, Фәнзия, Фәнзия-ә! Бетердең бит нәселне. Рәхим печтергән эт кебекләр иттереп кенә яши бит синең янында-а. Койрык ботап кына. Әйтер иде миңа: «Әйдәле, бабакай,— дияр иде,— бер шаулатыйк әле тирә-якны. Син теге дөньяга киткәнче, урланган ат исе исник әле,— дияр иде, Рәхим миңа.— Каныңны бер кыздырып ал әле,— дияр иде ул, чын ат карагы булса-а...»

Йөрәгенең иң түреннән агылган ат карагы сагышы белән бергә Агач аяк Хикмәтулланың күзләреннән кайнар күз яшьләре тама.

Ат каракларының картлыгы барлык җир йөзендәге кешеләрнекеннән дә авыр була. Бу хакыйкатьне тик үзе ат карагы булмаган кеше генә аңлый алмый...

* * *

1965 елны, утыз җиде яшьлек Фәнзия тугызынчы баласы итеп малай тапты. Баланың тырпаеп торган ике кечкенә, түгәрәк колагына, таррак маңгаена, киң итеп утыртылган кечкенә соры күзләренә карап, куанычлы иттереп елмайды:

— Монысы да тач атасы. Аллага мең шөкерләр, бәхете, тәүфигы белән булсын, илаһым.

Хастаханәгә хәлен белергә килгән эреле-ваклы балаларына карап, куанып ятты. Бәбиләгәненә биш көн дигәндә баласын күтәреп, җайлап кына атлап өенә кайтты. Беренче улыннан соң туган, инде унбише белән киткән, үзе кебек сипкелле кызы, бала күтәреп, өй эченә кереп килгән әнисенә үпкәләгәндәй иттереп дәште:

— Нигә безгә әйтмәдең чыгам дип, әнекәй! Өзлексәң?

— И-и, Флүзә кызы-ым! — диде әнисе.— Сез балаларымны күргәч, өемнең исен иснәгәч, нинди өзлегү булсын ди инде тагын. Тот туганыңны, сал мич янына җылы урынга. Җылы кирәк аңарга хәзер. Өстен ач азрак, һава керсен.

Сипкелле, көләч йөзен балкытып, сәкегә менеп утырды да, бала тудыру йортында җыйган көчтәнәчләрен сәкене тирәләп уратып алган сөекле балаларына таратты. Бу минутлар Фәнзия яшәешенең иң бәхетле мизгелләре иде. Өй эче җылы һәм исән-имин балаларының тавышлары белән гөрләп тора иде.

— Аллага шөкер! — диде тугызынчы йөрәк парәсен алып кайткан ана.— Утырышыгыз, балалар, тирә-ягыма түгәрәкләнеп. Бер дога кылыйк. Аллаһы тәгаләгә рәхмәтләребезне белдерик. Без барыбыз да Аның гына колларыбыз. Исән-имин яшәгез. Әтиегезнең исәнлеген үтенегез Ходайдан. Илләргә иминлек, байлык, тынычлык бирсен Ходай!

Ишек алдыннан ук шаулап, шат күңелле, көләч йөзле ире Рәхиме кайтып керде.

— Сиңа тагын бер биш көннәр ятасы иде бит, әнисе. Нигә дип иртә чыктың инде син тагын? Ә-әй, шушы кайсы вакытларда тыңламаганлыклары-ың!

Ире кайткач, өй эче тагын да нурланып-матурланып, күңелләнеп китте...

Әмма төпчеген тапканнан соң, мантый алмады шул Фәнзия. Сипкелле, түгәрәк йөзе эчке сызланудан сулыгып, ябыкканнан-ябыкты. Шулай булса да, ана бурычын, изге бурычны үтәп, улын яше тулганчы имезде. Тырышып-тырышып, түшләрен нәни бармаклары белән тоткалап имгән, тулы тәнле малаена карап сокланды, аны туктаусыз сөйде, иркәләде. Тик, баланы имезгән чакларында, ни өчендер күзләренә яшь тула торган иде...

Төпчегенә өч яшьләр тулып килгән чакларда хастаханәгә кереп, айдан артык ятып чыкты. Дәваланды яхшы итеп. Тик файдасы тигәнгә охшамаган иде нигәдер. Өенә машина белән китереп куйдылар. Тик ул инде машинадан төшеп, үз аягы белән йортына керә алмады. Берсе — ун, икенчесе унике яшьлек малаеның кулбашына таянып, көч-хәл белән йорт баскычыннан күтәрелде. Аякларын бер-бер артлы баскычка күтәреп, берсе янына икенчесен куя-куя җайлап кына, гыжлап тын ала-ала күтәрелде Фәнзия. Бу аның урамнан кереп, үз йортының баскычыннан соңгы мәртәбә күтәрелүе булган икән...

Озак утырды сәкесендә, җылы мичендә аркасын терәп. Өй эче мичтән яңа гына чыккан ипи исе белән тулган иде. Урамнан тупырдашып килеп кергән биш һәм өч яшьлек ике малае аны авыр уйларыннан айнытып җибәрде. Башта ул малайларның баскычта тупырдашкан аяк тавышларын ишетте, күзләрен түземсезлек белән өй ишегенә төбәде. Ишек ачылып киткән уңайга ук өй эченә, бусагадан сикереп төшкән кебек сикереп, төпчеге, иң бәләкәче сикергәләп килеп тә төште. Аның артыннан өч литрлы ак бидон күтәргән икенче нарасые күренде. Мәхәббәт тулы күзләре белән балаларын иркәләп каршы алды ана. Биш яшьлек улы иплəп кенә бидонны почмак сәкесенә куйды да, әнисенә сарылды. Сәке йөзлеге янына килеп, әнисенә кыяр-кыймас кына каш астыннан карап торган энесенә дәште:

— Кил, кочакла әнине!

Фәнзия бик нык ябыккан иде. Төпчеге аны берничә көн генә күрми торуына карамастан, танымый иде бугай. Ул кыяр-кыймас кына абыйсына ияреп, сәкегә үрмәләде. Сәкегә менгәч, аягына басты да, ике куллап әнисенең муенына сарылды. Таныды малай әнисен...

Үләренә бер ай кала, сизенгәндәй туган-тумачаларын җыйдыртты Фәнзия. Ат җигеп авылыннан Чижук Хәйдәр дә килгән иде. Хатыны белән бергә. Җыйналган халык юату сүзләрен сөйләде, төрле киңәшләр биргән кебек итте. Тик инде, Фәнзиянең көннәре санаулы калганны барысы да аңлыйлар иде.

Икенче көнне, атын җигеп, хушлашырга дип кергән Хәйдәрне үзе янына сәкегә утырткты. Хәйдәр күз яшьләрен тыярга тырышып, башын игән хәлдә тыңлады Фәнзия апасын.

— Иркәм, син үзең дә, безнең кебек үз хәләл көчең белән көн күрәсең. Шунлыктан минем үтенечем Зөфәр туганыма булыр инде. Бер малаемны үзе кебекләр иттереп әфисәр иттерсен инде. Аның малае белән бергә, бер елны туган улым бар минем. Нәфис исемлесе. Ун яшьтә быел.

Шуны алып китсен инде, унны бетергәч. Хет бер балам югары белемле булыр. Калганнары укый алмас инде аларның. Миннән сәламнәр әйт күпләр иттереп. Кайткан-киткән чакларында кунак та итә алмадым, чакыртып. Ялгыз башы йөри иркәмнең чит-ят якларда...

— Яра-ар, чакырырсың әле. Терелә күр. Яшьсең бит әле син.

Бите алсуланып китте азрак Фәнзиянең.

— Шулай шул, туганым. Җаен кырыгым гына тулып үтте бит. Кырык яшь яшьмени әле, дөнья көткән кешегә. Тик, үз хәлемне үзем генә беләм инде. Аякка бассам, әйбәт булыр иде дә бит. Бик ваклар шул балалар. Терелермен дигән өмет белән догадамын инде үзем. Иншалла терелермен. Син, минем үтенечемне Зөфәргә җиткер инде, яме?!

— Ярар, ярар, җиткерермен. Терел исән-сау. Тизрәк аякка бас, бергә-бергә яшәргә язсын безгә.

— Мин юк дип, езнәгезне ташламагыз. Йөрешегез, ярдәм итегез бер-берегезгә. Кулыгыздан ярдәмегез тиярлек булмаса, очраганда иркәм дип, балаларымның, башларыннан булса да сыйпап китегез. Онытмагыз минем балаларымның туган булганын үзегез белән...

Тамагына килеп тыгылган каты, зур төенне йота алмыйча Хәйдәр өй эченнән акрын гына атлап чыгып китте.

Хәлен белергә килгәннәр ешая башлады. Туганнары да, күрше-тирәләр дә, бергә эшләгән, бергә үскән ахирәтләре дә. Йола булгач, килгән кешене чыгарып җибәреп булмый. Фәнзия көннән-көн биреште, бетүгә табан китте. Үз хәлен үзе дә аңлый иде инде.

Тынын көчкә алып, өенең киң бусагасына күпләп җәйгән паласлар өстендә, төрле зурлыктагы мендәрләр белән терәтелеп куелган хәлендә, җәйге кояшта җылынып утыра Фәнзия. Болдыр кырып юылган, тәмле иттереп такта исләре чыгарып тора. Тыз-быз килеп йортлары аша күршеләрнең умарта кортлары оча. Әллә кайларда, әллә нинди кошларның сайраган, кычкырган тавышлары ишетелә. Һаваларда кабаланмый гына күчмә болытлар каядыр табан агылалар да агылалар. Кояшка мереп болдырда Фәнзия ята. Кырык яшендә күп нужалар күргән, иреннән җәбер-җәфалар татыган, күп иттереп, туйганчы матур-матур балалар тапкан, тик әле аларны үстереп өлгермәгән хатынның гомере өзелүгә килеп җиткән. Әллә йокы баса, әллә үлем күзләрен йомдыра — күз кабаклары авырайганнан-авырая баралар. Шуларны күтәреп, ачып карарлык та дәрманы юк...

Капка шыгырдап ачылганга көч-хәл белән күз кабакларын күтәреп карады. Ире... Рәхим... икән. Авыру хатынның күзендә кайгы белән нәфрәттән башка тойгы чагылмады. Рәхимнең бите тимгелләнеп торганнан салмыш икәнен чамалады. Авыру хатынына карап та тормыйча, итекләрен салмыйча гына, өйгә үтәргә дип уйлап, Рәхим баскычтан күтәрелә башлады. Авыру хатын, көч-хәл белән уң кулын урыныннан кузгатып, иренә ишарәләде:

— Рә-х-хи-им! Утыр әле... яны-ма... Соңгы сүзем бар...

Ире коры гына җавап бирде. Исәбе туктамаска иде.

— Урамда кеше көтә мине. Вакытым тар. Нинди сүз инде тагын?

Болдырда менеп җитмичә туктады.

— Си-ин... тагын... иске кә-се... бецә тотын... гансың икән. Уй... нашыңны да... баш...лаган..сың, диделәр...

— Син нәстә, хәйван, юкны лыгырдап утырасың. Үләлмичә! Бирермен башыңны ярганчы!..

— Мин-ем башым... ярылган инде... ул. Бет... кән... Тукта урлыгың...нан... Рәх-хи-им... Кхэ-кхэ... Уйнаш-тан... Бала-л-а-ар, бала-ла-а-а...

Ире өйгә кереп тормады, урам якка атлады. Хатын тона башлаган күзләре белән ире артыннан карап, тик кенә утыра иде. Кызы, Флүзәсе нинди тавыш икән дип, ахрысы, бусагага килеп чыкты, капкага үрелеп карады да, аннан соң гына әнисе янына иелде:

— Кем иде ул әни? — дип сорап, әнисенең битен сыйпарга дип үрелде. Әнисе җавап бирмәде. Фәнзия кызына нәрсәдер әйтергә омтыла, иреннәрен хәрәкәт иттерергә болаша иде. Ача алды:

— Син... зурым минем... Ба-лаларга әни бул! Ән-ни... ...бала-ла-а...рым-м...

Куркынган кыз бала әнисенең битләреннән, кулларыннан үпте. Үлем салкыны кергән кулларын сулышы белә өреп җылытырга болашты. Ана кулларын кузгатырга итте, ахрысы, тик булдыра алмады. Инде хәле беткән бармаклары белән кызының кулын аз гына кыскандай итте дә, иренен кымтап, нәрсәдер әйтергә теләде бугай. Тик булдыра алмады. Уң ягына ава башлады. Моңа кадәр үлем күрмәгән кызы ачыргаланып кычкырып җибәрде:

— Ән-некәй-йем минем-м! Бәгырь-кәй-йем! Ни эшлисе-ең син? Ән-нек-кәй-йем мине-е-ем!...

Тик ана инде кызын ишетүдән узган, теге дөньяга таба авышпа бара иде...

* * *

Олы малае шоферлыкта читтә йөри иде инде Рәхимнең. Өендә торып калган сигез бала өстенә, бер балалы Зәухиҗә исемле, үзеннән ике яшькә олы хатынны алып кайтты Рәхим. Фәнзиянең үлгәненә биш көн дигәндә. Кич кунарга кайтмаган иде әтиләре. Иртән, көтү киткәч, бер өер энеләре, сеңелләре белән Флүзә аларга иртәнге аш әзерләүне кайгыртып, мич янында урала иде. Әтисе алдыннан атлап кергән ят апага балалар әйләнеп карадылар да, мич янында коймак пешергән апаларын тирәләп, аның янына җыелдылар. Әтиләре егетләрчә яшь һәм азрак салмыш иде.

— Исән-сау тордыгызмы, балалар? — диде ул кәр, хуҗаларча чык-кан тавыш белән. Тик балалар җавап бирмичә, яңгырдан качкан тавык чебешләре кебек, зур апаларына сыенганнан-сыена биреп, басып торула-рын дәвам иттеләр.

— Менә, яңа әни алып кайттым сезгә. Авырмый торганын. Теге әниегез урынына була инде...

Башкача сүз таба алмыйча, тукталып калды. Үзенә төбәлгән сигез пар күз карашын күтәрү аңарга да авыр иде, ахрысы. Шулчак зур апаларының ике ботыннан кочаклаган иң кече ике бала парлашып елап җибәрделәр. Бәләкәй малай такмаклый ук башлады:

— Кирәкми яңа әни-и! Үзебезнең әнине-е кире алып кай-йт! Кирәк-ми-и яңа әни-и! А-а-а! Кирәк-ми-и!...

Рәхим зур кызына ачулы иттереп карады:

— Туктат, энеләреңне, хәз-зер үк! Сине генә тыңлыйлар бит алар. Туктат дим!

Флүзә казан янына үрелеп, капкачына кызыл чүпрәк бәйләгән бидон-ны алып, иң кече балага тоттырды:

— Барыгыз, иркәм, фермага. Сөт алып кайтыгыз!

Ике бала җитәкләшеп, әтисе алып кайткан апага курку тулы күзләре белән карый-карый, өйдән чыгып киттеләр. Флүзә янында калган туган-нарын әтисе белән «яңа әни» басып торган тарафка эткәндәй итте. Берәм-берәм.

— Ис-әнме... әни, дигез, балалар! Үзебезнең әни кайтмый инде хәзер зираттан... Яңа әни... белән яшәячәкбез хәзер... Әти шулай ди бит. Исәнләшегез!..

Фәнзия үлгәннән соң, Рәхимнең бәйләнгән куллары чишелде. Яшь хатыны аның төнге «кәсебен» яхшы гына белә иде һәм соңгы елда ул «кәсептән» үзе өчен яхшы гына файда да кергән иде. Эшендә дә җаен чыгарды Рәхим. Мастерской белән җитәкчелек иткән Харраска да ярап

алды. Өенә алып кереп яхшы иттереп бер сыйлады, ике сыйлады да, сүзара сүз чыгарып, ничекләр иттереп эшкә йөрүенә рөхсәт алды:

— Син, Харрас туган, минем хәлне аңла инде. Бала-чага күп. Барысын да ашатырга, киендерергә, укытырга кирәк. Мин кирәк чакта станукта көн-төн эшләрмен. Һич кенә дә каршы килмәм. Эшеңә карап түләрсең. Кешенекеннән ким булмас, иншалла. Төнге каравылчыларга әйтеп куйсаң, әйбәт булыр иде, миңа төнгелектә дә эшләргә рөхсәт, дип. Аннан кирәге чыккан чакларда ике-өч көн мин үземнең эшләрне карар идем. Аннан әнинең ягыннан без синең белән якын гына туганнар да бит әле...

— Чту за разговур! Рәхим абый! — Харрас урысча сөйләргә ярата иде. — Булдырабыз аны! Сал әйдә тагын берне! Яңа җиңги теге урыс шиен шәп пешерә икән.

— Торф чыгарган җирдә повыр булып эшләгән ул. Шунда өйрәнеп кайткан урысча пешерергә.

— Әйдә, мин нәчәлник чакта файдаланып кал. Тик миңа әйтмичә чыгып китәсе булма.

Рәхим җайлап, кабаланмый гына элек «кәсепкә» бергә йөргән иптәшләрен барлап чыкты. Тирә-яктагы авылларда югалган маллар турындагы хәбәрләргә колак салгалап, тыңлап йөреп Мөхти белән Сәлмәннең «кәсепне» ташламаганнарын чамалый иде.

Бер кичне Мөхтинең авылына кереп өеннән алып чыкты да, матай коляскасына утыртып, «Байлар совхозы»на элдертте. Сәлмәннең йортына барып кергәндә, мәҗлес шаулап-гөрләп тора иде. Коляска эченнән, калын киндердән теккән букчаны алып, Мөхтине, Сәлмәннең биегәннән сикереп-сикереп киткән өе эченә алып кереп китте. Хуҗа кеше аларны тәрәзәдән үк күреп алган, ахрысы, ишек ачылган көенә икесен дә кочаклап алды.

— Һе-ей, яшибез икән әле болай булгач! Инде бүгенге көнне бу дуслар да килеп тапкач, шәп икән әле мин. Яшәсен безнекеләр белән сезнекеләр! Әйдәгез, егетләр, түрдән үтегез! Болай булгач, шатлык бик зурдан минем. Картайганда-тыртайган, дигәндәй булдым әле мин. Кырыкка җиткәндә хатын малай табып бирде әле миңа. Алмаш булды миңа... эһһем, эһһем, әййе... Малайның тәпиен юабыз бүген...

Күңелле табыннан соң, кунаклар куна калдылар. Иртән матай артына утырып, Сәлмән дусларын озата барды. Авылны чыгып азрак киттеләр дә, зур таш астыннан бәреп чыккан чишмә янында матайдан төштеләр. Бер кесәсеннән башланмаган ярты аракы, икенче кесәсеннән ипи һәм ит кисәкләре чыгарды Сәлмән. Матай коляскасы эченнән стакан алып, Рәхим аңарга сузды.

Сәлмән стакан тутырып аракы салды.

— Тот! — шатлык нурлары чәчеп торган күзләре белән Рәхимгә яратып карады. — Атаман!

Рәхим аның шаяртуын әһәмияткә алмыйча, стаканны кулына алды да, башын азрак артка ташлап, ике йотуда эчеп куйды. Матайның коляскасы алдына гәҗит өстенә куйган бер зур гына кисәк итне алды да, авызына кабыр алдыннан ымлады:

— Сал, Мөхтигә!

— Слушаюсь! — диде Сәлмән, артлары тапталып беткән сандалиларының үкчәләрен бер-берсенә бәреп. — Болай булгач, салабыз инде... Мөхтигә!

Бушап калган шешәне Сәлмән кулыннан алып, чишмә артында үскән тал куаклары арасына ыргытты. Костюмының түш кесәсенә тыгылды да, гелән бишлекләрдән генә торган ике төргәк акча чыгарып, иптәшләренә сузды:

— Икегез дә матайларыгызны бик шәп иттереп ремонтлап, көйләп куегыз. Тәгәрмәчләре шәп булсын. Тормозлары.

Сәлмән суза башлаган кулын кире алды:

— Мин матайны саттым бит, әй!

— Яңасын ал.
Кесәсеннән чыгарып, күп иттереп акча өстәде.
— Әле өстәгәнен кире кайтарырсың.
— Ярар.
Сәлмән икесенә дә шатланып карап алды да, башындагы кирәкмәгән уйлардан арынган кебек, куанычын яшермичә чыгарып салды:
— Кәсепне мин, ялгыз башым булсам да, ташламаган идем. Инде җан өшеп бетте, берүзем сарык бастырып йөреп фермаларда. Матайны да, шул тыела алмаганнан саткан идем. Ташлап булмасмы «кәсепне» дип. Димәк, яшибез әле.
Рәхим, сөйләшү булды дигәнне аңлатып, Мөхтигә баш какты.
— Утыр, киттек!
Моторын кабызды да, Сәлмәнгә кулын сузды:
— Хуш иттек. Ялгыз йөрүеңне туктат. Якын-тирәдә исең чыкмасын. Без Гафияткә киттек.
Сәлмән төсе беткән тавыш белән әйтте:
— Юкка барып йөремәгез.
— Нәрсә булды?
— Беткән ул, әй. Эчкедән сируз пичен дигән авыру белән ята. Атна-ун көнлек гомере бардыр инде. Беткән ул.
Мөхти барысының да уен әйтте:
— Дүртенче, кирәк бит инде.
— Пока, өчәү алып барып карарбыз. Аннан күз күрер...

* * *

Китте тирә-як авылларда башмак тана, симез сыер, сарык маллары югалулар. Авыррак булса да, «кәсеп»не өчәү генә башкардылар. Баштарак калага итләтә илтә торганнар иде. Тора-бара анысын да җайладылар. Бер баруында Рәхим кала ягын көйгә салып кайтты. Каланың Агыйдел агышы белән уң ягында, кала читендә Шах Тауга барган юл өстендә бер йорт сатып алдылар. Уртакка, «кәсеп» акчасына. Дүртенчеләре, хәрби истребительләрнең канатын шомартучы булып эшли иде. Йортка шуны керттеләр. Нәселе Юрматы башкортларыннан булса кирәк, күп уйлап тормастан утка-суга керә торган башкорт иде. «Кәсеп» буласы көнне телефоннан шалтыратып, «Юрматыны» кирәк җиргә чакыртып алалар. Ул, дәшмәс энесенең йөк машинасы белән кирәкле җиргә килеп җитә. «Алган» аяклы малны тере көенә кузовка яткырып төйиләр дә, машина юк та була. Машина китеп күздән югалгач, өчесе бер матайга утырып калага юнәләләр. «Йортка» ашыгалар. Барулары белән ишек алдындагы сарай эчендә ныклап эшкә тотыналар. Аяклы малны иткә әйләндереп, баш-тиресен кайтышлый ук урман-чокыр төпләренә күмеп калдыралар. Андый чакта ирену ярамый — тиз эш итәргә кирәк. Милицияләр югалган аяклы малны эзләп көннәрен уздырган арада, аның ите инде катлит-матлит булып ашханә өстәлләрендә булырга тиеш.
Тора-бара «кәсеп» итәргә көндезгә дә күчтеләр.
Соңгы елларда авылларда көтүче кәсебе бетеп, малны йорт саен чират белән көтүгә күчтеләр. Урман-кырларыннан узган чакта гомере кыскарып, пычак астына керә торган симез башмаклар, сыерлар булып тора. Кигәвен-чебеннән качып, агач тирәләрендәге яшел үләнне эзләнеп кергәннәре дә була. Тик көндезге «кәсеп»нең бер җитешсез ягы бар — караңгы төшеп, төн булганчы алган малны агачка бәйләп калдырырга кирәк. Кемнәр йөреми, кемнәр узмый урман юлларыннан. Соңгы елларда күпчелек, кайсысы агач урлый, кайсысы суккан комбайннан ашлык эләктереп, урман эчендә калдырып китә. Алар да төнне көтә бит. Машина, матай заманы — күпләп урлап, өйгә ташу заманы! Урман юллары

белән нәрсәдер ташып йөргәннәргә тап булгаладылар, урманда агачка бәйләп калдырган симез (үзең урлаган симез була!) сыерны, башмак тананы да югалттылар. Берсендә, ике башмакны бәйләгән җирдә, шуларның тиресен генә таптылар. Башлары, эчәкләренә кадәр алып киткәннәр иде. Эзләренә караганда йөк машинасы белән булганнар. «Бурныкын карак урлаган!» Рәхим ул төнне иптәшләре белән бит сыпырып кайтып китте. Уйлап куйды: «Чын ир-егетләр бездән башка да бар икән әле...»

Солдаттан кайткан, 1954 елда туган улы Әхмәтне район үзәгендә, тулай торакка урнаштырып, шоферлыкка эшкә кертте. Район үзәгенә начальствоны йөртергә керде. Җитезлеге, уңганлыгы белән үзенә охшаган иде. Әнисеннән сипкел генә алган үзе. Аннан соң тамак төбеннән чыккан, азрак карлыкканрак тавыш та әнисенеке. Эшли башлавына ел тулар-тулмастан хуҗасының «Волга» машинасы белән кайтып кунды. Кичен энеләрен шатландырып, күрше авылдан әйләндереп кайтты. Әниләренең бертуган Камилә исемле апасы яныннан.

Иртән торып, китәргә җыенгач, әтисенә әйтте:

— Әйдә, эшеңә илтеп куям. Күрсеннәр синең дә «Волга»га гына утырып йөргәнеңне.

Шаяртып сөйләсә дә, тавышында ниндидер сәерлек сизде Рәхим. Утырды машинасына. Азрак баргач, ярты юлда улы машинасын туктатты. Үтенече бар икән.

— Мин, әти, өйләнергә уйладым бит әле. Рөхсәт итсәң, килен буласыны киләсе атнада алып кайтыр идем. Сезгә күрсәтергә.

Рәхим шатланып елмайды:

— Әйбәт, алай булгач. Алып кайт кәнишне. Киңәш итүеңә рәхмәт. Кем кызы? Мин беләмме?

— Белмисеңдер. Әтисе колхозда сөт җыя. Рәхилә исемле кыз. Тегү мастерскоенда эшли. Ел тула инде, йөрибез.

— Алып кайт, күрсәт. Үзеңә ошаса, безгә ни инде, ярар.

Нәрсәдер абайлады:

— Тел ягы ничек соң? Сер тотарлыкмы, күп сөйләнмиме?

Улы көлде:

— Кем белсен инде, әти. Кеше кебек кеше инде. Ике аяклы, ике куллы. Сорасаң җавап бирә инде, сорамасаң — юк. Алай бик күп сөйләүчән түгел кебек...

Туйны зурдан кубарып уздырдылар. Авылда Черки Әхмәдулла дигәннең олы кызы икән дә, тәүге туй ясаулары икән. Әхмәдулла атасын сугышка озатып, ун яшеннән, 1942 елның кышыннан колхозда эшли башлаган. Шуннан бирле туктаганы юк. Тик менә соңгы биш ел чамасында гына ат җигеп, йорттан йортка йөреп, сөт җыя икән. Хөкүмәткә. Бөтен Түбән оч йортлары Черки Әхминеке икән. Киң күңелле, җор сүзле, бөтен кеше өчен дә яхшы була белгән Әхми — һәр йортта үз кеше. Сөтен дә җыя, кирәк булса арбасы, чанасы белән атын да биреп тора. Мөгәрич тә сорап тормый хәтта.

Туйлар узып, шау-шулар басылгач, «яңа кошлар», Әхминең әнисе япа-ялгыз яшәгән йортта тора башладылар. Ел үтәр-үтмәстән әтисенең киңәше белән Әхмәт зур йөк машинасына күчеп утырды. Әүҗән якларына барып юан, озын карагайлардан бураган зур бура алып кайтып утыртты. Башын ябарга калаен да, мичкә кирпечен дә, идән-түшәмгә тактасын да алды яшь кияү. Йортның шулай тиз салынганына исе киткән күрше-тирәгә, агай-энеләргә Черки үз киявенең акчаны каян әтмәлләгәнен шаярта биреп, аңлата белде:

— Чишендерә инде бу кияү мине дә, коданы да... Миндә калмас, давай бирегез, ди...

Дөресе дә, Черки Әхми үз киявенә булышу ниятеннән шактый бурычка алды... кодасыннан. «Бер елда түләрсең»,— дигән шарт куйды аңа Рәхим кодасы, хәйләкәр елмаеп.

Акча булгач, эш тиз дә, җайлы да бара икән. Черки Әхми әнисенең бакчасына, тыкрыктан яңа капка ачып, яңа ишек алдына, яңа йортны эшләп, зурдан, карагайдан утыртып та куйдылар. Әүҗәннән алып кайткан бураны язын күтәргәннәр иде, көзгә йортны бетереп тә керделәр.

Яңа йортны котлап җыйган мәҗлестә Рәхим белән Әхми кодасы икәү бергә утырдылар. Табын кызганнан кыза барды. Черки Әхми кызыклар сөйләп, табынны көлдереп, үзенә дә рәхәт тапты, кешеләргә дә бик күңелле булды. Яшьләр котырып биергә тотынгач, Рәхим кодасын ишек алдына алып чыгып китте.

— Әйдә, син тәнәфес яса, мин азрак һава алмаштырып утырырмын. Әйтәсе сүз дә бар...

Ярыйсы гына салган булса да, Черки Әхми исерек түгел иде. Аңлады, кодасының акча турында сөйләшергә теләгәнен. Ишек алдына чыгып, койма буена тезеп салган имән бүрәнәләр өстенә менеп кунакладылар. Черки кесәсеннән кабы белән сигарет чыгарып, аны кабызды да сорады:

— Син кода, узган ел, мин бурычка алган акчаны трибувайт итәргә уйлыйсыңдыр инде? Шуңа дип алып чыктыңмы мине?

— Шуңа кода. Үзең дәшмисең, ә миңа акча кирәк.

— Бурыч түләү изге эш, дип әйткән ди китапта. Миңа да акча бик кирәк иде бит әле. Бик кирәк. Түләргә... пока юк...

Черки үтә дә тәмләп сигаретын суырды да, тешләре арасыннан тавыкларын җыйган урамга алып чыгып барган, кара койрыклы ак әтәчкә, «черт» иттереп төкереп җибәрде. Әтәч «кот-кот» дип тавыш чыгарып, барган җиреннән читкә сикерде. Черкинең кәефе килде, кодасына күңелле иттереп карады.

— Минем бүгенге көннәрдә бурыч түләрлек рәт юк бит әле. Син көт инде... тагын берәр ел...

Кодасы җавап бирмәде. Бурычка биргәндә үк башына кергән уен барлый иде. Чөнки бу уй барып чыгарга охшап тора иде инде. Эченнән генә, Черки кодасының андый уйларның башына китерә дә алмаганын уйлап, аны мыскыллап көлеп куйды. Әхми кодасы сүз беткәнне аңлатып, тартып бетермәгән сигаретын төкереп сүндерде дә, имән бүрәнәләр өстеннән торып җиргә төште.

— Киттем мин. Тагын көт инде син, чит кешеләр түгелбез бит.

— Туктале, син кода кеше! — диде бурычын көткән кода.— Сөйләшеп бетереп куйыйк инде.

— Нәрсәсен сөйләшәсең инде аның. Юк акча... пака. Бирермен димен бит... акча җыелгач. Сөт җыела бит, акча да шуның кебек җыелырга тиеш. Алла кушып...

Рәхим бөтен йөзен балкытып елмайды. Шул елмаю Черкинең әле генә тантаналы иттереп типкән йөрәгенә курку салды. Үзе дә сизмәстән, янә бүрәнәләр өстенә үрмәләде.

— Менә шулай, әйбәт иттең кире менеп утырып, кода белән сөйләшкән җирдән шулай итеп торып китәләрмени инде. Тыңла. Илленең теге ягына чыктым, тик бер генә кешедә дә минем бурыч калдырганым юк. Иншалла, синдә дә калмас. Бирми дип син башыңа да китермә, кода... Бирмим дигәнем юк бит минем. Бирермен, булгач та. Чит кешедә түгел бит, үз малаеңның кесәсенә кергән. Әнә утыра йорты. Кара күрмәсәң, күзләреңне ачып...

Черки Әхминең һич кенә дә бурычын түлисе килми иде шул.

— Ярар алайса, кода. Үпкәләштән булмасын! — диде Рәхим. Тавышында Черки өчен моңарчы бер вакытта да ишетелмәгән кискенлек ишетелде. Куркыту да, янау да бар иде ул тавышта.— Бирергә исәбең юк, ахрысы?

Черкинең куллары үзләренә урын таба алмыйча нәрсәдер эзләнә башладылар. Ул кирәген тапкандай, кесәсеннән тагын пачкасы белән сигарет тартып чыгарды.

— Син, нәрсә инде, Рәхим кода-а! — диде ул, үтә дә йомшаган тавыш белән.— Азрак кына көт инде син. Табарга тырышырмын... шушы арада... Аз гына...

— Ярар алайса. Азрак көтим. Бер ай.

Утырган җиреннән кузгалды.

— Әйдә керик. Әйтерләр, кодалар аерыла алмыйча сөйләшәләр, дип. Минем башлаган бер эш бар. Шуны бетереп куярга кирәк. Син миңа азрак булыш инде. Шуны башкарып чыксам, мин өч-дүрт ай көтәргә дә риза. Күз күрер аннан соң да. Тик ярдәм ит миңа.

Черки Әхми күңелләнеп китте.

— Яра-ар! — диде ул.— Безнең эштән качкан юк инде анысы. Итәрбез ярдәмне. Нәрсәсе бар аның. Кайчанрак кирәк, әйт кенә.

— Килеп алырмын мин. Алдан әйттерермен телефон белән. Әзерләнеп торырсың мин килгәнче. Бер дә булмаса, малай китереп китәр сине матай белән.

— Матайны каян алыр икән соң ул?

— Мин аңарга матай алырга акча бирдем. Каладагы зур малай табам, диде.

«Миннән бурычын таптыра. Акча моңарда-а!» — дип көнләшеп уйлап куйды Черки Әхми. Тик уен тышка чыгармады.

— Йә, килештек. Шушы арада килеп алырлар сине.

Атна үтәр-үтмәстә «Коммунизмга» колхозыннан өч үгез югалды.

Кодасын үз кәсебенә тиз алып кереп китте Рәхим. Гомере буена колхозда урлашып, шуңарга табигый эш иттереп караган Черкигә, кодасы белән «кәсепче» булып китү бернигә дә тормады. Рәхим дә кеше холкын яхшы чамалый иде. Кодалар булып елдан артык йөрешкән арада ул инде Черки Әхминең комсызлыгын да, кеше байлыгына көнләшеп каравын да, инде гомере үтеп барып һаман җитәрлек акчага, яхшы киемгә, әйбәт тормышка ирешә алмаганнан җанын кая куярга белмәгәнен дә яхшы аңлаган иде. Черкинең холкын яхшы белеп, үзенең кирәгенә борып та куйды.

«Кәсепкә» барасы кичне Черкине үзенең малаеннан яңа матай белән китертте Рәхим. Өенә алып кереп, кодасына җиңелчә генә итеп чәй эчерде. Үзе сөйләнде:

— Ашау-эчү бик күптән булмасын. Эш авыр, күп ашаган булсаң, тын кысыла. Эшне башкаргач, барысы да булыр. Алла боерса...

Кодасын келәтенә алып кереп, аңа юка гына фуфайка, аякларына җиңел генә эрзинкә итекләр кидерде. Төнге уникеләр тирәсендә, кая алып барганын әйтеп тә тормыйча, матаена утыртып, алып чыгып та китте. Черки дә ләм-мим дәшмәде, бернәрсә дә сорашмады. Кодасы артында утыруын гына белде.

Колхозга барып җитәрәк ике чакрым җирдә, агачлар баскан бер чокыр янында туктадылар. Рәхим юлны караңгыда да яхшы күрә иде, шунлыктан малайның фарасын яндырмый гына бардылар. Мөхти белән Сәлмән анда иделәр инде. Кодасы белән таныштыруны кирәк тапмады. Тегеләр дә сорап тормадылар. Каракләр арасында тәртип юк-бар әрмия солдатларыныкына караганда да әйбәт һәм ныграк бит ул. Караңгыда беленер-беленмәс кенә сизелгән сукмактан матайны кечкенә бер аклан эченә кертеп яшерделәр. Совхозның мал сарайларына карап, бүреләр кебек, бер-берсенең эзенә баса-баса китеп бардылар...

Әйе, кодасы Черкине кәсепкә алып кереп китү авыр булмады. Чөнки үн яшеннән колхоз эшенә чыгып, үзен белгәннән алып урлашуга күнегеп, шуның белән бергә кочаклашып үскән, яшәгән Черки үзе дә, бер генә көн дә урлашмыйча тора алмый иде. Үзе әйтмешли, кем инде колхозда урлашмыйча яши! Юк андый кеше! Утыз елдан артык колхоз эшендә изелеп, ярым ач яшәп, каян яхшылап эләктерергә дигән сорауга ул тик җавап кына табалмыйча йөргән икән! Кодасына рәхмәтләр яусын!

Чөнки, Черкинең уенча, «урыннарда утырган белемлеләр» аңардан күбрәк эләктерәләр дә, хәйләкәррәкләр дә. Эшләмиләр һәм үзе кебек колхозда эшләгәннәрнең «чутыннан» яшиләр. Һәм оста иттереп алдап сөйли беләләр. Шуңа укып чыкканнар да инде алар. Кодасы артыннан тавышсыз гына атлаган Черки Әхми инде нәрсәгә барганнарын, кодасы әйтмәсә дә, белеп атлый. Бу эшнең куркыныч икәнен дә, төрмә белән бетү ихтималы булуын да белеп атлый. Шулай булса да, бармаска, кире борылырга дигән уй юк аның башында. Чөнки колхозда эшләгән чакларында, төрле вак-төяк, берничә капчык ашлык яисә колхоз эскертеннән бер йөк печән урлап кына байый алмаган Черки, үзе өчен менә дигән акчалы, тиз баерга мөмкинчелек бирә торган «кәсепкә» тарыганын тиз аңлап алды...

Төн бик тә уңышлы үтте. Авызларына азрак солы салган капчыклар кидерделәр дә, эре гәүдәле өч башмакны сайлап, алып чыгып киттеләр. Тиешле җирдә көткән машинага аякларын бәйләп, төяп җибәрделәр. Матай белән чыгып ычкынып, башмаклар төялгән машинадан да алдан кайтып җиттеләр.

Ике атна узгач, бурычтан котылсам ярар иде инде, дип йөргән кодасына Рәхим төргәге белән акча тоттырды.

— Менә сиңа, узган ел биреп торган акчага, урыс әйтмешли, дабавка. Тот. Игелеген күр. Теге бурыч вәссәлам!

— И-и-и! — дип сузды Черки, комсыз күзләренә юмартлык карашы бирергә тырышып.— Бер чыгуга-а! Күбрәк түгелме со-оң?

Кодасының күзләрендә мыскыллы елмаю елтырады:

— Өйрәнчеккә без күбрәк түлибез бит. Куркуы тизрәк үтсен, дип. Безнең «кәсеп» шулай төшемле ул.— Тавышын акрынайтты:— Казакълар ягыннан җылкы малына заказ бар. Рәвил карак заманында казакътан куган атларны. Хәзер кире куарга кирәк. Сезнең тугайда йөргән атларны мин карап киттем. Төрлесе бар инде. Тик, тагын бер ай чамасы йөреп торсыннар әле. Бар анда шәпләре. Казакълар иткә сорыйлар бит. Урыс бетерде казакъ далаларындагы җылкыларны, чучка фермаларына алмаштырып бетерде.

Бер төн эчендә бурычыннан котылып, түш кесәсен тагын өстәмә акча белән тутырган Черки Әхми башын күтәреп, кодасына яратып карады. Гомере буена колхоз эшеннән чыга алмыйча эшләсә дә, аның мондый күп акчаны кесәсенә салганы юк иде әле. Юантык, бәләкәй гәүдәсе тураеп, озынаеп киткәндәй булды.

— Һы! Җылкы малы! Бар инде алар безнең авыл тугайларында. Өере белән йөриләр. Шуларга налуг та салучы юк хәзер. Асрасын халык, диләр. Тугай иркен бит безнең. Берәр атнадан әйтермен ниндирәкләре барын...

* * *

Төнлә белән тугайдан алган атлар белән мәшәкать бик аз булды. Чөнки атларны калага да кумадылар, суймадылар да. Әлеге дә баягы шул, «Байрак» совхозында эшләүче казакъ дүртесен дә сатып алды. Бер атның бәясен тулысы белән алдан түләп куйды. Урланган атларны ташырга да машина үзеннән иде казакъның.

Черки Әхми белән Мөхти куеннарына тоз сибелгән ипи тыктылар да төн караңгылыгында тугай ягына кереп югалдылар. Киткәннәренә инде бер сәгатьтән артык вакыт узды. Тик алар күренмәделәр. Яшереп куелган машинадан читтәрәк, карт юкә төбендә Сәлмән белән Рәхим, кузгала башлаган шикләрен басып, сабыр гына утырырга тырыштылар. Байтак утыргач, Сәлмән түзмәде, Рәхимнең колагына иелеп пышылдады:

— Мин башымнан ук куфайкы белән томаланып, берне генә тартып алыйм әле?

Рәхим аңарга җавап урынына зур йодрыгын гына күрсәтте. Бик тә озакка сузылган минутлар җаннарын талкыды. Тагын байтак вакыт узгач, түгәрәк, тырпаеп торган колаклары белән төнге тынлыкны бик җентекләп тыңлаган Рәхим аягына басты. Картаеп килгән, ләкин сизгерлеген югалтмаган бүре кебек, төн караңгылыгына, тугай ягына текәлде.

— Юк ла инде! — диде Сәлмәне, пышылдап кына.— Ишетелми бернәрсә дә.

— Ишетелә шул! — диде, шатлык, өмет кергән тавыш белән Рәхим.— Тартай шыңгыравыннан туктады.

Төн караңгылыгыннан атларның икесен менеп, икесен җитәкләп, Әхми белән Мөхти килеп чыктылар...

Машинаны, калкулык астында аккан кечкенә елганың текә ярына судан китереп терәделәр. Атларны егып, аякларын бәйләп, ярдан этеп машина кузовына өстерәп төяделәр. Сикәлтәләрдә, үрләрдә машина кузовында шуып йөрмәсеннәр дип, атларны бер-берсенә һәм машина кузовларын яба торган тимерләргә бәйләп куйдылар. Машина утларын яндырмыйча гына, кырдагы бер эскерткә кереп атлар өстеннән салам төяделәр. Күп иттереп, саламны таптамыйча төяделәр дә, җинелчә генә бастырыклап куйдылар. Атларга тын алырлык иттереп һава юллары калдырырга да онытмадылар.

Авылның Ырымбур ягына чыккан юлда, Тәләкәй авылына чыккан күпер төбендә атлар төялгән машинаны казакъ Аманбай көтеп тора иде. Салам төягән машинаны күргәч, юл кырындагы канаудан күтәрелеп, юлга чыкты. Рәхим кабинадан төшеп, анда казакъ кереп утырды.

— Булды бу эш. Исән-имин кайтып җит тә, кирәк кешеләренә тапшыр атларны. Ат хуҗаларының берничә көне атларын эзләп, аннан соң тагын берничә көннәре милиция бусагасын таптап үтәчәк. Синең атнадан артык вакытың бар. Әйдә, кузгал...

Шул көннән соң, тирә-якларда югалган малларның яртысыннан күбесе җылкы малы була башлады. Инде хәзерге замананың мал белән «кәсеп» итүчеләре, борынгыдан килгән ул шөгыльне җылкы урлауга күчереп, үзләренең «ат караклары» дигән исемнәрен яңадан кайтардылар... Заманалар үзгәреп, авылда яшәгән кара халыкка җылкы малын тотарга рөхсәт ителү яңа ат каракларына яңа мөмкинлекләр дә тудыра иде...

* * *

Дүрт ат суга төшкән кебек югалдылар, юкка чыктылар. Көнтөн диярлек тирә-яклардагы ялан-кырларны, урман-чокырларны, күрше авылларны актарып эзләгән хуҗалары да, галифе чалбарлы, хром итекле милиция начальнигы Хәмитов та, хәтта күрше райондагы күрәзәче чуаш Әким дә югалган малларның эзенә төшә алмадылар.

Утыз ел Совет Армиясендә хезмәт итеп, подполковник дәрәҗәсендә отставкага чыккан Зөфәр Саратов каласыннан авылын сагынып кайтып төште. Үзе әйтмешли, «атлы колхозник дәрәҗәсеннән кырык биш еллык стаж белән отставкага чыккан» абыйсы белән кичен бик озак сөйләшеп утырдылар. Балалары кайсысы кая таралышып беткән абыйсына энесе кайту зур шатлык иде. Яңалыклар күп авылда. Туган-тумачаны, күршекүләнне, авылдагы таныш-белешләрне сөйләшеп беткәч, Зөфәр сорады абыйсыннан:

— Теге елны дүрт ат югалган иде. Табылмады бит шулар тәки. Андый-мондый исе-косы да чыкмады, ахрысы?

— Берсе минеке иде бит аларның. Берсе Көрпә Зарифныкы. Юк инде, нинди ис чыгарга тиеш, ди инде. Милиция аларны эзләми дә хәзер. Ярар инде, ул атларны без онытып та беттек инде. Әйдә, берне тотыйк

тагын. Син бу нәстәне эчәргә тәки өйрәнә алмадың әй, даром чтү офицерсың.

Эчкәне артыннан бер кисәк ит капты да, аны тәмен белеп чәйнәргә тотынды.

— Рәхим езнинең, теге син хәрби училищега керергә ярдәм иткән улы Нәфис кереп китте яз көне безгә. Чибәр, бер старший лейтенант булган ул, әй. Инде сиңа рәхмәтләре зур инде. Зөфәр абый ярдәм итмәсә, мин ул училищега гомеремдә дә керә алмаган булыр идем, ди. Югары белем дә ала алмаган булыр идем, ди. Озакламый капитан буласы икән.

— Рәхим езни... Үзе исән-саумы соң?

— Исән болай. Тик тазалыгы, исәнлеге юк, әй. Аяк-куллары ни йөреми, ни тотмый, дигәндәй. Йорт тирәсендә генә кыҗмырдый шунда. Чыгып йөрерлек түгел ул хәзер.

— Балалары таралып беткәндер инде?

— Читтәләр инде. Тик таралдылар дип әйтеп булмый аларны, әй. Тугыз баладан берсе бездә шофер, берсе Эстәрлетамакта. Аннан әле мин әйткән Нәфисе офицер, Чита ягында. Бездәгесе теге Черки кияве бит инде, үзең беләсең. Калганнары барысы да Салават каласында, зур апалары Флүзә янында. Ире бик шәп бер башкорт егете. Гәүдәгә миннән дә таза. Иллә дә киң күңелле, шат, юмарт башкорт инде. Ул курайда уйный, ул җырлый башкорт көйләрен — табыннарның һушын ала инде. Флүзәнең үзе белән алтаулар Салаватта. Фәнзия апаның абыйсы Галиулла абзый да бик ярдәмчел булды. Фәнзия апа гына күрә алмады шатлыкларын. Тик, ни сәбәптер, авылга сирәк кайталар. Әнкә үгәйгәме икән, бүтән сәбәбе бармы икән. Черкинең кияве генә кайтып-китеп йөри. Анысы еш кайта...

Абыйсы сөйләвеннән туктап, энесенә карады:

— Баядан бирле сизеп утырам, нәрсәдер сине борчый дип, әйтимме, әллә берәр нәрсә хәбәр итәргә уйлыйсыңмы миңа. Күзләрең борчулы, димме шунда. Ә?

Зөфәр кызарып чыкты. Абыйсы дөрес чамалаган иде.

— Ни бит... абый! Теге дүрт атны... Э-э...

Хәйдәр кул хәрәкәте белән энесен туктатты.

— Син белгәнне мин дә беләм, энем. Тик син, Зөфәр энем, бернәрсә дә белмисең. Шуны һәрчак исеңдә тот. Бел-ми-се-ң! Аңладыңмы? Белми-сең!

— Юк, аңламадым.

— Аңласаң да, бернәрсә дә белмисең. Кирәкми аны белү безгә.

Алдындагы тулы рюмканы читкәрәк этәрде дә өстәп куйды:

— Балалары күп иде езнинең, ул атлар... югалганда. Фәнзия апа хакына бездән ярдәм булды дип исәплим инде мин ул югалган атны. Син, берәр нәрсә белсәң — оныт. Кешенең картлык көннәре рәшәткә артында үтәргә тиешмени? Ни әйтсәң дә, үзебезнең езни бит. Кемнеке — аныкы дигән даны да бар. Кеше арасында яхшы түгел. Ә балалары?..

Бер атна кунак булганнан соң, Зөфәр юлга чыкты. Автобус килгәнне көткәндә ике ирнең сөйләшкәнен тыңлап утырды.

— Кичә Черки егылган урамда. Лаякыл исерек. Торалмый да, атлый да алмый. Шуннан Сәббах тегене өенә илтеп куярга булды. Сәббахның машинасына төйи башлаган идек, кесәсеннән сберкнижкәсе төште. Карадык Сәббах белән ачып. Исләребез китте, әй. Кырык өч мең дә әллә ничә сум акчасы бар книжкәсендә-ә. Менә сиңа Черки-и...

— Кит, сөйләмә булмастайны! Урам буйлап, гомере буена сөт җыеп, каян килсен инде Черкигә шул хәтлек акча. Өч «Жигули» дигән сүз бит ул. Өчәү! Черкигә андый акча тагын!

— Соң инәңнең күлмәге! Үз кулым белән книжкәсен тотып карап, үз күзләрем белән укыдым, дим бит мин сиңа. Ышанмасаң, Сәббахтан сора. Ул илтеп куйды өенә.

— Хәзер, соранып йөрим тагын кешедән, Черкинең күпме акчасы бар, дип. Миллион булса да, шул Черки инде. Беткән бит инде, күрмисеңмени. Черкине акча гына коткарырлык түгел инде хәзер. Ул корсагы күбенгән, ул аяк-куллар шешенгән. Йөрәге бик начар икән.

— Җитмәсә, эчә бит әле.

— Эчүенең без белмәгән берәр сәбәбе бар инде аның. Шуңа эчә дә инде ул. Хәзер аңарга мәчет юлында йөрергә дә бит инде, Ходайдан мәрхәмәт белән исәнлек үтенеп...

— Кит, кеше көлдереп сөйләмә дә, Черки мәчеткә йөримени. Йөрер бик...

Башы тулы уйлар, яңалыклар белән чыгып китте Зөфәр туган авылыннан Саратов каласына.

* * *

Дүрт ат авыл тугаеннан югалган көздән соң байтак еллар үтте, бик күп сулар акты, озын-озын юллар узылды. Тирә-якларда җылкы малы да, башка аяклы маллар да югала торды. Тик аларга кул салган караклар гына күренмәделәр дә, сизелмәделәр дә. Авыллардагы кешеләр ул каракларның тотылмаячакларына ышанып бетеп бара иде инде.

Чижук Хәйдәрнең кунакка кайткан отставкадагы подполковник энесе Зөфәр киткәннән соң атна тирәсе үтүгә, авыл тугаеннан тагын ике җылкы малы югалды. Көпә-көндез. Бу юлысы авыл ныклап, шикләнмичә әйтте: ат караклары!..

---

## АЛДАГЫ САННАРДА УКЫГЫЗ!

**Күренекле язучы — фронтовик һәм галим Атилла Расих (Рәсүлев) автобиографик трилогиясенең соңгы китабында каләмдәш дусларын, чордашларын, татар зыялыларын тасвирлауга да шактый зур урын бирә. Хәзер сезгә шул әсәрдән өзек тәкъдим итәбез.**

Салих Баттал Сталинның шовинистик сәясәте аркасында халкыбызның икенче сорт милләт булып калуын ифрат авыр кичерә иде. Табигатенә хас буларак, эчтән генә янмый, зур протест белдереп, бөтен дөньяга моны фаш итәргә тырыша иде. Ул үзәккә — Мәскәүгә бу турыда бер генә хат язмагандыр, бер хатынның күчермәсен саклау өчен миңа да биргән иде. Аны бер заман партиядән сөрүне оештырдылар. Аның бу турыда ачынып сөйләгәне һич онытылмый. «Мәскәүдә мине ЦеКа комиссиясе алдында тыңладылар»,— дип сөйләгән иде Салих абый. Комиссия әгъзалары, утырышып, сорау ала башлаганнар. Салих абый да утыра бирә икән... Комиссия җитәкчесе рус хатыны була. Салих Баттал сөйли башлагач, ул аңа, алай әйтмә, болай әйт, дип акыл сата башлый. «Мин рус кешесе түгел, ялгыш әйтсәм, гафу итегез»,— ди Салих абый. Теге хатын, бөтенләй кызып: «Сезне Иван Грозный җитәрлек өйрәтмәгән шул әле»,— ди. Шулай итеп, шагыйрьне милләтчелектә гаепләп, төрле сәяси ярлыклар тагып, партиядән чыгаралар...



## Фирдәвес Әһлия

### ЙӨРӘКНЕҢ СОҢГЫ КЫЛЫ

* * *

Тынмыймы әле авылда
Бүреләр улаганы? -
Тыңлыйсым килә давылның
Скрипкада уйнаганын.

...Өзгәләнә, өзгәләнә...
Кылларын ничек өзми?
Әллә инде бу дөньядан
Минем йөрәкне эзли?..

Бер-бер артлы өзеләләр
Йөрәгемнең кыллары.
Берсе кала. Соңгы кылда
Уйный давыл куллары.

### Бәраәт[1] кичәсе

Күктән җиргә иңә тынлык...—
Бүген бәйрәм кичәсе.
Алланың сулышын тыңлыйк...—
Бу — бәраәт кичәсе.

Тәнебезне пакьләндерик, —
Бүген бәйрәм кичәсе.
Җаныбызны сафландырыйк,—
Бу — бәраәт кичәсе.

---

[1] Бәраәт — гаепсезлек, аклану, котылу.

Гөнаһлардан тәүбә кылыйк,—
Бүген бәйрәм кичәсе.
Намазлыкта оеп калыйк,—
Бу — бәраәт кичәсе.

Иманыбызны яңартыйк,—
Бүген бәйрәм кичәсе.
Өммәтебезне яратыйк,—
Бу — бәраәт кичәсе.

Күктән җиргә иңә тынлык...—
Бүген бәйрәм кичәсе.
Алланың сулышын тыңлыйк...—
Бу — бәраәт кичәсе.

## Аллаһе әкбәр!

— Аллаһе әкбәр! Аллаһе әкбәр! —
Мөселманнар әйтә тәкбир.—
Кая илтер, кая ташлар,
Нинди булыр безнең тәкъдир?..

— Аллаһе әкбәр! Аллаһе әкбәр!
Аллаһе бар! Аллаһе бер!
Озын юлның азагында
Һәммәбезне көтә кабер.

— Аллаһе әкбәр! Аллаһе әкбәр! —
Тәкъва җаннарда нур гына:
— Якты вә шат күңел белән
Барыйк Алла хозурына!

## Ичмасам...

Күк йөзеннән
Учыңача
Йолдыз булып
очмасам.
Җан учагың
Үрләтергә
Очкын булыйм,
ичмасам...

## Мизгел

Тынып калыйк әле шушы мәлне,
Иеп авырайган башларны:
Бу мизгелдә тәмамланыр гасыр
Һәм... өр-яңа гасыр башланыр.

Үтә гасыр... Соңгы сулышлары...
Ясин чыга аңа мәңгелек.
Үтә гасыр. Аның белән бергә
Тәмамлана иске меңьеллык.

...Туар гасыр. Бәби туе ясап,
Исем кушар аңа мәңгелек...
Яңа туган бәби белән бергә
Сулыш алыр яңа меңьеллык.

## Серле төн

Дөнья тулы ай нурлары,
Һавадан йолдыз ява,
Сибелешкән йолдызлардан
Кырларда карлар яна.

Кыш илаһи кыйссаларын
Йолдызлар белән яза.
Нинди аклык! Нинди сафлык!
Могҗиза бу, могҗиза!

Күңелләр дә йолдызлана
Әкият үзәгендә:
Галәм үзе — айлы дөнья
Чагыла күзләреңдә.





# Фәндидә Харрасова

## Соңгы пәрдә

Өмет уты әле пыскып яна
Соң кат чаршау төшәр алдыннан,
Тормыш сәхнәсендә
безнең драма —
Соңгы сүзне сиңа калдырам.

Акланышлар берүк вакланмачы,
Аңлыйм һәрчак, керәм хәлеңә.
Яратуга исбатлаулар эзләп,
Мәхәббәтнең тимик чәменә.

Йөрәк ярсуына ничек түзим?
Тамашаның соңгы пәрдәсе,
Өмет уты сүрәнләнә бара,
Чишелешне көтә һәммәсе.

Йөрәгемне кысып учым белән
Башым иям, сәхнә әйрәткән,
Тамашачы түземлеген аяп,
Соңгы сүзне, кичер... мин әйтәм.

* * *

Бирешмәстәй идем давылга да,
Карашларың белән бөгәсең.
Таянычым диеп сыенырлык
Синең иңнәр түгел, күрәсең.

Кодрәтсездер димим мәхәббәтне,
Тик аерым юл сайлыйм офыкка.
Күрәчәгем күкләр расласа да
Күнегәлмәм синең юклыкка.

Үзем белән барлыгыңны алам,
Хушлашканда ак юл тели бел.
Күзләреңнең карасында калыйм,
Каерылып артка карыйм гел.

Ышанычтан койган күпер аша
Җан җылымны тояр син генә.
Язмышлардан узмыш юллап чыгам,
Кыйбламда кояш сүрелә...

Язмышлардан узмыш юллап чыгам...

* * *

*...Все отнято: и сила, и любовь*
*В немилый город брошенное тело*
*Не рада солнцу. Чувствую, что кровь*
*Во мне уже совсем похолодела...*
Анна Ахматова.

Алтынчы кат шәрран ачык тәрәз,
Төссез офык, җуелган шул кәгъбәм.
Бер омтылыш, алга тик бер адым
Һәм йотачак мине салкын галәм.

Эзлә кыйблаң, имгәтелгән рухым,
Керсен гүргә бары канлы гәүдәм.
Ак кәгазьгә мине аклау яза,
Калтыранып, тугры каурый-каләм.

Күтәргәчтен сүз сөңгегә элеп,
Мәйданында яшәү-көрәшнең.
Кансыраплар корбан көткәннәргә
Бер җанымны телеп өләштем.

Күңел дәфтәремнең соңгы бите,
Гомер язмам тәмам, соң кат тамгам.
Акласаң да чорым, тапласаң да
Хакимем бер, тик ходайга багам.

Соңгы адымымны фатихасыз,
Ләгънәт укып үтәр чагыммы?
Ансат кына котылмакчы берәү —
Җилдән кинәт тәрәз ябылды.

* * *

Алдым сине бары чынбарлыктан,
Тудырдым тик хыялымда кабат.
Өстен куеп барлык ваклыклардан,
Ант-шартлардан сине иттем азат.

Сокланганмын, ахыры, чама белми,
Хыялыйлар иткән сурәтеңә:
Йолып алып гади булмышымнан
Табындырган рухи кодрәтеңә.

Син тезләндең, ә мин әле һаман
Яшен кайтаргычтай түбәңдә.
Мәхәббәтең югарылыгыннан
Тәгәрәде җаның түбәнгә.

## Елый, диләр, атлар бәйгеләрдә...

Томырылып оча толпар атым,
Куәтле тик йөрәк кагышы.
Ак күбеккә батып чабыш түгел,
Яшәү өчен, гүя, алышы.

Күзләрендә — бары ярыш чәме.
Калды артта күпләр өзлегеп,
Хыянәтчел бу язмышка каләт —
Тугры дустым китте сөрлегеп.

— Аһ, дип мәйдан бер мәл өнсез торды —
Харап булды, ахры, малкаем,
Юк, сикереп торды каударланып,
Тарый кабат җилләр ялкаен.

Елый, диләр, атлар бәйгеләрдә
Узышып та сөлге алмаса —
Толпарымның керфекләре дымлы
Елый икән чынлап ләбаса.

Тормыш-бәйге саран алкышларга, —
Таләпләрен үтә Уенның!
Ап-ак сөлге салгач тынычланган
Толпарымның кочам муенын.

## Яшәргә тик яшәп өйрәнәбез

Яшәргә тик яшәп өйрәнәбез,
Яратырга — бары яратып.
Бу дуамал тойгы акылдан да,
Өстен булып куя кайвакыт.

Көлемсерәп язмыш күзгә карап
Үгетләгән була һаман да,
Мәхәббәтсез дөнья сансыз диеп
Яшәдең бит, килер таманга.

Тәүбә иттем, әмма ант итәлмим —
Язылмаган канун көчлерәк.
Газаплардан үлеп терелгәчтен
Тернәкләнер өчен көч кирәк.

Әл дә уяу мәхәббәт һәм нәфрәт —
Чәмләндереп алга этәрә.
Гөнаһлыны тәңре ярлыкасын —
Нахакны да иңнәр күтәрә.

Яшәргә тик яшәп өйрәнәбез,
Яратырга — бары яратып.
Газаплардан үлеп терелгәчтен
Тернәкләнеп килгән бер вакыт...

## Әйтче, татар!

Изелгәнсең, сибелгәнсең, җигелгәнсең,
Кайда бакма — синең асыл сөяккәең,
Бозын ягып Колыманы төяк иткән,
Чарасыздан газиз булган йөрәккәең.

Читсенгәнсең, кимсенгәнсең һәм кунгәнсең,
Гөл үстергән кара тирең хәтта чүлдә.
Кайда да син солтан түгел, олтан гына,
Санга барсың, тик санлау юк уртак илдә.

Кагыласың, сугыласың, лаф орасың,
Галиҗәнаб ишетмәмеш, әй илаһым,
Килмешәккә әйләнгәнче милләтемнең
Рәхим кылып тыңласаңчы зарын-аһын.

Иелгән баш, җәллад кылычында күптән
Тутык булып катып калган канлы таплар.
Җиңеләсең, чигенәсең, тибеләсең:
Болгар канын, Тукай рухын кем соң саклар?
Әйтче, Татар!

## Төн тарлыгын ертып һаман алдан барам...

Хак тәгалә яратса да кабыргадан,
Шаһинәләр рухы тибә тамырларда.
Чүкелсәм дә аяусыз чор сандалында,
Яклауга да, саклауга да хакым бар ла...

Төн тарлыгын ертып һаман алдан барам,
Даһиларны әвәли тик бары заман.
Ә мин аңа — аналарның хакын хаклап
Богауларда көйләп бишек җыры язам...

Гөнаһы да савабы да бер җилкәмә —
Дөнья көтәм, дөньялыкны җир күтәрә.
Яратылгангамы җаным кабыргадан,
Шаһинәләр рухы сыктый тамырларда...

* * *

Шәраб койдым сыңар бокалыма,
Ай да килде табын уртасына,
Пыскып янган шәмне сүндердем.
Аулак өйдә бәйрәм тантанасы,
Түгелепләр килә бер еласы,
Мизгелләрен барлап гомернең...

Бокалым буш, ай да моңсу гына
Урыныннан инде кузгалды.
Булмышымның үз туксаны туксан:
Туктачы, дим, җимерелмәс җиһан,
Яшәп торыр әле, үзаллы.

Яктырт әле, сүнә яшәү чәмем,
Тән җылыткыч кына бары хәмер,
Ходай, көнең шуңа калдырма.
Мин, хыялый, беләм, әй замана,
Төшә алмадым шул кубызыңа,
Биш бассаң да килеп алдыма.


* * *

Гомер баскычларын саный-саный
Юнәлүе аның түбәнгә.
Яклаучысыз калган картлык килә,
Үткәрегез, берүк, түрләргә.

Буыннары сыек, күңеле сынык,
Сәләмәгә калган күлмәге.
Әзерләгән аңа дәүләт абзый —
Шыплы кәкре каен терәве.

Җеп өзәрлек җегәрлегем дә юк,—
Кырыс замананың хикмәте,
Сөйрәлепләр атлап картлык килә,
Иңнәрендә еллар михнәте.

*Уфа.*



8*

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Рәшит Гариф**

## КЫСКА ХИКӘЯЛӘР ДӘФТӘРЕННӘН

### Көтелмәгән янәшәлек

Хөрмәтле Акболыт туган! Синең тормышыңда булган ул хәлләр, ул көннәр мине һәрвакыт дулкынландырып, җанымны борчып торды. Язмыйча түзә алмадым. Яздым, күңелем бушанып, тынычланып, сафланып калгандай булды. Ни өчен шулай — үзем дә әйтә алмыйм. Тик бер теләк: тирән яраларыңны кабат яңартмаган булсам ярар иде.

Гафу итәрсең, дип белəм, фамилияңне, әтиең-әниең исемнәрен атамадым. Хикәянең синең турыңда икәнен белүче булмас.

* * *

Әле кайчан гына Акболыт ерак ил чигеннән кунакка кайтып киткән иде. Әнисе ничек әзерләнеп, сагынып көткәндер. Ул чакта күпме дуслары җыелды. Никадәр күңелле минутлар, сәгатьләр, көннәр кичерелде. Уйнау, көлү, шаяру, җырлау... Аһ, ул чаклар! Барлык туганнарын, дусларын кочкан кебек, колачын җәеп тартты ул гармунын. Ә бүген менә үзәк өзгеч авыр уйлар эчендә кайтып килә. Аны армия хезмәтеннән ашыгыч телеграмма сугып чакырдылар. Өйдә бу юлы кочак җәеп: «Балам!» — дип кем каршы алыр соң? Әйе, мондый хәсрәтне туганыңа, дустыңа түгел — дошманыңа да күрсәтмәсен, диләр бит.

Казанның очкычлар мәйданыннан өйгә кадәрге булган арада башын, йөрәген туктаусыз бораулаган шул уйлардан Акболытның күз аллары караңгыланып китә иде.

«Кайтарасылары, күрәселәре килеп кенә чакырмадылармы икән?» — дип уйлап куя егет. Татлы хыяллары белән күңелен юатасы килә. Шул чагында түгәрәк ике битенә сыек кына матур алсулык йөгереп ала.

---

Рәшит ГАРИФ (1933) — *хикәя һәм шигырьләре көндәлек матбугатта басыла килә. Ул әдәби тәрҗемә белән дә шөгыльләнә. Татарстан китап нәшриятында аның тәрҗемәсендә «Болгар әкиятләре» һәм «Украин халык әкиятләре» басылып чыкты. Казанда яши.*

Юк, тагын бер тапкыр юк инде. Күңеле бөтен хәлләрне сизеп тора. Әнә инде өйләре дә күренде. Подъезд төбендә кешеләр кайнаша. Туганнары, дуслары, якыннары, күрше-күлән булыр. Инде машина да килеп туктаган ич. Ләкин Акболыт үзен солдатларча тота, киҗерешләрен сиздерми, күзеннән яшь агызмый. Ир-егет эчтән генә елый бит ул.

— Исән-сау кайтып җиттеңме?

— Ходай сабырлыклар бирсен үзеңә!

— Исән генә була күр инде,— дип каршылады аны карт-коры. Дус егетләр дә тынычландырырга, үзләренчә хәлен җиңеләйтергә тырыштылар.

— Без сине ташламабыз, Акболыт. Бергә булырбыз.

— Рәхмәт сезгә, әбиләр, бабайлар, дуслар!—диде Акболыт. Андый чакта тагын нәрсә әйтәсең соң?

Ил чигеннән Казанга кайтып җитүе дә алай ук кыен булмады кебек. Менә подъезд баскычыннан күтәрелү, бусаганы атлап керү мондый чакта, ай-һай, авыр икән. Аякларга меңәр потлы йөк асканнармыни.

Мәрхүмәне өйдән алып чыгарга җыенган кешеләр Акболытны күргәч, туктап калдылар.

— Озак көттек.

— Ярый кайтып җиттең әле, улым.

— Әниеңнең йөзен ачып кара, балам.

— Яшь килеш көтмәгәндә китеп барды шул, бәбкәм,— дип, пышылдап әйткән тавышлар ишетелеп торды.

Акболыт әнисенең йөзен ачып карады, маңгаена кулын куеп торды. Әнисе йоклап кына ятадыр кебек тоелды. Аннары картлар дога кылып алдылар, егет тә алар белән бергә амин иткәндәй хәрәкәтләр ясады.

— Җәмәгать,— диде арадан бер өлкәне,— кузгалдык, Мәрҗани мәчетенә вакытында барып җитәргә кирәк. Анда да чират бит...

Аның сүзләре катгый яңгырады һәм берәү дә аңа каршы килмәде.

Акболытка өй эче бөтенләй туздырып ташланган кебек тоелды.

Бер генә әйбер дә әнисе кулы белән урнаштырылган түгел. Бары тик түр стенадагы әти-әнисенең иңгә-иң куеп төшкән кәләч сурәтләре генә һаман шул килеш—һаман чәчәкләр эчендә иде. Тик бу юлы аларның елмаюлары кайгылы-моңсу булып күренде Акболытка.

Өсте ябулы машина Мәрҗани мәчетенә юл алды. Шул чагында гына Акболытның исенә төште: аның әтисе кайда соң әле? Әйтүче, хәбәр итүче булды микән үзенә? Әллә әйтеп тә килмәскә уйладымы икән? Алай булуы да бик мөмкин. Аерылганнарына ничә еллар, минем анда ни кирәгем бар, дисә дә—аның эше. Гаепләп тә булмый. Әнисен күмеп кайткач, туры әтисе янына китәр, мөгаен. Шулай булыр Ходай кушса. Әтисе улының авыр кайгыларын җиңеләйтер...

Монысы да мәгълүм булсын: әти-әнисенең аерылышу уңае белән Акболыт аларның берсен дә гаепләп сүз чыгармады. Яшәгән кадәресен бик матур яшәгәннәр иде бит. Бу хәлне туган-тумача, дус-ишләр дә аңлый алмады. Бердәнбер көнне аерылдылар да куйдылар. Әмма әтисе өйләнмәде, әнисе кияүгә чыкмады.

Машина мәчет янына килеп туктады. Барысы да сикереп җиргә төштеләр.

— Мәрхүмәне монда алып килегез,— диде кемдер.— Ике мәеткә бергә укырга туры килер, янәшә куегыз,— дип боерды аннары әлеге абзый. Димәк, җеназа укыячак мулла шушы икән инде. Барысы да ул кушканча булды. Ике мәетне озата килүчеләрнең кайсы тезләнде, кайсы чүгәләде. Мулла абзый кешеләргә тынычланырга кушты. Мәрхүмнәрнең исем-фамилияләрен сорашты. Башта Акболыт әнисенең, аннары теге мәетнең исем-фамилиясен атадылар. Ир кеше исем-фамилиясен әйтүгә, Акболыт сискәнеп китте. Тукта, бу аның әтисе түгелме соң? Әллә бер үк исемдәге кеше генәме? Йөрәкне нидер телеп, кисеп үткәндәй булды. Шул

чакта тыныч һәм моңлы тавыш белән мулла абзый тәбәрәк укырга кереште: «Тәбәрәкәллэзил бийәдиһил мөлке вәһүүә гәллә көлли шәйиң кадир...»

Бу минутларда Акболыт доганы тыңламый иде инде. Аның йөрәгендә яңа ут кабынды. Әлеге мәетнең исеме эчке дөньясын айкый иде аның. Шулкадәр охшаш исем, фамилия булырмы, әллә чыннан да аның әтисеме бу? Тирә-ягына күзен ачыбрак караса, анда әтисенең туганнары, дуслары барлыгын күрде. Ул әкрен генә аларның берсе янына барып чүгәләде. Колактан-колакка сөйләшеп алдылар. Әйе, кызганыч ки, бу — аның әтисенең дә җеназасы иде. Йа Хода, йодрык кадәрле йөрәккә берьюлы никадәр кайгылар сыядыр.

Машиналар мәчет яныннан кузгалып китте. Тик үкенеч,Акболыт каушауданмы, әтисенең кайсы зиратка күмеләчәген дә сорамый калган. Хәер, берьюлы икесен дә күмү мөмкинмени? Соңыннан белешер, әтисенең каберен табар.

Яңа бистәнең татар зираты айлы капкасы, бөреләре яңа гына ачылып беткән ямь-яшел агачлары белән каршылады аларны. Җирдә үләннәр баш калкыта. Табигатьнең үзгәрә, яшәрә торган чагы. Гаҗәп, нинди капма-каршылык: җир, табигать көч ала, ә кеше дигәнең, барысын калдырып, шул мәлдә мәңгелеккә китеп бара. Әнә, бер кабер, салкын авызын ачып, Акболытның әнисен йотарга көтеп тора. Аның янында ук икенче бер кабер дә казып куелган. Димәк, анда да кемнеңдер мәетен китерәчәкләр.

Кабер янында мулла абзыйның тавышы ишетелде.

— Ягез, мәрхүмәне ләхеткә иңдерергә кемнәр төшәргә тиешле?

Өч кеше, шул исәптән Акболыт, берсе — кода баш очыннан, икенчесе — майор кияүләре бил турыннан, өченчесе аяк очыннан кызыл башлы сөлгеләр белән күтәреп алып, мәрхүмәнең гәүдәсен ләхеткә салдылар. Аннары ләхетне махсус китерелгән такталар белән әйбәтләп томаладылар. Аннары кабер өстенә шыбыр-шыбыр туфрак коела башлады...

— Хуш, әнкәй, урының җәннәттә булсын,— диде Акболыт әкрен генә.

Шул арада янәшәдәге кабергә дә кемнедер китерделәр. Ым кагыш аңлашу, сөйләшү, дога уку ишетелде. Көрәкләр кыштырдавы ишәя бара иде.

— Акболыт! — дигән сүзгә егет күтәрелеп карады. Өстәге кеше, имән бармагын изәп, аны кабер эченнән чыгарга чакырды. Бу аның әтисенең якын дусты Самат абыйсы иде.

— Дөньялыкта аерым яшәсәләр дә, кабергә янәшә ятсыннар инде. Ходай шулай язган, күрәсең,— диде ул.

Акболыт күпмедер вакытка телсез калды. Башы әйләнеп киткәндәй булды. Тәненә салкын тир бәреп чыгуын сизде. Изүен чишеп, солдат каешын бушатып җибәрде. Аннары, өнгә килгәндәй, көрәккә ябышты һәм әле әнисе, әле әтисе каберенә балчык ташлый башлады.

Мулла абзый тарафыннан догалар укылып беткәч тә, Акболыт, көрәге сабына таянган килеш, ике кабер арасында басып тора иде. Инде кайтам дисә — әнисе, барам дисә, әтисе юк аның. Ичмасам, йә кыз, йә ир туганы булсын икән. Бу минутларда Акболытның бөтен торышы, кыяфәте бөек шагыйребез Хәсән Туфанның шигъри юлларын искә төшерә иде:

> «Бирде дөнья кирәкне,
> Еламаска өйрәтте...
> Кайсыгызның кулы җылы? —
> Бәйлисе бар йөрәкне...»

Соңгы вакытта аларның гаилә хәлләре һич көтмәгәнчә катлауланып китте. Бу аеруча Акчәчәк әби белән Гөлбөттин бабайга каты сукты. Атналар буе сүз куерткannan соң, киленнәре Зилзилә ханым бу юлы кырт кистереп әйтте:

— Иртәгә иртәдән кузгалырлык итеп җыенып куй, Акчәчәк әби,— диде, каядыр чыгып китәргә җыенып.— Мине бүтән төрле хәрәкәтләр ясарга мәҗбүр итмә.

Әлеге сүзләр карт белән карчыкны судагы балыклар шикелле телсез калдырды. Өйдә авыр тынлык урнашты. Бу минутларда алар һәркайсы үз уенда иде.

Әйе, әле бер ел элек кенә бу йортта Гөлбөттин бабайның ялгыз башы — тыныч колагы иде. Изге күңелле кешеләр аңа күрше Якты Алан авылыннан ялгыз карчык Акчәчәк әбине димләделәр. Һәм дә бик дөрес эшләделәр. Карт белән карчык бер-берсен бик тиз үз иттеләр, бер-берсен кайгыртып, тормышларын үзләренчә күңелле корып яшәргә сүз куештылар.

Акчәчәк әби килгәч, Гөлбөттин бабайның дөньясы түгәрәкләнеп киткәндәй булды. Өй яктырып, ямьләнеп калды. Иртәләре, кичләре бер җан рәхәте: кара-каршы утырып чәй эчүләр күңелне иркәләүче бер дәвам, бәйрәм иде. Кечкенә генә агач бакчасы, каралтыдагы берничә тавык, каз-үрдәк тә уңай үзгәрешләрне сизеп, тоеп тордылар.

Былтыр көз көне, авылда беренче чана юллары төшкәч, Гөлбөттин бабайның оныгы Казаннан бөтенләйгә монда кайтты. Тырыш һәм уңган егет кайтып озак та тормый эшкә чумды, дуслары, иптәшләре ярдәмендә бизнес белән шөгыльләнә башлады. Ярты ел дигәндә ул инде машиналы булды, озакка сузмыйча, күзе төшкән кызга — Зилзиләгә өйләнеп тә куйды. Карт белән карчык боларның барсына да бик шат, хәерхак иделәр.

Әмма Сарытау кебек зур район үзәгендә бик тыныч түгел иде шул. Кемнедер көчләү, кайсындыр талау турында хәбәрләр ишетелеп тора иде. Гөлбөттин бабайның оныгы да явыз көчләрнең даими күзәтүендә булган, күрәсең. Матур яз көннәре килеп җиткәндә билгесез мөртәтләр аның гомерен өзделәр. Менә шул көннән гаиләдә бәрәкәт калмады. Киленнең өйдә артык кеше күрәсе килми иде. Карт та, карчык та моның сәбәбен аңламадылар, чөнки килен кайсына да ниндидер гаеп ташламый иде.

Бу кичне алар барысы да соң гына йокларга яттылар. Ләкин Акчәчәк әбинең дә, Гөлбөттин бабайның да күзләренә йокы керерлек түгел иде.

— Ахыргы төнне сөйләшеп кенә үткәрсәк иде, Гөлбөттин,— диде Акчәчәк әби йомшак һәм ялварулы тавыш белән.

Карт җавап бирми күпмедер вакыт тавыш-тынсыз ятты. Әби әлеге соравын яңадан кабатлагач кына, Гөлбөттин бабай катгый карарын белдерде:

— Беркая китмисең, беркая бармыйсың. Соңгы сулышыбызгача бергә яшибез. Ходай безгә шулай язган,— диде.

Нигәдер Акчәҗәк әбинең тамагына яшьле төер утыргандай булды, аннары шушы төер эреп, күзләреннән яшьләр тәгәрәп чыкты. Картның бу сүзләре Акчәчәк әбидә ничә төрле уй, ничә төрле сорау барлыкка китерде. Нигә соң ул шулай итеп Зилзилә киленгә әйтми, нигә карчыгын якламый, нигә соңгы минутка кадәр берниндi ачыклык юк? Әйе, әби боларны үзе дә картына ишеттереп әйтергә базмады, хәтеренә авыр алмасын, дип уйлады ул.

— Гөлбөттин, әле йокламадыңмы? — дип сорады әби янә, гаепле кешенеке сыман тавыш белән.

— Юк, йокламадым, карчык.

— Мин әйтәм, әгәр калсам, сиңа кыенлык килер бит. Минем аркада килен сиңа туктаусыз бәйләнер?! Сине, дәү әтисен, куа алмас анысы. Ә мин килен өчен чит бер кеше, артык кашык кебек күренәмдер инде.

Бик ашыгып сүзгә кушылмый торган Гөлбөттин бабай бу юлы да сабырлык күрсәтте, ул һаман тирән уйда, авыр кичерешләр эчендә иде. Карчыгын ул ничек итеп юатырга, бу кыен хәлдән ничек чыгарга икәнен дә белми иде. Ә Акчәчәк әбинең һаман сөйләшәсе килде. Әйтерсең, иң кадерле кешесе белән озак еллардан соң очрашкан да һич сөйләшеп туймый иде ул.

— Ишетәсеңме, Гөлбөттин, шуны белеп кал: мәкерле язмыш безне аерса да, синең белән булган көннәрем гомеремнең иң матур, рәхәт чаклары булып истә калыр. Мин сине беренче һәм соңгы ирем дип санаячакмын.— Бераз сүзсез торганнан соң өстәп куйды: — Бу көннәрне сагынып яшәве авыр булыр шикелле, Гөлбөттин.

Ә Гөлбөттин бабай бер үк сүзләрне диярлек кабатлады:

— Беркая китмисең, беркая бармыйсың!..

Сөйләшә-сөйләшә таң атты, өйгә яктылык төште, әйберләр ачык күренә башлады. Гөлбөттин бабай тыенкы гына гырылдап, йоклап китте. Аның чал чәче, ап-ак сакал-мыегы бөтен йөзен яктыртып тора кебек иде. Акчәчәк әби картының җитмеш биш яшькә җитеп тә күркәмлеген җуймаган йөзенә, тирән сулыш алуына карап торды. Ә бит бүтән көннәрне ул үзе дә шулай онытылып, тәмле итеп йоклый иде.

Урамда берәм-сәрәм кешеләр үткәләп йөри башлады. Кайдадыр мотоцикл тырылдап кузгалды. Акчәчәк әби дә, яңа гына йокыга киткән картын уятмас өчен, әкрен генә урыныннан торган иде. Ләкин Зилзилә килен, мыгырдана-мыгырдана җәһәт кенә килеп, бабайның гәүдәсенә төрткәли-төрткәли:

— Монда яшисең килсә, бу карчыкны хәзер үк үз авылына озатып куй! — дип китеп барды.

Акчәчәк әби белән Гөлбөттин бабай район үзәген чыкканчы берни сөйләшми атладылар. Тирән кичерешләр нәтиҗәсендә кулларындагы төенчекләренең авырлыгын да сизмәделәр алар. Бары тик Бистәне үтеп, Якты Алан басулары башлангач кына, ял итеп алырга уйладылар. Ирләрчә сабыр, эчтән генә җылый белә торган әби, төенчекләрне куйгач, артка борылып карады. Бу аның күпмедер вакыт яшәгән һәм торган җире белән шулай саубуллашуы, соңгы тапкыр карап калырга тырышуы иде, күрәсең. Ни гомер яшәп тә агармаган, сирәкләнмәгән чәчләре, кершән яккан кебек ап-ак йөзе, уңъяк бит уртасындагы зур миңе — барысы да үзенә бик килешеп, аны мөлаем итеп тора иде.

Гөлбөттин бабай яшел дулкыннар йөгерешкән иген кырларына таба борылды. Бу минутларда алар икесе дә бер-берсеннән тартынган, оялган, бер-берсеннән нindидер серләрен яшерергә тырышкан кешеләргә охшыйлар иде. Тынлыкны карты бозды, сүз булсынга гына әйткәндәй:

— Җәй көне, мин әйтәм, авылда рәхәт инде, карчык...— дип куйды.

Акчәчәк әби картының кыен хәлдә булуын бик яхшы аңлый иде. Шуңа күрә аның йөзендә аңа карата үпкә-сапка сизелмәде.

— Бүген без икәү кичерә торган хәлләр элек халкыбызда булмаган, Гөлбөттин. Заманасы шулай,— дип, хәлен җиңеләйтергә теләде ул иренең. Шуның белән ике арада тел чишелеп киткәндәй булды:

— Ашыкмый гына, ял итә-итә барыйк,— дип дәвам итте сүзен Акчәчәк әби.— Барасы җир ерак түгел, әнә шул калкулыкны менәсе дә төшәсе генә ич. Бер чакрымлап ара.

— Ничек матур гына яши идек, Акчәчәк,— дип өзелеп әйтеп куйды Гөлбөттин бабай, юлга кузгалып.

— Мин ялгыз булмам, Гөлбөттин, гел бергә чакларны истә тотармын. Шуның белән юанырмын.

Алар юл буе берөзлексез сөйләшеп бардылар, узган көннәрне кат-кат искә төшерделәр, туктап-туктап ял иттеләр, матур булып күтәрелеп килгән игеннәргә, бу якларның табигатенә карап сокландылар. Калкулык өстенә менеп җиткәч, калкулык итәге буйлап бормаланып сузылган инешнең теге ягына, тигезлеккә урнашкан авыл күренде.

— Менә безнең Якты Алан. Килеп тә җиттек,— диде Акчәчәк әби.

Алар калкулык өстеннән агач бакчаларына күмелеп утырган авылны күзәттеләр. Озын манаралы яңа таш мәчет, анда-санда яңа салынган өйләр авылны яшәртеп, яңартып җибәргәннәр. Хисләр өермәсе Акчәчәк әбинең бөтен уйларын биләп алды. Бу өйләр, урамнар, кешеләр белән күпме хатирәләр бәйле. Бу җирләрдә никадәр шатлык, никадәр кайгы кичерелгән. Кайсыдыр урамнан, кайсыдыр өйдән аның балачагы йөгереп чыгар төсле.

— Гөлбөттин, риза булсаң, хәзер мин сине озата барам?— диде Акчәчәк әби, картның күзләренә карап. Гөлбөттин бабай, әлбәттә, бу тәкъдимгә риза иде:

— Алда көн әле озын, бүгенге вакытны булса да бергә уздырыйк, Акчәчәк!— диде ул.

Карт белән карчык көн буе юлның әле бер, әле икенче башына кадәр бер-берсен озатышып йөрделәр. Инде көн тәмам кичкә авышты. Район үзәге белән Якты Аланны тоташтыручы юлның урта бер җирендә дияр-лек тукталып, саубуллашырга килештеләр. Берничә минут тынлык, күз-ләрдә — ирексездән бәреп чыккан ачы һәм татлы яшь бөртекләре. Ерак-тан караганда янәшә куелган һәйкәлләр кебек күренә иде алар бу минут-ларда.

Монда күпме басып торсаң да, барыбер кайчан булса да аерылырга кирәк иде. Рәхимсез тормыш шуны таләп итә. Гөлбөттин бабай соңгы тапкыр карчыгына кул биреп, башын түбән иеп, кайтыр юлга борылды. Акчәчәк әби аңа:

— Гөлбөттин, киленгә миннән сәлам әйт. Минем аңа кыек караганым, ялгыш сүз әйткәнем булмады бит...— дип калды. Онытылган сүзе искә төшкәндәй өстәде:— Гөлбөтти-и-ин, үзеңне саклый кү-ү-үр.

Карт артка борылып кул болгады. Ләкин нидер әйткәне ишетелмәде. Акчәчәк әби урынында берничә минут сүзсез басып торганнан соң, яңадан кычкырды:

— Кыен хәлдә калсаң, миңа килерсең, Гөлбөтти-и-н!

Бу сүзләрне карты ишеттеме-юкмы, карчыкның үзен җан өшеткеч уйлар биләп алды. Йорт-җире, якын туганнары инде юк. Кемгә, кая кайта соң әле ул? Аны монда кем көтеп тора?

Акчәчәк әби якынлашып килгәндә, авыл өстенә караңгылык җәелә башлаган иде инде...

* * *

Бөтенләй күз бәйләнгәнче кайтып җитием, дип ашыккангамы, Гөлбөттин бабай шактый талчыккан иде. Капканы ачып кергәч, бу арганлык үзен тагын да ныграк сиздерә башлады. Әлбәттә, монда тирән борчулы уйларның да тәэсире зур булгандыр.

Нигә соң әле ул үзенең яраткан карчыгы Акчәчәкне бик җиңел генә авылларына кире илтеп куйды? Бергә торып калсалар, аларга кем нәрсә эшли алыр иде икән?! Бу сораулар аңа юл буе тынгылык бирмәде һәм менә, кайтып җиткәч, күңелендә тагын да көчлерәк дөрли башладылар. Бу минутларда аңа йорт, бөтен каралты-кура моңлы, кайгылы булып күренде. Ишек алдындагы, көне буе суда йөзеп, болында йөреп, кунарга кайткан казлар аңа: «Кайда ягымлы әбиебез, ялгыш гамәлләр кыласың түгелме, аксакалыбыз?» — дип карыйлар төсле иде. Яктырак чакта куна-časына менә алмый калган кара тавыкның абзар капкасы янында «кырр-кырр» дип йөренүе дә күңелгә шом сала иде.

Гөлбөттин бабай, өйгә дә кереп тормыйча, агач бакчасына үтте. Әнә аның карчыгы яраткан алмагачы. Төбендә, икесе утырып ял итү өчен, үзе ясаган эскәмия. Шунда бераз ял итсә, кичке саф һава суласа, хәл кереп китәр төсле. Ходай кушса, аннары өйгә кереп чәй эчәр.

Әмма яшел бакча, саф һава гына аңа көч өсти вә җан тынычлыгы бирә алмады. Матур булып үсеп килүче бәрәңгеләр, инде тирес өстен томаларлык булган кыяр, гөрләп-яшьнәп утырган яшелчә түтәлләре берсе дә Гөлбөттин бабайны куандыра алмады.

— Кара-каршы утырып инде кем белән чәй эчәрмен? Серләремне сөйләрлек янымда кемем бар инде минем? — дип сөйләнде ул үз-үзенә.

Аның өчен дөньяның бөтен матурлыгы бетте. Һәм ул аны үзе бетерде бугай. Нигә Акчәчәк карчыгын авылына кире илтеп куйды соң әле ул? Илткән тәкъдирдә, нигә соң әле аңа карчыгы белән шул авылда калмаска иде? Нигә соң әле килене Зилзилә алдында коелып төште ул? Бу каушап калуны, тирән ялгышуны ничек төзәтергә? Әйе, иртәгә үк ул аны бәхилләтергә, кабат алып кайтырга барачак. Бу инде картның катгый карары. Шулай булыр да, дип беркетте ул күңеленә. Ләкин Акчәчәк карчыгының йөрәгенә уелган тирән яра төзәлерме соң? Кеше күңеле пыяла — кагылдымы уала, диләр бит. Юк, карчыгы аның хатасын гафу итәр. Ул шундый заттан, шундый нәселдән. Үзенә авырлык килсә — килер, ләкин кешегә авырлык китермәс. Үзенә авыр сүз әйтсәләр дә, ул кешегә авыр сүз әйтмәс.

Зилзилә каяндыр кайтып керде, кичке ашны әзерләп тамак туйдырды, чәй эчте. Гөлбөттин бабайның һаман кайтып җитмәвен исенә төшереп, капка төбенә чыкты. Инде урамга эңгер-меңгер төшкән. Күрәсең, картның кайтмавыдыр, йә кунарга, йә бөтенләй аның белән калгандыр, дип уйлады ул. Хәер, ничек булса да аның өчен барыбер иде. Шулай хәл ителгән, күңел шуңа күнгән. Бөтенләй кайтмаса да җыламас.

Мәсьәлә иртә белән ачыкланды. Ашка яшел суган алып керим, дип бакчага чыкса, Зилзилә ни күрсен, Гөлбөттин бабай алмагачы төбендәге эскәмиядә утыра. Зилзилә аны яңа гына кайткан да, киленен уятмаска теләп, юлдан соң ял итеп, хәл алып утыруы дип аңлады.

— Дәү әти, әйдә чәй эчәргә кер! — диде ул, суган кыякларын өзә-өзә.

Карт дәшмәде. Зилзилә шул ук сүзләрне кабатлады. Карт тагын дәшмәде. Килен аның янына килде һәм шунда гына Гөлбөттин бабайның күзләре мәңгегә йомылган икәнен күрде. Сорау билгесе кебек катып калган гәүдәсе, әйтерсең, тормышның, гомеренең болай тәмамлануына кемнәндер, ниндидер җаваплар көтә иде...

## Кайда син, Хәмдия?

Үземнең ике абыем була торып, әнием никтер бөтен вак-төяк эшләрне миңа гына куша торган иде. Әле башлангыч сыйныфларда гына укуым аның уена да кереп карамый иде, күрәсең. Бу бигрәк тә җәй көннәрендә шулай була иде. Бала карау, бакча чүбен утау, бәрәңге әрчү, иртүк терлекләрне көтүгә куу дисеңме — аларның барысын да санап бетерерлек түгел инде. Бигрәк тә теңкәмә тигәне — кичен көн саен көтүдән кайтмый торган бер кысыр сакалбай кәҗәбезне эзләү иде.

Бу юлы да шулай булды. Көтү күптән кайтты. Урамда, читән буйларында үлән ашап йөргән сыерлар да, әле теге, әле бу урамда «бә-ә-ә» дип кычкырышкан аңгыра сарыклар да, үз өйләрен-абзарларын табып, тынып калдылар. Ә безнең кәҗә һаман юк та юк.

— Бүреләрдән ашатасың бит, юньсез, ник эзләмисең кәҗәне? — дип кычкырган әнкәй тавышына сискәнеп киттем һәм бүген авылга көтү килеп кергән якка шешә бөкеседәй атылдым. Йөгерергә дисәң, миңа гына куш инде! Шул кәҗәне эзли-эзли тәмам узышчыга әйләнеп беттем бит.

Эңгер-меңгер төшкәнче дип, тиз арада авыл янындагы үләнле урыннарны, иңкүлекләрне, коры елга, күл буйларын әйләнеп чыктым. Дүрт урамны аркылы-торкылы урадым. Шуннан соң гына, уйнак тай шикелле, кыр өстенә сыпырдым. Әллә шул тирәләрдә көтүдән аерылып калмаганмы, мин әйтәм. Кыр өстенәрәк күтәрелгән саен авыл һава диңгезенең төбе шикеллерәк күренде миңа. Бөтен тирә-якта җәйге зәңгәр кич хөкем сөрә. Биткә салкын да, эссе дә булмаган, үзенә бер рәхәт, тәнне иркәләүче һава килеп бәрелә. Тегендә-монда сугыла торгач, миңа таба йөгерүче бер җан иясе пәйда булды. Чү, мин әйтәм, нәрсә булыр бу? Эт яки бүре-фәләнгә охшамаган үзе. Шүрәле дә юк — калмагандыр инде безнең сыек урманнарда. Ниһаять, якынлашкач, ни күрим: әлеге җан иясе авылыбызның икенче башында яшәүче минем яшьләрдәге Хәмдия ич!

— Нишләп кыр бетереп йөгереп йөрисең, кызый? — Сулышы капканга, бераз вакыт сүзен әйталмый торды бу.

— И Йосыф, син икәнсең әле. Әллә ниләр уйлап бетердем, — диде аннары.

— Алай курыккач, бу вакытта нишләп йөрисең соң?

— Бозавыбыз көтүдән кайтмады шул.

Без кәҗәне дә, бозауны да икәүләп эзләргә сүз куештык. Кайда гына булмадык, ләкин эзли торган малларыбызны очрата алмадык. Башны иеп, өйгә кайтып китәргә туры килде. Хәмдия ничек иткәндер, әмма мин үзем эчтән генә кәҗәнең тетмәсен теттем инде! Иртәгә барыбер табармын, дидем. Ну, тапсам, Вәлишә абзыйларның борылып-борылып, кәкрәеп-кәкрәеп үскән мөгезле кәҗә-тәкәләренә алып барып җаныңны алдырам түлке, дидем. Тагын әллә нәрсәләр әйтеп тиргәдем.

Өйдә ниләр булганын сөйләп тормыйм. Әмма кәҗә белән икенче көнне дә шул ук хәл кабатланды. Көтү кайтты, безнең кәҗә тагын күренмәде! Тагын шул ук эзләрдән чыгып йөгердем. Гаҗәп, бик тә гаҗәп килеп чыкты: кабат Хәмдия белән очраштык. Аларның да бозаулары тагын кайтмаган. Бу юлы да бергәләп дөнья бетереп әйләндек. Шунысы куанычлы, йөрүебез бушка китмәде. Аның бозавы, минем кәҗәм табылды! Шатлануыбызның чиге-чамасы юк иде.

Тик шул чагында минем өчен көтелмәгән бер нәрсә булып алды. Хәмдия колагыма үрелде дә, кеше ишетмәсен дигәндәй, пышылдап кына:

— Исемең бигрәк матур бит, Йосыф! Мин сине яратам! — диде.

Кызның ачык итеп, өздереп әйткән шушы сүзләре, колагыма бәрелгән җылы вә татлы сулышы мине тәмам әсир иткән иде, ахрысы. Күземне ачып җибәрсәм, Хәмдиядән җилләр искән иде инде.

Икенче көнне мин үзем үк кәҗәбезнең көтүдән кайтмавын тели башладым. Аны, миңа кылган изгелеге өчен, иркәли, сыйпый идем, тәмле ипи каптыра идем. Шунысы гаҗәп, кәҗә мине киресенчә аңлады булса кирәк, көн саен туп-туры өйгә кайта торган булды. Алай да югалып калмадым. Хәмдия безнең кәҗәнең кайтканын-кайтмаганын беләмени? Икенче көнне дә мин, кәҗә эзләгән кыяфәттә, шунда йөгердем. Бик кызганыч булды, аны очрата алмадым. Ун көн, егерме көн чыктым бугай. Менә бүген, менә бүген бозаулары көтүдән кайтмас, Хәмдия аны эзли чыгар, дип күңелемне алдадым. Әгәр бозауларын танып калган булсам, көтү кайтканда каршы чыгып, аны кайтармыйча тоткарлау чараларын күрергә дә әзер идем.

Бераз вакыттан алар гаиләсенең бөтенләй үк каядыр күченеп китүе турында ишеттем.

Еллар аккан судай, искән җилдәй узды. Әмма Хәмдиянең теге чакта: «Исемең бигрәк матур бит, Йосыф! Мин сине яратам!» — дигән сүзләре бүген дә колагымны иркәләп тора.

Мин йокыдан уяныш киткәндә тәрәзәдән төшкән кояш нурлары битләремне рәхәт җылытып, бөтен тәнемне иркәли иде. Яңа гына күргән төшнең матурлыгыннан уйларым яктыра, күңелем сафлана бара сыман. Шул татлы төштән аерыла алмыйча урында озак яттым шикелле. Һәр манзараны күз алдыма китерәм дә үземә-үзем: әллә чыннан да дөрес микән? дип сорау биреп куям. Барысы да хыялый төш кенә, дип күңелне ышандыру, әлбәттә, авыр иде.

Ә төшемдә менә ни күрдем. Имеш, Казансуның уң ягыннан — гәзит-журналлар нәшрияты тирәсеннән үтеп барам икән. Күзем шул тирәдә калку итеп махсус эшләнгән бер мәйданчыкка төште. Аның тирәсенә тыштан ялт-йолт килеп торган ниндидер автобуслар килеп туктаган. Мәйданчыкта төркем-төркем кешеләр, имеш. Моңа кадәр күрелмәгән бу нәрсә икән соң? дип шунда юнәлдем. Килгәч кенә аңлашылды: бу төркемнәр барысы да чит ил туристлары булып чыкты. Үзем дә бер төркемгә барып кушылдым. Зифа буйлы, алсу йөзле, чәч дулкыны иңенә коелып торган татар кызы чит ил кешеләренә каршы яктагы Кремльнең һәм дәүләтебезнең үткәне, бүгенгесе турында сөйли. Татарча да, инглизчә дә аңлата, имеш. Кремль ягына карасам, күрәм: бөтенләй күзгә чалынмаган илаһи бер күренеш. Элеккеге амбарларга охшаш дүртәр катлы иләмсез биналарның эзе дә калмаган, имеш. Алар урынына 1552 еллардагы Кремль торгызылган кебек. Ерактан ук хан сарайлары, Колшәриф, Нургали мәчетләре, алтын айлы күп манаралар балкып, күңелләргә нур биреп тора, имеш.

Әлеге махсус мәйданчык янынннан өр-яңа автобусларга төялеп килгән туристлар иң әүвәл Кремль белән Казансу арасына салынган бер мәһабәт һәйкәл янына тукталдылар. Кунакларны таныштырып йөрүче татар кызы бу һәйкәлнең Явыз Иванга каршы канкойгыч сугышларда илебезне яклап шәһит киткән ватандашларыбыз истәлегенә куелуы турында сөйли. Һәйкәлнең иң биек урынында әллә ничә потлы сәгать урнаштырылуын әйтә. Ул сәгать шәһәрнең дошман тарафыннан алынган вакытына туры китереп, көнгә бер тапкыр шомлы да, моңлы да бер көй уйный, аннары мондый шигырь укый, имеш:

Чал Казан искәртә узганны:
— Гафу ит, киләчәк, яндык без.
Иңрәде җиребез ул көннәр.
Ирексез һәм Илсез калдык без.
Бик ерак юлыбыз. Тагын бер
Фаҗига кичмәсен халкыбыз.
Бердәмлек, кыюлык, туганлык! —
Милләттәш, нык булсын антыбыз!

Бу көй, бу сүзләр кеше тәненең барлык күзәнәкләренә үтеп, җаннарны тетрәтеп, шәһәребезнең барлык почмакларына ишетелеп тора кебек. Кызның сүзе тәмамлангач, гарәп илләреннән килгән мөселманнар да, ялтыратылган хром итектәй йөзле африкалылар да фотоаппаратларын чалт-чолт китереп алалар, һәйкәлгә сокланып карап торалар, үзара нидер сөйләшәләр иде. Сөйләп-аңлатып йөрүче кызның:

— Хәзер Кремльнең эченә керәбез. Миннән, бер-берегездән аерылып йөрмәгез,— дигән мөрәҗәгате барысын да хәрәкәткә китерде. Без Казансу ягы капкасы аша Кремль эченә атладык. Йа, Ходай, монда никадәр үзгәреш, никадәр яңалык! Керүгә үк эреле-ваклы кибетләр тезелеп киткән. Чит ил кунаклары алардан түбәтәйләр, читекләр, кәзәки, камзол, чапан, Казан һәм Болгар патшалыгы чорындагы киемнәрне, күптөрле башка бүләкләр ала башладылар. Ә кибетчеләр сатып алучы-

ларны тәмле тел белән каршылыйлар һәм озатып калалар иде. Сувенир алган һәркемгә алар:

— Рәхмәт сезгә, тагын килегез,— дип кул изиләр.

Кызыл гранит баскычлардан өскә таба күтәреләбез. Һәркемнең күзендә шатлык һәм кызыксыну чаткылары. Чит ил кешеләре бер-берсенә әле Сөембикә манарасын, әле ак мәчетләрне, озын манараларны, башка корылмаларны күрсәтешәләр, кыскасы, фикер алышалар иде.

Бераз күтәрелгәч, безне туктаттылар. Бу — Кремль эчендәге хәрәкәтне тәртипкә салып торучылар иде. Төркем җитәкчебез, мәсьәләне аңлатып, безне тынычландырырга ашыкты:

— Хөрмәтле әфәнделәр, берничә минут сабыр итегез. Әз генә вакытка хәрәкәт тукталып торачак. Хәзер сезнең алдан гарәп илләренең Казандагы илчеләре хан сараена үтәчәкләр,— диде.

Олы кунакларны һәркем яхшылап күреп калырга тырышты. Төркемнәр эчендә җанлылык башланды. Һәркайсы уңайлы урыннарны сайлап бастылар. Туристлар озын торбалы фотоаппаратларын, кайсылары кечкенә киноаппаратларын көйләп куйдылар.

— Киләләр! — дигән аваз ишетелде.

Ул да булмады, алдыбыздан кайсы Ясир Арафатныкы шикелле шакмак яулыклы, кайсы ак яулык япкан, баш түбәсенә кара кыршау сыман әйбер киергән, озын күлмәкле мөселман дәүләтләре эшлеклеләре хан сараена таба үтеп киттеләр. Шуның белән безнең дә маршрутыбыз, йөрү тәртибебез үзгәреп куйды бугай. Чөнки Кремль белән танышуны безгә панорама караудан башларга тәкъдим иттеләр. Төркем җитәкчебез безне шул якка әйдәде. Бу бина Кремльдәге башка корылмалар арасында шактый үзенчәлеклесе булып, тышкы ягы белән Мәскәүдәге «Бородино сугышы панорамасы»на охшабрак тора икән. Аның алгы ягына алтын хәрефләр белән латин шрифтында мондый сүзләр язып куелган: «Татар халкының 1552 елгы Ватан сугышы күренеше».

Изге бер йортка кергән кебек, сөйләшү дә пышылдашуга гына күчте. Йөзләрдә җитдилек һәм кызыксыну. Аяк киемнәрен милли чүәкләргә алыштыргач, яңа экскурсовод безне беренче катта урнаштырылган экскаваторлар белән таныштырды. Казанны саклауны оештырган ул вакыттагы хәрби җитәкчеләрнең рәсем-сурәтләре, шул чорның кораллары беркемне дә битараф калдырмады. Әмма иң мавыктырганы — панораманың икенче катында иде.

— Ерак илләрдән килгән кадерле кунаклар,— дип башлады сүзен экскурсовод.— Сезнең алда — Казан шәһәренең Явыз Иван тарафыннан камап алынуы. Казанны бирмәс өчен барган каты сугышлар күренеше. Аны Татарстаныбызның иң күренекле рәссамнарыннан дистәләрчә сәнгатькәрләр бригадасы озак еллар эшләде...

Әйе, безнең күз алдыннан татар халкының тигезсез авыр сугышта тиңсез батырлыклар күрсәткән исәпсез фаҗигале күренешләр узды. Дошманның шәһәр кальгалары янына килүе, каланы утка тотуы, җир астыннан казып килеп, Кремльнең берничә манарасын шартлатуы. Кремльгә кертмәс өчен сугышлар, барлык әсирләрне кылыч белән турап бетерү... Ядкәр ханны кулга алу, шәһәрне талау, балаларны, хатын-кызларны мәсхәрәләү күренешләре — барысы да тетрәндергеч буяуларда сурәтләнгәннәр. Кирәк урында әсирне төрле төстәге утлар белән яктырту да бу тиңдәшсез полотно-әсәрне бик тәэсирле итә иде.

Безнең моннан соң тукталган урыныбыз ханнар зираты булды. Аның милли нәкышләр белән бизәкләп эшләнгән тимер капкасыннан һәркем баш киемен салып, кулына тоткан хәлдә керде. Бөтен тирә-як ямь-яшел чирәм, имеш. Урта бер җирдән тигез рәт булып җыйнак-җыйнак символик каберләр тезелеп киткән (символик дибез, чөнки Казанны алганда дошман барлык мавзолей-төрбәләрне җимереп бетергән). Каберләрнең баш очларына зур булмаган мәрмәр ташлар куелган. Аларның һәркайсында бер ханның исеме: Алтынбәк хан, Галимбәк хан, Олуг Мөхәммәт

хан, Мәхмүт хан, Хәлил хан, Ибраһим хан, Илһам хан, Мөхәммәтәмин хан, Габделлатыйф хан, Сәхипгәрәй хан, Җангали хан, Сафагәрәй хан, Үтәмешгәрәй хан (Сөембикәнең улы), Шаһгали хан, Ядкәр хан...

Безне алып йөрүче кызыбыз һәр ханның яшәгән чоры, аның эшчәнлеге турында кыска гына сөйләп үтте. Халкыбызның үткәне, дәүләтебез тарихы күпмедер дәрәҗәдә күз алдыбызга килеп баскандай булды. Һәркем күбрәкне дә белергә тели иде. Берәү сорап куйды:

— Казан патшалыгының соңгы ике ханы — Үтәмешгәрәй һәм Ядкәр ханнарның җәсәдләре Мәскәү Кремле эчендә күмелгән. Сөембикәнең кабере Касыйм шәһәрендә. Татарстан хөкүмәте өчесенең дә җәсәден алып кайтып җирләү турында уйламыйммы?

— Ике хөкүмәт арасында сөйләшүләр бара,— дип әйтү белән тәмамларга теләде җавабын экскурсовод кызыбыз. Аннары өстәп куйды:— Мәсьәлә хәл ителер дип ышанырга кирәк.

Хан сараена аеруча дулкынлану, тетрәнү белән аяк атладык. Сөембикәне улы белән икесен 1551 елда шушыннан алып чыгып, көймәдә Идел буйлап Мәскәүгә озатканнар. Патшалык җимерелгәч, Казанның соңгы ханы Ядкәрне шушыннан кулга алганнар. Дәүләтчелегебез бетүенең соңгы нокталары шушында куелган.

Хан сараеның алгы бүлмәсендә үк безне озын буйлы, нык тәнле бер егет каршылады.

— Әссәламегаләйкем! Хуш киләсез, хөрмәтле кунаклар! — диде ул ачык йөз белән. Аңа шулай ук мөселманча җавап кайтардылар:

— Вәгаләйкемәссәлам, туган!

Туристларны каршы алган егетнең кара хәтфәдән тегелгән түбәтәе, аягындагы сафьян итеге, өстендәге кәтүк җебе нечкәлегендәге ак буйлы камзолы үзенә бик тә килешеп тора иде. Аңа карап, әйе, бабайлар киенә белгәннәр, дип уйлыйм, имеш. Ханнарның эш бүлмәләренә керер алдыннан ул безнең белән тулы бер инструктаж үткәрде:

— Гафу итәсез, кунаклар, фото һәм кино аппаратларын монда калдырыгыз. Аларны чыкканда алырсыз. Тәртип шулай. Монда бернәрсәне дә рәсемгә төшерергә ярамый. Арагызда журналистлар булса, исегездә тотыгыз: каләм-блокнот кирәк булмас.

Акыллы киңәшләрне тыңлаган хәлдә, шуны гына әйтә алам. Сөембикә 1551 елда, үзен алып китәргә килгән урыс төркеме кергәндә, ничек утырып торган булса, балавыздан ясалган сында да нәкъ шул мизгелне койганнар. Янында дүрт яшьлек Үтәмешгәрәе басып тора. Матурлыкларын, әлбәттә, сөйләп бетерерлек, кешегә аңлатырлык түгел иде. Ядкәр хан исә килешү буенча Мәскәүдән алып кайтылган алтынлы-зәбәрҗәтле һәм асылташлар белән бизәүле урындыгында утыра. Мәскәүдән алып кайтылган шундый ук кыйммәтле һәм зиннәтле бүреге, таягы янына куелган. Сөембикә дә, Ядкәр хан да зур-зур пыяла шкафлар эченә урнаштырылганнар. Кайбер мизгелләрдә бу балавыз сыннар тере кешеләр кебек күренәләр иде.

Озын манаралар, ак мәчетләрне, узган заманнарны чагылдырган музейны тышкы якларыннан гына күреп калдык шикелле.

Мин тәрәзә аша күземә төшкән иртәнге кояш нурларыннан уянып киттем. Хикмәтле төшем шул урында өзелеп калды. Миңа бу хәл бик тә кызганыч булып тоелды. Шулай да күргән кадәресе мине ваемсызлык сахрасыннан тирән уй-кичерешләр диңгезенә кайтарып куярга бик җиткән иде инде...

«Зингерулла энем... Әстәгъфирулла, исемегезне әйттем дә бөтен тәнемә бала йоннары чыкты бугай, әйе. Хәер, ул исемне син үзең сайлап алмаган инде анысы. Әти-әниең укыган кешеләр булырга охшый, әйе. Безнең кебек гади крәстияннән андый сүз чыкмас. Аңа китсә, бүген нинди генә исемнәр ишетмисең: Энгель, Альфред, Адольф, Спартак, Трактор, Рево. Хәтта бер хатын сырхауханәнең ишегендә күреп кайткан «информация» дигән сүзне үзенең яңа туган кызына исем итеп кушкан дип тә сөйлиләр, әйе.

Ләкин әйтәсе килгән сүзем башка турыда иде, энем. Сез авылыбызда тел турында сөйләп киткәннән соң, кешеләрнең тынычлыгы тәмам югалды бит әле. Без, гади авыл кешеләре, бу өлкәдә бөтенләй артта калганбыз икән, шуны аңладык, әйе. Үзегез монда чакта яныгызга килергә батырлык җитмәде. Аңлашылмаган бик күп сорауларыбыз калды. Әгәр шуларның кайберләрен генә язып үтсәм, ягъни, ниндидер дәрәҗәдә кыюлык күрсәтсәм, мине — бер авыл картын — бик ачуланмагыз инде.

Әле кичә генә күршем Сафиулла карт кергән иде. Сез әйткән «Түгәрәк өстәл артында сөйләшү» дигән сүзләр белән саташып йөри. Ничә кабат әйләнеп чыксам да, түгәрәк өстәлебезнең артын таба алмадым, ди ул. Кешеләрне өстәл янына, өстәл тирәсенә генә утыртсак, дөрес булмас микәнни, дип сорый. Сездән, галимнәрдән узып мин аңа рөхсәт бирә алмадым, энем Зингерулла. Тап, күрше, өстәлнең артын, ничек тә табарга тырыш, галим кеше белми әйтмәс, бардыр аның арты, дип аңлатып чыгардым, әйе.

Беркөнне галимнең «кунаклар табын артына урнаштылар» дигән сүзләре үземне дә борчуга салды әле. Бигрәк тә кунаклар кызганыч тоелды миңа. Алар каяндыр арттан табын янына килеп, ризык капкалап, чәй эчкәләп яңадан артка китеп утырырга мәҗбүр ителгәннәр, күрәсең. Кунакларны болай ук мәшәкатьләү ярап бетәр микән, дип уйлыйм. Моңа кадәр бездә укучылар парта артына түгел, партага, шоферлар руль артына түгел, рульгә, кешеләр, аш вакыты җиткәч, табын янына утыралар иде. Белми йөргәнбез икән бит. Бөтен авылыбыз белән гаепләмәгәйләре дип куркабыз.

Табын дигәннән искә төште әле. Татар газитләре «пешекче» дигән сүзләр язып чыгаралар. Нәрсәгә кирәк икән тагын ул пешекчеләр, хөрмәтле галим энем. Кечкенә балаларның бот аралары, култык аслары пешегүдән безнең авыл хатын-кызлары болай да аптырап бетәләр: мамык, пудра дигәннәре дә юк бит хәзер. Җитмәсә, шәһәрдә пешекчеләр укытып чыгара торган мәктәпләр ачканнар дип ишеттек, әйе. Авыл халкы аш-су осталары әзерли торган мәктәпләр ачылуын тели, югыйсә.

Зингерулла энем, кадерле вакытыгызны аламдыр дип, курка-курка гына язам. Галимлек эшегездә зыян китермәсәм ярар иде, шуңа күрә тагын бер-ике сүз турында гына сорыйсым килә. Күп кенә укыган кешеләр бу язучы мондый әсәр өстендә, тегe композитор шундый әсәр өстендә эшли дип сөйләп китәләр. Без, артта калган авыл кешеләре, тагын аптырашта инде. Ул әсәрләрнең өсләренә менмичә генә эшләргә мөмкин түгел микәнни? Ягъни авылдашлар әйтмешли, әсәр яза, иҗат итә, дип кенә әйтсәк, артталыкны, наданлыгыбызны күрсәтү булырмы? Аннары «исемен йөртә» дигән табышмакны бөтен авылыбыз белән дә чишә алмадык. Кем йөртә, ничек йөртә, ник йөртә? Без «Җәлил исемендәге күмәк хуҗалык», «Тукай исемендәге район» кебек сүзләрне шулай әйтмиләрме икән дип уйлыйбыз. Галим әфәнде Зингерулла, хатыгызда әнә шуларны да төшендереп язсагыз иде безгә.

Сорауларыбыз бик тә күп, Зингерулла энем. Аның барысын да язып бетереп булмас. Зур эшләрегезне куеп торып, безнең ишеләрнең мөрәҗә-

гатьләрен укып ятмассыз инде. Шуңа күрә иң кирәкле соравымны гына бирергә булдым, әйе. Эш менә болай килеп чыкты, энем. Былтыр көзнең беренче айларында «Ватан» дигән гәзитәбез соңгы битен тутырып, ат башы шае хәрефләр белән бер белдерү бастырып чыгарды. Укып карагыз әле, менә нәрсә дип язылган иде анда:

«Тиз барып ала торган вкладларга беренче октябрьдән процентлар арта!» Әлбәттә, вак хәрефләр белән язылган сүзләр дә бар иде. Безнең өчен шушылары әһәмиятле булганга күрә, калганнарын язып тору мәгънәсезлек тә, озынга сузу да булыр иде, әйе. Шуннан, галим энем, миңа җан кереп китте. Бүтән пенсионер картлар да мин аңлаганча төшенгәннәр икән. Вәт, без әйтәбез, хөкүмәткә рәхмәт, кеше турында ничек кайгырта бит. Мөстәкыйльлек алмаган булсак, мондый хәлләргә ирешер идек микән әле, дибез. Белдерүне бастырган гәзитәнең мөхәрриренә, аның акыллы урынбасарларына рәхмәтләр укый-укый, егерме чакрымдагы район үзәгенә саклык банкына чыгып киттек. Акчаларыбызны банкка салып, тиз генә барып алып, тагын салып, тагын тиз генә барып алып, процентны һаман арттыра-арттыра ярты ел буе район үзәгендә фатирда яшик әле, без әйтәбез. Өйдә тик ятканчы дибез. Акчаларыбыз бик күп арткач кына авылга кайтырга уйлыйбыз үзебез.

...Зингерулла энем, белсәң иде акчаны беренче тапкыр алырга килгәндә үк безне ничек орышканнарын. Ул белдерүдә сүз озак срокы вкладлар турында барырга тиеш булган лабаса. Менә шул көннән телне үстерәбез дип йөрүчеләргә дә, гәзитә чыгаручыларга да ышанычыбыз какшады әле. Авылча гына сөйләшеп, авылча гына язсагыз иде инде. Сезнең телне безнең кебек прастуй кешеләр түгел, районның укымышлылары да төшенә торган түгел икән. Бу хәлләргә тәмам ачуларыбыз чыгып, бер шагыйрь әйтмешли чурту-матыр, дип өйләребезгә кайтып киттек.

Хатка язып кына сүзләр бетмәс, ахры, Зингерулла энем. Тагын килүеңне авылыбыз белән көтәбез. Бу юлы туры үзебезгә кайт. Карчыгым милли пәрәмәчләр пешереп ашатыр үзеңә, Алла боерса. Телеңне йотарлык булыр.

Сәлам белән, Томанлы Тау авылыннан — Чулпани бабаң».

## Бәхетсез

Берәнбер көнне, җәй урталарында, авылның иң читендәге, тәрәзәләре такталар белән томаланып, каралты эчләренә, якын-тирәләренә әремнәр үсеп беткән өйдә яшь бер ир-егет кеше күренгәли башлады. Аның турында бөтен Каепбиргән авылында төрле сүзләр таралды:

— Берәр җирдән килгән жулик түгелме икән?

— Авылыбызга зыян китерә күрмәсен, Ходаем,— диючеләр булды. Ә кайберәүләр бүтәнчә фикер йөртте:

— Сугыш бара торган Таҗикстаннан, Чеченстаннан, йә Үзбәкстаннан кайткан кешедер ул.

— Төрмәдән чыккандыр да, торырга урын таба алмагандыр.

Ләкин бу юрауларның, имеш-мимешләрнең берсе дә дөреслеккә туры килми иде. Эш чынында менә болай булды. Кичке аштан соң, хәләл җефетем белән көн саен урамның бер башыннан икенче башына кадәр йөреп ял итү гадәткә кергәнлектән, әлеге йорт турыннан кат-кат үтәргә туры килә иде. Бу юлы да ул шулай килеп чыкты. Урамга карап торган томалаулы дүрт тәрәзәнең кырыйдан икенчесенең өске өлеше генә такталардан ачылып, кое төбендәге суның күзгесенә охшап калганлыгы

турында үзара сөйләшеп бара идек. Әлеге кеше, өй янында утырган җиреннән торып, туп-туры каршыбызга килеп басты.

— Казаннан килеп йорт сатып алган кешеләр сезме?— дип ул туп-туры һәм, җавап биргәнне дә көтеп тормыйча, сорауларны яудыра бирде.— Ә бу тирәдә көн саен нәрсә эшләп йөрибез?..

Ул һаман сораштыра, ә мин аның төсен-битен, буен-сынын күзәтәм. Кемгә, нинди адәмгә охшый, начар гадәтле кешеләр нәселен хәтерләтмиме, янәсе. Болай карап торышка үзе ким-хур түгел кебек, гәүдәгә дә ходай кимсетмәгән. Тик дулкынлануы бөтен торыш-кыяфәтеннән нык сизелеп тора. Тәмәкене суырганнан соң, бик тирән итеп эчкә ала һәм бөтен күзәнәкләренә сеңдерергә теләгәндәй күпмедер вакыт эчтә тотканнан соң, төтенне ике борын тишегеннән һәм авызыннан берьюлы бик тәмләп кенә чыгарып тора.

— Кайчаннан бирле сөйләшәбез, үзең исемеңне һаман әйтмисең,— дидем бу иптәшкә.— Гел үзең сөйлисең, ә мине ишетмисең дә.

— Андый гына кимчелекне төзәтеп була. Ә минем исемемне Хикмәтулла, дип белерсең, абый җаным. Вакытыгыз артык кысмаса, әйдәгез, мәнә капка төбендәге бүрәнәдә бераз сөйләшеп утырыйк?

Ә миңа, дөресен әйткәндә, урам буйлап йөрдем ни дә, авыл һавасын иснәп бер җирдә утырып тордым ни. Нәрсәдер турында сөйләргә теләге булгач, әйдә, сөйләсен. Һәм бергәләп утырып торырга, аны тыңларга әзер булуымны әйттем. Ләкин миңа саф һава иснәргә насыйп булмады. Чөнки әңгәмәдәшем тәмәкене берсе артыннан икенчесен кабызып кына торды.

— Бик авыр чакларым, абый җаным,— диде Хикмәтулла сүзен дәвам итеп,— өемне, гаиләмне ташлап чыгып киттем мин.

— Үз теләгең беләнме?

— Әйе, үз теләгем белән.

— Алай булгач, җәмәгатегез янына кире кайтырга киңәш итәр идем, энекәш.

— Юк, ул турыда сүз дә булырга мөмкин түгел, абый җаным.

Хикмәтулла тирән уйларга бирелеп, сөйләвен дәвам итте:

— Туйларыбыз нинди матур булган иде, абый җаным. Хатынымның Казаннан язучы, гәҗитче, табиб булып эшләүче туганнары килде. Ә нинди матур теләкләр теләделәр алар. Бөтен сүзләре йөрәк түремдә язып куелган кебек саклана.

Язучы туганыбызның чыгышы аеруча эчтәлекле булды: «Без кечкенә чакларда,— диде ул,— җиргә ап-ак кар яткач, беренче чана юллары төшкәч, икмәкләр амбарларга салынгач, мал-туар кулга кереп, суеласы суелгач, авылларда туйлар башланып китә торган иде. Бүгенге шушы күркәм тантанабыз да халкыбызның әнә шул матур гадәтләренә бик тә туры китереп үткәрелә. Бу кадерле минутларда мин Нәзифә белән Хикмәтуллага башланмаган бәхетләр, башланмаган шатлыклар телим. Тик шуны белегез, туганнар, тормыш гел бәйрәмнәрдән генә тормый. Иң авыр вакытларда бер-берегезгә терәк була белегез, авыр сүз әйтүдән сак булыгыз. Бер начар сүзне мең яхшы сүз дә йөрәктән юып төшерә алмый. Тәрәзә пыяласы да бер чатнап китсә, икегә аерылып төшкәнче ярыла гына бара бит. Өйдә янәшә торган чакларда да бер-берегезне сагынып яшәгез. Соңгы сулышларга кадәр адресыгыз бер булсын».

Бик тә күңел түренә үтеп керә торган сүзләр бит, абый җаным.

Хикмәтулла янып беткән тәмәкесен җиргә салып таптады, яңасын кабызды, тирә-як кабат тәмәке төтене белән тулды.

— Мондый тирән мәгънәле, җылы, ягымлы сүзләрне төн буе тыңларга риза,— дидем мин.

— Әйе, ул язучы саксыз әйтелгән бер сүзне мең яхшы сүз дә йөрәктән юып ала алмас диде. Ә мин, абый җаным, бер түгел, хатыныма-матурыма мең начар сүз әйткәнмендер шул. Туй барганда ук: «Авызыңны җәеп, күзләреңне елтыратып бүтән ирләргә карап утырма»,— дип

ысылдадым. Ә ул, артык әллә ни булмагандай, елмаеп утыруын дәвам итте. Эчтән борчылмагандыр дип уйламыйм. Әнә шундый сабыр, бик тә сабыр иде инде ул минем Нәзифәм. Соңыннан, аңыма килгәндәй, бу сүзләрем өчен мин үземне эчтән генә бик каты орыштым. Ләкин эш моның белән генә бетмәде шул. Бер гаепсезгә туганнары, дуслары алдында ничә мәртәбә әрләп ташладым. Өйдә икәү булганда да аны — матурымны кимсетә торган сүзләр әйттем. Әйтәм, әйтәм дә үкенәм, күңелем, җаным газаплана. Аннары үземне кая куярга белми йөрим. Әз генә вакыт үткәч тә, шул ук начар гадәтем яңадан кабатлана, үз-үземне һич тә тота алмыйм.

Турысын әйткәндә, абый җаным, мин аңа лаек була алмадым. Нәзифә бик тә тыйнак, бик акыллы хатын. Аңа үзенә тиң кеше лаек булгандыр. Берничә айлык улым белән икесен калдырдым да чыктым да киттем.

— Китмә инде, Хикмәтулла, безне ятим итмә, — дип өзгәләнеп җылап калды.

— Нәни улыңны, гаиләңне ташлап китәргә бер сәбәп тә күрмим, энекәш. Өйдә табак-савыт шалтыраган саен чыгып йөгерү эш түгел.

Хикмәтулла минем сөйләп бетергәнне дә көтмәде, каршы җавап бирергә ашыкты:

— Ә, юк, абый җаным, син аңлап бетермәгәнсең бит. Бездә табак-савыт шалтыраганы булмады. А-а-ай минем хаты-ы-ным! Иртән эшкә хәерле юл теләп озатып кала, кичен елмаеп каршы ала иде. Соң кайттың, иртә кайттың димәде, акча аз кайтаргансың дип зарланмады. Күбәләгем, фәрештәм, конфетым иде ул минем. Үземнең характерым гына бер тиенгә торырлык булмады. Гел юк-барга кычкырдым, бакырдым. Хаксызга тавышлануымны ахырдан гына аңлый идем. Ләкин ук атылган, йөрәк яраланган була иде инде ул. Соңгы көннәрдә, җаны сызлагандыр, матурым бөтенләй ябыгып бетте. Нәзифә күбәләгемне артык яраткан өчен киттем, аны гомергә җәзалап яшисем килмәде.

Җиргә җәйге кичке салкын төшкәнгәме, тәнем туңып, калтырап куйды. Никтер миңа уңайсыз тоела башлады.

— Ярый, туганкай, безгә кайтырга вакыт, — дидем мин озак утырудан талчыккан аякларымны турайта-турайта. — Ходай саулык, акыл бирсен үзеңә.

Нәрсәдер исенә төшкәндәй, Хикмәтулла кулларын сузып миңа мөрәҗәгать итте:

— Абый җаным, исемегез ничек соң сезнең? Сөйләштек, үзем сезнең кем икәнлегегезне дә белми калдым ич.

Киткән җиремнән артка борылып карадым. Ул ике кулын сузып һаман миннән җавап көтә иде.

— Минем исемем Хөрмәт була, — дидем дә юлымны дәвам иттем. Берничә секундтан соң Хикмәтулла кабат мөрәҗәгать итте.

— Хөрмәт абзый, иртәгә тагын килегез. Сезнең белән сөйләшәсем килә.

Капка төбеннән инде шактый ераклашкан идек. Хатыным белән авыр уйлар кичереп барганда, икебез дә берьюлы бер үк сүзне пышылдадык:

— Бәхетсез.

## Җылы эзләр

Иртән ишекне ачып чыгуга, баскыч төбендә сузылып яткан Тигр һәм Рексны күреп алдым. Тәнем буйлап шатлык йөгерде. Башымнан: «Ул килгән» дигән уй йөгереп үтте:

— Ваня абый, Ваня абый! — дип кычкырып җибәрдем мин.

Ə этләр сикерешеп торып, төрле якка карана башладылар. Миңа җавап бирүче булмады. Үземне тынычландырып, берәр күршегә кереп торгандыр, менә хәзер килеп тә чыгар, дигән уй белән җылындым.

* * *

Болай булды. Без башка чыктык. Авылның бер читеннән колхоз җир бирде, йорт салырга булышты. Колхозыбызның яшь, əммa өметле балта остасы, диделәр минем турында идарәдә.

Мактаганны кем яратмый. Бу сүзләр минем йөрәгемә дә сары май булып ятты. Өйне генә салып бетерим, киләчәктә дә идарә кушканны төгәл үтәрмен, дидем.

Ə күрше Займуш авылыннан Ваня абый (сакал-мыексыз булгангадыр инде, пенсиядә булса да абый дип йөрим) мин дигәндә утка керергә әзер. Алдан әйтеп куйыйм: урта мәктәпне тәмамлауга, колхозның балта осталары бригадасына мине алган кеше Ваня абый булды. Безнең бригада әйбәт кенә сыер абзары салып куйды.

Менә бу юлы да безгә иң алдан ул килеп җиткән.

— Хәерле сәгатькә,— диде ул балта, пычкы һәм башка коралларын аунап яткан бүрәнәләр янына иплəп кенә куйгач. Үзе минем белән күрешеп, җилкәмнән кагып алды. Бу минутта аның битендәге бөтен күзәнәкләре елмая кебек иде. Аннары болай дип өстәде: «Борчылма, аякка басканчы яшьләргә булышырбыз».

Хөрмәтле бригадирымның бу сүзләре миңа кояшлы җылы яңгыр кебек тоелды. Тормышка, яшәүгә ышанычым ныгыды, көчем артып киткәндәй булды.

Яз иде. Ул елны май бик матур килде. Бакчада көздән утырткан алма, чия агачлары, карлыган, кура җиләге шаулап яфрак ярган. Кая карама — яшеллек. Алдагы Идел суы исе һәм нарат урманы һавасы бергә кушылган бу урында сулыш алу иркен һәм рәхәт иде. Һаваны суламыйсың, гүя эчәсең кебек тоела.

Беренче көнне кичкә кадәр нигез салдык. Башта измә ясадык. Кирпечне җеп сугып кына тездек. Матур нигез килеп чыкты. Ваня абый ниндидер көй көйли-көйли онытылып эшләде. Үзе гел бер сүзне кабатлады:

— Нигезе нык булсын, туган, нигезе...

Икенче көнне беренче бүрәнәләрне бурап куйдык. Эш күзгә күренеп үрчи башлады. Тирә-як эреле-ваклы йомычкалар белән тулды. Йомычкага кырын ятып ял итәсе килеп китте. Ваня абыйга әйтсәм дә, игътибар бирмәде, һаман эшләвен белде. Агачны ул шулкадәр бирелеп, онытылып юна, чәчләренә ябышкан, асылынган йомычкаларны да сизми, əллә сизсә дә, дикъкать итми. Аны бераз хәл алдырасы килде.

— Ваня абый, сине ничек онытырсың. Өйнең һәр бүрәнәсе сине искә төшереп торыр инде,— дидем.

Ул балтасын бүрәнәгә чабып куйды да, маңгаен җиңе белән сөртеп алды, аннары кесәсеннән тәмәке алып, ут кабызды. Аның бармаклары кат-кат киселеп, җөйләнеп беткән иде. Ə үзе сүзне икенчегә борды:

— Туганкай, ялыбыз үтеп киткәнче өйне аякка бастырырга тиешбез. Артыгын колхоз рөхсәт итмәс. Безнең кул бик кирәк аңа.

Бу — мине шелтәләү, кисәтү идеме, әллә болай гынамы, төгәл аңлап бетерә алмадым. Ə үзем никтер уңайсызланып киттем. Күпмедер вакыт сүзсез тордык. Тигр белән Рекс кына койрыкларын болгый-болгый безнең тирәдә ялагайланып йөрделәр. Аларга карап, бераз онытылып та киткәндәй булдым. Үзләре кечкенә генә көчекләр, ә исемнәре — Тигр белән Рекс бит! Мин аларга тора-бара бөтенләй ияләшеп беттем. Хәтта яраттым диярлек. Матурлар, акыллылар үзләре. Ваня абый килгәндә, көн саен беренче булып алар күренә. Кыска аяклары белән тырпылдап чабалар. Ерактан караганда, бер урында сыртларын биетеп кенә торалар кебек күренә. Ə бераздан Ваня абый үзе килеп чыга.

Беркөнне, гадәттәгечә, төш вакытына мин иртән хатыным пешереп киткән ашны җылыттым, тәмле чәй кайнаттым. Ваня абыйны чакырдым да, битне-кулны юып, үзем ясап куйган өстәл янына утырдык. Тигр белән Рекс та койрык болгап, килеп җитте. Бу юлы бераз ачуым чыкты минем бу маэмайларга.

— Җиләк яфракларымны таптыйсыз, юньсезләр,— дип кычкырдым.

Алар әйткәнне аңлагандай, кырын-кырын карап, Ваня абый янына килеп сыендылар. Ваня абый елмаеп куйды. Аннары болай диде:

— Минем хакка син аларны кичер инде, туганкай. Миннән башка тора алмый шул алар. Кая китсәм дә, эзләп табалар.

Бу сүзләрдән үземә бер уй кордым: кеше сине кирәксенсен, сагынсын икән. Яхшы кеше белән булу кайчан да рәхәт шул.

Чыннан да, кечерәк кенә, җыйнаграк кына өйне без кыска вакыт эчендә торырлык хәлгә җиткердек шикелле. Иң әһәмиятлесе — бураны күтәрү, түбәсен ябу, идән-түшәмен җәю, тәрәзәләрен кую ич аның. Калган вак-төяген үзем дә төгәллим мин аның.

Көзен без яңа йортка күчендек.

* * *

Беркөн, иртән ишекне ачып чыгуга, баскыч төбендә сузылып яткан Тигр белән Рексны күреп алдым. Бөтен тәнемә шатлык йөгерде. Башымнан: «Ул монда, ул килгән»,— дигән уй йөгереп үтте.

— Ваня абый, Ваня абый! — дип кычкырдым мин.

Ә этләр сикерешеп тордылар да, кемнедер эзләгәндәй, төрле якка карый башладылар. Ләкин җавап бирүче булмады. Үземне тынычландырып, күңелемә: кемгәдер берәрсенә кереп кенә киткәндер, менә хәзер килеп тә чыгар, дигән уйны беркеттем. Өйгә кереп, хатыныма чәй әзерләргә куштым. Чәй дә ничә кат кайнап, ничә кат суынды. Әмма кадерле кешебез күренмәде. Хатыным сүз кушты:

— Әтиебез урынына күрә торган абыебыз. Бер чакрым җир ерак ара түгел, Фәрит. Әллә Зәймушка барып, үзен хатыны белән алып киләсеңме?

— Ярый,— дидем мин.— Тиз генә өстемә киенә башлап.

Соңга калган булып чыктым. Йорт мәшәкате белән җәй буе янына бара алмадым. «Ул юк инде»...— диделәр. Ә Тигр белән Рекс авылның әле бер, әле икенче урамы буйлап теркелделәр, ахрысы, хуҗаларын эзлиләр. Күрсәм, йөрәккәем өзелә. Күңелемдә — Ваня абыйның бездә өй салганда әйткән сүзләре:

— Миннән башка тора алмый шул алар. Кая китсәм дә, эзләп табалар.

Җылы эзләр озак саклана икән. Уйлар тулы башны иеп, Ваня абый белән бергәләп салган җылы өемә таба атладым...



## Сафуан Мулла Гали

### Өметемне өзмәдем

Юлларымда адашсам мин,
Тар юлларга юлыксам,
Ык буйларын, Аккүлләрне,
Чишмәләрне онытсам,
Чаганлыма кайталмасам
Әрәмә арасыннан —
Башын чайкап борылыр да
Ык үргә агар сыман...

Үрләргә агар ул, мине
Эзләп, ерак-еракка.
Их, дусларым, сагышымны
Баса алмыйм җырлап та...

Күрешербезме, әйтәлмим,
Өметемне өзмәдем...
Кайтсам ятып үбәр идем
Атам-анам эзләрен.

### Колагыма әйтте гөлчәчәк

Күп милләттән торган бу зур халык,
Катлам-катлам булып яшәгән.
Иң астагы катлам, изелсә дә,
Гөл тамыры булып яшәргән...

Иң астагы катлам өскә чыкты,
Җирне иңләп алды — гөл чәчәк!..

«Бар милләтләр тигез булып яшәр,
Миһербанлы булыр киләчәк!»,—дип,
Колагыма әйтте Гөлчәчәк...

## Юксынып йөрәк әрни

Тегәрҗепкә тезде әни
Туксан тугыз төймәсен.
Асылташ кебек төймәләр —
Тик күз генә тимәсен...

Зөбәрҗәт кебек төймәләр
Балкыйлар ялт-йолт килеп.
Әйтерсең, күз ачып-йомып,
Сабыйлар уйный көлеп...

...Ничә еллар тәсбих әйтеп,
Дисбесен тарткан әни.
Үзе юк шул инде хәзер —
Юксынып йөрәк әрни...

Төшләремә керә әни,
Таныш дисбесен тартып.
Догалары хәтеремне
Торалар гел яңартып...

Кулымда әни дисбесе,
Күңелемдә — бер аллам.
Тәсбих әйтеп, иман укып,
Рухыма саулык алам...

## Кыланмадым артыгын

Моң ага, янып эчемнән,
Әрнеп моңлы җыр ага...
Гомер буе йөзеп киләм
Хәсрәт дигән елгада.

Сикермәдем чоңгылларга,
Ни файда югалуда?
Ир булып каласым килде,
Юл ярып югарыга.

Кермәдем сазлык-баткакка,
Булса да ут чакларым,
Акча-байлыкка кызыгып,
Намусымны сатмадым...
Булса да ут чакларым.

Фиркагә дә димләделәр —
Кирәклеген күрмәдем.
Тик хәрәм кызлар янында
Мин дә бераз керләндем...

Аз-маз керләнсәм дә, синең
Белдем мин киләсеңне,
Кояш сыман нур-йөзеңнән
Үбәсем килә сине!

Утыр әле яннарыма,
Бәхет биргән картлыгым,
Йә килмәс дип куркып ласа
Кыланмадым артыгын...

И картлыгым, яшьлегемдә
Кыланмадым артыгын...

## Упкын читендә

Күреп шаян күзләреңне,
Нурландылар күкләрем.
«Мәхәббәтем син икән»,— дип,
Кулларыма күтәрдем...

Күтәрдем башым өстенә,
«Ярым»,— диеп куандым.
Артык ышанган булганмын —
Яр читендә уяндым...

«Йоклатып», ярга илткәнсең,
Упкын яры читенә.
Ах, бу дөньяда кешене
Белүләре читен лә!..

Башым упкын читендә...

## Күрешмәбез микәнни...

Ияре дә чак иде,
Әти миңа ат бирде.
«Кайда күрсәң мулла кызын,
Эләктер дә чап»,— диде»...—

Шулай диеп җырлый идек
Терсәк буе чактан ук.
Коралыбыз да бар иде:
Җәя белән аткан ук...

Атларыбыз ат кынамы,
Тулпарларның солтаны —
Яшел тал таягы иде —
Тиңдәш кызлар сокланды...

Икенче өебез итеп,
Уйлый идек кылларне...
Җырлый-җырлый ача идек
Боеккан күңелләрне.

«Үчтик, үчтик» үсеп җиттек,
Очып киттек як-якка...
Мин каңгырып йөргән юллар
Ком чүлләрендә ята...

Көннәребез үтеп китте,
Үтмәсәни, үтсәни...
Җырлап үскән тиңдәшләрем,
Күрешмәбез микәнни?!



# Нур Ислам

## Ике йолдыз

Чикләвекләр ник коела?..
Калдырмыйк әле җирдә.
Без бит чыныккан кешеләр
Карлы, яңгырлы җилдә.

Вәгъдә бирдек — сөю дидек,
Дошман кермәс арага.
Нигә читләргә карадың,
Ник кагылдың ярага?!

Тузгытты безне җил-давыл,
Очрашулар — икеле...
Син — гаребтә, мин — шәрекътә:
Ике йолдыз шикелле.

## Язгы ашкыну

Көне буе кырпак карлар ява,
Барыр юлларымны күмә көрт.
Сөюеңә ышан, диләр миңа,
Син сагынып, диләр, аны көт!

Елмаер да көннәр, шашып язлар
Килер, бәгырем, безнең каршыга.
Мәхәббәт бит язгы ташуларда
Туып, күңелләргә ашыга.

Көне буе энҗе карлар ява
Сиңа очкан уйларым сыман...
Кышны җиңеп, якты язлар кебек
Сиңа барып җитәрмен сыман.

---

Нур ИСЛАМ (1944) — *һөнәре буенча табиб, көндәлек матбугатта шигырьләре басыла килә. Казанда яши.*

## Танышу

Язгы яңгыр яуганда,
Ләйсән тамчы тамганда,
Аланда гөл атканда,
Каеннан су акканда,
Синең белән таныштым,
Синең белән кавыштым.

Ярым, дидем, яр гынам,
Балым, дидем, бал гынам!
Киләчәкнең таңнарында
Балкыр гөлем — ал гынам!
Тауларда карлар ята...
Елмайсаң, таңнар ата...

Безгә килдең яз гына,
Көлче, диден, аз гына.
Син — гөлчәчәк, мин — күмер,
Шулай үтәрме гомер?
Син — гөлчәчәк, мин — күмер,
Алга таба күз күрер!..

## Чаганнарым

Чаганнарым, хушлашмагыз,
Мәңгелеккә китмим мин.
Китүләрем вакытлыча...
Сезне ятим итмим мин.

Туган җир киңлекләрендә
Юл гизәм, бәхет эзлим.
Чаганнарым, күңел белән
Мин һаман сезне күзлим.

Сезнең җырлар минем җырга
Кушылар, чаганнарым.
Калсын моңы истәлеккә
Без узган заманнарның.

## Зирек алкалары

Зирек алкалары коела нигә?
Беркем белми, ахры, серләрен.
Бар сагышым шул алкалар белән
Эзләп йөри шатлык илләрен.

Зирек алкалары коела нигә?
Кем белә бит нидә бар хикмәт.
Кемнең кайда эчәр суыдыр бит,
Кайда безнең ашасы икмәк?

Зирек алкалары акты-китте,
Карап торам аккан суларга:
Алка-алка көннәр өзелә тора,
Бар сагышым бәйле шуларга.

## Әткәйне сагыну

Кызыл кар ява... тирә-як
Буран эчендә калган.
Кайтмады әткәй, кайтмады,
Бары кызыл кар яуган!

Җанны сыгып, яшем тама:
Әй, ачы да соң сагыш!
Илебезне җәһәннәмгә
Тартып алды бу сугыш.

Тик хәзер кемнән сорыйм соң,
Әткәй кайтырмы диеп?
Чирәмнәр генә тәбәнәк,
Еллар дивары — биек...

Әйткән иде күрше карты
Күңелләр ятим калгач:
«Әткәң кайтыр, энем,— диеп,—
Бары кызыл кар яугач...»

Карлар ява, бар дөньясы
Буран эчендә калган.
Әткәйләр исәндер сыман,
«Кара кәгазьләр» — ялган!

## Акбулат

Җир йөзендә син бер генә, Акбулат,
Күңелләрдән кайнап чыккан Ак болак.
Ак юлларың синең безгә Ак келәм,
Шул келәм буйлап һаман да Ак киләм!

Акмын, акмын дөнья халкы алдында!
Син биргән белем вә гыйлем ядымда.
Син агарткан, син пакъләгән күңелем,
Әй, Акбулат, мәгърифәттә пакъ гөлем!

Ничә чакырым юл үттем мин, Акбулат,
Сагынып, синең сукмакларыңны уйлап.
Белем алам дип куанып килдем мин,
Кызлар суга барган сыман йөрдем мин.
Миңа, бирдең син тормыш фәнен, Акбулат!
Шуңа да барыр юлларым яктырак.

Җир шарында бер генә син, Акбулат!
Күгендә мин бит йөзәм — ак болыт...



**Кәбир Нигъмәтҗанов,**

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, мәгариф отличнигы.

# МИН — УКЫТУЧЫ

Кеше тормышта хыялсыз яши алмый. Ул матур шәһәрләр, илләр күрү турында, сәяхәт итү, очрашулар-кавышулар хакында хыялланып яши. Үзен-үзе белә башлагач та һәркем тормыш дәрьясында барыр юлын табу, нинди дә булса һөнәр иясе булу турында фикер йөртә, уйлана башлый.

Хыял диңгезенә чумып яши белә торган балалар төрле уйлап чыгаруларга, оештыру сәләтенә ия булалар. Мин дә әнә шундыйларның берсенә керә торган хыялый зат идем. Иптәшләрем белән уйнаганда мине балалар котүчесе итәләр иде. Туры булуны бар күңелем-фигылем белән яратмасам да, балалар төркеменең уртасында һәрвакыт мин кайнаша идем.

Хәтердән бер дә чыкмый: җәйге эссе көннәрдә шау-гөр килеп уйныйбыз да, гүзәл Чулман буйларына, аның салкын суында коенырга төшеп китәбез. Элек Чулман көчле агымлы елга иде. Агым яхшы булган урында су коену үзе бер рәхәт! Бөтенең бергә тезелешеп, көлешә-көлешә эчкә йөзеп керәсең дә, агым уңае белән ермакларга агып китәсең, ак пароход үтеп китсә, аның артыннан ургылып килгән усал дулкыннар өстендә тирбәләсең, әлсерәп яр кырыена чыгасың да гөрәбәдәй комга сузылып ятасың.

Озак итеп су коенгач, бала-чаганың өзелеп карыны ача. Бүре чәйнәп йотардай булып ачыккан һәрберебез, Чулман белән саубуллашабыз да, әти-әниләре өйдә булмаган берәр иптәшебезнең өендә җыелабыз. Үзебезнең өйләребезгә таралышу турында уйлап та карамыйбыз. Менә шул вакытта безнең хыял көче эшкә җигелә: әйдәгез, яңгыр боткасы оештырабыз! Ә авыл халкы яңгыр боткасы оештырган вакытта бернәрсәләрен дә кызганып тормый. Кычкырышып-көлешеп, этешә-төртешә өйдән-өйгә йөрибез дә кирәк нәрсәләр җыябыз. Ризыкны мулрак тамызган кешеләргә күмәкләшеп:

— Бәрәңгегез чәйнек-чәйнек булсын! — дип, теләкләр телибез, ә бирмәгәннәре булса, «Бәрәңгегез борчак-борчак булсын!» — дип, аларны да өлешсез калдырмыйбыз. Ләкин кем генә үз бәрәңгесенең борчак-борчак булуын теләсен икән? Берәүләр, рәхәтләнеп берәүләр авылдашлар ачыккан бала-чагаларына ризыкны. Күмәкләшеп «хәер эстәп» кайткач, тотынабыз ботка пешерергә, чәй кайнатырга. Кызлар бәрәңге әрчи, суган турый, малайлар төрлечә булышкалап йөри, ә мин — ашханә мөдире — җитәкчелек белән мәшгуль.

Оештыру сәләтенә ия булу югары классларда укыганда бик нык ярдәм итә: классташларың гына түгел, башка сыйныф укучылары да сиңа тартыла, сине

берәүдән дә кыерсыттырмаска тырыша, тәртипсез укучыларның да сиңа тешләре үтми. Урта мәктәпне мин күрше авылда тәмамладым, ләкин мине кыерсыткан, миңа теш кайрап йөргән бер генә кешене дә хәтерләмим.

Унынчы сыйныфта укыганда мине үзешчән сәнгать түгәрәге җитәкчесе итеп куйдылар. Түгәрәк белән укытучы кеше җитәкчелек итәргә тиешле, ләкин мәктәп директорыбыз Алишев Сәлам Хатыйпович бу вазифаны миңа курыкмыйча йөкләде һәм мин үз эшемне җиренә җиткереп башкарырга тырыша идем. Лаеш районы үзәген ул вакытларда татарча чыгышлар белән артык шаккатырып булмый иде, чөнки поселокта татарлар аз яши, район җитәкчеләре урыслар иде. Һәм менә без, Татар Сараланы урта мәктәбе укучылары, районда концерт бирәбез. Сәхнәгә энҗеле калфаклардан, милли киемнәре белән ялтырап торган яшь кызлар-егетләр чыгып баскач, Лаеш халкының йөрәге «аһ» итеп куйды, һәр номерны алкышлар белән сәламләде. Коллективка җиңүче исеме бирелде, шул ук елны мин үзем дә, җырчы буларак, республика күләмендә лауреат исеме яуладым.

Үзебезнең авылда, Чулман белән Идел кушылган төбәктәге әкияти Атабай авылында, мине «артист» дип йөртә башладылар. Берара мин үзем дә, артист булырга микән әллә, дип йөри башладым. Укытучы һөнәре күңелгә бик якын, ләкин туган авылым Атабайда укытучыга кадер-хөрмәт мактанырлык түгел иде. Без кечкенә вакытларда укытучы һөнәренең илкүләм дәрәҗәсе какшаган иде инде.

Укытучы — хөкүмәт кулындагы курчак, партиянең бөтен кампанияләрен тырышып үтәүче, ул «айт» итсә, «тайт» итә торган күндәм бер җан иясенә әйләнгән эш аты. Заем вакытларында, куркыта-куркыта, көче җитмәгән суммаларда ясак түләү өчен халыкны кул куйдырып йөрүчеләр — укытучылар иде. Сугыштан соңгы авыр елларда урактан кайтучы колхозчыларның җан җирләренә кадәр кереп тентүдән дә тартынмаган кешеләр дә укытучылар булды, ике кишер «урлап», зур җинаять эшләгән дип, төрмәгә утыртуда гаепләп, авылдашларын хөкемгә тарттыручылар арасында алар да бар иде.

Укытучылар дингә каршы көрәштә дә зур активлык күрсәткәннәр. Дин әһелләрен хурлап спектакль куюларда, гарәп имласындагы китапларны юк итүдә, мәчетләрне яптыруда алар башлап йөргәннәр. Балаларга ят исемнәр кушу да укытучылардан килеп керде, авылда Эрнест, Альберт, Дарико, Сулико, Клара, Аида, Эльвира, Карл, Регина, Арсен кебек исемнәр үрчеп китте.

Ләкин, нинди генә кимчелеккә ия булмасын, укытучы — авылда бердәнбер һөнәр иясе. Укытучы профессиясе авыл баласының канына кечкенәдән үк сеңә иде. Баштарак артист булырга микән дип иләсләнеп йөрсәм дә, күңелем «укытучы бул» дип пышылдый иде, һәм мин укытучы һөнәрен сайларга булдым. Казан дәүләт университетының тарих-филология факультеты хыял чишмәләрен үз агымына борып җибәрергә ярдәм итте. Менә мин студент. Мәһабәт ак колонналары белән үзенә әллә кайдан чакырып торган чал университетта фән нигезләрен кимерү теләсә кемгә тәтеми, ләкин безнең анда эшебез юк: яңа дуслар белән бергәләп лекцияләр тыңлыйбыз, имтиханнарга әзерләнәбез, фәнни түгәрәкләргә йөрибез, опера театрында опералар, концертлар, Камал исемендәге академия театрында спектакльләр карыйбыз.

Биш ел дәверендә булып узган истәлекләрнең исәбе-хисабы юк, чыгарылыш курста укыган еллар — үзе бер дөнья. Әдәбият кафедрасы җитәкчесе Хатип Госман үзебезне җыеп, диплом язар өчен темалар өләшеп чыкты. Ләкин миңа һәм тагын берничә студентка диплом темалары тәтемәде. Мәрхүм галимнең кешеләрне ак һәм кара буяуларда гына күрә торган психологиясе бу очракта үзен сиздерми калмады. Байтак студентлар, диплом эше язабыз дигән булып, фәнни хезмәткә «чумдылар», ә без исә дәүләт имтиханнарына әзерләнәбез...

Дәүләт имтиханнарын «4» һәм «5» билгеләренә генә тапшырып, музыка училищесының җыр бүлегендә укуымны өздем дә, дипломны кесәгә салып, Актаныш районына авыл укытучысы булырга юл тоттым.

Җырга-моңга бай, гүзәл кешеләргә мул булган Актаныш мине кочагын җәеп каршы алды. «Монда җырлый һәрбер агач, монда бар да сандугач» дигәндәй, Актаныш мине җырчы итеп үстерде, Актаныш миннән укытучы ясады. Егерме ел буена мин Актаныш халкына мәгърифәт нурлары чәчтем, җырым-моңым белән тәрбияләдем. «Син Актанышныкы бит, әйеме?» — диючеләргә хәзер дә: «Әйе, мин Актаныштан»,— дип горурланып җавап бирәм. Физик яктан Лаеш районының Атабай авылында тусам да, рухи яктан чынлап та Актанышта тудым мин. Актаныш районында гел урыс теле укыттым. Татар балаларын урыс теленә, матур итеп җырларга, биергә өйрәттем. Казан дәүләт педагогия институтының

урыс теле һәм әдәбияты факультетын тәмамлап, икенче диплом алырга да житештем. Мәктәптә ике дипломга ия булган укытучы эшләве нур өстенә нур гына. Тик минә укытучының эш шартлары, яшәү дәрәҗәсе, вакыты мәсьәләләре белән бер дә исәпләшәселәре килми. Атна саен йә профсоюз җыелышы, йә ачык партия конференциясе, «теоретик» семинарлар, методсовет, педсовет, тагын әллә нинәр булып кына тора, өчәр сәгатьләп кирәкле вакыт бушка-заяга уза. Мәктәп директорыбыз андый җыелышларны ярата, үткәрергә сәбәп кенә эзләп йөри. «Блаканатларыгызны алыгыз, тиратик семинарны башлыйбыз» дигән сүзләре колак төбендә хәзер дә яңгырап тора. Блокнотлар алып, теоретик семинар дип аталган бу җыелышта сөйләнгән «докладларны» язып, конспектлап барырга куша директор әфәндебез.

Ә менә бу бик кызык тоела, андый сөйләмне беренче тапкырлар ишеткәнгә, түзә алмыйча көләргә мәҗбүр булам. «Син, энекәем, безнең мәктәпне таркатырга килдеңмени?» — ди хуҗа. Үзем дә җавапка аптырамыйм. «Юк, таркатырга түгел, киресенчә, таркала башлаган мәктәпне төзәтергә килдем»,— дип, көлә-көлә ярып салам. Директорыбыз Алабуга педагогия институтын читтән торып тәмамлаган. Аның укып йөргән чакларындагы кызыкларны хәзер дә мәзәк итеп сөйлиләр.

Имеш, ул диктант язган. Укытучы диктантны тикшереп, эштән 55 хата тапкан һәм кызыл кара белән «55 ошибок» дип язып куйган. Ә безнең абзый: «Кара, минем эшкә ике бишле куйганнар!» — дип гаҗәпләнә икән. Абзыйның рәхәтләнеп кенә белем аласы еллары авыр сугыш елларына туры килгән, илбасарлар белән сугышкан, вакытында белем ала алмаган, ләкин акылы камил, башы эшли һәм югалмаган, кеше булган, оста житәкче, тәрбияче вазифаларын яхшы башкаруы аркасында озак еллар мәктәп директоры йөген тарткан.

Коллектив дус, шаян, тату иде. Ләкин эш җиңел түгел. Совет педагогикасы һәрвакыт уртакул укучылар белән эшләүне күздә тотты. Дәрестә яхшы укучылар белән эшләргә вакыт юк диярлек, материалны начар, авыр үзләштерүчеләр белән тирләп-пешеп, дәрес тәмамланганны сизми дә каласың. Дәрес тыңларга кергән завуч-директорлар, инспекторлар, материалны авыр үзләштерүче тәртипсез укучылар белән эшләмәсәң, тәнкыйть итәргә генә торалар. Укытучы, үзенең сәламәтлеген какшата-какшата, берни дә белергә теләмәгән баланың башына белем орлыклары салырга азаплана. Ул укучыга синең сыйфат дәрәҗәләрең, «причастный оборот»ларыңның һич кирәге юк, ләкин укытучы аңлата, өйрәтә, укучыны ничек тә «3»легә өлгертергә тырыша.

Әллә үзләре белән күп азапланганга, мәктәпне «3»ле билгесенә тәмамлап, әлле-мәлле генә укып чыккан укучылар укытучыга гомергә хөрмәтле булалар. Алар әллә кайдан исәнләшәләр, булдыра алганча ярдәм итәргә тырышалар, кунакларга чакыралар, туган көннәр, бәйрәмнәр белән тәбрик итәргә дә онытмыйлар. Ә «5»легә генә укучы отличникларның күбесе йә күрмәмешкә салышып узып китәләр, йә теләр-теләмәс кенә елмаеп үтәләр.

Минем хәзер завод директоры булып эшли торган элекке укучым бар. Класс кирәк-ярагына укучылар 5—10 тиен акча җыйган вакытларда шул тиеннәрне дә күбесенчә бирми иде, күмәкләшеп үткәргән кичәләрдә катнашмаска тырыша, иптәшләре белән аралашканда үзен эре тота иде. Тик менә сату-алу эшләренә кечкенәдән махир булды. Помидор көлшәсе утыртсалар, ничә орлыктан ничәсе тишелеп чыгачак, ничәсе һәлак булачак, ничәсе күпме уңыш бирәчәк, ничә сум табыш керәчәк — һәммәсе дә исәптә малайның.

Югары классларда коеп куйган карьерист иде инде. Портфель, урындык өчен туган әнкәсен дә сатарга риза егет. Чын йөзен битлек астына бик оста яшерә белә. Озак еллар комсомол яшьләр белән житәкчелек итте, югары катлам белән генә аралашырга тырыша, классташларын, авылдашларын санга сукмый, бик дорфа сөйләшә. Бергә укыган иптәшләре минем белән очрашкан саен аңардан зарланалар...

Укытучының эше — тавык та чүпләп бетермәслек вак эш. Эшенең артык вакլыгына укытучы үзе дә гаепле. Иптәшенең дәресен тыңларга керсә, һәр укытучы: «Фәлән-фәлән бу дәресендә минә ничә төрле метод кулланды, минә никадәр карточка-өләшү материалы таратты, ничә төрле күрсәтмә материал ясаган»,— дип, дәрескә анализ ясарга тотына. Шул ясалган анализлар укытучыны өләшү карточкалары төзергә, төрле картиналарның репродукцияләрен җыярга, төрле иллюстрацияләр тупларга, беркемгә дә кирәкмәгән папкалар әзерләргә этәрә.

Актаныш районында андый кәгазь боткасына исләре китми иде, ә менә Чаллыда укытучының хезмәтен шул күрсәтмә-күргәзмәлекләр белән бәяләргә тырышулары белән очрашырга туры килгәләде. Ул күрсәтмәлекләр укытучының

иҗат лабораториясе дип атала. Андый иҗат лабораторияләрендәге әйберләрнең 90%ы үле капитал булып тузан җыеп ята бирә, ә тикшерүчеләр өчен алар — укытучының иң кыйммәтле хәзинәсе. КамАЗ машинасы әрҗәсенә дә сыеп бетмәгән бай «лаборатория»ле укытучыларыбызның кайбере әллә нинди мактаулы исемнәр алып бетерделәр, тик укучылары укытучыларын яратмыйлар, дәресләре дә мактарлык түгел. Укытучының төп иҗат лабораториясе — башында, телендә, белеме һәм методик осталыгында, хезмәтенең нәтиҗәсе — дәрес бирү осталыгында, материалны аңлата белүендә, балаларының белеме һәм тәрбиялелекләрендә. Дәресендә йөз төрле әйбер күрсәтеп тә, дәресең чыш-пыш булса һәм укучыларның белемнәре түбән булса, андый укытучының хезмәте югары бәяләнмәскә тиеш.

Укытучының ярты эше өенә кайта, аның гомере план төзеп үтә. Ул һәрвакыт нинди дә булса педагогия фәннәре докторының «уйлап чыгарулары» һәм фәнни хезмәтенә яраклашырга тиеш. Шуңа күрә укытучы Липецкий методын да үзләштерә, укытуны индивидуальләштерү алымнары, танып белү, актуальләштерү проблемалары өстендә дә эшли, тегендә чәчелә, монда чәчелә. Дәрес планнарын төзегәндә дә өч төрле максатны конкрет билгеләп куярга тиеш: өйрәтү, эш күнекмәләрен үстерү, укучыларны тәрбияләү максатлары — һәммәсе күренеп торсын. Укытучы уйлана, баш вата. Җитмәсә — ачык дәресләр үткәрттереп теңкәгә тияләр.

Ачык дәресләр үткәрү — бигрәк тә өлкән яшьтәгеләргә, нервлары какшаган, таушалганнарга олы йөк. Ә үткәрми чараң юк, сәламәтлегең җан тәслим кыларлык дәрәҗәдә түгел икән — үткәрергә мәҗбүрсең. Мине хәтта 29 нчы майда, уку елы бетәсе көнне, ачык дәрес үткәрергә мәҗбүр иткәннәре бар. Барлык тема инде күптән үтелеп беткән, укучыларның күңелләре әллә кайларда, ә укытучы җан тирләрен агыза-агыза районнан килгән «кунаклар» алдында ачык дәрес биреп азаплана, тыңлаучылар исә• дәресеннең кай җире турында нәрсә әйтим икән дигәндәй, кәгазь сырлап утыралар.

Хәзер ачык дәресләрне күбрәк балаларның уены рәвешендә уздырырга тырышалар. Рәхәтләнеп уйныйлар, тыңлаучыларны шаккатыралар, ләкин күпчелек очракта балаларның белем күнекмәләре генә бик чамалы була.

Чаллы шәһәренә килүемнең беренче елларында мин урыс теле һәм әдәбияты укытуымны дәвам иттем, ләкин марҗа түтәйләребезнең күбесенең бу предметны башка милләт вәкилләре укытулары белән канәгать түгеллекләре һәрдаим сизелеп тора. Ничек инде татар Әсәдуллин, грузин Амонашвили бөек урыс милләтенең бөек телен бөтен нечкәлекләре белән белә алсыннар ди?! Шуның белән килешәселәре килми аларның. Һәм Татарстан мәктәпләрендә татар телен укыту бөтен проблемалары белән килеп баскач, мин татар теле укыта башладым, урыслаша башлаган татар балаларына туган телебезне өйрәтергә алындым.

Алда — Каф тавы хәтле авырлыклар, чишәсе проблемаларның исәбе-хисабы юк. Иң авыры — татар теле дәресләрен уку расписаниесенә кертү. Татар балалары үз туган телләре дәресләренә урыс балалары татлы йокыларыннан торган вакытка, «нулевой» сәгатьләргә килеп утыра иделәр, йә җиденче-сигезенче сәгатьләргә калып өйрәнергә тиеш иделәр. Ә укытучыга җиде таң тишегеннән мәктәпкә килергә кирәк. Дәрес барган вакытларда өйләренә кайтырга җыенган тәртипсезләре татар теле «кабинеты»ның ишеген ачып кычкырып китәләр, бер кирәксезгә шакып узалар. Тешне кысып булса да түзәргә туры килә. Мәктәпләрдә татар мохите тудыру турында уйлау мөмкин түгел, татар сөйләме 12 квадрат метрлы татар теле бүлмәсеннән башка бер җирдә дә ишетелми.

Ләкин дөньялар үзгәрә, тормыш яңача атлавын дәвам итә. Хәтта шәһәр мунчасында баласы белән татарча сөйләшкән татар милләттәшләребезгә: «В общественном месте не разговаривайте по-татарски» дигән чаклар артта кала бирде. Мәктәпләрнең ишеген татар теле ныграк, кыюрак һәм ешрак шакый башлады. Һәм, ниһаять, Татарстан хөкүмәте бу фәнне расписаниеләргә рәсми керттерү бәхетенә ирешә.

Мәктәпләрдә татар класслары ачыла, татар мохите барлыкка килә башлады. Мин эшләгән Чаллының 33 нче мәктәбендә дә татар классы ачып җибәрдек. Милләтебезнең йотылуына битараф булмаган ата-аналар балаларының татар классында укуларына карышмыйча риза булдылар. Ләкин башлангыч классларда укытучы ханымнар яхшы укучы татар балаларыннан тиз генә аерылырга теләмәделәр һәм үзләренә котылырга кирәкле тәртипсез, начар укучы, сәламәтлеккә туймаган балаларны гына татар классына күчәргә «үгетләделәр». Баштарак без моның белән дә килештек, татар классын авырлык белән булса да оештырдык. Сәламәтлекләре мактанырлык булмаган, кайберсенең ике күзе ике

якка караучы, өйләрендә рәтләп тәрбия күрмәгән Чаллы кош фабрикасы эшчеләренең татар балаларын мәктәп ашханәсенә тезеп алып барганда, маржа апаларыбыз:

— Вон будущие национальные кадры идут,— дип, көлеп кала иделәр үзләреннән.

Икенче елны татар классларының саны үсә башлады. Бу классларда эшләүче укытучылар балаларганыклы белем-тәрбия бирүгә, аларда милли аң үстерүгә ныклап тотындылар. Мин исә бер төркем милләт баласын, кышның 30° суыкларыннан да курыкмыйча, каникул көннәрендә Ленинградка экскурсиягә алып барып кайттым. Балалар да ким-хур итмиләр үзебезне: укулары, тәртипләре яхшырды, милиция бүлмәсенә исәпкә эләгү белән дә борчымыйлар. Татар классларында тәртип яхшы һәм ата-аналар балаларын татар классларына шатланып бирә башладылар.

Мәктәптә беренчеләрдән булып оештырылган татар классында уздырылган әдәбият дәресен искә аласы килә. «Тукай» романының авторы Әхмәт Фәйзи иҗатына багышланган иде ул. Дәрестә Әхмәт Фәйзинең тормыш юлы өйрәнелде, «Тукай» романыннан өзекләр яңгырады, шигырьләр сөйләнде. Дәреснең йомгаклау өлешендә укытучы дәвам итә:

— Үзе вафат булгач та, Ә. Фәйзи иҗаты халык күңелендә моң чишмәсе булып ага башлады. Халык аның «Умырзая» исемле шигырен җыентыкларыннан табып алды да, көй чыгарып, «Умырзая» җыры итеп җырлый башлады:

Боз катлавы эрегәч, җир өстенә
Умырзая чыга, карагыз...

Класска матур көй, татар көе таралды.

Ә укытучы дәресне йомгаклау сүзләрен дәвам итә:

— Кадерле укучылар! Сез дә безнең умырзаяларыбыз, татар классларының беренче чәчәкләре, беренче карлыгачлары. Ләкин Әхмәт Фәйзинең шигырендә умырзаяларның гомерләре кыска икәнлеге искәртелә, ә сезнең гомерегез озын, киләчәгегез өметле булырга тиеш. Моның өчен милләтебезгә уянырга кирәк.

Шул вакытта тальян гармунында барысы өчен дә таныш аккордлар алына, аңа балалар кушыла:

Уян, татар, уян инде
Уян син дип кояш чыга.
Тор да кузгал изге эшкә,
Бу җыр сиңа булсын дога.

Һәм Чаллы шәһәренең 25 нче бистәсендә урнашкан 33 нче мәктәп уянды. Хәзер ул татар мәктәбе статусы алды. Ләкин урыс милләтле кайбер педагоглар моның белән һич кенә дә килешергә теләмиләр, урыс балаларын «кызгану» йөзеннән югары оешмаларга язуларын дәвам итәләр: имеш, бистәдә икенче мәктәп юк, ә күрше мәктәпләргә йөрер өчен юлны аркылы чыгарга туры килә икән. Чаллыда бердәнбер татар мәктәбе эшләгән вакытта татар балаларына шәһәрнең бер башыннан икенче башына әллә ничәшәр транспортта йөрергә туры килә иде. Әмма кызганучылар күренмәде. Башка шәһәрләрдә һәр мәктәп баласының ишеге төбендә мәктәп басып тормый ләбаса! Ходай саклый, хәвефхәтәрсез генә балалар берничә квартал йөреп, белем алуларын дәвам итәләр. Ә Чаллыда һәр урыс баласының борыны төбендә мәктәп салынган булсын!

Аларның дәлилләре көчсез, дәгъвалары урынсыз. Үзенә кирәктә җир тишегенә керергә булдыра ала торган бала юлны гына аркылы чыга ала бит ләбаса. Авырлыклар белән милләтебезне торгызып йөргәндә, шундый буламы «тугандаш» халыкның фикере?!

Укытучыга оештыручы да, режиссер да, рәссам да, әдәбият белгече дә, җырчы да булырга туры килә. Укытучы барысын да белергә, эрудиция, тылсым көченә ия булырга тиеш. Укытучы профессиясе ул көн кадагы профессиясе, тормыш профессиясе. Ул тормыштан артта калырга тиеш түгел, бүгенге көн белән, яңалыклар белән бергә атлап барырга тиеш. Артта калдыңмы, төссезләнүең, тоныклануың ансә бөтенләй күгәрүең бар.

Тик укытучы хезмәте безнең илдә тиешле бәяне ала алмады. Хәзер укытучы — иң түбән эш хакы алучыларның берсе. Күп илләрдә иң зур эш хакын укытучылар, бигрәк тә башлангыч класс укытучылары ала, ә бездә укытучы — күпчелек очракта бушка эшләүче эш аты. Хәзерге заманда бер генә җирдә дә

бушка эшләтү мәҗбүрияте калмады, ә мәктәп системасында, киресенчә, җәелеп кенә китте.

Укытучы һәрчак матди яклауга мохтаҗ, шуңа күрә ул күп сәгатьләр укытырга яисә ике җирдә хезмәт итәргә мәҗбүр. Ике мәктәптә эшләүче укытучыны мәктәпләрнең берсендә «совместитель» дип йөртәләр. Үзенең төпләп эшләп йөргән мәктәбенә дә йөгерә укытучы, икенчесенә дә. Нәтиҗәдә, бөтен көчен биреп берсендә дә эшли алмас була. Көлкеле мәзәктәге попугай шикелле. Имеш, бер попугай булган ди: уң аягыннан тартсаң, татарча сөйли икән теге попугай, сулыннан тартсаң — урысча сиптерә икән. Бер кызыксынучы кеше:

— Тукта, ике аягын да берьюлы тартып карыйм әле, нишләр икән бу мескен? — дип, ике аягыннан да тарткан теге кошның. Попугай теге кешенең күзләренә карап:

— Бәтәч! Чуть-чуть не упал! — дип әйткән, ди.

Бичара укытучыга да шулай дип әйтергә генә кала.

Укытучының эше — катлаулы хезмәт. Ләкин мин укытучының хезмәтен пәйгамбәрләр эшчәнлеге белән чагыштырырга яратам. Пәйгамбәрләр бит гомерләре буена кешеләргә Аллаһы тәгалә тәгълиматын таратып яшәгәннәр. Алар ходай ихтыярын алдан хәбәр итүче һәм төшендерүче изге затлар. Укытучы да яшь буын тормышында иң көчле, иң кодрәткә ия булган тылсым хуҗасы. Ул баланы кеше итүче көч. Шуны истә тотып, мин балаларны кече яшьтән алып, мәктәпне тәмамлап чыкканчы үзем укытып чыгаруга басым ясадым, ягъни 5 сыйныфтан алып, соңгы чыгарылыш сыйныфына кадәр. Югары классларга житкәч, ул укучылар минем эшемдә таянычым булдылар, белемнәре, тәрбиялелекләре белән башка сыйныф укучыларыннан күпкә яхшы яклары белән аерылып тордылар. Күбесе югары белемгә ия булды, телләренең җорлылыгы, күңелләренең киңлекләре белән тормышта үз юлларын тиз таптылар. Һәркем үз сәләтен үстерә алды, алгы сафларда хезмәт итеп торалар.

Туган телебезнең укучыларны тәрбияләүдәге кодрәте мәңге саекмас һәм күмелмәс чишмә булган кебек, минем педагоглык хезмәтем дә тукталмады, өзелмәде. Үземнең эшсез тинтерәп йөргәнемне хәтерләмим, өзлексез балалар белән кайнашу гадәткә кергән, күнегелгән, тормыш таләбенә әйләнгән. Мәктәп тузанын эчү, балалар алдында дәрес бирү, алар белән гәп кору, аларның аркасыннан сөюдән тәм табам мин. Гомер буе мәктәптә. Дәрес планнары язып, исәпсез-хисапсыз дәфтәр тикшереп, төрле кичәләр уздырып үткән тормыш. Балаларны белемле итәм, киләчәк буынны тәрбияле итәм дип ышанып яшәү. Чөнки бары тик белемле кеше генә, тәрбияле кеше генә дөньяны күркәм итә ала. Мин шуңа ышанып яшим: укытучы хезмәтен яратсаң, укучыларга да, үзеңә дә синең хезмәтең канәгатьләндерү китерә, уй-хыяллар үстерә, яшәргә дәрт уята, иҗат итү теләге кузгата.

Чулман белән Идел кочаклашып аккан җирдә, Атабай авылында шытып чыккан, Актаныш һәм Чаллыда чәчәк аткан тормыш, җыр сәнгате белән укытучы хезмәте бергә үрелеп барган тормышым дәвам итә. Чишмә башым булган гүзәл Атабай Сабан туйларында, ямьле җәй айларында кайтып, туган авылым, дусларым, авылдашларым турында җырлап килсәм, балачагыма кайткан кебек булам, ел буена җитәрлек илһам, күңел тынычлыгы алам мин.

Чулман белән Идел-елга  
Кочаклашып алга ага.  
Иркә гөлләрдәй елмаеп  
Туган авылым каршы ала.  
        Атабаем, кайтам сиңа,  
        Сине күрү — дәва миңа.  
Сагындырды урманнарың,  
Бөдрә таллар, яланнарың.  
Монда минем яшьлек таңым,  
Җан дусларым, туганнарым.  
        Атабаем, кайтам сиңа,  
        Сиңа кайту — җанга шифа.  
Искә төшкәч айлы кичләр,  
Басыладыр шашкын хисләр.  
Еракларга кабат китсәм,  
Күңелкәем инде нишләр?  
        Атабаем, кайтам сиңа,  
        Сиңа кайту — җанга шифа.

*Чаллы.*



Харис Әшрәфҗанов

# ЯЗУЧЫ ҺӘМ ТАРИХ

Иҗат кешесенең күңелен бүгенге тормыш кына түгел, ә үткән чорның зур вакыйгалары да, андагы күренекле шәхесләр дә дулкынландыра. Әнә шулай итеп тарихи темага караган әдәби әсәрләр языла, алар кызыклы һәм гыйбрәтле китаплар булып укучылар кулына килеп керә. Эстетик тәрбия бирү, кешенең дөньяга карашын киңәйтү белән бергә ул әсәрләр безнең халкыбызның милли үзаңын үстерү буенча да мөһим рухи вазифа башкаралар.

Соңгы елларда илдә барган социаль-сәяси үзгәрешләр исә «язучы һәм тарих» мәсьәләсен тагын да үткенәйттеләр, җәмәгатьчелекнең аңа булган игътибарын нык кына арттырдылар.

Әлбәттә, язучы ул — иң башта үз чорының «җимеше», шуның вәкиле. Чорга хас булган күренешләр, вакыйгалар, билгеләр аның иҗатына турыдан-туры тәэсир итә. Язучы каядыр читтә яшиме, яисә үз илендәме — ул берничек тә чор таләпләреннән азат була алмый. Хәер, чит илдә яшәсә, үткәннәрне бәяләү мәсьәләсендә ул бу илдә хакимлек итүче сәяси-идеологик системадан, төрле «советизм» нардан азат була, үткәннәргә һәм бүгенгегә тәнкыйди күзлектән карау мөмкинлегенә ирешә, әмма шул ук вакытта ул тарихи-милли җирлектән аерыла. Аннан соң читтәге язучы үзе яшәгән мохит белән халкы яши торган илдәге тәртипләрне чагыштыра, уртаклыклар һәм аерымлыклар табып, гомумиглобаль үсеш-үзгәреш тенденцияләрен билгеләргә омтыла, шулардан чыгып, тарихи вакыйгаларны бәяли ала. Әлбәттә, безнең мондый әдипләребез аз.

Безнең бөтен язучыларыбыз да диярлек шушы илнең вәкиле. Ә бу илдә хөкем сөргән идеология һәм башка факторлар әдәби процесска, үткәннәрне өйрәнүгә, аны сәнгати чагылдыруга нык йогынты ясый. Мисал өчен, бездә озак еллар дәвамында тарихи вакыйгаларны Октябрь революциясе «казанышлары» ноктасыннан чыгып кына бәяләделәр. Тарихилык бездә сәяси кысаларда гына аңлатылды, шулай күрсәтелде. Мисалларны эзләп ерак барасы түгел, бөтен тирә-ягыбыз, социалистик реализм әдәбияты алар белән шыгрым тулы иде. Н. З. Шамота дигән бер автор, мәсәлән, тарихилыкның мәгънәсе партиялелектән һәм сыйнфыйлыктан гыйбарәт, дип язды (Кара: Шамота Н. З. За конкретно-историческое отражение жизни в литературе // Коммунист Украины.— 1973.— №5.— С. 77—96). Хәер, сыйнфыйлык, партиялелек принципларын җәмгыять тарихының билгеле бер дәверендә — тирән социаль үзгәрешләр, кузгалышлар һәм аеручa сыйныфлар көрәше чорында — әдәбият-сәнгатькә хас күренеш дип карарга да мөмкин. Шуңа күрә, татар тарихи-революцион романының барлыкка

килүе дә закончалыклы күренеш иде. Г. Ибраһимов, М. Галәү, Ш. Усманов, А. Шамов, К. Нәҗми, И. Гази һәм башкалар (без телибезме-теләмибезме) реаль булып узган вакыйгаларны — тарихи чынбарлыкны реалистик образлар аша чагылдырдылар бит. Аларның әсәрләрендәге төп конфликт XX гасырның беренче чирегендә бер-берсенә каршы торган сәяси көчләр көрәшеннән гыйбарәт иде.

Язучы үзе дә ул елларда билгеле бер сыйныф вәкиле буларак иҗат итте. Һәм бу безнең өчен бик табигый иде. Чөнки әлеге әдәби әсәрләр язылган дәвердә җәмгыятьтә рухи кыйммәтләр белән беррәттән, большевистик (партиячел) идеология, сыйнфый карашлар һәм мәнфәгатьләр тулаем өстенлек итте.

И. Нуруллин үз вакытында: «Үткән турында язу, әлбәттә, җинелрәк һәм хәвефсезрәк: вакыйгалар инде тарихи факт буларак тиешле бәясен алган, сәнгатьчә чагылдыру алымнары өлкәннәр тарафыннан эшләнгән»,— дип язган иде (Нуруллин И. З. Тормыш һәм сәнгать чынлыгы (Әдәби тәнкыйть мәкаләләре).— Казан, 1983.— 122 б.). Без бу фикер белән килешә алмыйбыз. Чөнки вакыт әлеге бәяләрнең еш кына субъектив булуын, үзгәргәләп торуын, кайбер бәяләрнең турыдан-туры ялганга корылуын күрсәтте. Әйтик, Казан ханлыгының Явыз Иван гаскәрләре тарафыннан 1552 елда яулап алынуының «прогрессив» характеры, аның татарлар өчен дә фәкать «уңай» роль уйнавы, «зур тарихи әһәмият»кә ия булуы хакында бездә күп язылды. «Явыз милләтчеләр», «ак эмигрантлар» — Г. Исхакый, З. Вәлиди, Г. Баттал, «буржуаз шәрәфчелек» турында да безгә күп тукылды. Саный китсәк, мисалларның очына-азагына чыгып җитәрбезме? Әмма вакытлар узу белән без боларның барысының да чеп-чи ялган икәнлегенә ышандык.

Язучы — барыннан да бигрәк үз халкының вәкиле. Шуңа күрә аның тарихи вакыйгаларны милли-психологик күзлектән бәяләве — бик табигый күренеш. Мисал өчен, А. Толстойның Петр I гә карата мөнәсәбәте (әдипнең шул ук исемдәге романында), әлбәттә, әлеге тарихи шәхеснең замандашы (көндәше) швед короле Карл XII гә карата фикерләре, бәяләмәсе белән бер үк төрле булу алмый. Биредә авторның милли-патриотик карашы үзеннән-үзе аңлашыла. Чөнки әдип үз халкының милли, тарихи, психологик кичерешләрен чагылдыра. 1972 елда Литва шагыйре Ю. Марцинкявичюс болай дип язды: «Халыкның дөньяга карашларыннан мин һәрвакыт көч алам, шуның нәтиҗәсендә эмоциональ рәвештә үземне бөтенлекнең, кешелек җәмгыятенең бер кисәге, тарихи процесста катнашучы икәнлегемне аңлыйм, хис итәм» (Марцинкявичнюс Ю. Я к земле губами припаду // Литературная Россия, 1972, 17 ноябрь).

Әйе, язучының милли-психологик позициясе, беренчедән, аның тарихилык хисенең мөһим күрсәткече булса, икенчедән, ул иҗат иткән әсәрнең милли йөзен дә билгели. Тарихилык хисе — һәр тарихи романның милли йөзе. Хәзерге вакытта, күп кенә халыкларның дәүләтчелекләре кире кайтарылган һәм яңарган дәвердә, әлеге мәсьәләләрнең актуальлеге үскәннән-үсә бара.

Безнең әдәбият фәнендә тарихилык мәсьәләсе Ф. Мусин хезмәтләрендә еш яктыртыла. Аның: «Тарихилык принцибы язучы иҗатында автор хыялы белән документализмның үзара тыгыз бәйләнештә булуларын, бер-берсенә булышулары таләп итә. Шунлыктан, иҗат процессында һич тә аларның берсенә генә өстенлек бирергә ярамый»,— дигән сүзләре бернинди дә шик уятмый, бүген дә заманча кабул ителә. (Мусин Ф. М. Чор белән аваздаш. Татарстан китап нәшрияты, 1983, 97 б.)

Сәнгатьнең кайсы төрен гена алмыйк — аның кызыксындыру һәм ышандыру көче турыдан-туры чынбарлыкны дөрес сурәтләү белән бәйле. Соңгысы, шарт буларак, тарихи әсәргә (ул кайсы гына жанрга карамасын) аеруча кагыла. Биредә, әлбәттә, кыенлыклар байтак. Шуларның иң җитдиләреннән берсе — тарихи үсеш-үзгәрешнең катлаулы процесс булуы. Әйе, алга бару юлында тайпылышлар, вакытлыча чигенүләр, кискен борылышлар, сикерешләр бар. Тарихның әнә шундый катлаулы булуы әдипләр тасвирлаган әсәрләрдә дә чагыла.

Борынгы чор турында тарихи әсәр язуга алыну — игелекле, әмма җаваплы адым. Әйе, әдип үз өстенә зур җаваплылык йөкли. Аерым бер шартларда (тарих буенча махсус хезмәтләрнең тиражы азлык, аларның башлыча фәнни даирәләргә генә багышлануы, гыйльми тикшеренүләрнең стиль һәм анализ нисбәтендә гаять үзенчәлекле булулары һ. б.) әсәр киң катлау укучылар өчен тарихи шәхес, чор, вакыйгалар хакында бердәнбер чыганак булырга мөмкин. Бу очракта язучы, әдәби хәрәкәт вәкиле генә булып калмыйча, билгеле бер дәрәҗәдә белгеч (тарихчы, археолог, фольклорчы) һәм тарих укытучысы сыйфатында да чыгыш ясый. Ул үз иҗатында тарихи дөреслеккә тугры булу өчен тарихи чыганакларны өйрәнә, махсус әдәбият, фәнни тикшеренүләрнең нәтиҗәләре белән таныша, халык авыз иҗаты үрнәкләренә (милли мираска) мөрәҗәгать итә.

Әсәрнең уңышы авторның иҗат фантазиясенең документаль материал белән тыгыз бәйләнгән булуыннан да тора, ә аның кыйммәте һәм әһәмияте тарихи чынбарлыкны дөрес бәян итүдән чыгып билгеләнә. Кыскасы, иҗади күзаллау тарихилыкка зыян ясамаска тиеш. Фантазия белән артык мавыгуның тарихи җирлектән аерылуга китерүе бик тә ихтимал. Чын тарихи әсәрләр исә тарихи дөреслекне бозуга юл куючан субъективизмнан һәм модернизацияләүдән азат булалар, әмма әдәби хыялдан, уйлап чыгарудан баш тартмыйлар — чөнки әдәбият-сәнгать алардан башка яши алмый.

Әлбәттә, язучы белән тарихчы-галимне капма-каршы куярга, әдәби әсәргә фән таләпләре тагарга ярамый. Тарихны өйрәнүдә язучы тарихчының көндәше түгел, ә якын дусты, хезмәттәше булырга тиеш. «Тарихи роман жанры» исемле хезмәтендә (Метод, стиль, жанр.— Казан, 1976.— 126 б.) бу хакта әдәбият галиме Х. Хәйри дә язган иде.

Тарихчы күренекле шәхеснең тарихи үсеш-үзгәрештәге урыны, аның иҗтимагый йөзе белән кызыксынса, язучы исә үз игътибарын персонажларның психологиясенә, уй-кичерешләренә, әхлакый йөзләренә юнәлтә. Шуңа күрә тарихи шәхескә, аның гамәлләренә карата язучы һәм галим тарафыннан бирелгән бәяләмәләр арасындагы аерымлыклар, үзгәлекләр дә табигый кабул ителә. Мәсәлән, Н. Фәттахның «Әтил суы ака торур» романында Койтым бикә Алмыш ханга: «Син... көч, байлык иясе...» хәлифә ялчысы!» дип әйтә икән, моның нигезе бар һәм без бу ачу-үч тойгысына һич гаҗәпләнмибез. Чөнки беләбез: тәңредән аерылып, мәҗүсилектән китеп, ислам динен кабул итү катлаулы процесс булган. Мәҗүсилекнең тамырлары күп гасырлар тирәнлегенә барып тоташа. Шул ук вакытта Койтым бикә бердәнбер улы булган Тотыш алыпны Алмыш ханның өч батырына каршы чыгара. Әйе, бердәнбер улын! Әлбәттә, Болгар илтабарының сәясәтен, ялауларын аерым кабиләләр, җирле халыклар кул чабып, сөенеп каршылый алмаган. Ә менә икенче яктан караганда, тарихчы өчен, Алмыш хан (илтабар, патша, әмир) — болгар кабиләләрен берләштерүче, Урта Идел буйларында ислам дине кабул ителүгә, димәк, Шәрекъ мәдәнияте, икътисады белән тыгыз бәйләнешләр булдыруга юл ачкан, этәргеч биргән, ягъни прогрессив, әһәмиятле гамәлләр кылган шәхес.

Мисалларны дәвам итеп, И. Калашниковның «Дәһшәтле гасыр» («Жестокий век») романында олы улы Жучи үлеменнән соң Чыңгыз ханның өлкән хатыны Бортэ-хатун белән көчле психологик диалогын китерә алабыз. Бортэ җиһангирне «мангус (явыз аждаһа — Х. Ә.), үз балаларының канын эчүче елан» дип атый (Калашников Исай. Жестокий век.— М., 1978.— С. 821—822). Бертуганы Хасар ханга: «Карындашыңның, туганыңның канын агызу — синең өчен гадәти хәл»,— ди. Әйе, Чыңгыз ханның рәхимсез булуына беркем дә шикләнми — бу хакта күп язылды. Әмма тарихчы булса — беренче чиратта, аның монгол дәүләтчелеге тарихындагы урыны белән кызыксына. Монгол сахраларында тарихи аренага калкып чыккан, таркау монгол кабиләләрен бергә җыю юлында шул халкының тарихында *бәхәссез* (курсив безнеке — Х. Ә.) уңай роль уйнаган Чыңгыз хан, Кытай диңгезеннән алып, Идел-Урал якларына кадәрге араларны тулысынча яки өлешчә буйсындыру вакытында, һичшиксез, күпләгән илләрнең, дәүләтләрнең җимерелүенә, меңләгән-меңләгән кешеләрнең үлүенә, кырылуына сәбәп булган (Госманов М. Алтын Урда: тарих һәм мирас // Мирас.— 1993.— № 8.— 38 б.) Бердәм дәүләтчелекнең тууы кыйммәткә төшә, әмма үзара сугышлар туктатыла. Шул рәвешчә, монголлар, үз тарихларында беренче тапкыр, көчле бер дәүләт булып оешалар. Бу дәүләт элгәреге берләшмәләрдән, шул исәптән «Хамаг Монгол»дан үзенең феодаль асылы белән аерылып тора (Әшнәки И. (И. Халиуллин). Монгол ялаулары // Мирас.— 1993.— № 8.— 104 б.).

Барлык фактларны да колачлау — язучы бурычы түгел. Ул бер факт, бер вакыйга яки бер шәхес язмышы белән чикләнергә дә мөмкин. Әмма аның фантазиясе башка тарихи фактлар белән каршылыкка кермәскә тиеш. Бездә исә, кызганычка каршы, соңгы елларда дөнья күргән тарихи романнарда әнә шундый каршылыклар, төгәлсезлекләр очраштыргалый. Беренче карашка бу кимчелекләр «вак-төяк» булып тоелсалар да, аларның арта баруы безне битараф калдыра алмый. Чөнки «Тамчыдан күл җыела», диләр. Үз вакытында В. Ян тарихи төгәллекне тарихи роман иҗат итүдә иң төп шартларның берсе буларак бәяләгән иде.

Без әлеге төгәлсезлекләрне берничә төркемгә бүләбез. Аларның беренчесе — **хронологик төгәлсезлекләр.** Алар шактый еш очрыйлар. Мисал өчен Н. Фәттахның «Сызгыра торган уклар» романында сурәтләнгән Бөек Кытай диварын төзү эпизодын китерергә мөмкин. Фәнни даирә әлеге корылмаларны төзи башлау

вакыты итеп безнең эрага кадәрге IV гасырны күрсәтеп килсә дә, автор бу вакыйганы безнең эрага кадәрге III гасыр ахырына күчерә: «Шихуанди... (Безнең эрага кадәр 246—210 елларда хөкемдарлык итә, ягъни б. э. к. III гасырда) төньяк кыргыйлар моннан соң беркайчан да изге Чин җирләренә якын килергә батырчылык итмәсеннәр өчен, көнчыгыштагы диңгез буеннан алып көнбатыштагы ком чүлләре арасындагы соңгы төбәккә кадәр сузылган төньяк чикне биек койма белән тотып алырга боерды». (Фәттах Нурихан. Сызгыра торган уклар. Беренче, икенче китаплар.— Казан, 1991.— 534—537 б.). Дөрес, мәсьәләгә бераз төгәллек кертергә тырышып, ул «Ун мең ли озынлыгындагы бу Чан чен — Озын койма элеккеге иске коймаларны да ялгап алып китте»,— дип яза. Бәлки, бу «вактөяк»кә тукталып та торасы түгелдер? Безнең борынгы бабаларыбыз сөннәр ул тирәләрдә тереклек итү сәбәпле, әлеге вакыйга күпмедер дәрәҗәдә безнең дәүләтчелегебезнең тарихи тамырларына кагылышлы булса да (ә бу дәвердә сөн җәмгыяте белән Кытайдагы баштa — цзинь, аннан соң Хан империяләре арасында көрәш бара), Бөек Кытай дивары милли тарихыбызның бер өлеше түгел бит! Шулай булгач, бу вакыт төгәлсезлеге безнең татар укучысының фикерләвенә кардиналь үзгәреш-йогынты ясый алмый. Чит халык дәүләтчелеге тарихында моннан ике мең ел — ике мең ике йөз еллар элек булып узган вакыйгаларны тасвирлаудагы кайбер кимчелекләр аның игътибарын җәлеп итмәскә дә мөмкин. Ләкин шулай да, бу «безнеке» түгел икән — теләсә ничек язарга ярый дигән сүз түгел. Ничек кенә булмасын, язучы үз әсәре чикләрендә тарихилыкның барлык аспектлары өчен дә җавап бирә. Милли тарихыбызның «үз йөзе», аерылгысыз өлеше булган фактларның, вакыйгаларның вакытларын дөрес күрсәтү мәсьәләсендә әдипнең җаваплылыгы исә тагын да зуррак.

М. Хәбибуллинның «Илчегә үлем юк» романы — бик тә мавыктыргыч итеп язылган, тарихи фактларга бай әсәр (Хәбибуллин Мөсәгыйт. Илчегә үлем юк.— Казан, 1990). Ләкин монда да без анахронистик күренешләргә юлыгабыз. Әүвәл нәүбәттә тарихи шәхесләр — Баян, Җик (Җик Мәргән), Бачлан безне гаҗәпләндерәләр. Чөнки романда XII гасырның икенче яртысында, башлыча аның өченче чирегендә булып узган вакыйгалар бәян ителә. Югарыда искә алынган шәхесләр исә, язма чыганаклардагы мәгълүматлардан күренгәнчә, тарих мәйданында шактый соңрак — XIII гасырның 30 елларында гына шөһрәт казанган затлар. Алар өчесе дә 1237—1240 елларда монгол илбасарларына каршы баш күтәргән халыкларның азатлык хәрәкәтен җитәклиләр. Баян һәм Җик ниндидер Кернек каласы өлкәсенең хакимнәре булалар, ә Бачман исә, гомумән, кыпчаклар башында Түбән Идел буйларында хәрәкәт итә (Рашид-ад-дин. Сборник летописей.— Т. 2.— М.— Л., 1960.— С. 17—18. Шулай булгач, әсәрдә баянны Булат оланның хәрби остасы, ә Бачманны Гали олан остазы итеп күрсәтү, Җик Мәргәнне инде, бөтенләй, ниндидер Тубыкбайның энесе итеп бирү кирәкме икән? Язучы тасвирлаган дәвердә туып кына калсалар да, тарихи чыганаклар раслаган чорда алар инде 60—70 яшьтә булырлар иде. Юк шул, туып кына калмыйлар... Бачман баһадир, әнә, ул чакта ук инде Акбикәгә гыйшык тота...

М. Хәбибуллин Хаҗитархан (Әстерхан) каласының салынуын гына түгел, аның атаклы сәүдә үзәге булып әверелүен дә тизләтә — шәһәрне ким дигәндә йөз-йөз илле елга «картайта». Баксаң, Хаҗитархан, галимнәр фикеренчә, XIII гасыр азагында гына нигезләнгән икән (Арсланов Л. Ш., Висторин В. М. Астраханские татары // Материалы по истории татарского народа.— Казань, 1995.— С. 336; Федоров-Давыдов Г. А. Общественный строй Золотой Орды.— М.: Издво МГУ, 1973). Ул авторның «Шайтан каласы»нда да күренеп ала әле.

Әйе, тарихи шәхесләр турында язганда саграк эш итәргә кирәк. Әйтик, Чыңгыз хан турындагы эпизодны романга кертергә кирәк идеме? «Шайтан каласы»нда булсын да ди. Әлеге эпизод «Илчегә үлем юк»та Владимир-Суздаль кенәзе Андрей Боголюбскийның Болгарга килү вакыйгасы алдыннан ук бирелә:

«— Маңгелләрнең ыруы зурмы, көч-куәтләре нидә?

— Көч-куәтләре Тәңре кулындадыр, хан. Унбиш яшьтән алып җитмеш яшькә кадәр һәр маңгел орышта катнаша. Илтабарларының аты Тимерҗандыр (автор аның Чыңгыз хан булуын «Шайтан каласы»нда тәфсилләбрәк яза — Х. Ә.), ыруының исәбен белмим, хан.

Сәлим хан кәтибә Хафиз ягына күз ташлады.

— Кәтиб Хафиз, маңгелләр ыруы хакында син хәбәрдармы? Ни ашый, ни эчә ул халык? Көнкүреше? Утрак яшиләрме, җәйлиләрме? Тоткан иманнары, гореф-гадәтләре? Ни әйтерсең?..

— Ханиям, табгачлар әйтүенә ышансак, маңгелләр гайрәтле халыктыр. Ашаганнары иттер, эчкәннәре кымыздыр. Маңгел атта туа, атта үлә, диләр. Төп

кәсепләре ау вә мал асраудыр, әмма юлбасарлыктан да баш тартмыйлар, еш кына күрше-күлән кабиләләрен рәнҗетәләр, талыйлар. Сәүдәгәрләр әйтүенә ышансак, монгелләр бүген күрше тирәдәге ыруларны буйсындырып, көч-гайрәт җыеп киләләр».

Хәзер инде уйлыйк. Югарыда романда башлыча XII гасырның өченче чирегендә булып узган вакыйгалар бәян ителүе турында әйтеп узган идек. Андрей Боголюбский Болгарга килсен дә ди. Килсә дә ул 1174 елга кадәр генә килә ала, чөнки шул елда ул боярлар заговоры нәтиҗәсендә үтерелә (Сборник документов по истории СССР. Ч. 1.— М.: Высшая школа, 1970.— С. 118). Бу вакытта Тимучин (булачак Чыңгыз хан) 19 яшьтә генә (ул 1155 елда туа)— Сандаг Ш. Образование единого монгольского государства и Чингисхан // Татаро-монголы в Азии и Европе.— М.: Наука, 1970.— С. 26), ун ел элек ятим кала; кая анда дәһшәтле җиһангирлек, ул әле керсит ханының вассалы була, башка монгол кабиләләре өстеннән хакимлеккә ирешү өчен көрәшне башлап кына җибәрә. Шулай булгач, ул бу вакытта әле берничек тә, романда тасвирланганча, Иртыш елгасы буена килеп чыга алмый.

Анахронизмнардан Р. Батулла да ахыргача арына алмаган. Аерым алганда, «Сөембикә» кыйссасына кереш рәвешендәге аңлатмаларның берсендә (Сөембикәгә илтүче беренче сукмак) түбәндәге юллар күзгә ташлана: «Алмас хан. Аның исемен китапларда төрлечә язалар. Алмыш, Үлмәс... Татар чыганакларында — Алмас... бу бөек хан идарәсендә 922 елда Болгар дәүләте, рәсми рәвештә, Ислам динен кабул итә. Алмас хан, Риза Фәхретдин хәзрәт язганча, Болгар дәүләтенең икенче ханы булган. «Йосыф белән Зөләйха» исемле мәшһүр кыйссаны язучы шагыйребез бөек Кол Гали — Алмас ханның оныгы; ул Алмас ханның улы Мирхаҗидән туган булган, диләр» (Батулла. Сөембикә.— Казан, 1992.— 9 б.) Моны кем әйтә икән соң? Моңа ишарә юк. Фәндә кабул ителгәнчә, Кол Гали 1236 елда, монголлар явы вакытында һәлак була (Усманов М. Кул Гали — основоположник булгаро-татарской письменной литературы // Поэт-гуманист Кул Гали.— Казань, 1987.— С. 43.) Тууына килгәндә, кайберәүләр 1183 ел датасын күрсәтәләр. Хәер, соңгысы әлегә тәмам расланып бетмәгән. Шуның өчен беренче дата белән чикләнәбез. 922 ел белән 1236 ел арасында 314 ел килеп чыга. Батулла, әнә, бер буынны шулкадәр яшәтә (Алмас хан — Мирхаҗи — Кол Гали). Ай-һай, безнең бабайлар бигрәк озын гомерле булганнар икән! Монда инде: «Алар бит тәмәке тартмаганнар, нитратлар ашамаганнар» дияргәме?

Хәзер икенче төр — **тарихи-географик төгәлсезлекләргә күчик.**

Кимчелекләрнең бу төре безнең тарихи проза жанрында (соңгы елларда дөнья күргән әсәрләрдә) әлләни еш очрамый. Әмма аңа карап аларның тарихилыкка зыяны кимеми. Хәер, әлеге төгәлсезлекләрнең барлыкка килүендә билгеле бер шартларда фәнни карашлар арасында туган каршылыкларның да өлеше юк түгел. Шулай да, язучы тарихи әсәр иҗат итү процессында мөмкин булганча алардан читтә булырга, күпмедер дәрәҗәдә белгечләр фикерләренең уртак нокталарына таянырга омтыла. Ләкин болай эшләү һәрвакытта да мөмкин булмый. Мәсәлән, «Илчегә үлем юк» романында М. Хәбибуллин кайчандыр фәнни даирәдә бәхәсләр кузгаткан «Хәзерге Казан Иске Казаннан үсеп чыгып, алга таба яңа урынга салынганмы, яисә ул хәзерге урынында башлап нигезләнгәнме?» дигән сорауга үзенчә җавап эзли. Ул, ничектер, ике фикерне дә килештерергә теләгәндәй, «Казан дәрьясы Олуг Иделгә койган төбәктә моңа кадәр тиңе булмаган кала» салыначагы хакында яза. (68 бит) «Моңа кадәр тиңе булмаган кала» — димәк башлап (элгәрерге шәһәрне яңа җиргә күчереп салу рәвешендә түгел! — Х. Ә.) нигезләнәчәк яңа кала турында сүз бара. Шул ук вакытта Казан кирмәнен (нигәдер кала салынгач — Х. Ә.) күчереп салу фикере дә күтәрелә («Кала салынгач, Казан кирмәнең шунда күчерерсең. Казан кирмәнең уңай урында түгел, ни зур елгадан ерак, ни олы юлдан дигәндәй» — 66 бит).

Казанның нигезләнүе мәсьәләсен язучы шулай хәл итә. Бередә ул тарихи-географик нисбәткә тугры кала. Ә менә Бөек Кала (аны тарихчы-археологлар Биләр шәһәрлеге белән тәңгәлләштерәләр — (Халиков А. Х., Зухин Ф. Ш. К вопросу о названии столицы домонгольского периода // Биляр — столица домонгольской Булгарии.— Казань, 1991) мәсьәләсендә тарихи-географик ясссылыкта эш башкачарак. Әйтик, югарыда искә алынган романның бишенче битендә үк: «Һәм менә Бөек Каланың йөзек кашы булып Идел елгасы буенда хан сарае торгызылды»,— диелә (5 бит). Утыз өченче биттә исә без түбәндәге юлларны укыйбыз: «Кояш чыгып, үлән-чәчкә кыякларында энҗедәй чык бөртекләре кибүгә, Ага-Базар аша Бөек Кала халкы киң болынга агыла башлады». Кыскасы, әлеге җөмләләрдән үк укучы Бөек Кала — Идел ярындагы шәһәр дип уйлый.

Житмешенче биткә житкәч исә ул икеләнә башлый. Бөек Кала Кече Чирмешән елгасы янында икән бит («Кече Чирмешән елгасына житкәч, атларны эчерделәр, бераз ял итеп алдылар. Бөек Каладан чыккач, авыз ябмый сөйләшеп барган оланнар да тынып калдылар.

Кече Чирмешән елгасын кичкәч, Баян баһадир дүрт азатны алдан җибәрде. Алар хан сәфәрчеләре үтәсе юлның иминлеген тикшереп килергә тиешләр иде. Бу юлдан бер тапкыр гына үтмәгән Баян баһадир, кичкә кадәр Ибраһим каласына җитәргә тиешлекләрен искәртеп куйды»). Бөек каланың Кече Чирмешән елгасы буенда булуы инде беркемдә дә шик уятмый (Смирнов А. П. Волжские булгары.— М.: Изд-ие ГИМ, 1951.— С. 30; Хузин Ф. Ш. Великий город на Черемшане.— Казань, 1995). Тик менә ни өчен аны Идел ярына күчерергә кирәк, Ага-Базар белән бәйләүнең дә сәбәбе аңлашылып бетми. Югыйсә, Ага-Базар Шәһре Болгар — ул чордагы Ибраһим каласы (Фахрутдинов Р. Г. Болгар в письменных источниках // Город Болгар: Очерки истории и культуры.— М.: Наука, 1987.— С. 17—18) белән бәйле бит. Ул соңгысыннан нибары биш-алты чакрымда гына урнашкан (Казаков Е. П. Старостин П. Н., Халиков А. Х. Археологические памятники Татарской АССР.— Казань, 1987.— С. 147—148.— № 298а). Ә романда исә дистәләрчә чакрымлык арадагы Олуг кала халкы (өйләреннән чыгып, шундук) болынга Ага-Базар аша агыла икән... Хәер, югарыда без җәя эчендә әлеге өзекне күрсәтеп үттек инде, М. Хәбибуллин Ибраһим каласы барлыгын да таный. Әмма ул аның Ага-Базарга терәлеп утыруын танып бетерми булса кирәк. Чәчкә бәйрәменә агылучы халык бөек Каланыкы түгел, ә нәкъ менә Ибраһим каласы кешеләре була да инде.

Өченче төр исә — **гомуми-тарихи төгәлсезлекләр.**

Кимчелекләрнең бу төре халыкларның гореф-гадәтләрен, тарихи шәхесләрнең дөньяга карашларын бәян итүдәге кайбер тайпылышлар белән бәйләнгән. Алар югарыда искә алынган төгәлсезлекләрнең барысына караганда да тарихи романнарда сирәгрәк очрыйлар. Без, сүзне артык озынга сузмыйча, бу очракта дин-иман мәсьәләләренә бәйле берничә мисалга гына тукталабыз. Чөнки халыкларның көнкүреше, гореф-гадәтләре, тарихи шәхесләрнең дөньяга карашлары, мәгълүм булганча, гасырлар дәвамында аларның рухи мәдәниятен, дини мәсләген чагылдырган.

Билгеле ки, хәзерге диннәр килеп чыкканчы, яки алар этнос тарафыннан кабул ителгәнче халыклар мәҗүсилектә булганнар, тәңрегә табынганнар. Н. Фәттах моны сөннәр мисалында («Сызгыра торган уклар» романында) тәфсилле бәян итә. Әмма ул әсәр ахырына җиткәндә кө тмәгәндә «Иншалла!» дип куя (740 бит). Бу сүз исә бөтенләй артык. Чөнки ислам дине (625 ел), бер аллалык белән бәйләнешле бу гарәп сүзтезмәсенең (ин шаэ — фигыль, «теләсә» мәгънәсендә — алла) борынгы сөннәргә бөтенләй катнашы юк. Ә менә Р. Батулланың «Сөембикә» романында исә киресенчә, Сөембикә дога кылганда «Илаһым» диеп кенә калмый, «И, тәңрем» дип тә өсти (400 бит). Югыйсә, Сөембикә — мөселман дәүләтенең ханбикәсе, ислам динендәге зат. Ф. Латыйфи тагын да «уздыра» — хәтта Кол Шәрифнең дә тәңрене «исенә төшерә» (282 бит). Ж. Рәхимов каршылыкка керергә теләмичә, дин-иман мәсьәләсен үзенең персонажы — тарихи шәхес Котлымөхәммәт Тәфкилев мисалында үзенчә хәл итә. Авторның «Батырша» романындагы берничә эпизодка игътибар итик.

«Илчелекнең башлыгы (Котлымөхәммәт морза — Х. Ә.), үзе дә мөселманга охшарга тырышып, өстенә яшел җилән, аягына сәхтиян читек кия, башына чалма урый һәм... шулар белән хурлыкка кала да.

Урдага барып төшүгә, Тәфкилев үзен: «Котлымөхәммәт морза»,— дип таныштыра. Ләкин казакълар аның чукынганлыгын белеп алганнар, имеш. Әбелхәер аны салкын каршылый:

— Атыңны Котлымөхәммәт дидең. Син Әләкчәй Иванович икәнсең гуй. Динен саткан кеше казакъны сатмасмы?! — дип кылычын ук тартып чыгара» (Рәхимов Җәмит. Батырша.— Казан, 1992.—31 б.).

Моңа өстәп, Неплюевның Тәфкилевкә: «күптән чукынганга саналасың, ә өеңдә намаз укыйсың икән, дигән сүзләр йөри», диюенә каршы Тәфкилевнең «Өемдә икона тора минем, Иван Иванович»,— дип җаваплавын китерергә мөмкин (667 бит). Яки менә морзаның халыкка мөрәҗәгать итүеннән бер эпизод:

— «Ник алкышламыйсыз?! Шәрәфәтле патшабикәбез сез мөселманнар («Без» дими бит,— Х. Ә.) мәгыйшәтен кайгыртып, ясакны бетергән лабаса!» (206 бит).

Тарихчылар фикеренчә, Тәфкилевләр үзенчәлекле рәвештә ике төрле (мөселман һәм христиан) исем йөртсәләр дә мөселман булып калганнар. Хәер, тарихи

чыганакларда әлеге нәселнең берничә вәкиленең православиегә күчүләре хакында әйтелә, ә Котлымөхәммәт морзаның, аерым алганда, православие кабул итмәве, мөселман булып калуы тәгаен мәгълүм (Гилязов И. А. Помещики Тевкелевы в XVIII — начале XIX в. (К вопросу об исторических судьбах татарского феодального класса) ««Классы и сословия России в период абсолютизма.— Куйбышев, 1989.— С. 80). Дөрес, әсәрнең ахырына таба Җ. Рәхимов үз позициясен бераз йомшарта: «Юк, бу аның базар бәһасен күтәрүе түгел иде. Чыннан да, ул соңгы елларда үзенең бирешүен сизде, еш кына чирләштерә башлады. аны инде төрле бүләкләр дә, дөнья малы да кызыксындырмый диярлек. Бөтен уе-җаны тарткан Тирсәдәге утарына кайтып, Барҗы буендагы заводына күз-колак булгалап кына тыныч-имин картлык кичерү, инде тәмам онытыла башлаган Коръән сүрәләрен укый-укый, йомшак түшәктә бу фани дөнья белән хушлашу» (420 бит).

Гомум-тарихи төгәлсезлекләр, кимчелекләр чорның, вакыйганың датасын күрсәтү белән турыдан-туры бәйле булмаска да мөмкин. Алар борынгы халыкларның көнкүрешен чагылдырганда да очраштыргалыйлар. Н. Фәттахның «Сызгыра торган уклар» романында сөннәрдәге сәүдә мөнәсәбәтләренә дә урын бирелгән. Мәсәлән, кыпчакларның сөннәргә затлы тиреләр, эретелгән һәм чүкелгән бакыр, алтын, тимер алып килүләре, ә алмашка йон, ефәк, киндер, тукыма, савыт-саба һ. б. алып китүләре турында телгә алына (333 бит). Урынлы бу. Әдәбилеккә дә куш була, укучының тарихи фикерләвен баетуга да өлеш кертелә. Ул тирәләрдә яшәгән, көн күргән халыклар, әйтик, Алтай төркиләре, Енисей кыргызлары (борынгы хакаслар) һәм шул исәптән әлеге кыпчаклар борын-борынгыдан мәгъдән эшкәртү осталары буларак танылганнар. Әмма мәгъдән эшкәртү, гомумән, сөннәрдә югары үсешкә ирешкән. Урынның тимер һәм бакыр рудаларына бай булуы моның өчен бик ышанычлы нигез. (Мәсәлән, сөннәргә караган Түбән иволгино шәһәрлегендә археологик казулар вакытында бик әйбәт сакланган тимер эретү мичләре, шлак һәм әзер продукция калдыклары табылды — (Кара: Хәлиуллин И. Сәхифәләр калка тарихтан // Казан утлары.— 1990.— № 5.— 170 б.). Әсәрдә бу детальгә тиешенчә игътибар бирелеп бетмәгән. Әйтик, кыпчакларның товарлары (шулай дияргә яраса) белән танышканда укучыда берьяклырак фикер туарга мөмкин: сөннәр (шулкадәр халык, гаскәр!) читтән килгән чималга, продукциягә генә туенып яшәгәннәрмени, сугыш һәм талаудан башка һөнәр белмәделәр микәнни? Юк икән шул, аларның үз шәһәрләре, тимер эретү мичләре булган — сөннәр өчен утрак тормыш бөтенләй үк ят түгел икән. Димәк, әлеге мисалда тарихилыкның бөтен яктан да, тулы чагылдырылуы зарур икәнлеге янә раслана.

Ф. Латыйфинең «Хыянәт» (1993) һәм М. Хәбибуллинның «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» (1996) романнарында исә тарихи төгәллеккә карата җаваплылыкның үсүе сизелә. Авторлар инде тарихи фактлар белән саграк эш итәләр. Аларның әсәрләрендәге һәр эпизод хронологик, тарихи-географик нисбәтләрдә борынгы чыганаклар белән генә расланып калмыйча, характер ягыннан персонажлар үзләре чагылдырган тарихи шәхесләргә бик тә якын торалар. Хәтта әсәрләргә керел-чыгып йөрүче персонажларның гамәлләре дә чыганакларда бәян ителгәннәрдән әлләни читкә тайпылмыйлар. Бу нисбәттә Җ. Рәхимовның «Батырша» романы да (югарыда телгә алынган детальләр белән бергә), аны төрле яктан килеп бәяләсәк, әлеге оягa кepә ала.

Тарихилык — тарихи әсәрнең нигезе, умыртка баганасы. Элегрәк бездә соңгысы сыйфатында документальлек күздә тотыла иде. В. Оскоцкий үз вакытында аның тарихи жанр өчен зарури булуын шик астына алды (Оскоцкий В. Роман, история, современность // Литература, искусство и формирование личности в социалистическом обществе.— М., 1974.— С. 129.) Ул тарихи әсәрләрдә документальлекнең ролен бөтенләй диярлек инкарь итеп, икенче чиккә ташлана. Ф. Мусин хаклы рәвештә әлеге тәнкыйтьченең «тарихи романның үзенчәлекләрен билгеләгәндә... аның иң элек роман, аннан соң гына тарихи булуыннан чыгып эш итәргә кирәк» дигән фикерен тәнкыйтьли (Мусин Ф. М. Чор белән аваздаш, 95 б.). Чыннан да, В. Оскоцкий фикере белән ризалашканда, билгеле бер дәрәҗәдә, тарихи жанрның үзенчәлекләре юкка чыгарыла, әүвәл нәүбәттә алгы планга романлык кыйммәте чыгарыла. Нәтиҗәдә күләм-вакыйгалар киңлеге романның тарихи булу асылына капма-каршы куела. Ләкин без, табигый ки, романның тарихилыгы турында сүз йөрткәндә, башта ук әсәрнең роман буларак үзенчәлекләрен ачыклаган хәлдә, тарихи-әдәби анализ гамәлгә керешәбез. Хәер, В. Оскоцкий моның белән килешә булыр. Әсәрнең романмы, повестьмы әллә хикәяме икәнлеген ачыклау — гомумәдәби мәсьәлә. Ул прозаның тарихилык жанрын билгеләүгә яки бәйләүгә турыдан-туры бәйле проблема түгел. Тән-

кыйтьче проза әсәренең төрен билгеләгәндә, ачыклаганда әле аның тарихимыюкмы икәнлеге турында фикер йөртми. Ахыр чиктә (бу очракта) без әсәрнең жанр үзенчәлекләренә түгел, аның тарихилыгына игътибар итәбез.

Тарихи әсәрнең асылын билгеләүче үзенчәлекләр тирәсендә вакытында җанлы гына бәхәсләр булып алды. Үзәккә куелган сорау бер иде: «Тарихи әсәр нәрсә ул?» Ул киңәя дә, шул ук вакытта төгәенләнә дә барды: «Тарихи әсәр хронологик сыйфатлардан башка була аламы? Документальлек — бердәнбер (абсолют) дәгъвамы?» Әлеге сорауларга җавап эзләү юлында безнең әдәби тәнкыйть һәм әдәбият галимнәре башлыча Ю. Андреев фикеренә таяндылар (Хәйри Х. Язучы һәм тормыш, 178 б.). Ю. Андреев, тарихи роман жанрының асылын билгеләргә омтылып, болай ди: «Барыннан да элек бу — үткән заманны тасвирлау. Тарихи романның хәлиткеч төп үзенчәлеге — ул вакыт дистанциясе булу, хәзерге заман өчен гыйбрәтле булырлык инде төгәлләнгән бер чорны тасвирлау.

Аннары, тарихи романның жанр хасияте аның документальлек нигезе, матур әдәбият законнары буенча чын тарихи вакыйгалар һәм шәхесләрнең сурәтләнүе кебек үзенчәлек белән билгеләнә.

Кыскача әйткәндә, тарихилык, үткән заман турында хикәяләү һәм документальлек — классик төрдәге (формадагы) тарихи романның төп билгеләре менә шулар» (Андреев Ю. А. Русский исторический роман.— М.— Л.: Изд-во АН СССР, 1962.— С. 6—7).

Тарихи романнардагы хикәяләү рәвешләре турындагы мәсьәләгә кагылып, Ф. Мусин 60—70 нче еллар прозасында ике төрле тарихи хикәяләү турында яза. Беренчесе — ныклап өйрәнелгән документаль материалга нигезләнгән конкрет тарихи хикәяләү. Бу очракта авторның роле үсә. Икенчесе — автор фантазиясенә тагын да киңрәк мәйдан ачылган, документаль төгәллеккә азрак дәгъва белдерелгән тарихи хикәяләү. Әлеге бүленеш (ул, әлбәттә, шартлы) әдәбиятыбызда бүген дә саклана. Соңгы елларда басылган тарихи романнарыбыз мисалында беренче төр хикәяләү — Н. Фәттах, Ф. Латыйфи, ә икенче төр М. Хәбибуллин, Р. Батулла әсәрләренә хас дип нәтиҗә ясарга мөмкин.

Ә хәзер тарихи роман жанры белән әдәби тәнкыйтьнең үзара мөнәсәбәтен карап үтик.

Әдәби мирасны барлау һәм өйрәнү буенча бай тәҗрибә тупланган. М. Гайнуллин, Г. Халит, Х. Госман, М. Хәсәнов, И. Нуруллин, Ф. Мусин һ. б. үзләренең хезмәтләрендә әдәби процессны тарихи күзлектән чыгып анализларга омтылдылар. Алтмышынчы еллардан башлап Х. Хәйри, И. Нуруллин, Н. Юзиев, Ф. Миңнуллин, Р. Мостафин, Ф. Хатыйпов, Р. Сверигин һ. б. мәкаләләрендә акрынлап булса да тарихилык мәсьәләләре белән кызыксынуның җанлана баруы күзәтелә.

Югарыда әйтелгәнчә, совет чорындагы татар прозасында тарихилык принцибы мәсьәләсе махсус рәвештә Ф. Мусин тарафыннан өйрәнелде, әлеге тикшеренүләрнең нәтиҗәләре сиксәненче еллар башында расланды (Мусин Ф. М. Преемственность и развитие художественного опыта татарской советской прозы (К проблеме историзма) // Автореф. дисс. ...докт. филол. наук.— М., 1983.— 38 с.). Бераз соңрак В. Борщуковның «Әдәбият фәнендә һәм тәнкыйтьтә тарихилык принцибы» дип аталган мәкаләсе дөнья күрде (Борщуков В. И. Принцип историзма в литературоведении и критике // Проблемы историзма в русской советской литературе (60—80-е годы).— М.: Наука, 1986).

Кызганычка каршы, тарихилык — үткәнне, бүгенгене һәм киләчәкне тоташтыручы төшенчә буларак — әдәби тәнкыйтьнең игътибар үзәгендә торса да, соңгысының тарихи роман жанрына карата мөнәсәбәте аерым мәсьәлә (процесс) буларак бездә әлегә махсус тикшерелмәде. Бер тарихи романга язылган рецензия генә түгел, гомумән, теге яисә бу язучының тарихи проза өлкәсендәге иҗаты анализланган фәнни хезмәт тә мәсьәләнең тулысынча чишелеше буларак кабул ителә алмый. Биредә хикмәт әлеге жанрда эшләүче авторларның ишәюендә генә дә түгел. Аерым алганда, иҗат алымнарының төрлелеге һәм тарихи фикерләү юлларының үзенчәлекле булуы — болар үзләре үк әдәби тәнкыйтьнең тарихи прозага (романга) карата мөнәсәбәтен бербөтен мәсьәлә итеп махсус өйрәнүне сорый. Уртак тема кысаларында конкрет чор тасвирланган, һәркайсының үзәгендә хронологик, сәяси, социаль-икътисади нисбәттә бер үк төрле диярлек проблема күтәрелгән, әмма бер-берсеннән күпкә үзгә булган тарихи әсәрләрнең кечкенә генә вакыт аралыгында иҗат ителүе дә (мәсәлән, Р. Батулла, Ф. Латыйфи һәм М. Хәбибуллинның Казан ханлыгы тормышын яктырткан романнары), факт буларак, югарыда китерелгән фикерне көчәйтә.

«Тарихи роман жанры һәм әдәби тәнкыйть» мәсьәләсен күтәрүебезнең тагын бер сәбәбе бар. Тәнкыйтьчеләрнең һәм әдәбият галимнәренең моңа кадәр дөнья күргән мәкаләләрендә башлыча язучының тарихи-революцион жанрда язылган романына игътибар бирелде. Хәер, Х. Хәйри тарихи-биографик роман мәсьәләсен дә күтәрә, әмма бу очракта ул ике әсәр — Ә. Фәйзинең «Тукай» һәм Гайшә Шәрипованың «Гафур гаиләсе» романнарын тикшерү белән чикләнә, А. Расихның «Ямашев», Ш. Маннурның «Муса», Җ. Тәрҗемановның «Көмеш дага» романнарын телгә генә алып уза. Ул тарихи-революцион роман мәсьәләсендә К. Нәҗминең «Язгы җилләр» романын анализлый. Тик аның Н. Фәттахның «Әтил суы ака торур» романын шул ук кысаларга этеп кертүе (Хәйри Х. Язучы һәм тормыш, 173, 180—214 б.) безгә бөтенләй дә аңлашылмый. Бу очракта нинди революционлык күздә тотыла икән? Әллә соң Х. Хәйри әлеге әсәргә теоретик билгеләмә генә таба алмаганмы?

Вакыйганы төрлечә бәяләү яки тарихи үсеш баскычларында идеалларның үзгәрүе мөмкин булган кебек, әдәби тәнкыйтьнең тарихи роман жанрына карата мөнәсәбәте дә бертөрле генә түгел иде. Шул ук вакытта кайбер уртак тенденцияләр дә күзгә ташлана. Мәсәлән — якын үткәндәге вакыйгаларны гына түгел, бәлки борынгы чорлардагы күренешләрне дә сыйнфый-партиячел күзлектән чыгып бәяләү. Без бу хакта түбәндәрәк махсус тукталып узарбыз. Икенче уртак нокта — тарихи роман авторының иҗат алымын ачыклауга, бигрәк тә әсәрнең стилистик үзенчәлекләрен тәгаенләүгә өстенлек бирү. Бу күзлектән караганда хәзерге чорны чагылдырган әсәрне анализлаудан тарихи романга карата булган мөнәсәбәт концептуаль яктан әллә ни аерылмый булып чыга. Һич югы моңа ышану өчен тарихи романнарга карата язылып, моңарчы дөнья күргән рецензияләргә күз салу җитә. Югыйсә, тарихи романның үзенә генә хас булган сыйфатлары әдәби тәнкыйтьнең аңа мөнәсәбәтендә дә чагылыш табарга тиеш иде. Әлбәттә, бу очракта әдәби тәнкыйтькә күп эшләргә туры килә, җаваплылык бермә-бер арта. Чөнки әсәрдән, аның авторыннан тарихилык таләп итү өчен тәнкыйтьченең махсус әзерлекле булуы, тарихи вакыйгаларны, чыганакларны белүе сорала.

Әдәби тәнкыйтьнең тарихи роман жанрына карата мөнәсәбәтен дә иҗтимагый фикернең чорга хас этно-социаль һәм сәяси үзгәрешләргә бәйле булуы чагылыш таба. 20—30 нчы еллардан алып, сиксәненче елларның беренче яртысына кадәр тәнкыйтьчеләрнең күпчелегенең тарихи әсәрләрне тарихилык, партиялелек, сыйнфыйлык принциплары таләпләреннән чыгып, социалистик реализм кысаларында бәяләүләре ачык күренә. Ара-тирә алар халыкчанлык принцибы турында да искә төшергәлиләр, әмма аның асылы исә шул ук партиялелеккә кайтып кала. Табигый ки, бездә «партия — эшчеләрдән, крестьяннардан һәм хезмәт интеллигенциясеннән торган халыкның бер өлеше, авангарды» дип тәкрарларга гадәтләнделәр бит. Кайбер хезмәтләрдә исә югарыда телгә алынган принципларның алдагы икесе арасындагы чикләр бетерелә, тарихилыкның партиялелеккә буйсындырылуы сизелә. Гомумән, бу күренеш әдәби даирәдә дә, гуманитар фән өлкәсендә дә ят нәрсә түгел иде (Кара: Шамота Н. З. За конкретно-историческое отражение жизни в литературе // Коммунист Украины.— 1973.— № 5. С. 77—96). Күренекле тарихчы, рус халкының XIII гасырда илбасарларга каршы көрәше хакындагы фәнни хезмәтләр авторы В. Т. Пашуто, мәсәлән, тарихилыкны принцип кысалары белән чикләмичә, аны тагын да үзенчә киңрәк яссылыкка чыгара, партиялелек — аның төп принцибы дип исәпли (Коммунист.— 1984.— № 5. С. 86). Шул рәвешле тарих философиясенә партиячел-сыйнфыйлык балласты тагыла). Аның тамыры Ленинның тарихи хакыйкатьне барлык үзенчәлекле билгеләре белән тулысынча танып-белү бары тик партиячел, пролетар позицияләрдән, иҗади-яңарыш позицияләреннән чыгып эш иткәндә генә мөмкин, дигән фикеренә барып тоташа.

Тарихи жанрның бер төре булган тарихи-революцион характердагы әсәрләр якын үткәнне тасвирлауда аерым урын алып торалар, әдәби-тәнкыйди мөнәсәбәткә дә бу очракта кайбер үзенчәлекләр хас. Мәсәлән, 1917 елгы Октябрь революциясе, аның нәтиҗәләре белән бәйле вакыйгалар һәм алар тасвирланган әсәрләр барлыкка килү арасында шактый вакыт узса да еш кына әлеге әсәрләрдәге төп геройлар һәм персонажлар гына түгел, аларны иҗат иткән язучы һәм хәтта әдәби тәнкыйтьче дә дистәләрчә еллар дәвамында хөкем сөргән бер үк төрле идеологик климат шартларында яшиләр. Аерма исә бары тик соңгыларының ара-тирә кискенләшеп яки, киресенчә, йомшарып алуында гына. Бу үзгәрешләр турыдан-туры әдәби тәнкыйтькә йогынты ясыйлар, аның аркылы тарихи әсәрләрне бәяләүгә дә үтеп керәләр.

Әдәби тәнкыйтьнең озак еллар дәвамында идеология коллыгында яшәве хәзер беркемдә дә шик уятмый. Егерменче елларда — утызынчы еллар башында партиялелек принципның сыйнфый асылы тәмам тәгаенләнә. Ул әсәрләрне анализлаганда, бәяләгәндә төп «ориентир» булып әверелә. Г. Сәгъди, мәсәлән, К. Нәҗми иҗатының, пролетариатның сыйнфый көрәшчелек психологиясе, пролетариат идеологиясе белән сугарылуын югары бәяли (Сәгъди Г. Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты.— Казан, 1930.—75 б.)

Утызынчы елларның икенче яртысында әдәби-эстетик фикер герой характерындагы гомумкешелек сыйфатларын аерып чыгара башлый. Әмма соңгылары сыйнфый сыйфатларга ярдәмче, ягъни икенче дәрәҗәдәге билгеләр буларак карала (Гыйлаҗев Т. Ш. 20—30 еллар татар әдәби тәнкыйте үсешендә төп тенденцияләр (метод һәм герой мәсьәләләре) // Филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә дәгъва итүче диссертация.— Казан, 1991.—199 б.). Димәк, әсәрләрдә сыйнфыйлык линиясенең көчәюендә әдәби тәнкыйтьнең дә катнашы бар. Моны гомумән социалистик реализм әдәбияты тәнкыйтенә карата да әйтергә мөмкин. Аерым алганда, Х. Хәйри, К. Нәҗминең «Язгы җилләр» романындагы Халявин, Айвазов образларының индивидуаль характерларына игътибар җитеп бетмәве, әлеге образларның художество көче ачылып җитмәве турында пошынып яза (189 бит).

Ф. Хатипов: «Совет чорында язылган әсәрләр нинди иде? Аларга карата нинди бәя гадел булачак?» дигән сорауларны куя һәм үзе үк җавап та бирә: «Иң әүвәл бу дәвер, электәге кебек, бик зур талант ияләренең исемнәре белән бәйләнгән. Совет чорында М. Шолохов «Тын Дон», М. Ауэзов «Абай», Ч. Айтматов «Гасырдан озын көн», И. Гази «Онытылмас еллар», Ф. Хәсни «Йөзек кашы», «Җәяүле кеше сукмагы», Г. Бәширов «Туган ягым — яшел бишек», Ә. Еники «Әйтелмәгән васыять», «Гөләндәм туташ хатирәсе», Н. Фәттах «Әтил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар» исемле повесть, романнарын, А. Твардовский, Ф. Бурнаш, Һ. Такташ, М. Җәлил, С. Хәким, Х. Туфан, Н. Исәнбәт, Т. Миңнуллин матур-матур поэтик, драматик әсәрләр яздылар. Аларның һәм тагын шундый бик күп гүзәл әсәрләрне рухи тарихыбыздан сызып ташларга берәүнең дә кулы күтәрелмәс дип уйларга кирәк» (Хатипов Ф. Тәнкыйть реализмы булганмы? // Казан утлары.— 1994.— № 7.—139 б.). Менә шундый мөнәсәбәт. Әйтергә кирәк, әлеге исемлектә без карап үткән тарихи, тарихи-революцион романнар да бар. Без дә Ф. Хатипов фикере белән ризалашабыз.

Монысы шулай, монысы хәзер.Кызганычка каршы, социалистик реализм әдәби тәнкыйте борынгы тарих тасвирланган әсәрләрне дә партиялелек күзлегеннән чыгып бәяләүдән баш тартмады. Мәсәлән, гасырыбыз башында иҗат ителгән әсәрләргә карата түбәндәге караш мәгълүм: «XX йөз башында (Октябрь революциясенә кадәр) элеккеге заманны сурәтләгән, Чыңгыз, Туктамыш, Идегәй, Сөембикә кебек ханнарны «милли герой» итеп, идеаллаштырып, романтик легенда рәвешендә язылган әсәрләр поэзиядә дә, прозада да еш күренеп торды. Алар буржуаз милләтчелек идеяләрен чагылдырган реакцион романтизм әсәрләре иде, алар өчен халык тормышы, реаль тарихи чынлык ят иде» (Хәйри Х. Тарихи роман жанры // Метод, стиль, жанр.— Казан, 1976.— 129 б.). Ярый, Чыңгызы монгол булды ди. Туктамышшка да тими торыйк. Ә менә милли тарихта үзенчәлекле эз калдырган Идегәй һәм Сөембикәне нигә кире кагарга? Ю. Сафиуллин белән Р. Батулланы орышыргамы? Алар бит «безнеке» түгел, нигә ул пьеса белән романыгызны яздыгыз, дип? Бу бит тарихилыкка каршы килү, мирастан баш тарту була! Әйе шул, без хәзер шулай дип әйтә алабыз. Ә элек? Менә шулай, тәнкыйди фикерләр, бәяләр дә искерәләр.

Халыкчанлыкны милләтчелек, миллилек идеясенә каршы кую — үткәннәргә сыйнфый күзлектән карау өчен хас күренеш. Ул безнең тарих һәм әдәбият фәннәрендә шактый озын гомерле булып чыкты. Н. Фәттахның «Әтил суы ака торур» романының төп геройлары Тотыш һәм Аппак Х. Хәйри тарафыннан социаль һәм рухи коллык корбаннары буларак бәяләнә (101 бит). Әмма әлеге фикер ахыргача дәлилләнмәгән; тәнкыйтьче гомумгуманистик кыйммәтләргә ишарәлиме, әллә сыйнфыйлык-партиялелек позициясеннән чыгып фикер йөртәме — болары ачыкланмаган хәлдә кала. Аның күбрәк соңгысына нигезләнүе турында түбәндәге юллар ачыклык кертә сыман: «Бигрәк тә романда болгар-татар халкы һәм аның башлангыч феодализм, чынында коллар сәүдәсе дә әле яшәгән феодализм дәүләтенә мөнәсәбәте һәм гаделлек, бәхет өчен көрәш идеалларының сәнгать теле белән социаль-экономик, политик анализ нигезендә тиешенчә ачылып җитмәүләре безне уйландыра, өлешчә канәгатьсезлек хисен дә кузгата» (195 бит). Х. Хәйри, «гаделлек, бәхет өчен көрәш идеаллары» турында

сүз кузгатса да, аларның IX—X гасырлар өчен сыйфат һәм эчтәлек җәһәтендә нинди булырга тиешлекләре турында баш ватып тормый. Дәгъва белдергән очракта аларны ачыклап үтү артык булмас иде.

Болгар дәүләте оешуын тасвирлау мәсьәләсендә дә Х. Хәйри һәм Ф. Мусин Н. Фәттахны дәүләт барлыкка килүнең марксистик-ленинчыл тәгълиматын аңлап бетермәүдә, шул сәбәпле әлеге тарихи процессны легендалар һәм риваятьләр рухында сурәтләүдә гаеплиләр (Хәйри Х.. Язучы һәм тормыш, 195 б.; Мусин Ф. М. Связь времен.— Казань, 1978.— С. 39). Р. Мостафин исә моны тасвирланган чор буенча тарихи чыганакларның аз булуы, шул сәбәпле язучының легендаларга һәм риваятьләргә, шулай ук борынгы татар әдәбиятының романтизм традицияләренә таянуы белән аңлата (Кара: Казан утлары.— 1972.— № 5.—171 б.).

Безнеңчә, югарыда күрсәтелгән тәнкыйтьчеләр мәсьәләне берьяклырак карыйлар. Беренчедән, Н. Фәттах X гасыр башындагы Болгар җәмгыяте турында чагыштырмача иң тулы, мәгълүматларга иң бай чыганактан — гарәп сәяхәтчесе Ибн Фазлан язмаларыннан файдаланган. Әлеге тәнкыйтьчеләрнең фикерләре белдерелгәннән соң егерме еллап вакыт узса да, сурәтләнгән чор яктыртылган «яңа» чыганакның әлегәчә табылганы юк. Икенчедән, мәҗүсилек чорын халык авыз иҗаты әсәрләреннән башка гына тасвирларга омтылу — бик үк дөрес юл булмас иде. Чөнки фольклор әсәрләрендә бу очракта шактый кызыклы детальләр (мәгълүмат димик) табарга мөмкин. Әйтик, әсәрнең исеме үк М. Кашгари (XI гасыр) Сүзлегендә урнаштырылган җырдан алынган. Өченчедән, реализм әсәрләрендә генә түгел, романтизм әсәрләрендә дә иҗатның предметы — тормыш, җәмгыятьтә төрле бәйләныш җепләре белән бәйле кеше. А. Н. Гуляев фикеренчә, «романтизм аның эстетик асылына бәйле рәвештә бәяләнергә тиеш. Әдәбиятның бердәнбер казанышы итеп тормышның бары тик конкрет-социаль чагылышын гына исәпләргә ярамый, хәер, ул романтизм сәнгате өчен дә ят түгел. Әгәр дә реалистик сәнгать барыннан да элек объектив чынбарлыкны аның үсеш-хәрәкәтендә күрсәтүне күздә тотса, романтизм вәкилләренең төп максаты кешелекнең рухи тарихын ачыклаудан гыйбарәт» (Гуляев А. Н. Социально-эстетическая и гносеологическая сущность романтизма // Русский романтизм.— М.: Советский писатель, 1974.— С. 25). Романдагы киеренкелек һәм мавыктыручанлык аның соңгы битләренә кадәр саклана. Д. Иванов «Әтил суы ака торур»ның классицизм, «Вальтер Скотт традицияләрендә» язылуын билгеләп үтте (Кара: Литературное обозрение.» 1980.— № 1.— С. 82).

1974 елда «Казан утлары»ның 1 нче санында Ф. Хатиповның «Әтил суы ака торур»га рецензиясе басылды. Рецензент башлыча әсәрнең тарихи төгәллеге мәсьәләсенә түгел, ә аның идея-сәнгати эшләнешенә игътибар иткән. Ул романдагы Койтым бикә образын М... Җәлилнең «Алтынчәч»ендәге Тугзак ана образы белән чагыштырып карый, төп уртак сыйфат ит п патриотизм хисе алына. Койтым бикә образында исә бу хис әлләни сизелми, Тугзак ана исә яубасарларга каршы халкын күтәрә — биредә азатлык рухы, идеясе, патриотзм хисе ярылып ята. Үз вакытында Х. Хәйри дә мондый чагыштыру-тиңләштерүнең урынсыз булуы турында билгеләп узды (193 бит).

Романның эпик киңлеге, манзарасы турында да берничә сүз әйтеп китик.

Әсәрнең эпик киңлеге беренче бүлекләрдә үзенең күләмен сакласа да, торабара ул тарая башлый, һәм яңа дин кабул иткәндә ихтимал һәм табигый булган каршылыклар белән очрашырга җыенган укучы ваграк масштаблы вакыйгаларга тап була. Н. Фәттах иҗатын өйрәнүчеләр бу күренешне төрлечә кабул итәләр, аңлаталар. Ф. Урманчиев, мәсәлән, халык авыз иҗаты әсәрләренең татар язучылары иҗатына йогынты ясавы мәсьәләсендә «Әтил суы ака торур» мисалына тукталып, «романның ахырына таба халык эпосы образларының үсеш-үзгәреш логикасы бозыла бару»ы турында билгеләп узды. Ф. Хөсни дә әсәрнең мәхәббәт интригалары белән тәмамлануына ризасызлыгын белдерде (Хөсни Фатих. Ни әйтергә? Ничек әйтергә? — Казан, 1974.— 48 б.).

Романның сәнгатьчә эшләнеше, жанр үзенчәлекләре мәсьәләсенә килгәндә, Х. Хәйри аны «иң яхшы мәгънәдә тарихи-романтик әсәр» дип атады (193 бит), ә Р. Мостафин исә бу очракта «авантюрно-романтик роман» (авантюралы-романтик роман? — Х. Ә.) гыйбарәсен кулланды (Кара: Советская Татария, 1985, 3 марта).

Н. Фәттахның «Сызгыра торган уклар» романы әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан беренче тарихи романына караганда җылырак кабул ителде. Әдипнең әлеге әсәре — татар әдәбиятында хәзергә милли тарихыбызның иң тирән катламнарын тасвирлаган роман. Бу хакта И. Хәлиуллин («Сәхифәләр калка тарихтан

Казан утлары.—1990.—№ 5.—169—171 б.) телгә ала. Рецензент романга гомумәдәби анализ ясамый, ә аны башлыча тарих фәне (тарих, археология, этнография) күзлегеннән тикшерә, тарихи тегәллек дәрәҗәсен ачыклый, эпизодларны һәм детальләрне төрле тарихи чыганаклардагы мәгълүматлар белән чагыштыра, ул борынгы чорның тарихи манзарасы белән таныштыра. И. Хәлиуллин «Сызгыра торган уклар» романын тарихи тегәллек мәсьәләсендә бик югары бәяли.

Ф. Миңнуллин бу әсәргә кечерәк кенә әдәби тәнкыйть мәкаләсен багышлый (Миңнуллин Ф. Балта явызлар кулында.—Казан, 1994.—332—334 б.). Ул романның кыйммәтен, әһәмиятен ачыклый, аңа югары бәя бирә. Аның Туман каган (тархан)—Албуга мөнәсәбәтләрен «Идегәй» дастанындагы Идегәй—Норадын мөнәсәбәтләре белән чагыштыруы кызыклы. Абзацны тулысынча китерик: «Романның умыртка сөяген—төп конфликтын—Туман каган белән улы Албуга арасында хакимлек өчен, каганлык өчен көннән-көн көчәя, рәхимсез төс ала барган дошманлык билгели. Безнең күз алдында Туман каган көче һәм җегәре бетеп килгән хәлсез картка, Албуга исә беркатлы, самими егеттән нык куллы ханга әйләнә бара. Соңгы ау вакытында каган улы Албуга аткан уктан һәлак була. Аларның күпмедер дәрәҗәдә «Идегәй» дастанындагы Идегәй һәм Норадын мөнәсәбәтләрен хәтерләткән гыйбрәтле һәм драматик язмышы романга моңсу яңгыраш бирә, трагик төсмерләр өсти».

Тарихи әсәрләр арасында гына түгел, гомумән, соңгы елларда нәшер ителгән романнар даирәсендә Ф. Миңнуллин Н. Фәттахның югарыда күрсәтелгән әсәре белән М. Хәбибуллинның «Кубрат хан» романын аерым урынга куя: «Шул рәвешчә язылган ялыктыргыч һәм пассив стильле романнар арасында, соңгы могикан кебек күңелле сюрприз булып, ике әсәр калкып тора. Аларның берсе—М. Хәбибуллинның «Кубрат хан» романы...


Икесе ике стильдә язылган (М. Хәбибуллин романында халык әкиятләренә тартым романтик стиль өстенләк итсә, Н. Фәттах дилогиясе заманга авазлашлыгы, чынлык һәм реальлек хисенең зурлыгы белән аерылып тора), сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан икесе ике биеклектә торган (Нурихан дилогиясе, һичшиксез, бер баш югары тора) әлеге әсәрләрне бер-берләренә иң элек җанлы сурәт һәм динамик картиналар муллыгы, аннары төп геройларның эшләнеше якынайта» (128—129 битләр).

Кызганычка каршы, соңгы берничә ел эчендә чыккан тарихи романнарга карата әдәби тәнкыйтьнең фикерен белә алмыйбыз әле. Әдәби тәнкыйть арткарак кала башладымы, аның мәнфәгатьләре үзгәрдеме, әллә махсус әзерлек җитеп бетмиме—матбугатта рецензияләр үтә сирәгәйде. Хәер, элек тә алар еш күренми иделәр. Безгә калса, бүгенге көндә рецензияләр кытлыгының (без биредә тарихи роман жанрын гына күздә тотабыз) төп сәбәбе—әдәби тәнкыйтькә карата булган таләпләрнең кискен үзгәрүе. Чөнки элек яшәгән сыйнфыйлыкпартиялелек принцибы әдәби тәнкыйтьне шаблон системага салып, тәнкыйтьчеләрнең шөгылен шактый гадиләштергән, җиңеләйткән иде. Хәзер инде ул принцип юк. Бердәнбер принцип—тарихилык. Димәк, безнең әдәби тәнкыйтьчеләребез дә хәзер әдипләр сыман бары тик милләт һәм гаделлек, тарихилык турында гына уйлап язарга тиешләр.

**С. Алишев,**
тарих фәннәре докторы

**Р. Галләмов,**
тарих фәннәре кандидаты

# УТ ЭЧЕНДӘ КАЛГАН КҮГӘРЧЕН КЕБЕК



Быел күренекле тарихчы-галим, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе Һади Мифтахетдин улы Атласиның (Һади Атласи) тууына 120 ел тулды (1876—1938). Аның бай иҗади мирасы, билгеле тарихи хезмәтләре белән беррәттән сәяси-публицистик һәм әдәби әсәрләрне дә үз эченә ала. Заманның кайнар сулышын тоеп язылган ялкынлы публицистикасы аша Һади Атласи милләтпәрвәр шәхес буларак аеруча ачык күзаллана. Бу уңайдан аның 1906 елда Оренбургта күренекле нәшир Фатих Кәрими матбагасында аерым китапчык булып басылып чыккан «Яңа низам вә голямаларыбыз», ягъни «Яңа закон һәм укымышларыбыз» дигән мәшһүр сәяси-публицистик әсәрен үрнәк итеп алырга була.

XX гасыр башында Русия дәүләтендә барган процесслар, вакыйгалар анда яшәүче күпсанлы изелгән милләтләр өчен берникадәр тәрәккыят мөмкинлеге тудырса да, патша хөкүмәтенең гасырлардан гасырларга килүче урыслаштыру сәясәте барыбер дәвам иткән. Бу сәясәт мәгариф өлкәсендә үзен бигрәк тә ачык сиздергән. 1905 елның маенда Русиянең көнчыгышында яшәгән «урыс булмаган» халыкларда уку-укыту мәсьәләләре буенча хөкүмәт махсус киңәшмә үткәрә. Анда империя тарафыннан изелгән халыкларның милли аңы үсешенә киртә кую максаты белән татар әлифбасын урыс хәрефләренә күчерү (димәк, бу Сталин һәм партия башлаган эш кенә түгел!), аларның мәктәпләрендә урыс теле укытуны мәҗбүри итеп кую, балаларны урыс рухында тәрбияләү мәсьәләләре карала. Киңәшмәнең карарлары 1906 елның мартында мәгариф министры тарафыннан кагыйдәләр җыелмасы рәвешендә расланып, бастырылып чыгарыла. Карагруһчыларның шовинистик планнарына каршы протест белдереп, Һади Атласи шул ук елда югарыда искә алынган мәкаләсен яза. Бу публицистик әсәрендә ул хөкүмәтне изелгән милләтләрнең ихтыяҗларын исәпкә алмавы, бары тик урыс халкы мәнфәгатьләрен генә кайгыртуы өчен каты тәнкыйть итә. Хәер, әсәрнең эчтәлеген укучылар үзләре укып та белә алырлар. Шунысы игътибарга лаек, Һ. Атласи карагруһчыларның шовинистик сәясәтенә каршы көрәштә дини фәлсәфәне иң ышанычлы корал итеп күрә һәм дин әһелләрен бу көрәшнең әйдәп

баручылары сафында күрергә тели. Әсәрнең төп эчтәлеге милләтне уяту кирәклеген өндәү буларак кабул ителә һәм шул нисбәтле авторның үзен «ут эчендә калган күгәрчен кебек» хис итүе бер дә гаҗәп түгел.

Шушы публицистик әсәре өчен хөкүмәт 1909 елда Атласины судка бирә. Һәм ул өч айга төрмәгә хөкем ителә. Шулай ук ул указлы мулла һәм башка рухани дәрәҗәләрдән мәхрүм ителә. Әлмәт авылында (хәзерге Әлмәт шәһәре) аның тырышлыгы белән ачылган кызлар мәктәбе дә ябыла. Әсәр бастырылган китапчык тиражының бер өлеше яндырыла. Төрмәдән чыкканнан соң да Һ. Атласи хөкүмәт өчен «ышанычсыз» кешегә әйләнеп, 1917 елга кадәр полиция күзәтүе астында яши. Атласиның совет чорындагы фаҗигале язмышы инде мәгълүм — ул репрессияләнә һәм 1938 елда «халык дошманы» буларак атып үтерелә. Шулай итеп, империя нинди иҗтимагый җәмгыять чоры булмасын — патша чорымы ул, совет чорымы — «ялгышларны» беркайчан да онытмый һәм гафу итми! Сүз уңаенда Һ. Атласиның шушы әсәрен дөньяга чыгарган күренекле нәшир Фатих Кәриминең дә Сталин репрессияләреннән котылып кала алмавын әйтеп китү урынлы булыр.

Әсәргә бәя биргәндә аның бүгенге көнебез өчен дә аваздаш булуын күрми мөмкин түгел. Ул замандашларыбызга бер үк вакытта кисәтү булып та, чакыру булып та яңгырый.

## ЯҢА НИЗАМ ВӘ ГОЛЯМАЛАРЫБЫЗ

Бер заманнан бирле хөрмәтле ата-бабаларыбызга, чабата туфракларын авыру күзләребезгә сөрмә итеп тарту тиеш булган голяман гыйзам (бөек галимнәребез) вә әсляфе кирамнарыбызга (борынгы хөрмәт ияләребезгә), дин вә милләт юлларында газиз җаннарын вә хөрмәтле каннарын фида иткән шәһидләребезгә, дин ислам өйрәтеп ул мөбәрәкләрнең дөнья вә ахирәттә мәсгуд (бәхетле) үлемнәренә сәбәп булган милли хәрефләребезнең рус хәрефләренә алмаштырылып, тел вә әдәбиятыбызның дәрелфәнадән (фани дөньядан) дәрелбәкага (теге дөньяга) рихләт итәчәген (күчәчәген) 31 мартта мәгариф вәзире граф Толстой тарафыннан тасдыйк ителгән (расланган) указдан гәзитә укучылар, шаять, аңламышлардыр. Кальбендә (йөрәгендә) гайрәте диния (дини гайрәте) вә хәмияте миллиясе (милли уяулыгы) булган иманлы адәмнәр бу тугрыда азмыкүпме булса да, әлбәттә, хәсрәт тә чикмешләрдер, ялкынлы кызу сулуларыны һәм суламышлардыр. Ләкин «хак мөселманмын» дәгъвасында булып та, Коръән вә хәдисчә әсла (һичбер) хак мөселман булмаган иддигаи (һавалы) карендәшләребезнең, дин вә дөньядан һич тә хәбәре булмаган әсхабе кәһәфләрнең (тау куышы ияләренең) бу хосусларда (бу хакта) берни белми ятуларында вә соңра шәкавәт (бәхетсезлек) диңгезләренә батуларында тузан кадәр шик вә шөбһә юктыр. Бу хәреф үзгәртү мәсьәләсе тышкы яктан бик кечкенә генә вә бик әһәмиятсез генә күренсә дә, ләкин эчке катта гаять зур вә соңы (ахыргы) олуг нәтиҗәле бер мәсьәләдер. Бу хактагы минем фикерем күршеләремә билгеле булса да, ерак карендәшләребезгә бөтенләй билгесез вә бөтенләй караңгыдыр. Минем белгәнем түбәндә язылачак менә шундый берничә җөмләләрдән гыйбарәттер.

Шөйлә (шулай итеп): без мөселман татарлар (150) миллион әһалисе (халкы), дүрт миллион гаскәре, бөтен җирнең алтыдан беренә хуҗалык итмәктә булган Руссия хөкүмәтенең тәбәгасеннән (кул астындагы халыктан) вә аның итагатьле колларыннанбыз. Бу хөкүмәтнең идарәсе идарәи мөстәкыйлә булып, монда баш милләт рус милләте вә бөтен диннәргә хуҗа булган дин дә христиан динедер. Руссия хөкүмәте үзе никадәр бөек булса да вә әһалисе (халкы) йөз илле миллион булынса да, бу мәмләкәттә гыйлем вә мәгърифәт, һөнәр вә сәнаигъ (сәнагать, индустрия) шулкадәр түбән вә шулкадәр арттадыр ки, Аурупада Төркиядән башка моннан артта вә моннан надан вә моннан караңгы бер хөкүмәт юктыр. Бу мәмләкәттә гыйлем дә юк, мәгърифәт тә юк, һөнәр дә юк, сәнаигъ тә юк, тәрәкъкый (алгарыш) дә юк, хөррият тә юк. Бар нәрсә салкынлыкта котып бозларына тора торган караңгылыклар һәм дә золым вә җәберләрдер. Хөкүмәтнең үз рәгаясенә (халкына) һичбер илтифаты вә һичбер ригаясе (кайгыртуы)

юктыр. Гыйлем урынына наданлык, хөррият урынына пулемет, мәктәп урынына төрмәләр белән җавап бирмәк, сәгадәтләрне (бәхетләрне) шәфавәтләр (яманлык) белән алмаштырып, ригаяэсене (халкын) кан дәрьяларына батырмак, Сибирия (Себер) сахраларында катырмак — бу хөкүмәтнең мәңгелек кадимге (борынгы) гадәте вә һәм дә иң яраткан бер эшедер. Димәк ки, яраткан нәрсәсе золым, сөйгән нәрсәсе золым, аның ригаяэсенә (халкына) сайлаган нәрсәсе тагын да золымдыр... Золымнан соңра (башка) тагы да бер ятраткáны вә авызына чиләкләп суларыны китергән бер нәрсәсе бар исә, ул да бөтен халыкны вә хосусилә (аеруча) мөселманнарны руслаштырмак, үзләре әйткәнчә, христиан нуры белән нурландырмактыр.

Белгәнне вә яратканы каһәр вә золым булган бу хөкүмәтнең безне мәхү итмәк (бетермәк) вә җир йөзеннән корытмак фикере бик иске вә бик тә борынгы һәм дә үзенчә беренче дәрәҗәдә кирәкле фикердер. Ничә йөз меңнәрдән гыйбарәт булган мәкруһларны (православие динендә булмаганнарны) рәсми суратта христиан итүе, ислам динене тотдыклары хәлдә араларына хөкүмәт химаясендә (канаты астында) булган миссионерларны күндерүе, поплар җибәреп, аларга ирексезләп христианлык тәлкыйн иттерүе (иңдерүе), башын бөкмәгәннәрне Сибирия сахраларына сөрүе — барчасы да күз алдыбызда ап-ачык вә кояш кебек яп-яктыдыр. Тугрысы, кыскача әйткәндә: бюрократиянең беренче максаты безнең динебезне вә милләтебезне мәхү итмәк (юк итмәк), җир йөзеннән корытмактыр. Дин вә нәсәб (нәсел-ыру) җәһәтеннән безем лә (безнең белән) карендәш булган ничә йөз мең адәмнәрне христиан итүе, үзе теләгән чокырларга салып, хәрәкәттән вә бәрәкәттән мәхрүм итүе күз алдыбызда тулган вә ялтырап ятмактадыр. Безне дә шуларча итмәк, дин вә милләтебезне үзенең сөйдеке (сөйләгән) дине белән алмаштырмак хакында хөкүмәте мөстәбидә (изүче хөкүмәт) чук (күп) заманнан бирле иҗтиһад итеп килмәктә, максатын акрынлап булдыра бармакта, күпме еллардан соң безне дә тәмам хак христиан итәчәгенә канәгать кылмакта, заһирән (ачыктан-ачык) гаскәр вә куәи җәбериә истигъмаль итмәгәндә дә (куәтле җәбер кулланмаганда да) куәи хәрбия (хәрби куәт) канаты астында булган миссионерлар, инсафсыз вә вөҗдансыз чиновниклар аркасында безне корытачагын куя, расламак та вә, сугым симеркән кебек, вакыт җиткәнче симертмәктә иде. Заманнар искечә барганда, җилләр һаман бюрократия теләгәнчә уңайлы яктан гына исеп килгәндә безне бетерәчәгендә, дин вә милләтебезне һәбаән мәнсүра (тузан бөртеге) итәчәгендә тузан кадәр шик вә шөбһә дә юк иде. Бу тарихтан өч-дүрт ел элек мин үзем бюрократиянең безне бетерәчәген, динебезне вә милләтебезне корытачагын бик ачык белмәктә, «бетәбез, мәхү булабыз (бетәбез, юк булабыз)!» җөмләрен җан ачысы белән кычкырмакта, ни кылырга белмәенчә ут эчендә калган күгәрчен кебек ахылдап, төрле тарафка чапмакта идем... Хәмедләр (рәхәтләр) вә шөкерләр булсын, җилләр искечә исмәде. Заманның тегәрмәчләре залим, бюрократия теләгәнчә әйләнмәде. Билгакес (киресенчә), бөтенләй башка вә аларның теләвенә кире булган бер тарафка хәрәкәт итте... Бер дә хисапламаган җирдән вә әллә кайдан гына Япония мөхарәбәсе (сугыш) килеп чыкты... Порт-Артур, Мукден вакыйгалары, Цусима мәсьәләләре кебек хәл кылуы мөшкел (кыен) булган гаять авыр мәсьәләләр галәмгә баш күтәрде... Вөҗданлы вә инсафлы, безнең дусларыбыз дип тәгъбир әйткән рус каһарманнарының тартышу вә тырышулары, 1904—1905 сәнәләрнең (елларның) хәрәкәтләре, октябрь-декабрь вакыйгалары эшнең тәртибен бөтенләй бозып ташлады... Черек карт имән агачының куәтле җил белән пәраканда уллагы кеби (таркалганы кебек) хөррият җиле белән черек залим бюрократия дә пәраканда улып, мәхү булды-китте (җимерелеп төште).

Гаять юаш вә гаять мәзлүм булган (җәберләнгән) зур бер милләтне бетерергә бар куәтен сарыф иткән залимнарга үзләренә торырга урыннар тар калды. Яшеннән качкан шайтаннарга, карчыгадан качкан чыпчыкларга, бүредән качкан этләргә урыннар тар булганы кебек, безне мәхү итәргә (юк итәргә) бөтен көчләрен сарыф кылган күзлекле еланнарга да киң җир өстендә бер аршин кадәр булса да кабердән башка тыныч урын калмады. Кайсылары Франциягә, кайсылары Швейцариягә вә кайсыберләре дә әллә кай җиргә-кабердәргә китте-барды. Ләкин хөррият хәрәкәтләре вакытында тау тишегендәге боеккан елан кебек боегып яткан зәһәрле еланнар бу көндә терелә башлады. Җыенда үзен куштаннар кыйнап эт иткән мужикның өенә кайтып ачуыннан күсәк белән атын, чыбыркы белән хатынын кыйнарга башлаганы кеби инсафсыз вә кара йөрәкле бюрократлар да хезмәтчеләр ачуын бездән ала башладылар. Бу көндә галәни (мәгълүм) суратта динебезне вә милләтебезне тәгадди иттеләр (рәнҗеттеләр) Җәнабе хак (Аллаһу тәгалә) тарафыннан пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәлавәтевәс-

сәлам, аның белән Кәлям Шәриф (Коръән) иңдерелгән мөкаддәс хәрефләребезне, тел вә әдәбиятыбызны аңлатуда бөтенләй касыйр (җитешсез) булган рус хәрефләре белән алмаштырып, уку хакында законнар чыгардылар. Сәяси вә гражданский хокукларыбызны алып җәберләү итмәгән кебек, рухани-дини булган җәберләрне бу көнгәчә татыганлыгыбыз туярлык булмаган кебек иң актыккы җәберләргә бу көндә тагын да башладылар. Әүәлдәге рәнҗүләре бетмәгән, борынгы яралары да төзәлмәгән йөрәкләребезгә хәнҗәрләр белән тагын да чәнчеделәр... Корырга җиткән каннарыбызга, чыгарга җиткән җаннарыбызга тагын да агулар сиптеләр... Беренче буларак эшне хәреф үзгәртүдән башладылар. Әле дә сезне күп саклап килдек, вакыт җитте, диеп, һичбер игътиразларыбызга (каршы төшүләребезгә) илтифат итми эшкә керештеләр. Акрынлык белән эш булачак түгеллеген, аз булса да уянуыбызны күреп, көч белән тиз заманда эшне башкарырга уйлап һөҗүм иттеләр. Ильминский кебек ислам бәласе булган адәмнең планын аз заман эчендә вөҗүдкә чыгарып (тормышка ашырып), дин вә миллләтебезгә хатимә бирергә (азагына китерергә) чын көч белән керештеләр... иман ярып! Илаһым хакына... дәһа (тагын да) кыскарак аңлата алам: бюрократиянең әүәлге вә хакыйки фикере безне бетермәктер. Хәреф үзгәртү шуның бер мөкаддәмседер (башыдыр).

Әй, дин башлыгы хисап ителгән (итеп исәпләнгән) безнең голяман варисәт әл-әнбияләребез (пәйгамбәрләрнең укымышлы варислары)! Сезләр кайдасез? Сезнең гайрәтегез вә һимматегез (тырышлыгыгыз) кайдадыр? Сезнең хәмиятегез (уяулыгыгыз) кай җирегездәдер? Сезнең мөселманлыгыгызның мәгънәсе нидер? Варисәте әнбиялелегегез (пәйгамбәр варислары булуыгыз) кай кулыгызда, кай җирегездәдер? Сезнең кальбләрегезнең (йөрәкләрегезнең) нуры, хәяте (тереклеге), кайда вә нәрсәсендәдер?

Дин өчен тешләрен сындырып, битләрен канатып тартышкан адәм сезнең кемегездер? Дөя эчендәге тизәк суларын эчеп сәфәрләрдә булган адәмнәр сезнең әсхабе кәрам тәгъбир иттекеңез (хөрмәт ияләре дип танылган) адәмнәр түгелмедер? Корсагына таш бәйләп, ач булганы хәлдә дин юлында иҗтиһад итеп (тырышып) йөргән адәм сезнең пәйгамбәрегез өммәте дәгъвасында булган рәсүл ходагыз түгелмедер?

Кайда сезнең иман вә Коръән гайрәтегез? Кайда сезнең иманнан тумыш хәмиятегез-(уяулыгыгыз)? Кайда сезнең миллләт кайгыгыз? Кайда сезнең Коръәнегез? Кайда аның белән гамәлегез? Кайда аның аятьләрен хак илә аңлау вә татбикыгыз (укуыгыз)? Кайда Коръәнгә, үзе әйткәнчә, иманыгыз вә аның белән хәрәкәтегез? Оят! Газиз вә мөбарәк исемен алган, пәйгамбәрләрнең варислары намены (исемен) күтәргән, Мөхәммәд галәйһиссәлаваты-вәссәлам кебек хак (изге) вә хак гаюр (гайрәтле) рәсүлнең өммәте саналган, гыйлем вә мәгърифәттән, гайрәт вә иҗтиһадтан (тырышлыктан) гыйбарәт булган Коръән әһле догасында булган сезнең кеби картларга! Безнең кеби яшьләргә! Оят сезгә, соңра оят безгә! Дин исламга хиляф (каршы) диеп, кирәкмәгән җирләрдә ач бозау кадәр кычкырдыгыз хәлдә, динебезгә хакыйки хиляф булган бу кебек урыннарда, дин вә миллләтебезне мәхү итәргә (юк итәргә) беренче сәбәп булган бу кебек мәсьәләләрдә ни хәйлә таптыгыз да постыгыз? Нигә протест бирмисез? Нигә бирергә дәлялӛт итмисез (өндәмисез)? Алла рәхмәт итсен Оренбург имамнары вә мөселманнарына — алар протест бирделәр. Тавышларын җир кырыйларына кадәр ишеттерделәр. Гайрәт диния вә хәмияте миллиянең (дин гайрәтенең һәм миллләт уяулыгының) нәрсә икәнлеген фигыльләре (эшләре) белән күрсәттеләр, күңелләрендә иман нуры вә Коръән икътикады (ишануы) барлыгын мәйданга куеп, иманлы вә хак мөселманнар тарафыннан чын күңелдән хөлус (ихлас) кальб (йөрәк) белән булган рәхмәт вә догалар алдылар. Яшәсен Оренбург имамнары вә мөселманнары!

Шул мәсьәләләрне белеп тә, соңында мәңгелек хараплык икәнен сизә торып та, башка миллләтләрнең бирелмәгән хокуклары өчен матди вә мәгънәви куәтләр белән тырышлыкларын, тузан кадәр хакларын югалтмас өчен үзләрен корбан иткәннәрен күрә торып та, Коръәнегездә иҗтиһад вә гайрәткә өндәгән, түгел аятьләр генә, хәтта камил сүрәләр булганын белә торып та, пәйгамбәрегезнең дин юлында кан коеп тырышканлыгын ишетеп тә, Коръәнегез гыйлем, хәят (тормыш), тәрәккъый (алгарыш), сәгадәт (бәхет), гайрәттән гыйбарәт була торып та, сезнең бу кадәр гайрәтсез вә бу кадәр хәмиятсез (ваемсыз) вә бу кадәр каткан булуыгызның мәгънәсе нидер? Газиз борадәрләрем (туганнарым) вә хөрмәтле карендәшләрем, хәй гали әл-фалях (котылу — зур җанлылыктадыр)!...

**ҺАДИ.**

# «КЫШ САЙРАМЫЙ САНДУГАЧ...»

Илленче еллар уртасында мин Баулыда комсомолның беренче секретаре булып эшләдем. Шул вакытта бездән ерак булмаган Кәрәкәшле авылында (ул күрше Ютазы районына керә, Баулыдан кырык чакрым тирәсе) атаклы шагыйрь Сирин яшәвен ишеттем. Аның турында Казан университетында укыган елларымда миңа курсташым, бүлмәдәшем Зыя Мансур бик мавыгып сөйләгән иде. Ул Сиринне зур шагыйрь, үзенчәлекле талант, хәтта Такташның көндәше булырлык, ләкин репрессиягә эләгеп, иҗат юлы шактый иртә киселгән шагыйрь, дип бәяләгән иде.

Ниндидер йомышны туры китереп, җәйнең матур көннәрендә мин Кәрәкәшлегә юл тоттым. Авылда беренче очраткан кешем, сүзнең кем турында баруын абайлап:

— Ул монда юк шул. Җәй көне ул умарталыкта эшли, көне-төне шунда,— дип аңлатты, умарталыкка барыр юлны да өйрәтте.

Минем моңа әлләни исем китмәде, чөнки Сиринең, Ватан сугышыннан каты яраланып, авыр контузия алып кайтканнан соң, туган авылында гади колхозчы булып эшләвен белә идем инде.

Колхоз умарталыгы авылдан ерак булмаган тау сыртына, елга буена, агачкуаклар үскән искиткеч матур урынга урнашкан иде. Кошлар сайрый, чәчәкләрдән хуш исләр аңкый, бал кортлары безелди... Умарталар арасында йөзен сакал-мыек баскан, өстенә каешланып беткән иске бишмәт кигән бер карт йөри. Башында — колаклары тырпаеп торган сәләмә бүрек. Аягында — куныклары киселгән, таушалган киез итек. Кыскасы, шагыйрьгә бер дә охшамаган.

Килүемне шактый усал эте иләмсез өреп хәбәр иткәч, карт бөкрәеп, көч-хәл белән, кыштыр-кыштыр итеп, яныма якынлашты.

Исәнләштек.

— Миңа шагыйрь Сирин Батыршин кирәк иде...

Бу сүзләрне ишеткәч, карт, корт чаккандай, сискәнеп китте. Каш астыннан гына яхшы райком тарантасына, елкылдап торган тук айгырыма күз ташлап алды да:

— Сез үзегез кем буласыз соң? — дип сорады.

Аңлаттым. Картның йөзе каралып ук китте. Һаман өреп торган этенә каты гына кычкырды да:

— Юк, андый кеше монда юк,— дип кырт кисте.

— Ничек инде — юк? Аны монда, умарталыкта эшли дип әйткәннәр иде...

— Юк, дигәч, юк инде. Монда миннән башка берәү дә юк. Ә мин — гади кеше, умартачы, үзегез күрәсез ич...

Тегеләй дә, болай да картның кылларын тартып карадым. Колагына да элмәде. «Белмим»нән башка сүзе булмады. Хәтта бал белән чәй эчәргә дә эндәшмәде. Алҗыган, авызым кипкән көе кайтып китәргә туры килде. Карт үзен шулкадәр нык тотты ки, хәтта мин үзем дә, әллә ялгыштыммы, дип, шикләнә башладым. Тик, айгырны кирегә борып, китәргә торганда гына әйләнеп карасам, картның шактый акыллы кысынкы күзләрен шәйләп алдым. Аларда хәйләкәр елмаю уты балкый иде. Минем карашым белән очрашкач, карт күзләрен шундук читкә борды. Димәк, башын тилегә салып кыланган гына...

Шулай итеп, Сирин белән очрашсам да, җәелеп сөйләшә алмыйча китеп барырга мәҗбүр булдым. Югыйсә, ул якыннан аралашкан замандашлары — Такташлар, Кутуйлар, Җәлилләр турында сорашырга, башыннан кичкәннәрен белешергә бик теләгән идем...

Шагыйрь белән тагын бер очрашуым 1989 елның октябрь аенда, Сиринның вафатыннан соң ике дистәләп ел үткәч булды. Дәүләт куркынычсызлыгы комите-

тының архивында утызынчы елларда кулга алынган татар язучыларының эшләре белән танышканда, кулыма 1087 номерлы «Дело» килеп эләкте. Сирин Хәниф улы Батыршин һәм аның белән бергә кулга алынган тагын дүрт кешенең эше. Мин бу «Дело» белән йөрәгем әрнеп, эчтән сыкрый-сыкрый таныштым.

«Дело»дан күренгәнчә, Сиринны 1935 елның 22 августында шагыйрь Әсгать Айдар, нәшриятта эшләүче Г. Ризванов, И. Кулиев һәм И. Хәкимов белән бергә кулга алалар. Черек күл күзәтүчеләре бу «котпы таратучы куркыныч төркем» артыннан ике елга якын күзәтеп, һәр адымнарын, һәр сүзләрен теркәп барганнар. Кайчан, кем белән бергәләшеп эчкәннәр, салмыш баштан кемне сүккәннәр, нинди шигырь укыганнар — бәйнә-бәйнә язылып барылган. «Дело»дан күренгәнчә, алар җитәкчеләргә дә тел тидергәннәр, тормышның авыр булуыннан да зарланганнар, совет власте, колхоз төзелеше турында мәзәк тә сөйләгәннәр. «Дело» сүзләре белән әйткәндә, «сгруппировавшись между собой на почве недовольства существующим строем, вели антисоветскую пропаганду и агитацию, сочиняли, хранили и распространяли такого же содержания свои произведения».

Дәлил итеп «Дело»га тоткыннарның әсәрләре дә теркәлгән. Шулар арасында иң җитдие һәм иң «куркынычлысы» — Сиринның «Ана» исемле поэмасы. Бу поэма өстендә ул кайтып-кайтып утызынчы еллар дәвамында эшләгән (поэманың бер варианты астына, 1934 ел, 25 ноябрь, дип куелган). Поэма тәмамланмыйча калган. Күрәсең, автор үзе дә аның басылып чыгуына ышанмаган.

Әсәрнең кереш өлешендә автор шәһәрнең урам чатында басып торган хәер сорашучы сабый малай белән очрашуын тасвирлый. Аны чын күңелдән жәлли, ярдәм итәргә омтыла. Ләкин шул ук вакытта, аның «кулак баласы» булу ихтималын белеп, аңа нәфрәт белән карарга тиешлеген аңлый. Шагыйрь күңеле бу каршылыклы хисләр арасында читлеккә эләккән җәнлек сыман бәргәләнә. Ул бу хәлне аңларга омтыла. Ләкин аңлый да, кичерә дә алмый...



Поэманың төп өлешендә вакыйгалар тагын да куера, чын фаҗига төсен ала. Лирик геройның үз әнисен, берничә сыер асрауда гаепләп, «раскулачивать» итәләр, өен, барлык мал-мөлкәтен тартып алалар, нәни балалары белән урамга куып чыгаралар. Ул да хәер сорашып тамак туйдырырга мәҗбүр була. Лирик герой исә — җаны-тәне белән революция идеяләренә ышанган, совет властена бирелгән кеше — ни эшләргә дә белми. Бер яктан карaганда, ул үз әнкәсенә сыйнфый дошманга караган сыман, нәфрәт белән карарга тиеш була. Әмма бит аның әнисе — дөньяда иң якын, иң газиз кешесе — революцияне яклаучы, гражданнар сугышында акларга каршы корал тотып сугышучы берничә солдат тәрбияләгән, тол калса да, көн-төн тир түгеп эшләгән. Аның гаебе нәрсәдә? Шагыйрь шуны аңларга тырыша, шундый кискен һәм заманы өчен шактый куркыныч сорауларга җавап эзли.

Моңарчы тәнкыйть Сирин турында «күмәкләшү бәхетен җырлаучы» шагыйрь дип язып килде. Чыннан да, утызынчы еллар башында язылган шигырьләрендә ул колхозларга керергә өндәп, күмәк эшне мактап берничә шигырь язган иде.

Аерым-аерым
Матур тормыш
Булмый!
Булмый!

Ялгыз-ялгыз
Матур тормыш
Булмый!
Булмый!

Машиналы
Күмәк тормыш
Төзеп җибәр!

Әмма күмәкләшүнең ничек алып барылуын үз күзләре белән күргәч, шагыйрь фикерен кискен рәвештә үзгәртә, икенче төрле җырлый башлый.

Сирин турында «оптимистик рухта язучы», «яңа тормышның матурлыгын күтәренке рух белән җырлаучы» дип язып килсәләр, КГБ архивында саклаган шигырьләре аны бөтенләй башка яктан ача. Караламада гына калган, беркайда да басылмаган әсәрләрендә Сирин шагыйрь һәм власть, гади халык һәм «яңа байлар» проблемасын күтәрә, үз хәле аша ачлыкта-ялангачлыкта яшәгән халык хәлен күрсәтә:

Аягымда ертык, өс алама,
Ашарга да юк бит,— ни зарар!
Яңа байлар шуңа оялмагач,
Сөйләп торуда ни файда бар!

Сүз уңаенда шуны да әйтергә кирәк, мондый юлларны НКВД тикшерүчесе М. Каменьщиков кушуы буенча юлга-юл русчага тәрҗемә иткәннәр, иң «усал» яңгыраган урыннарның астына кызыл каләм белән сызып куйганнар. «Советка каршы» юнәлдерелгән шигырьләре арасында мондый юллар да бар:

Шигырь яза бүген көчле шагыйрь,
Белми әле нәрсә буласын.
Иртәгә ул, бәлки, урамнарда
Шигырь укып, икмәк сорашыр.

Әйтерсең лә, Сирин бу юлларда үз язмышын күрәзәчелек иткән. Һәрхәлдә, мин күргәндә ул нәкъ шундый хәлдә иде. Ләкин шагыйрь, матди кыенлыклардан бигрәк, сүз иреге булмаудан зарлана, шуңа сыкрана. Аның шактый усал язылган, кечкенә генә күләмле мәсәле шул ук архивта сакланган. Берәү, кибеткә кереп, сатучыга эндәшә:

Баш булса да үлчә, бик туйдым шул
Кәбестәдән, итсез әйрәдән.
Тукта, моның теле юк бит,
Ничек соң ул телсез яшәгән?

Сатучы:

Теле булган аның, син кайгырма,
Тик соңыннан шулай иткәннәр:
Түшен кем ашаганны сиңа
Әйтмәсен, дип телен кискәннәр.

Чыннан да, шагыйрьне юк итү — халыкның телен кисү белән бер бит! Шагыйрь Сталин чорындагы тискәре күренешләргә шул кадәр уфтана, бәргәләнә ки, хәтта үз-үзен үтерү фикеренә хәтле барып җитә, үлем турында уйлана, туган иле, иптәшләре белән хушлаша:

Хушыгыз, әй, кырларым,
Дус-ишләрем, хуш, мин китәм.
Мәңге кайтмаска, күрешмәскә,
Гомерлеккә китәм.

Ут төртәм таудай теләкләргә,
Сөйгән эшләргә мин.
Чик куям кинжал белән
Ялкынлы саф хисләргә мин.

Сезгә монда бер телем
Икмәк кала, чүпрәк кала.
Сезгә монда алдашырга
Полный возможность кала.

Хушыгыз, таллар, иманнар,
Хушыгыз, әй, алмагач!
Кичерегез шагыйрь Сиринне:
Кыш сайрамый сандугач.

*23.11.34 ел.*

Көчле әйтелгән бит — кышын сандугач сайрамый! Һәм аны сайратмыйлар да... Сиринне дә чын мәгънәсендә сындыралар, шигъриятгән биздерәләр.

Моңарчы без Сиринны лирик шагыйрь буларак кына белә идек. Чыннан да, аның бик матур, бик җылы мәхәббәт шигырьләре бар (Сүз уңаеннан: надан тикшерүче М. Каменьщиков мондый нечкә лирикалы шигырьләрне «порнографик шигырьләр» дип бәяли). Архивта сакланган шигырьләре буенча исә без Сиринның бөтенләй яңа ягын — ачы сатирасын, тирән мәгънәле иронисен күрәбез. «Идеологик тотнаксызлыкта» гаепләп, Сиринны Язучылар берлегенә алмыйлар, «формализм»да һәм башка «изм»нарда гаепилиләр. Әсәләтсез шагыйрьләрне, «идеология» ягына гына карап, бастыралар, бүләкилиләр, югары күтәрәләр. Мондый күренешне ачы телле Сирин «ат кәмите» дип атый:

Ярминкәдә ат кәмите әйләнә дә әйләнә.
Их, мин дә әйләнер идем, эш акчага бәйләнә.

Әйләнә тайлар, агач атлар, малайлар әйләнә,
Әйләнә кызлар, кызыл утларга күзләр бәйләнә,
Әйләнә Нәҗми. Толымбай, Нигъмәти әйләндерә,
Әйләнә Сәйфи, Әмирләр. Әйләнү бәйләндерә.
Татиздатның ат кәмите әйләнә дә әйләнә.
Их, мин дә әйләнер идем, эш билетка[1] бәйләнә.

КГБ архивында Сириннең дистәләп көндәлек дәфтәре дә сакланган. Алардан без шагыйрьнең тормышын, эчке кичерешләрен, чор күренешләрен шактый тулы итеп күз алдыбызга китерә алабыз. Монда берничә папка шигырь дә бар. Бүгенге көндә бу материалларның барысы да Татарстанның Дәүләт музеена тапшырылган. Кызганыч, әлегәчә алар белән кызыксынучы, аларны өйрәнүче генә юк. Күптән инде бу материаллар нигезендә Сириннең тулы басмасын чыгарырга мөмкин булыр иде. Әмма аның йөз еллыгы да үтеп бара. Ә шигырьләр шул көе — тузанга күмелеп ята бирә...

Утызынчы еллар башында Сирин шактый популяр, исеме халык арасында билгеле шагыйрь санала. Аның кыю образлары, яңгыравыклы ритмы, көтелмәгән ритмик борылышларга бай булган шигъри юллары аеруча яшь укучыларның күңеленә хуш килә. Аның әсәрләрен сәхнәдән укыйлар (ул елларда поэтик декламацияләр модада була), композиторлар аның сүзләренә көйләр иҗат итәләр. Сириннең балалар поэзиясенә керткән өлеше бигрәк тә зур — ул балалар өчен берничә шигырь китабы бастырып чыгара. Аның «Бишек җыры», «Чепчепләрем, чебиләрем...», «Язгы тамчылар», «Бә-ә дә мә-ә» кебек искиткеч матур поэтик җәүһәрләре әлегәчә әһәмиятен югалтмадылар, балалар тарафыннан яратып укылалар. Сирин татар шигъриятен шактый баета, эчке аһәңнәр белән төрлеләндерә.

Ул үзе дә иҗатының башлангыч дәверендә киләчәккә зур өметләр белән карый, тормышның яхшыга таба үзгәрүенә ышана, шул дәрт белән яши һәм яна:

Яшисе килә,
   күп яшисе.
Көләсе килә,
   җиңәсе килә,
Киләсе көннәрнең
   көлгәнен
Күрәсе килә,
   күрәсе!
Күрәсе! Күрәсе!
Шул көләч көннәрнең
   гөлләрен
Үбәсе килә.

Менә шулай өметләнеп, дәртләнеп яшәгән вакытта Сириннең иҗат юлы кинәт кулга алу белән тәмамлана. Башта ул карыша, аңа таккан гаепләрне танымый. Әмма ахырдан «барлык гаепләремне дә таныйм» дип, кул куярга мәҗбүр була.

1936 елның 31 гыйнварында булган суд Сиринне биш елга ирегеннән мәхрүм итәргә дип хөкем чыгара. Төрмәдән Сирин Ватан сугышы алдыннан гына чыга. Озакламыйча, армиягә алынып, алгы сызыкка китә. Сугыштан яраланып кайта. Һәм тормышның соңгы көннәренә чаклы башта туган авылында, аннан соң Баулы поселогында яши. Беркем белән дә диярлек аралашмый. Әдәби мөхиттән читтә тора. Бәлки, «үзе өчен» ул нидер сызгалагандыр. Ләкин 1935 елдан алып 1970 елга чаклы аның яңа язылган бер генә шигъри юлы да билгеле түгел.

...КГБ архивында сакланган «Дело»сы белән танышкач, мин, ниһаять, Сириннең ни өчен минем белән сөйләшергә теләмәвен аңладым кебек. Ул мине хакимият вәкиле, райком кешесе, «начальник» дип кабул иткән, күрәсең. Үзен җәберләгән, җанын әрнеткән, шигъри утын сүндергән власть «вәкиле» белән ни турыда сөйләшеп торсын ди ул?

**Рафаэль МОСТАФИН.**

---

[1] Сүз Язучылар берлеге билеты турында бара.

## Зыя Мансур

(1916—1965)



Аларны «фронтовик шагыйрьләр» дип йөртә иделәр. Арадан иң кайнар, ярсу йөрәклеләре — Әнвәр Давыдов, Шәрәф Мөдәррис, Зыя Мансур кебекләр — Европаларны гизеп, фашизмны җиңеп, орден-медальләрен чыңлатып яу кырыннан исән-сау кайтсалар да, илле яшьләрен дә тутыра алмыйча дөнья куйдылар. Фронтта алган яраларына ватык-җимерек илнең ярлылыгы-мескенлеге, тоталитар режимның гаделсезлеге өчен әрнүләре дә өстәлеп, янып төшкән йолдызлардай иртә сүнделәр алар. Әнвәр Давыдов — 49 яшендә, Шәрәф Мөдәррис — 44 яшендә, Зыя Мансур 49 яшендә вафат булды.

Быел декабрь аенда шагыйрь Зыя Мансурның тууына 80 ел тулды. Ул 1916 елны Башкортстанның Дүртөйле районы Җитембәк авылында дөньяга килгән. 1937 елда урта мәктәпне тәмамлауга, үзенең хезмәт юлын башлаган: район газетында башта корректор, аннары әдәби хезмәткәр булган. 1939 елда Зыя Мансур армия сафларына алына, Бөек Ватан сугышы башлангач, хәрби пехота мәктәбенә җибәрелә, 1942 елның башыннан алып сугыш беткәнче яу кырында була, яралана, батырлыклары өчен орден-медальләр белән бүләкләнә.

Бөек Ватан сугышыннан җиңүче булып туган якларына кайткан Зыя Мансур 1946—1949 елларда Дүртөйледә радиотапшырулар дикторы, Илештә район мәдәният йорты директоры вазифаларын башкара. Әмма шигъри каләмен сугыш кырларында ук тибрәтә башлаган яшь шагыйрьнең татарның Мәккәсе булган Казанга киләсе, югары белем аласы килә. Ул, якты хыяллар белән рухланып, 1949 елда Казан дәүләт университетына укырга керә. Әмма сугыш яралары үзенекен итә — сәламәтлеге начараю сәбәпле, Зыя Мансур ике елдан соң укуын ташларга мәҗбүр була. Шуннан соң ул Татарстан радиосында әдәби тапшырулар мөхәррире, 1953—1955 елларда «Чаян» журналында әдәби хезмәткәр булып эшли. Тик сәламәтлеге нык какшаган шагыйрьгә рәхәтләнеп иркенләп эшләргә туры килми. Ул 1956 елдан өендә әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә башлый.

Шагыйрь Әхмәт Фәйзинең:

Шулай, Зыя, мактанырлык түгел —
Үпкәләрне, үләт тигере,
Гармун күреге кебек, теләгәнчә
Сузып булмый инде киереп.
Тик шагыйрьнең үпкәсендә бетсә,
Җырларында — сулыш запасы.
Дүрт юл шигырь язсаң, дүрт көн шуны
Рәхәтләнеп сулап ятасың...—

дигән шигъри юллары Зыя Мансурның һәм физик, һәм рухи халәтен ачык сурәтләп бирә.

«Җырларында сулыш запасы»ның чикләнгән булуын яхшы аңлаган фронтовик шагыйрь, каты авыру булуына карамастан, күп эшли, күп яза. Әле универ-

ситетта укыганда ук, 1950 елда аның «Язгы ташкыннар» исемле тәүге шигырьләр китабы дөнья күрсә, алга таба ул ел аралаш диярлек яңа китап бирә килә. Зыя Мансур үзенең ун китабын исән чагында чыгарып өлгерә, «Этаплар китабы» исемле сайланма әсәрләре җыентыгын да үзе төзеп калдыра, әмма ул китап шагыйрьнең вафатыннан соң гына — 1966 елда нәшер ителә.




Татар язучыларыннан бер төркем мәшһүр сынчы Бакый Урманче ясаган Тукай бюсты янында. *Сулдан уңга:* Әхмәт Исхак, Гали Хуҗи, **Зыя Мансур**, Илдар Юзиев, Нурихан Фәттах, Мәҗит Рафиков, Мирсәй Әмир, Бакый Урманче, Нур Гайсин, Сибгат Хәким, Нури Арслан, Галимҗан Латыйп, Нәби Дәүли, Салих Баттал, Габдрахман Әпсәләмов, Исмәгыйл Рәми.

*25 апрель. 1964 ел.*

Зыя Мансур, беренче нәүбәттә, лирик шагыйрь иде. Аның шигырьләре халыкчан гади, табигый, кешелекле, саф һәм якты хисле булыр иде. Каты авыруына карамастан, ул күңел төшенкелегенә бирелмәде, тормышны сөеп, янып яшәде. Зыя Мансур юмор-сатира өлкәсендә дә көчле шагыйрь булды: һәртөрле карьеристлар, бюрократ түрәләр, ришвәтчеләр, мактанчык бушбугазлар һ. б.— аның сатира уты шуларны көйдерә, шуларны фаш итә килде. Жанр ягыннан ул мәсәл, памфлет, пародия, эпиграмма һ. б. формаларны мул файдаланып иҗат итте. Шулай ук Зыя Мансур балалар өчен язуны да кирәк санады. Аның «Омтылу» (1951), «Озын колак баласы Елак-Мылак» (1955) кебек китапларындагы әкият-поэмалары әле хәзер дә яратып укылалар.

1955 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы Зыя Мансур 1965 елның ноябрендә Казанда вафат булды.

Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәкимнең Зыя Мансур иҗатына биргән бәяләмәсе гаять төгәл һәм ихлас: «Зыя Мансур шигырьләрен никтер бөтнек чәчәкләре белән чагыштырасы килә. Алар да артык күзгә бәрелмиләр, кайдадыр читтәрәк үсеп утыралар, таптыңмы — тиз генә аерыла алмыйсың»,— дигән иде ул.

Журналыбыз битләрендә шагыйрь Зыя Мансурның әнә шул «бөтнек чәчәкләре» шикелле, «тиз генә аерыла алмаслык» шигырьләреннән кайбер үрнәкләрне укучыларыбызга да тәкъдим итәбез.

**Марс ШАБАЕВ**

## Зыя Мансур

### Гомер юлында

Гомернең озынын
Теләми кем генә?!
Бик якын бу уйлар
Минем дә күңелемә.

Чыннан да, кызык бит,
Кем яшәп туйган, дим.
Ә кайчак сискәнеп,
Сагаеп куям мин.

Баса да каршыма,
Сүз куша намусым:
— Яшәүнең син һаман
Дәвамын карыйсың.
Тик менә гомереңнең,—
Әйт әле, дус кеше,—
Мәгънәле үтәме
Яшәлгән тиклесе?

*1960*

### Җылы сүз

Әйбәт кенә барган җирдән
Туктады ник бу атым?
Куам, бармый, сугам, бармый,
Инде ничек кузгатыйм?
Әллә үзем җигелимме
Каһәр төшкән арбага?
Килде күршем: «Куй әле, ди,
Атыңны гел каргама.

Сөй башыннан, гөлкәем, дип,
Син үзең дә кайвакыт
Бер җылы сүз ишетергә
Торасың ич җан атып!..»

*1962*

### Кайгы килгәндә

Көн күрәм, гомер сөрәм мин,
Уйланам, җырлыйм, көләм...
Кайвакыт тели кайгы да
Уйнарга минем белән.
Атлана менеп җилкәгә,
Мин көләм, һаман көләм.

Кайгыны чөнки җиңәргә
Мөмкин тик шатлык белән.
Ул кайчан һөҗүм итсә дә,
Көләм мин, һаман көләм.
Ул тая: ахры, борчаклар
Пешмәс, дип, моның белән...

*1963*

## Күңел

Ул гашыйк яшьлек ягына,
Ят аңа бүтән тараф.
Дәрт ала, илһам ала ул,
Юл яра һаман әнә шул
Гыйшыкның алтын учагы
Балкыган якка карап!

*1963*

## Шагыйрь дустыма

Көчле булсын дисәң җырда сүзне әгәр,
Тикшер аны энәсеннән җебенә кадәр.
Алып кара, борып кара, җуеп кара,
Бер чүп үлән түгелме ул, йөзе кара.
Җилгәр, җаным, алай булса, торма карап,
Дөньяда бит болай да күп әрәмтамак!..

*1963*

## Авырганда

Тәндә тулы кан юк әле,
Бит очымда алым да юк.
Кулымдагы гәзит төшсә,
Иелеп алыр хәлем дә юк.
Сагынып кына искә алам
Ташып торган чагын көчнең.
Мин кеше ич, шулай мәлҗеп
Ятумыни минем эшем?!
Ә бит әнә күршем минем
Күкрәк киереп утын яра.
Эх, аннан да бәхетлерәк
Кем бар икән бу дөньяда!..

*1963*

## Әйтте Хәйям...

Әйтте Хәйям: ни мәгънә бар
Яшәү дигән вәсвәсәдән? —
Чебен кебек безлисең дә
Җан бирәсең, һәм — вәссәлам...
Ә бит Хәйям, ялгышмасам,
Туган моннан мең ел элек.
Ах, нинди шәп булыр иде,
«Чебен» булсаң шуның кебек!..

*1964*

# УРМАН ШАВЫ

Бала чагым. Әдәби китапларның кулдан төшмәгән вакыты. «Пионер каләме» (хәзер «Ялкын» исеме белән чыга) журналы, «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газитен түземсезлек белән көтеп алам. Анда Шәрәф Мөдәррис белән Зәки Нури шигырьләре күп басыла. Язганнары исемдә калган дип әйтә алмыйм. Шигырьнең тәмен белеп, хискә бирелеп уку яшендә түгелмен әле. Вакыйгаларга корылган күләмле проза әсәрләрен күбрәк яратам. Мина Мөдәррисов фамилиясе ошый. Безнең як кешеләрендә булмаган әллә нинди ят, матур, серле фамилия. Ә Зәки Нури Лубьян урман техникумында укый икән. Шигырьләре астына шулай дип куя. Лубьян безнең авылдан биш-алты чакырым гына. Әтиләр базарына барсалар, «куян күчтәнәче» алып кайталар, җәй көннәрендә безнең кебек бала-чага карчык-корчыкларга ияреп Лубьян урманына җиләккә йөри. Шуларның барсы өстенә бу техникумда минем Хәмзә җизни татар теле һәм әдәбияты укыта бит әле. Шулай булгач Зәки Нури дигән исемгә ничек игътибар итмисең ди инде. Еллар үтәр, бу егетләрнең берсе гомер юлдашым булыр, икенчесе белән озак еллар бер оешмада эшләрбез дип кем уйлаган.

Сугыштан соң Казанның Әмәт тавы астындагы бер бәләкәй урамда яшәп яткан чагыбыз. Көннәрдән бер көнне Шәрәф озын буйлы, казакъкарак охшаган ачык чырайлы яшь бер кеше белән кайтып керде.

— Минем якташ. Чүпрәле мишәре Зәки Нури була ул,— дип, кунагы белән таныштырды.

— Шагыйрь Зәки Нури минем дә якташ,— дидем, авызын ерып, елмаеп торган кешегә кул биреп.— Лубьян техникумында укыган егет бит ул.

Без шулай гади генә таныштык. Алар бездән ерак түгел, Спартак урамындагы бер бүлмәле фатирда яшиләр икән. Шунда ике яшь бала уйнап йөри, еш кына авылдашлары килеп төшә, якташ студентларның юлы өзелми, фронтовик шагыйрьләр Гали Хуҗи, Әнвәр Давыдов, Мөхәммәт Садрилар утырып китә. Унике метрлы бүлмәдә кайчагында утырып торыр урын да булмый. Ә хуҗаларның һәркемгә ишеге ачык, йөзләре якты була. Бу кадәр ыгы-зыгыда, шундый кысынкылыкта ничек яза ала икән бу Зәки дип гаҗәпләнә идем мин. Матбугатта шигырьләре һәм төрле телләрдән тәрҗемәләре гел чыгып тора. Хәтта сугыш беткән елны ук «Шигырьләр» дигән китабы да басылып чыкты. Күп еллар үтеп, Зәкине якыннанрак белә башлагач, холкына төшенеп, эш алымнарын күргәч кенә аңладым: партизан тормышының кырыс һәм хәвефле шартларында, үлем белән күзгә күз очрашкан мизгелләрдә гомернең кадерен белергә, бер генә минутны да заяга үткәрмәскә өйрәнгән икән бит ул. Ыгы-зыгылы тормышта үзен эчке бер тәртипкә буйсынырга мәҗбүр иткән, әнә шул тыйнаклык, аерым җайлы вакыт көтмичә, һәрдаим иҗат итәргә әйдәячәк.

Бу гаиләнең «Нух пәйгамбәр көймәсендә» кебек тормышын Зәкинең Мәскәүдә гаиләсе белән яшәп укыган вакытында да күрдем. Гомерен иҗатка багышларга җыенган кешеләрнең сугыш елларында бүленеп торган укуларын дәвам итәргә, югары белем алырга омтылган еллары була ул. Безнең республикадан гына да, бер үк елларда дип әйтерлек, Шәрәф Мөдәррис, Ринат Суфиев (укучыларга Роман Солнцев исеме белән билгеле), Әдип Маликов М. Горький исемендәге әдәбият институтында читтән торып укыдылар. Зәки Нури шул институтның ике еллык Югары курсларында белем алды. Яшьләрдән Рәшит Гәрәй белән Габделхәй Сабитов та әдәбият институтының шәкертләре иде. Бер җәйне, Шәрәф сессиягә килгәч, Зәкинең хәлен белеп чыгарга дип Тверской бульвардагы институт тулай торагына киттек. Зәки әле укудан кайтмаган иде. Хатыны Валентина Дмитриевна безне ачык йөз белән каршы алды. Зәңгәр күзле, җитен чәчле

Валя партизан отрядының элемтәчесе була. Татар егете белән белорус кызының мәхәббәте шунда туа, чәчләре чәчкә шунда бәйләнә. Ирен өзелеп сөйгән кыз татарча сөйләшергә өйрәнә, кайнатасы белән кайнанасын, Зәкинең күп санлы туганнарын эчкерсез якын итә. Тормышның бар мәшәкатен ире белән уртак күтәрергә, хәләле кайда эшләсә шунда яшәргә сүзсез риза була. Мәскәүдә дә Зәкигә иҗат шартлары тудырырга тырышуын, хәтта аның дусларына да туганнарча җылы карашын тоярга мөмкин иде.



Шагыйрь Зәки Нури. Рәссам Ягъфәр Булатов эше. *Июль, 1972 ел.*

Биеклеге биш метрлы шактый зур бүлмәдә яшиләр иде алар. Югарыда иркен генә антресоль игътибарымны тартып:

— Анда малайлар йоклыйдыр инде? — дип сорадым.

— Ул безнең кунак бүлмәсе. Килгән кешене шунда урнаштырабыз, — диде Валя, уенын-чынын бер итеп.

— Шулай күп киләләрмени?

— Мәскәүдә кунакханәләргә керү авыр бит. Барсын да сыендырырга туры килә. Без өйрәнгән инде, кеше килмәсә күңелсез булыр иде.

Шулай сөйләшеп утырган арада Рәшит Гәрәй белән Зәки үзе дә кайтып керде.

— Балалар өйдә юк мени? — диде ул, безнең белән күрешеп хәл-әхвәл белешкәч.

— Җунусов Илдарны алып урамга чыгып китте, — диде хуҗа ханым, өстәл әзерләп йөргән арада.

Зәки күрше бүлмәдән курсташы Хузангайны чакырып керде. Чувашча, татарчалатып күңелле генә сөйләшеп утырганда Илдарны җитәкләп кыргыз шагыйре Камчы Җунусов та кайтып җитте. Барсы да бер институт шәкертләре булганга, сөйләшеп сүзләре бетмәде. Кара төнгә кадәр утырып та вакыт үткәнен сизми калганбыз. Хуҗалар фатирыбызга кайтып йөрмәскә, әлеге антресольдә генә куныП калырга тәкъдим итсәләр дә җәяүләп кенә Лаврушин тыкрыгына кайтып киттек. Төнге Мәскәү урамыннан Зәки белән Рәшит безне шактый ара озатып килделәр.

Кырыгынчы еллар азагы, илленче еллар башы татар әдәбиятының гөрләп үсеп киткән чагы була. Сугыш утыннан исән-имин чыккан язучылар өйләренә

кайтып беткән, хатлар аша гына хәл белешеп торган дус-ишләр бер-берсен кайнар кочакларына алып күрешкәннән соң тынычлап иҗат эшенә утырган вакыт ул. Шәхси хисләр дуслык, туганлык, җир-су, ватанга мәхәббәт, сугышны күралмау мотивларына үрелеп, шигырь һәм поэмаларга, проза әсәрләренә күчкән еллар. Барлык жанрларда да зур җанлану сизелә башлый. Әдәби кичәләрдә, иҗат секцияләрендә яңа әсәрләр укып тикшерелә. Алар шулкадәр җанлы һәм шаушулы булып үтә ки, ут ягып бәхәсләшкән кешеләр инде бер-берсенә сәлам дә бирмәсләр дип уйласаң, икенче көнне үк кул биреп күрешәләр иде. Югары уку йортларында, редакция бүлмәләрендә яшь каләмнәрнең әдәбият түгәрәкләре даими эшләп тора. Тирән тамырлы таза, нык имәннәр ышыгында калкып килгән яшь түйралар кебек, университет, педагогия институты, театр училищесы студентлары көннән-көн кыюрак язалар. Ибраһим Нуруллин, Нурихан Фәттах, Гариф Ахунов, Мәхмүт Хөсәен һ. б. зур әдәбиятка нәкъ шул елларда ныклы адым ясыйлар.

Иҗат атмосферасы әнә шулай шаулап-гөрләп торган чагында, 1949 елның азагында, Тархан леспромхоз директоры шагыйрь Зәки Нури, гаиләсен алып, Казанга күченеп килә һәм «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газитенең редактор ярдәмчесе булып эшли башлый. Газетаның редакторы танылган шагыйрь, фронтовик Гали Хуҗи була. Ул якташы Зәки Нури иҗатын сугышка хәтле үк күзәтеп барган, аңар зур өметләр баглаган кеше. Сугыш елларында күздән югалып торган шагыйрьнең исеме яңадан күренә башлауга, әдәби мохиткә якынайту, иҗат мөмкинлекләрен җайлау максаты белән Зәки Нурины үзе эшләгән газиткә чакырып ала.

Ул елларда ук Зәки әдәбиятта яңа кеше түгел иде инде. Аның иҗатына күренекле каләм ияләре игътибар бирә башлый. Мәсәлән, Фатих Хөсни «Шигырьләр» китабына уңай бәя бирә. Ә без, ул елларда каләм сынап маташкан яшьләр, Фатих аганың мактауга бик саран булуын, бигрәк тә яшь авторларга бәя биргәндә үтә сак килүен белә идек инде. «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналының 1946 елгы бер санында бу китап турында әдип болай дип яза: «Туган илгә, аның байлыгына, гадәт-йолаларына, аның кызларына, язына, зәңгәр төннәренә мәхәббәт һәм, икенче яктан, аның дошманнарына, бигрәк тә канлы вәхшәтләре белән дөньяны чиркандырган немец фашистларына утлы нәфрәт — бу шигырьләрдәге идея».

«Шигырьләр» җыентыгы чын мәгънәсендә ут эчендә туган китап. Сугышчан бурычны үтәп кайткач ял иткән араларда, партизан учаклары янында язылган, беренче тапкыр коралдашларына укылган шигырьләр тупланган аңар. Бу җыентык фронт сызыгы аша үтеп, Казанга кайта һәм 1945 елда Татарстан китап нәшриятында басылып та чыга. Берничә елдан соң күренекле әдәбият галиме Латыйф Җәләй авторның иҗатына: «Зәки Нури иптәш сугыш уты аркылы үтеп, бик күп яңа хисләр, бай кичерешләр алып чыккан кеше»,— дигән бәяләмә бирә. «Үлгәннәр дә үч алды» дигән проза китабындагы сүз башында автор үзе дә: «Урман шалашларында һәм окопларында, походта һәм һөҗүмнәрдә үткәрелгән 1100 көннең сугышчан эшләре һәм уйлары-хисләре бик күп булуын әйтеп тә торасы юк»,— дип яза.

Гомер-гомердән шулай булган: иң хәтәр вакытларда, халыклар язмышы кыл өстендә торганда, Алла сүзе кебек, поэзия ярдәмгә килгән. Адәм чыдамаслык авыр шартларда сынмаска, сыгылмаска ярдәм иткән рухи көчне Зәки дә шигырьләрдән, партизан лагерьларына килеп җиткән шигъри листовкалардан, ялкынлы публицистикадан ала.

«Правда» газитенең 1941 елгы июль санында Белоруссиянең халык шагыйре Янка Купаланың кайнар публицистик мәкаләсе басыла. «Әгәр дошман бакчабыздан алма өзеп алса, ул аның кулында граната булып шартлар, әгәр дошман бер генә уч ашлыкка кагылса да авыр башаклардан атылып чыккан орлыклар аның өстенә кургаш яңгыры булып коелыр, әгәр дошман салкын чишмәбездән су эчәргә дип килсә, аның суы кибәр» дигән юллар, халыкның ачы нәфрәтен, халык үчен бу кадәр дә дөрес, тирән итеп бирә алган утлы юллар, әле унтугыз яше дә тулмаган, әле сугыш исен рәтләп иснәргә дә өлгермәгән тәҗрибәсез солдатны нык тетрәндерә.

Яшьтәшләре кебек үк, Зәки Нури да сугышны ил чигендә сакта торганда Белоруссиянең Буг елгасы буенда каршылый, беренче бомбалар шартлавын шунда күрә, беренче корбаннар ачысын шунда кичерә. Бу минутларны, бу сәгатьләрне шагыйрь болай сурәтли:

Бу хәтәр көн, хәтта көн түгел — таң...
Безнең өскә бомба ташланды,

Чиктә идек. Тел күтәреп булмый,
Әйтеп булмый: «Сугыш башланды.»
Палаткадан очып чыкты берәү,
Ә берәүләр... чыга алмады.
Нинди афәт килгәнлеген илгә
Шунда гына йөрәк аңлады.

Дошманның әнә шул беренче һөҗүменнән башлап сугыша-сугыша көнчыгышка чигенү, рәхимсез бер бәрелештә чолганышта калу, озак еллар партизанлык итү һәм, ниһаять, җиңү көннәренең шатлыгы — Латыйф Җәләй әйткәнчә, шигърияткә килгән яңа хисләрнең чагылышы була. Шагыйрь үзе дә: «озын була, кан булып ялкынланып яна ул юллар», дип әйткән икән, шул чагында аның ниләр кичергәнен аңлау кыен түгел.

Нык яшеренгән, сугышчан тәртип белән яшәгән партизаннар отрядын чолганыштан чыккан кешеләргә табуы җиңел булмый. Аларны эзләп, атналар, айлар буе йөрергә туры килә. Башы ялы Зәки дә урманда көн үткәрә торгач, Орша шәһәреннән 40—45 км ераклыктагы белорус авылы кырына килеп егыла. Аны башта шул авылның тик тормас бала-чагасы күреп ала. Күрәләр дә зурларга кайтып әйтәләр. Зәки шул авылда дәваланып, хәл җыеп алганнан соң, партизан егетнең ярдәме белән легендар Заслонов җитәкчелегендәге берләшмәнең бер отрядына килеп кушыла. Партизаннар гадәте буенча аңар «Андрей» кушаматы бирәләр.

Зәки-Андрей баштарак дошман эшелоннарын шартлатучылар төркемендә көрәшә. Соңыннан разведка начальнигы була.

Әле сугыш барган елларда Константин Заслонов егетләренең батырлыгын гәүдәләндергән нәфис фильм күрсәткәннәр иде. Һәрберсе документаль дөреслекне сөйли торган эпизодларның берсе әле дә онытылмый. Партизаннар тимер юлга шартлаткыч куялар. Менә поезд килә, дөбердәп үтә башлый. Әмма шартлаткыч эшләми. Фашистларга корал илтүче поездны һич кенә дә уздырып җибәрергә ярамый. Һәм егетләрдән берәү гранаталар бәйләме алып тимер юл полотносына ташлана.



Драматург Хәй Вахит, шагыйрь Хәсән Туфан, шагыйрь Зәки Нури, прозаик Ләбибә Ихсанова һәм прозаик Мирсәй Әмир. 1968 ел.

Шул күренештә сурәтләнгән партизаннарның прототибы якташыбыз шагыйрь Зәки Нури булуы бик ихтимал дип уйлаганга, бервакыт сүз чыгып, шул турыда үзеннән сораганым булды. Ә ул, гади генә итеп, андый хәлләр еш кабатлана иде, дип кенә куйды. Чын сугышны күргән кешеләр ул фаҗигаларны

мөмкин хәтле искә төшермәскә тырышалар иде шул. Тик күңелдәген яшереп булмый. «Шундый еш кабатлана торган хәлләр» турында без шагыйрьнең лирик әсәрләреннән, «Дан юлы», «Урманда утлар» поэмаларыннан һәм «Үлгәннәр дә үч алды» дигән проза китабыннан укып белдек.

Зәки тумыштан оптимист кеше һәм гомеренең ахырына хәтле дөньяны туган ягы имәнлекләре кебек якты, кояшлы итеп күргән, яфрак шавында сихри моң ишеткән, нарат сагызларының тәмле исенә хушланган, авылының йолдызлы зәңгәр күген күтәреп торган биек төтен баганаларына сокланган, ак каеннарга кагылып киткән ирекле җил буласы килү тойгысын кичергән романтик җанлы шагыйрь булып кала алды. Шигырьләре якты моң белән өртелгән, ул юлларда купшы сүзләр, шапырынулар да юк, язмышны каргау, сыкрау-сызлануларны да күрмисең. Бар да сабыр, тыйнак, үз өлешенә тигәнне җиренә җиткереп эшләүче җир кешесенең хисләре генә. Үзе турында да ул гади генә итеп:

Еллар юлына мин бүгенгенең
Артыннан калмаска бастым

дип яза. Аның лирикасында урман образы киң урын алган. Чувашстан җирләренә барып терәлгән Чүпрәле имәнлекләре, Урал тауларына килеп җиткән Лубьян наратлары, язмышы кушып бераз эшләп алган Ерак Көнчыгыш тайгасы, партизан учаклары янган Белорус урманнары, андагы аккош кебек акрын гына йөзеп килгән ак каеннар, ак каен итәгенә өзелеп төшкән агач ботагы — шигъри бизәкләр генә түгел. Җир-ананың мәрхәмәтле көчен сурәтләү чаралары да. Алар кеше язмышы, бигрәк тә шагыйрьнең үз язмышына бәйләнгән. 1942 елда шагыйрь урман образына мөрәҗәгать итеп:

Кара урман, ешлыгына кердек,
Урман безнең туган йорт...

дип язса, инде сугыш бетеп, кешеләр иҗади, тыныч тормыш белән яшәгән вакытта:

Олы юлга чыксам — синнән
Китәм кебек кузгалып.

дип әйтә. Бу юлларны укыгач, ерак сәфәргә чыккан кеше һәм туган йортының капка төбеннән аны озатып калган мәрхәмәтле ананы күз алдына китерү кыен түгелдер. Сугышның соңгы сәгатьләрен автор урман белән бәйләп:

Мине бүген бомба шартлап түгел,
Сандугачлар сайрап уятты —

дип җырлый.

Инде шунысын да әйтик, хәтта үзенең физик таза, нык булып үсүен дә урман табигате белән бәйли:

Буйларым шуңа озындыр —
Урманга карап үстем.

Хәер, шагыйрьнең буе гына түгел, холкы да урман кебек киң, тыныч, сабыр һәм азрак кына серле дә кебек иде. Коралдашлары да аны тәвәккәл, кыю, гадәттән тыш зирәк һәм дуслыкның кадерен белгәне өчен (аңа бирелгән характеристикадан) яратканнар бит. Зәки гомере буе кешелекле, ярдәмчел, эшчән, тынгысыз булды. Җитәкчелекнең урта звеносында торып, җаваплы һәм күп көч куя торган эшләрне зарланмыйча, яратып эшли иде. Артык югарыга үрелмәде, җиңел эш, төшемле урын эзләмәде. Югыйсә дуслары гаять күп, берәр иҗат йортына барасыңмы, ерак республикаларда командировкаларда буласыңмы, Казаннан килгәнеңне белсәләр, «безнең Зәки ничек яши анда», — дип сорыйлар. Яратып, «безнең» дип әйтәләр. Инде китәр вакыт җиткәч, Зәкигә сәлам әйтегез, дип озаталар иде. Үз мәнфәгатен кайгыртучы берәү булса, шул дусларының җилкәсенә басып, баш әйләнгеч югарылыкка да күтәрелә алган булыр иде. Ләкин ул каләмдәшләре белән бергә яшәүне ярата төште. Зур кабинетларда түрә булып утырудан Татарстан китап нәшриятының балалар әдәбияты редакциясендә мөдир булуны артыграк күрде. Үзе дә нәниләр өчен күп кенә шигырьләр язды. Урман хозурлыгын сурәтләгән «Безнең яшел дустыбыз» китабын, «Син мәктәпкә йөрисеңме», «Аңлатыгыз миңа», «Табышмак әйтешү» кебек күңелле җыентыклар

бирде. Шулар өстенә төрле теллардән иң яхшы әсәрләрне тәрҗемә итеп, балаларны сөендерде. «Казан утлары» журналына баш редактор булып килгәч тә «Нәниләргә укыгыз» дигән рубрика ачып, һәр сан саен нәниләр өчен шигырьләр, хикәяләр әзерләүне таләп итә иде.

Әдәбият галимнәре шагыйрьнең иҗатын лирика, балалар әдәбияты һәм сатира әсәрләре дип, өч жанрга бүлеп карыйлар. Сүзгә тапкыр, шаян, иптәшләре хозурында мәзәк сөйләү, сүз уйнату осталыгына ия булган Зәкинең үзе «Чәнечкеле юллар»дип атаган сатира әсәрләре дә үткен, тәбәлгән җиренә барып тиярдәй булдылар.

Аның яратып, бөтен көчен биреп эшләгән тагын бер эш урыны — Язучылар союзы идарәсенең җаваплы сәркатибе вазифасы булды. Мондый тынгысыз, күп тармаклы, зур оештыру сәләте һәм житезлек сораган эштә ул үзен киң диңгездә йөзгән кораб кебек хис итә иде.

Ул елларда Татарстан язучылары күп республикалар белән элемтәдә яшәде. Казанга дөньяның атаклы язучылары Жорж Амаду, Джанни Родари килде. Олы әдипләрдән Рәсүл Гамзатов, Берды Кербабаев, Зөлфия, Габидин Мостафин һ. б. булды. Казакъ, кыргыз, үзбәк, әзәрбайҗан, башкорт, чуваш язучыларының әдәби атналыклары шаулап узды. Татарстан язучылары үзләре дә ул республикаларда кадерле кунак иде. Балалар әдәбияты, тәрҗемә мәсьәләләре, китап графикасына багышланган зур җыелышлар РСФСРның күренекле язучылар катнашында Казанда уздырылды. Шулар өстенә ике-өч ел саен үтеп торган яшь язучылар конференцияләре, дүрт елга бер чакырылган съездларның һәркайсы Зәкинең оештыру эшләренә осталыгы, көче, житезлеге аркасында уңышлы үтәләр иде.

Сәркатипнең эш бүлмәсен фронт сызыгындагы хәрби штаб кебек итеп күрә идем мин. Бәләкәй генә бүлмәнең ишеге, кайчан карама, төбенә кадәр ачык булыр. Ишеккә каршы куелган өстәл артында озын буе белән калкынып Зәки утырыр. Сәлам бирмичә, бер-ике генә булса да сүз алышмыйча узып китү мөмкин түгел. Кайчагында аның янына берьюлы ике-өч кеше килеп керә. Йомышлары да булмый үзләренең. Стена буена тезелгән урындыкларда үзара әкрен генә сөйләшеп утыралар. Эше муеннан булган сәркатип исә аларны күрми дә, ишетми дә. Нидер яза, нәрсәдер укый, шул арада көлеп-шаярып кына телефоннан сөйләшеп ала. Җитди генә мәсьәләләрне дә шулай җайлы гына хәл итеп куя торган осталыгы бар иде аның. Зәкинең эш һәм ял сәгатьләре бүленеп куелмаган. Ул эшли-эшли ял итә. Ял вакытларында да эше турындагы уйлар башыннан чыгып тормый кебек иде. Язучылар союзының секретарь-машинисткасы Хөршидә Алишеваның: «Зәки ул коридордан бүлмәсенә килә-килә дә ниндидер бер мәсьәләне хәл итеп куя»,— дигәне бар.

Зәки Нуриның:

Теленне талдырып түгел,
Эшең белән дан тарат.
Сине кеше сөйсен дисәң,
Син аны үзең ярат.

—дигән юллары бар. Бу аның яшәү девизы кебек яңгырый. Шагыйрьнең бөтен булмышы шуңар буйсынган.

Белоруссия җирләре дошманнан азат ителгәч, Зәки Орша шәһәр советының председатель урынбасары итеп билгеләнә. Татарстан Язучылар берлегенең председателе булып эшли. СССР һәм РСФСР Язучылар берлеге идарәләренең секретаре һәм әгъзасы да ул. Депутатлык вазифалары һәм күп төрле җәмәгать эшләренә дә вакыт таба. Шул ук вакытта иҗат итүдән дә туктамый. Аның илледән артык китабы дөнья күрә. Әнә шулай тормышны, кешеләрне яраткан-лыктан янып, ялкынланып яшәргә көч таба. Шагыйрьнең тормыш юлдашы Валентина Дмитриевна: «Ул гомере буе кешеләр өчен яшәде»,— дип әйтә икән, монда бик зур хаклык бар.

Зәки инде безнең арабызда юк. Ләкин сагынып сөйләрлек эшләре, яратып укыган китаплары аны онытмый һәм оныттырмас та.

**Ләбибә ИХСАНОВА.**

# ЗӘКИ НУРИ ХАТЛАРЫ

Танылган шагыйрь, ялкынлы публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Зәки Нури Татарстанның Бөек Ватан сугышыннан соңгы еллар поэзиясендә һәм гомумән иҗтимагый-мәдәни тормышында сизелерлек эз калдырган каләм остасы. Быел декабрьдә җөмһүриятебез җәмәгатьчелеге аның җитмеш биш еллыгын билгеләп үткәндә аның белән беренче мәртәбә танышкан, бергә эшләгән, аралашып яшәгән көннәр ихтыярсыздан искә төшә.



Шагыйрь Зәки Нурига ясалган дуслларча шарж.

Кырык алтынчы елның азагында Г. Тукай исемендәге клубта атна саен үткәрелә торган «Әдәби җомга»ларның берсендә фронтовик язучыларның эшче һәм укучы яшьләр белән очрашу кичәсе булды. Сигез ел хәрби флотта хезмәт иткәндә бик сагынылган Казанга яңарак кына кайтып төшкәнгәдер, бу очрашу миңа, зур бәйрәм кебек, бик тантаналы тоелды. Зал тулы халык. Сәхнәдә чал чәчле өлкән язучылар, сугыш елларында үсеп чыккан яшь талантлар. Кайберләре ярым хәрбичә киемнән. Күкрәкләрендә орден һәм медальләр җемелди. Бер-бер артлы трибунага чыгып, һәркайсы сугышта үз башыннан кичкәнне сөйли. Менә кичәне алып баручы Мөхәммәт Садри: «Сүз партизан шагыйрь Зәки Нурига бирелә», дип игълан итте, һәм минем белән янәшә утырган озын буйлы көләч егет трибунага чыгып басты.

Әлегә тикле үзе белән очрашып танышырга туры килмәсә дә, мин газеталардан укып, Зәки Нуриның Бөек Ватан сугышы вакытында дошман тылында Константин Заслонов җитәкчелегендәге атаклы партизаннар берләшмәсендә разведка начальнигы булганлыгын, күп санлы батырлыкларын ишетеп белә идем инде.

Зәкине бөтен зал тын калып тыңлады, сорау бирүчеләр күп булды. Фронтовик язучылар очрашу хөрмәтенә кичерәк кенә чәй мәҗлесе оештырганнар икән. Шагыйрь М. Садри мине Зәки белән шунда таныштырды.

Зәки Нури ул вакытта үзенең төп һөнәре буенча эшли, Тархан урман хуҗалыгында директор иде. Кырык тугызынчы елның азагында ул Казанга күчеп килде һәм байтак еллар дәвамында Татарстан Язучылар союзында җаваплы сәркатип, аннары «Казан утлары» журналында баш мөхәррир, Язучылар союзы идарәсе рәисе булып эшләде. Ә мин Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият редакциясе мөдире. Әдәбият чыгару планнарын бергә киңәшеп төзергә, кулга-кул тотынып эшләргә, хаксызга җәберләнгән авторларның әсәрләрен бюрократ түрәләрдән, күсәк тәнкыйтьчеләрнең тыкшынуларыннан бергәләп якларга туры килә иде. Сугыштан кайткач, пленда булган өчен байтак еллар рәтле эшкә урнаша алмыйча интегеп йөргән шагыйрь Нәби Дәүли, мәсәлән, идарә рәисе З. Нури белән С. Хәким ярдәме нәтиҗәсендә генә әсәрләрен дөньяга чыгара алды.

«Казан утлары» журналында баш мөхәррир, аннары Татарстан Язучылар союзы идарәсе рәисе, шул ук вакытта СССР Язучылар союзы сәркатипләреннән берсе буларак, Зәки Нури үзенә хас киң күңеллелек белән ярдәмгә мохтаҗ каләмдәшләре турында кайгыртучанлык күрсәтә, китап нәшрияты, газета, журнал редакцияләре белән элемтәгә кереп, яшь авторларга әсәрләрен бастыруда

булышлык күрсәтә, Казаннан читтә яшәүче каләм осталары белән хат язышып, тыгыз элемтәдә тора иде. Аның кыска җыйнак хатлары да югарыда телгә алынган күркәм хасиятләре белән сугарылган.

Бу көннәрдә Зәки Нуриның тууына җитмеш биш ел тулу уңае белән әдәбият сөючеләр игътибарына аның миндә сакланган кайбер хатларын тәкъдим итәм.

**Сафа САБИРОВ.**

27-XII-57

Сафа дускай!

Сиңа берьюлы өч нәрсә җибәрәм: 1) Яңа ел белән котлау, 2) Шәкертлегеңне тәбрик итү, 3) бик күп сәлам! Менә сиңа, браток!

Бездә хәлләр искечә, әллә нәрсә кырган юк әле. Әйе, үземнең поэманы («Әйдә дуслашыйк» иде, ә хәзер «Без таныш түгел...» булып калыр ахры) яңадан карап, эшләп чыктым, кичә Горький музеендагы әдәби түгәрәктә укыдык, ярыйсы шикелле. Инде сез, редактор иптәшләр, ни әйтерсез...

Мәскәүнең китапханәләрен актаруың әйбәт, әлбәттә, ләкин бераз бүтән якларын да өйрән башкаланың!

Семинар өчен булган вак-төякне Хөршидә диген шәфкать туташыбыз бүген үк җибәрергә булды, шунда бер ян кесәңә салып куярсың.

Йомышларың булса, яз, үтәрбез.

Хөрмәт белән **Зәки.**

* * *

3-X-60

Хөрмәтле Сафаҗан!

Сиңа бу якларның күксел таулары һәм сирәк булса да шактый кыздыргалаган зур кояшы хәтле сәламнәр җибәрәбез.

Без, союзыбызның нәни генә филиалы (Еники, Ярми һәм мин фәкыйрегез), бергә бер тау башына шәп кенә менеп алдык һәм диңгезгә төкереп кәгазь пычрата бирәбез. Син бу изге эшләрне Идел дулкыннарында чайкалып эшләдең, әлбәттә. Инде өйдәсеңдер дип беләм һәм менә бер йомыш белән борчыйм:

Нажар Нәҗминең Союзга адресланган хаты бирегә килеп юлыкты. Үтенеченең ни икәнен син дә укып бел — ул кайчан да булса чыгару өчен җыентыгына яңа әйберләр өстәүне ачыкламакчы. Минемчә, киләсе елларның берсендә нәни генә булса да бер китап эшләргә кирәк аңа. Үзенә сәлам хат җибәрдем, шигырьләрен җибәрсен дип бер-ике сүз яз инде син дә аңа. Сафа әйтер икәнен белә һәм көтәдер ул.

Мин 20 октябрьләр тирәсендә сезнең аяк асларыгызга кайтып авачакмын.

Хуш. **Зәки.** Ялта.

* * *

19.X-68

Сафа дус!

Бик-бик күп сәламнәр кабул ит һәм бу яклардагы макталган җылыларга кызыкма — яңгырлар коеп, җилләр сызгырып һәм дулкыннар ярсып тора бирәләр. Әмма барыбер куркырлык ук салкын түгел. Суга чумгалаган һәм туңгалаган чаклар да булды. Хәзер без бирегә бөтен бер землячество: хатыны һәм улы белән Галимҗан Латыйп, Сәлимәсе белән Яхин һәм без фәкыйрегез.

Безнең сырхауга биредә климатның үзеннән башка берниндн дәва юк. Ингаляция дигәннәре төчкертә генә... Барыбер юеш һәм салкын октябрь җиңелдә инде, апрельне аяктан егу турында гына кайгыртасы кала.

Укыйсы яңа әйберләр күп булды һәм табылды. Әмирхан абыйның «Вөҗданы» да бирегә килеп китте. Синең «Ленин турында халык иҗаты» китабы әйберләрен дә алып кайтырмын. 26 октябрьдә биредән китәм, Мәскәүдә өч көнлек эш бар, яңа ай башында күрешербез.

Нәби китабына тиешле сүзне язулары бик кыен булды: күпне әйтергә кирәк, ә урын тар, әйтәсе килгән нәрсә шактый булып азаплады. Ниһаять калыпка керде, оешты, һәм Нәбине бөтен яктан күрсәтә алырлык язма булды бугай. Мин аны иҗат портреты итеп күз алдында тоттым һәм шулай аңлашылыр да ул. Бик озын дип курыкмасагыз гына ярар иде. Мәхмүт тә, син дә укып чыкканда тиешле урынга каләм тидерә аласыз, кайткач тагын бергә ачыкларбыз. Нәби үзе дә обязательно укысын һәм ризалыгын әйтсен — биографиядән ялгышлар юкмы һәм тәнкыйтькә ризамы? (Шаяртып әйтү бу).

Зинһар, минем исәпкә 3—4 экземпляр бастыр, миңа икесе кирәк, сакла.
Ихтирам белән **Зәки Нури.**

19-X-68. Кырым. Күктүбә.

* * *

Сафаҗан!

Хатың һәм сәламең өчен рәхмәт. Мин аны адресатларга өләшеп чыктым. Кояшың һәм диңгезең белән котлыйбыз! Мин егермеләреннән соң Мәскәүгә, аннан Ялтага китәм. Октябрь азакларына хәтле шунда булам.

Казанда хәтсез салкын, җил һәм яңгырлар китте. Хикәяң уынчы санда калды. Шәһитне тизрәк эшлә, чөнки уникенче сан озакламыйча производствога төшәргә тиеш.

Менә кичәге «Татарстан»ның әдәби битен укы, Нәби бабаң кемнәрнеңдер бакчасына кара таш аткан.

Сәлам белән Әхмәт Зәкиулла.

10.II.69

* * *

Товарищ Сафа!

Сез суытып һәм «кызлыгын алып» киткән Кара диңгезнең (һәм безнең) чуктин-чук сәламнәрне кабул ит.

Бирелә дә инде икенче атнага аяк басылды. Ләкин бик җилле, салкын, юеш чакка тап булдык. Диңгез дигәнегезнең янына барулары да куркыныч — дулкыннары белән урам асфальтларын ялапмы-ялый. Бәлки, озакламый ачыкланыр. Әхәзер эш күп чак, чыгып йөрүләрнең кирәге дә юк.

Таҗиклар җыентыгының эше бетә. Аңа тышлык эшләргә заказ биреп куйсаң, шәп булыр иде. Орнамент тапсын һәм таҗикча язсын (текстларын терким). Тышлык сүрәтенә таҗикның төп сыйфатын, эшен күрсәткән рәсем кирәген художник Вацлав Зелинский яхшы белә. Ләкин ашыкмыйча, уйлабрак эшләве шарт.



Рәсемдә: беренче рәттә *(сулдан уңга)*: З. Нури, М. Саттаров, З. Хәбибуллин, С. Сабиров, З. Хәйруллина, Г. Ахунов.
Икенче рәттә: Е. Соколова, Ә. Ерикәй, М. Рахманкулова, М. Мозаффаров, Ф. Хөсни.
Өченче рәттә: М. Садри, И. Шакиров, Р. Билалова, Ф. Насретдинов, Һ. Хөсәенова, М. Хөснетдинова, М. Сибгатуллина, С. Вәлиди, С. Хәким. 1959 ел.

Укыйсы әйберләр күп җыелган иде, балалар китабына шигырьләр әзерлим, сайланмага керәсе яңалары булыр. Арыган араларда ял итә-итә дигәндәй «Күңелле китап»ка өстәмәләр җыям. Шундый күп һәм шәпләре бар,— бер кич утырып укырбыз әле, көлеп туймаслык булырга чамалый.

Сездә нинди яңалыклар бар, булырга тора? Буш арада сызгала, мин биредә 23 октябрьгә чаклы булам. Аннары Севастополь, Симферополь аша Мәскәүгә китәргә исәп. Илдарны, бәлки, шунда алып та калырлар.

Мәхмүт минем китапны карап куя алса шәп булыр иде. Кайткач ук утырып очына чыксак, өстән төшә бит.

Вакыйфның миңа җибәрәсе нәрсәләре бар иде, әллә Пермьгә китеп барган инде, хәбәре юк. Белеш һәм исенә төшер әле. Мин аннан менә нәрсәләр көтәм:

1) «Соц. Татарстан»да безнең журналга багышланган сәхифә.

2) Рәисә белән Рәдиф Уфадан алып кайткан «Кызыл таң» сәхифәсе.

3) «Советская Татария»да минем Татьяна Кузовлева тәрҗемә иткән берничә шигырем чыгарга тиеш иде.

Әгәр үзең тапсаң яки Ләбибәдән сорап таптырып, шуларны миңа җибәрә алмассыңмы.

Үзеңә һәм егетләр-кызларга бик күп сәлам.

**Әхмәт Зәкиулла.**

7.X.70. Ялта.

* * *

Әхмәтсафа һәм аның К° кайнар сәламнәр юллыйбыз.

Мин Киевтә ике көн үткәреп, 18 сентябрьдә Ялтага килеп баш тәрттем. Ике көн бик җылы һәм кояшлы булды, су 23 градуслы иде. Әлбәттә, бик тансыклап чумып та алырга туры килде. Хәзер менә борын йомшарды, ютәл газаплый.

Гариф Гобәй 27 сенә киләм диган. Фатих ага Күктүбәгә киткән икән, аннан хат һәм китап җибәргән. Биредә Уфадан Атнабай һәм Муса Гали бар, үзбәкләр күп.

Украиннар китабын үзем кайткач кына бирергә туры килер, ахры. Чөнки алар исемлекне бик җентекләп карадылар, һәм бик күп яңа исемнәр өстәлде. Украин булмаган бер генә шагыйрьне дә кертмәскә диделәр. Алар урынына 7—8 яңа автор өстәргә туры килә. Аларны исә эшлисе бар, биредә очына чыгачакмын. Бөтен материаллар да бар. Мәкальләр-әйтемнәрне мин кайтканчы укытып куйсаң, әйбәт булыр иде. Быел иртәрәк өстән төшерү хәерле. Киләсе елга яңа һәм мәшәкатьле эшләр күп булачак.

«Соц. Татарстан» газетасында минем җыелышта сөйләгән чыгышым басылырга тиеш иде. Шул чыкса, бер газета табып салырсың әле.

Минем «Еллар һәм юллар» күренмиме? Әгәр чыкса, хәбәр итәрсең, бәлки.

Тагын сәлам белән **Әхмәт Зәкиулла.**

23-IV-71.



# ҮЗЕМ ТУРЫНДА ҮЗЕМ

Хатын-кызны әйтәм, бер белмәгән нәрсәсе юк! Әле менә бүген дә карап-карап торды да: «И-и җаныем, быел сиңа алтмыш тула түгелме соң инде?!» — диде. Ни сөйлисең, мин әйтәм, нинди алтмыш ди әле?!

Бәхәсләшеп киттек. Шунда ул кайчан өйләнешкәнебезне, кызларыбыз Гөлзадә белән Светлананың кайчан тууларын, кайчан кияүгә чыгуларын, оныкларыбыз Руслан, Илдар һәм Данисларга ничә яшь тулуын тезеп китмәсенме! Боларның барысын да кайдан белә ул, дип, тераллем дә каттым! Ахырда паспортымны алып килеп күрсәтте (Аның кайда ятканын да төгәл белә икән!) Карасам, паспортка дөрес язган булсалар, чыннан да, 60 тулып ята икән. Ә мин әле һаман 40 кына тула дип йөри идем...

Белмим, кая ашыгадыр бу гомер? Әле кайчан гына Донбасста туып, 8 ай тулгач, әти-әнине җитәкләп, Балык Бистәсенең Иске Арыш авылына кайтып төшкән идем. Шунда дүрт ел, аннары Балыклы Чүкәйдә өч ел, соңыннан Олы Солтан урта мәктәбендә өч ел укып йөрүләрем дә кичә генә шикелле тоела иде.

Аннары — Казан, ике ел техник училищеда гыйлем өстәп, тәзүче мастер булып чыгуыма да күптән түгел сыман. Хәер, узган гомер гел эш белән үткәнгә генә тоелмаган икән бит, шайтан алгыры! Ни әйтсәң дә, 35 ел төзелешкә бирелгән! Мин бит Казан төзүче-инженерлар институтын да эшли-эшли укып бетердем.

Ә ял көннәрем вак-төяк юмореска, шаян һәм сатирик хикәяләр язып узды. Шаян булмаган хикәя, повестьлар да язып карадым. Алары «Язларында ялгыз йөрсәң...», «Онытылган вәгъдә» дигән китапларымда урын алдылар. Ә менә көлкеле, шаян әйберләрне шактый язсам да, әлегә бер генә андый китабым да юк — дөньясы асты-өскә килгәнгәме, өч җыентыгым, һаман да дөнья күрә алмыйча, нәшрият киштәләрендә тузан җыеп ята, укучыларга барып ирешә алмый...

Хатынның бер белмәгәне юк, дигән идем. Шулай булгач, аның сүзләренә ышанырга туры килә инде: миңа чынлап та 60 яшь туладыр, җәмәгать! Үзем ышанган кебек, сез дә шуңа ышансагыз, чын күңелдән котлауларыгыз өчен чын күңелдән рәхмәт!

Ә хәзер укучыларыма туган көнем бүләге — ике көлкеле хикәямне тәкъдим итәм. Укыгыз, көлегез, көләсегез килмәсә, һич булмаса, елмаегыз: ни әйтсәгез дә, миңа 60 яшь тула бит...

Әхәт САФИУЛЛИН.

**РЕДАКЦИЯДӘН.** Әхәт Сафиуллинның алдан ук әйтеп куйган рәхмәт сүзләренә җавап итеп, без аны, әлбәттә, 60 яшьлек гомер бәйрәме белән котлыйбыз һәм иҗатында елмаюдан көлә-көлә әдәбият сөючеләргә файда китерерлек яңа хикәяләр язуын теләп калабыз.

# ГАҖӘП СЕРЛӘР

Дөнья дигәнең бигрәк гаҗәп нәрсә инде. Башың чатнаганчы уйланып йөрсәң дә, аның серләренә төшенә торган түгел.

Менә кешене маймылдан барлыкка килгән, диләр. Уйланырлык нәрсә бит, ә?! Бер тамаклары аркасында маймыл башларын уйлатып, кулларына, ягъни алгы аякларына таяк алып, агачтан җимеш бәреп төшерә-төшерә әйләнгән икән алар кешегә. Тик белмим, нишләп аларны бәреп төшерергә кирәк булгандыр?! Әллә агач башына менеп ашарга иренгәннәрме, әллә шулай кызыграк тоелдымы икән аларга?! Ничек кенә булмасын, хезмәт маймылны кешегә әйләндергән. Дөрестән дә, мөгаен, тамагың ачса, кулыңа (бу очракта, алгы аягыңа, дип аңларга кирәктер) таяк түгел, әллә нәрсә алып, әллә нәрсәгә һәм әллә нәрсә белән сугарсың! Монысы аңлашыла да шикелле. Тик менә нәрсәсе гаҗәп: алар тора-бара маймылча гына аңлаша алмадылар микәнни?! Телләр ничек һәм нигә килеп чыккан?!

Әллә аларга тел бер-берсеннән таяк сорап торырга кирәк булдымы икән?.. Әйтик, бер маймыл агач башында бик тәмле җимеш күргән, тик аны җиргә бәреп төшерергә таягы юк, ди. Ә шул ук вакытта икенче бер маймыл таягын кочаклап, әле генә бәреп төшергән җимешләре белән сыйланып, рәхәтләнеп йоклап ук киткән, ди. Таяксызына нишләргә? Ул икенчесе янына килә дә, аны уятып, маймыл теле белән: «Кая, таягыңны биреп тор әле, әнә теге җимешләрне генә бәреп төшерәм, хәзер үк китереп бирәм»,— дип, тегесеннән таяк сорый. Ләкин маймылның икенчесе, үзенең йокысын бүлдерүенә ачуы чыгып, таягын күкрәгенә тагын да кысарак төшә, бирми, үзеңнекен булдырырга кирәк, дип, башка сүз куертасы килмичә, икенче ягына ук борылып ята. Ачның ачуы яман, ди, шуңа күрә таяк сорап килгән маймылның үз ачуын белдерергә хәзергәчә аңлаша торган маймыллар теле генә аз була, ә ул аны тегесе гомергә дә оныта алмаслык итеп белгертәсе килә. Шуннан ул, нишләргә белмичә, кычкырып җибәрә. Бу маймыл теле булмый инде! Аның ни дип кычкырганын хәзер төгәл генә әйтеп булмаса да, моның кешелек тарихы башындагы иң беренче сүз булуы турында фараз итәргә генә кала...

Хәер, икенче төрле дә килеп чыгуы бар. Бәлки, иң беренче сүзне үзенең йокысын бүлгәнгә җан ачуы чыккан теге, таягын кочаклап яткан маймыл әйткәндер...

Ничек кенә булмасын, шунысы бәхәссез: үсешләренең ниндидер бер этабында маймылларны үзләренең маймыл теле генә канәгатьләндерми башлаган. Аннары, вакытлар үтә торгач, маймыллар ел саен күбрәк эшли торганнар булса кирәк, таякны бик күп селтәгәнгә күрә, аларның алгы аяклары кулга әйләнгән, ышкыла-ышкыла, уч төпләрендәге йоннар бөтенләй беткән... Алар кешегә әйләнә барган саен бер-беренә әйтәсе килгән сүзләре, фикерләре дә күбәйгән. Һәм гасырлар артыннан гасырлар үтә торгач, алар тәмам чын кешегә әйләнгәннәр, сүгенергә өйрәнгәннәр һәм тора-бара аларның аңнары «революция», «плюрализм», «конверсия», «приватизация» дигән сүзләрне уйлап чыгарыр дәрәҗәгә тикле үскәннәр!

И-и, уйлый башласаң, һич очына-кырыена чыгарлык түгел бу дөнья серләренең! Күпме уйлансаң, шул кадәр сорау туып тора. Мин үзем, шулай уйлана-уйлана, кайчак төн йокыларымны йоклый алмый ятам... Чыннан да, гаҗәп бит! Әйтик, иң беренче маймыл нинди телдә кычкырган?! Урысчамы, татарчамы, инглизчәме? Телләр нигә шулай күп төрле? Хәер, монысына җавап та табып була шикелле... Әйтик, кулларына таяк тотып эшләгән маймыллар урысча, ә бамбук тотып эшләгәннәре японча сөйләшә башлаган булырга тиеш... Хәер, эш анда да түгел, монда тагын бик кызыклы бер сорау туа: нишләп хәзерге маймыллар кешегә әверелмиләр?! Нәрсә, алар хәзер таяк кулланмыйлармы? Хезмәт белән шөгыль-

ләнүдән туктаганнармы? Алайса, аларга кем ашарга әзерли, кем ашата? Кеше маймылдан килеп чыккан икән, елына ничәдер миллион маймыл кешеләр сафына басарга тиеш түгелме соң?! Менә шунысын һич аңлый алмыйм. Ул гына да түгел, хәзер нигә кире процесс бара? Ягъни ник үзебез яңадан маймылларга әверелә башладык?! Юк, көнен-төнен уйлансам да, минем баш кына җитми моңарга...

Күптән түгел генә бер китап укыдым. Гаҗәп китап, мин сиңа әйтим! Укыдым да шул китапны, башымда тагын сораулар өере купты. Әйтик, беренче булып «секс» сүзен кем әйткән?! Маймыл башына килгәнме ул, әллә инде маймыл кешегә әверелгәч, кеше башынамы? Язылганнарны укыгач, үлгән кешене дә торгызып утырырга мәҗбүр итә торган рәсемнәрен карагач, монда маймылның да, кешенең дә катнашы барын аңлыйсың. Хатын белән берни белмичә без дә яшибез икән дөньяда... Гомер буе үзебезчә генә... Хәтта мин борынгы бабаларымны да кызганып куйдым: дөньяда «секс» дигән нәрсә һәм аның кырыкмаса-кырык төре барын белмичә үлеп киткәннәр бит, мәрхүмнәр... Чөнки ул чакларда мондый нәрсәләр булмаган да булмаган инде. Гаҗәп, әбиләр белән ничек яшәде икән алар?!

Әй, уйлый башласаң, безнең тормышта уйланырлык нәрсәләр бик күп анысы. Менә үзгәртеп кору дигән нәрсәне генә алыйк...

Әле моңарчы ни төзүебезне дә белмичә шаккатып торганда, нәрсәне үзгәртеп торырга тотындык соң без?! Өебездән дуңгыз абзары ясап маташабызмы, әллә дуңгыз абзары нигезенә өй салырга уйладыкмы? Алай булса, йортның нигезе өчен дуңгыз абзарыныкы ярамый түгелме соң?! Әллә яшәгән йортыбызны бүтән җиргә күчереп салырга уйлыйбызмы? Ул чагында, нишләп җимереп аттык соң без аны?! Башта бүрәнәләрен тамгалап куярга кирәк түгел идеме? Безнең авыл картлары күчерәсе йортның бүрәнәләрен башта шулай тамгалап куярлар иде дә, шуның буенча икенче җирдә бик ансат кына җыеп та куялар иде. Черек бүрәнәләрен генә алыштыралар иде... Әллә, ул иске йорт бүрәнәләре башка кирәк булмас, яңаларыннан салырбыз, дип уйладыкмы? Әгәр шулай икән, ул вакытта нигә урманга барып, андыйлары бармы-юкмы икәнен карап кайтмадык? Булса, нигә кисеп-ташып куймадык? Нигә башта бурасын буратмадык?! Яңасын утыртып куйганчы нигә искесен сүттек тә, нигә хәзер урамда яшибез?!

Уйлана торгач, менә нинди сораулар туа, шайтан алгыры. Бу маймыллар мәсьәләсе генә түгел инде!.. Аларга җавапны аракыга каршы тагын бер Бөек Көрәш кампаниясе оештырып җибәрсәк тә таба алмабыз, мөгаен...

— Менә бу базар икътисады турында да уйлый-уйлый аптырап бетәм. Болай начар нәрсә дә түгел бугай ул. Күршем Галимҗанның тормышын күреп-белә торган кеше буларак, мин шундый нәтиҗәгә киләм. Ул гомере буе завод-фабрика ишекләренең кайсы якка ачылганын да белмәде, чөнки бер җирдә дә, бер көн дә эшләп карамады. Үзен белә башлаганнан бирле базар икътисадына чумды. Элегрәк кесә карагы иде, аннан соң үсте... Әле ул шушы базар икътисадына чумган вакытларда хәзерге академикларыбыз да, Югары Совет та моның ни икәнен белмиләр иде, аңа юл күрсәтүче булмады, ул бу нәрсәгә үз башы белән, үз белдеге белән күчте. Нәрсәдер ала, нәрсәдер сата — мәш килә шул базар һәм базалар тирәсендә, чөнки безнең базар икътисады базалар белән тыгыз бәйләнештә икән...

Дөрес, әллә ниткән сораулар тудыра бу базар һәм базалар икътисады. Әйтик, кибетләрдә исе дә булмаган нәрсәләрне базалардан ничек табып бетерә ул?! Әллә: «Монысы базарда сатар өчен — Галимҗанга!» — дип махсус җибәрәләрме?!

Ничек кенә булмасын, Галимҗанның тормышы түгәрәк, бар җире житешле, җырлап яши ул дөньяда! Димәк, без күчәргә җыенган базар икътисады кешене баета торган нәрсә булып чыга. Тик шунысы бар:

базарда сатар өчен базалардагы әйберләр барыбызга да җитәрме икән соң? Әллә аларны сату эшендә тәҗрибәсе булганнарга гына бирерләрме?

Аптыраган бу сораулардан! Аннары кешеләре дә әллә нәрсәләр сөйли бит аның. Чын булса, базар икътисадына күчүнең бер шарты бар диләр: имеш, анда күчтеңме, кеше беркайда да эшләмәскә тиеш. Сәүдә системасыннан башка җирдә, әлбәттә. Ә завод-фабрикаларда эшләдеңме аягыңны сузасың, ди... Нигә алай икән? Нигә киресенчә түгел? Мөнә шуны аңлый алмыйча җәфаланам. Тормыштан артта калдым, ахрысы. Гомер буе эшли-эшли, иртәгә нәрсә ашарбыз, дип уйлый-уйлый акылга зәгыйфьлек килгәндер, мөгаен...

Менә тагын нәрсә. «Эшләмәгән — ашамый!» диләр. Шул зәгыйфьлек галәмәте булса кирәк, моны да аңлап бетерә алмыйм. Ничек инде ул — ашамый?! Алайса, безнең илнең үгез кебек яшьләре (нишләптер, ир-атлары, дип әйтәсе килә) шушы көнгә кадәр ничек үлеп бетмиләр соң? Хәзер аларның эшләгәннәре йөзгә бер генә ич! Әллә сыраханә ишеге төпләрендә көннәр уздыру аларга эш көненә исәпләнәме? Алай булса, аларга акчасын кем түли? Хәер, сыраның калориясе бик зур диләр, ашамый да түзәрлектер, бәлки...

Ай-яй, гаҗәп нәрсә бу дөнья! Аның хәзерге бер көнендә башка мең төрле сорау килә. Аларга җавап табып бетереп буламы соң?!

## ҖИРЛЕ ВЛАЧ

Унҗиденче елдан бирле: «Бөтен власть — Советларга! Бөтен власть — Советларга!» — дип шау-гөр килеп йөри торгач, власть-ны урыннарга биргәннәр икән, наканис.

Шулай беркөн шул власть кешеләренең берсе минем таксины туктатты. Дөрес, башта мин аны авыр категориядәге көрәшче дип торам. Гәүдәне күрсәң — Гулливер! Ә куллары — көрәк тә көрәк инде. Икенче яктан караганда, власть кешесе икәнлеге дә әллә кайдан күренеп тора: туктавым булды, сорашу юк, сөйләшү юк, министр шикелле лык итеп кердә дә утырды.

«Бу — иң кимендә берәр районның исполком персидәтеле булырга тиеш»,— дип уйлап алдым мин.

Алай да ачу чыкты, чөнки без, таксистлар, мондый кыланышта өйрәнгән халык түгел. Гадәттә, безне ике кулны болгый-болгый туктатырга, аннары, йөгереп килеп, сак кына ишекне ачып, йомшак кына тавыш белән: «Сез буш түгелме?» — дип сорарга кирәк. Буш булсак та, барыргамы, юкмы икәнен без үзебез карыйбыз.

Ачу килсә дә, моның кулларына карадым да, никтер, Ходай саклаганны саклармын дигән, дип уйлап алдым. Һәм теләр-теләмәс кенә:

— Кая барабыз? — дип сорадым.

— Минем эш бик ашыгыч. Әйдә, җелдерт! — диде ул, адресын әйтеп.

Үзе культурный гына кешегә охшаган, ә үзе... Син аңа «сез» дип, ә ул әле кузгалып та китмәс борын, «син»гә дә күчеп өлгерде. Күренеп тора: власть кешесе. Кешене күбесенчә әнә шул власть боза бит инде.

Килеп туктадык. Ул, күтәргә кушып, бер йортка кереп китте. Бераздан аннан үзе шикелле үк тагын бер көрәшчене ияртеп килеп чыкты.

Утырдылар. Бер ресторанга таба юл тоттык. Килеп җиттек. Төштеләр. Керделәр. Аларны анда көтеп торганнар иде, ахрысы, күренүләре булды, каршыларына официант кына түгел, хәтта ресторан директоры үзе йөгереп чыкты. Нишләтергә дә белмиләр.

«Боларның берсе райисполком персидәтеле булса, икенчесе, һичшиксез, рестораннар трестының башлыгы булырга тиеш!» — дип уйлап алдым мин, чөнки алай булмаса, юкка гына шулай бөтерелмәс иде алар.

Ашадылар-эчтеләр. Үзләре ник бер тиен акча түләсеннәр! Алай гынамы соң? Әле чыгып барышлый, үзләре директорга:

— Онытмадыңмы, бу айда син өч кисәк артыграк тиеш! Тормыш кыйммәтләнде,— диделәр.

Мөгаен, сүз дәүләт налогы турында баргандыр, аңлап житкермәдем. Бәлки, бу директорның доходын яшерә торган гадәте булгандыр. Налогны азрак түләр өчен...

— Аңлыйбыз, аңлыйбыз,— дип җавап бирде ул. Бик тиз аңлый торган кеше, ахрысы. Мөгаен, югары белемледер.

Чыгып утырыштык.

— Әйдә, райисполкомга ку! — диде миңа алда утырганы.

«Әһә, чыннан да, райисполком персидәтеле икән шул монысы»,— дип уйлап алдым мин.

— Хәзер соңгы атнада нинди кооперативлар, кече предприятиеләр регистрацияләнгәнен белеп чыгарсың. Тулы информация кирәк! — диде ул үзенең иптәшенә.

Килеп җиттек. Икенчесе беренчесе кушкан информация артыннан кереп китте. Һәм озак та үтмәде, чыгып, машинкада басылган бер бит кәгазьне иптәшенә сузды.

— Молодец! — диде тегесе, кәгазьне караштырып.— Иртәгәдән или башларга кирәк булыр...

«Болар тире иләү белән дә шөгыльләнә, ахрысы,— мин әйтәм.— Әллә боларның берсе мех фабрикасы директорымы югыйсә?»

— Боровое Матюшинога! — диде миңа райисполком персидәтеле дип уйлаганым.— Һәм тизрәк бул!

Нишлисең, шундый зур кешеләрнең теләгән үтәмичә булмый, сыпыртам гына! Алай да канәгать түгел болар, һаман:

— Тизрәк! Тизрәк! — дип, эч пошырып баралар.

— Монда шофер — мин! Кайда һәм ничек барырга икәнен үзем беләм,— дидем ахырда, ачуым килеп.— Күрмисезмени, тизлек чикләнгән. Аннары моның нинди юл икәнен дә беләсез. Монда адым саен диярлек ГАИ постлары тора...

— Курыкма! — диләр.

— Сезгә әйтүе ансат. Штрафын миңа түләргә туры киләчәк бит,— дим.

Шулай дип әйтеп кенә бетердем, алда ГАИ посты күренде.

— Туктама! Тизлекне арттыра төш! — диде миңа райисполком персидәтеле.

— Туктамыйча ярамый. Минем правасыз каласым килми,— дидем мин. Һәм туктадым. Машинадан чыгып, инспектор янына килдем.

— Капитан Сафронов,— ди бу, миңа честь биреп.— Сез тизлекне арттырдыгыз. Ун сум штраф!

«Менә,— дим эчтән генә,— кеше сүзе белән йөрсәң, шулай була ул!» Алай да:

— Юк, мин арттырмадым шикелле... Бәлки, бераз булгандыр да, әлбәттә. Пассажирларым бик ашыга...— дип мыгырдандым.— Беренче юлга кичерә күрегез инде, иптәш капитан!

— Юк, штраф дигәч, штраф! — ди инспектор, үз сүзен итеп. Ул арада минем пассажирлар:

— Тиз буласыңмы син анда? — дип тынычсызлана башладылар.

— Ашыкмасагыз сана!!! — дип кул селтәдем мин.— Менә штраф түләргә кирәк әле...

Шулчак пассажирларым чыгып:

— Син нәрсә права качать итәсең монда, ә капитан? Без бик ашыгабыз. Аңлыйсыңмы син шуны, юкмы? — дип сөйләнә-сөйләнә безнең янга якынлаштылар.— Син нәрсә, безне танымыйсыңмы әллә? Синең күзеңне ачарга кирәк түгелдер бит, козел?!

Күрәм: кинәт капитанның төсе үзгәрде, минем праваны тоткан кулы калтырый башлады.

«Әһә, мин әйтәм, боларның берсе шәһәребезнең ГАИ начальнигы икән! Шуны таныды бугай бу...»

Чыннан да, таныды бугай. Ул тегеләргә елмаеп честь бирде, гафу үтенде, минем акча белән правамны кире кулыма тоттырды. Әле ахырда:

— Зинһар, гафу итәсез! Белмәдем бит... Хәерле юл сезгә! — дип калды.

Егерме ел таксида эшләп, мондый мөлаем милиция офицерын очратканым юк иде әле, валлаһи!

Кузгалып киттек. Туктаган өчен мине бераз шелтәләп тә алдылар болар. Аннары минем турыда онытты‌лар бугай, үзара сүзләрен дәвам иттеләр.

— Аракы мәсьәләсендә нинди информацияләр бар? — дип сорады беренчесе.— Безнең барлыгы кырык әрҗә чамасы гына калган бугай анда...

«И-и, мин әйтәм, нәчальствоның башында һаман кайгы: хәтта таксида барганда да һаман халык турында кайгыртучылары бар икән ләбаса! Ә без еш кына, нәчальствоның бернәрсәдә дә эше юк, дип, сүгәбез».

— Бүген аракы ике ноктага кәтелә. Икесен дә алырбыз дип уйлыйм. Сөйләшенгән, кешеләр, машиналар әзерләнгән,— дип җавап бирде икенчесе.

Ниндидер бер зур дача янына, урман эченә кереп туктадык. Тегеләр төштеләр, хәрәкәтләр ясап, тәннәрен язып алдылар. Аннары тегесе, мин райисполком персидәтеле дип уйлаганы, миңа карап:

— Сиңа түләргә дә кирәктер инде, ә? — дип, миңа мең сумлык акча сузды да: — Сдача кирәкми,— дип өстәде.


Алар дачага кереп киттеләр, ә мин, машинаны бордым да, Казанга таба сызырттым. Кайтышлый капитан миңа честь биреп калды.

Кемнәрне йөрттем мин ул чакта? Әле шушы көнгә кадәр шуны төшенә алганым юк. Соңыннан белдем: райисполком персидәтеле дә, рестораннар трестының башлыгы да, ГАИ начальнигы да бөтенләй башка кешеләр булып чыкты.

Бу турыда эштә дә сөйләп карадым, тик кистереп кенә әйтүче булмады. Би-ик тәҗрибәле Гарифҗан абый гына:

— Җирле влач була инде алар, энем,— дип куйды.

Менә шуңа күрә әйтәм, наканис властьны урыннарга бирделәр бугай...



# ДИНИ БӘЙРӘМНӘРЕБЕЗ ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛЕ КӨННӘР

## (1997 елда)

**Мөселман ай календаре буенча 1417—1418 һиҗри еллар.**

**7-гыйнвар, сишәмбе.** Раштуа (Рождество) бәйрәме.

**10-гыйнвар, җомга.** Изге Рамазан ае һәм ураза башланган көн.

**4-февраль, сишәмбе.** Кадер кичәсе. Бу төндә язмышлар хәл ителә. Бу Төндә Мөхәммәд пәйгамбәргә Корьән Кәрим аятьләре иңә башлый.

**9-февраль, якшәмбе.** Ураза бәйрәме Гайдел-фитыр. Ураза бәйрәме. Ураза тәмамлангач, авыз ачу бәйрәме башлана.


**17-апрель, пәнҗешәмбе.** Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку.

**18-апрель, җомга.** Гайдел Адха, Корбан бәйрәме. Иң зур Мөселман бәйрәме. Бу, ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме. Ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан җөмһүриятендәге барлык календарьләрдә кызыл төс белән билгеләнгән.

**19, 20, 21-апрель, шимбә, якшәмбе, дүшәмбе.** Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә мөселманнар фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы тәгаләне зикер итеп, догалар укыйлар.

**8-май, пәнҗешәмбе.** 1418 ел, Яңа мөселман елы башланган көн. Мөхәррәм ае. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**17-май, шимбә.** Гашура көне. Сөнниләр тарафыннан Аллаһы тәгалә үзенең ун пәйгамбәренә күндергән изгелекләре хөрмәтенә, ә шигыйләр тарафыннан Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы, Гали хәлифәнең улы — имам Хөсәеннең (626—680) җәзалап үтерелүенә багышланган матәм көннәре буларак билгеләп үтелә.



24-май, шимбә. Бабаларыбыз Ислам динен кабул иткән көн.

7-июнь, шимбә. Сәфәр ае башланган көн.

2-июль, чәршәмбе, һиҗрәт көне. Сәфәр аеның 27 көнендә Мөхәммәд пәйгамбәрнең һәм аның сәхабәләренең туган шәһәрләре Мәккәдән (Ясриб) Мәдинә шәһәренә мәҗбүри күчеп киткән, һиҗрәт иткән көне. Шушы төннән, ягъни 622 елның 16 июль төненнән башлап, мөселман ел исәбе, ягъни һиҗри ел исәбе башлана.

18-июль, җомга. Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне — Мәүлид бәйрәме башланган көн. Бу изге бәйрәм бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, Мөхәммәд пәйгамбәр хөрмәтенә җәмәгать намазлары укыла, хәер-садака (зәкят) өләшенә. Күп кенә мөселман илләрендә факеллар һәм фонарьлар кабызып, тантаналы мәрасимнәр уздырыла.

15-октябрь, сишәмбе. Хәтер көне. Казанны саклап каһарманнарча һәлак булган бабаларыбызны искә алу көне.

2-ноябрь, якшәмбе. Мөселман календаренда изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим һәм Гайсә пәйгамбәрләрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаҗ, гомрә хаҗы кылына.

7-ноябрь, җомга. Рәгаиб кичәсе, ягъни, Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдулла һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе.

27-ноябрь, пәнҗешәмбе. Миграҗ бәйрәме. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә — Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Миграҗ уразасы 60 ай яки 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

1-декабрь, дүшәмбе. Шәгъбан ае көне. Дүрт изге айның берсе, мөселман ае календаре буенча, сигезенче ай — Шәгъбан ае башлану көне.

16-декабрь, сишәмбе көн. Бәраәт кичәсе. Бәраәт кичәсе, ягъни ләйләтүл-Бәраәт. Бәхет һәм төрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Бәраәт кичәсендә Аллаһы тәгалә, һәркөннең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышына рәхмәт нурын төшерә.

30-декабрь, сишәмбе. Изге Рамазан ае һәм ураза башланган көн.

Ошбу язманы Абдулла Хаҗи ДУБИН әзерләде.

# 1996 ЕЛДА ЖУРНАЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

«1996 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләген бирү турында». № 6

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Айзатуллин Р. Ирекле тоткыннар. *Роман.* № 3.
Ахунов Г.Тимерханның авыл юллары. *Документаль повесть.* № 6.
Галиев Ә. Җимерелгән хыяллар. *Роман.* №№ 4, 5.
Галиуллин Т. Тәүбә. *Роман.* №№ 1, 2.
Гарипов Р. Кыска хикәяләр. № 12.
Гомәр Г. Мөһер. *Маҗаралы повесть.* № 8.
Вәлиев Р. Фининспектор һәм бабай. *Хикәя.* № 2.
Закир Л. Бүреләр. *Хикәя.* № 7.
Зәйнуллин З. Ат караклары. *Роман.* №№ 11, 12.
Камалов Б. Кыска хикәяләр. № 11.
Мөхәммәдиев Р. Утлы таба өстендә. *Роман.* №№ 5, 6.
Нагыймов Ф. Кыңгырау. *Хикәя.* № 11.
Поварисов С. Яшьлек иртәсе. *Роман.* № 10, 11.
Рәхимов Җ. Әҗәл вагонында. *Хикәя.* № 5.
Фәизов Р. Узган гомер — янган күмер. *Документаль повесть.* № 7.
Хәлим А. Кыйбла. *Хикәя.* № 8.
Яхин Ф. Ахырзаман пәйгамбәре. *Кыйсса.* №№ 8, 9.
Әмирхан М. Дөя муены. *Сатирик повесть.* № 12.

## ШИГЪРИЯТ

Баян Ә. Дога. *Шигырьләр.* № 2.
Габдрәхим Ф. Ватандар хис. *Шигырьләр.* № 5.
Гадел Ә. Сезгә — шигырем шифасы. *Шигырьләр.* № 11.
Гатауллин Г. Дөнья бу. *Шигырьләр.* № 1.
Гаташ Р. Җанның бер сәфәре. *Шигырьләр.* № 2.
Гатина Ф. Хәтер. *Поэма-баллада.* № 8.
Гыйззәтуллина Ф. Яратуым өчен. *Шигырьләр.* № 10.
Гөлнур. Таңда. *Шигырьләр.* № 9.
Зөлфәт. Тәнбоек күз йомган мәлләрдә. *Шигырьләр.* № 7.
Иделбикә. Триптих. *Шигырьләр.* № 10.
Ислам. Н. Ике йолдыз. *Шигырьләр.* № 12.
Иксанова И. Мин. *Шигырьләр.* № 3.
Латыйп К. Сурәтле сүзләр. *Шигырьләр.* № 5.
Мингалим Р. Җизле йөгән, җирән атың... *Шигырьләр.* № 12.
Миншин М. Дүрт җыр. *Шигырьләр.* № 7.
Миңнуллин Р. Җәйне озату. *Шигырьләр.* № 4.
Мулла Гали С. Өметемне өзмәдем. *Шигырьләр.* № 12.
Мәдияров Н. Тынды җилләр. *Шигырьләр.* № 5.
Мәннан Р. Ачы җилләр исә... *Шигырьләр.* № 9.
Низами Р. Мәхәббәт мәрҗаннәре. *Шигырьләр.* № 6.
Нәҗми Н. Минем кулны юасы юк. *Шигырьләр.* № 6.
Рафиков Б. Соң түгел. *Шигырьләр.* № 2.
Рәхимкулова М. Тәнең көчле... *Шигырьләр.* № 9.
Саттар-Мулилле Г. Кемнәр варисы без. *Шигырьләр.* № 9.
Сафина Н. Мәңгелек сер. *Шигырьләр.* № 2.
Сибат Р. Тән-җанның берлеге... *Шигырьләр.* № 7.
Солтан И. Көшел-көшел уй. *Шигырьләр.* № 8.
Сәгадәт К. Җан ярам. *Шигырьләр.* № 10.
Сөләйман Җ. Өмет. *Шигырьләр.* № 9.
Төхбәтуллина Ф. Алмагач. *Шигырьләр.* № 9.
Фәйзуллин Р. Яңа шигырьләр. № 3.
Харрасова Ф. Соңгы пәрдә. *Шигырьләр.* № 12.
Харис Р. Гармунчы. *Поэма.* № 9.
Хаҗиева Ф. Үземне эзләп йөрдем мин. *Шигырьләр.* № 9.
Чанышева Ф. Тыңлагыз, Казан сөйли. *Шигырьләр.* № 9.
Шагыйрьҗан Л. «Игезәкләр» йолдызлыгыннан мин... *Шигырьләр.* № 11.
Шәрипов Р. Моңлы җыр. *Шигырьләр.* № 11.
Шәрипов Ә. Әйләнәм дә кайтам Тукайга. *Шигырьләр.* № 9.
Юзеев И. Ут эчендәге чәчәк. *Шигырьләр.* № 1.
Яруллин Ф. Шушы килеш яратыгыз. *Шигырьләр.* № 1.
Эминева Н. Дустым буласыгыз килсә. *Шигырьләр.* № 8.
Әһлия Ф. Йөрәкнең соңгы кылы. *Шигырьләр.* № 12.
Җамал Р. Галәм очкыны. *Шигырьләр.* № 4.

## ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Камал Ш. Уяну. *Хикәя.* № 10.
Насыйри К. «Кырык бакча»дан. № 10.
Хуҗин М. Әдәбият һәм тормыш чынлыгы. № 10.
Әмир М. Мөстәкыйм карт йокысы. № 10.

## ДРАМАТУРГИЯ

Юзеев И. Гашыйклар тавы. Мәхәббәт кыйссасы. № 7.

## ОСТАХАНӘ

Мирза М. Кыска шигырьләр. № 7.
Мөхәммәтдин Р. Үзем булып калам. *Шигырьләр.* № 6.
Шафикова К. Күз яше. *Шигырьләр.* № 6.

## ӘДӘБИ МИРАС

Гаташ Р. Утыз елдан соң да соң түгел. № 6.
Исламов Р. Мисыр шагыйре Шәриф Амидле. № 3.
Амидле Ш. Газәлләр. № 3.
Ислам З. Әхмәт Фәйзи хатлары. № 6.
Туфан Х. «Нюанслар иле»ндәге шигырьләр турында. № 6.
Әхмәтҗан Рәшит. Соңгы шигырьләреннән. № 4.
Җамалетдин Л. Халык иҗаты үлемсез. № 7.
Баһадиршаһ вә гөмбә хикәясе. № 7.

## КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫННАН

Аксал С. К. Кичке эңгер. *Хикәя.* № 4.
Бу халыкта таулар горурлыгы. М. Мамакаев, Р. Әхмәтова, А. Дудаева, Х. Зибукаев шигырьләре. № 4.
Төрек шагыйрьләре Ю. Әмрә, Ф. Голәң, Г. Вәйсәл, Н. Фазыл, Кысакөрәк, А. Нихат Асъя шигырьләре. № 6.
Хаҗи Әминуглы Н. Нишләргә? *Хикәя.* № 8.

## ПУБЛИЦИСТИКА

Батулла Р. Американы мин ачтым. *Сәяхәтнамә.* № 4.
Без — тормыш театрының артистлары *(җәмәгать эшлеклесе, фольклорчы галим Р. Ягъфәров белән әңгәмә).* № 2.
Борһанов Ә. Кая бара бу Россия? № 6.
Нигъмәтҗанов К. Мин — укытучы. № 12.
Сабиров Н. Мәмдәлләрдә генә утлар яна. № 3.
Салахов И. Хәсрәт төенчекләре. № 5.
Сибат Р. Текә күтәрелеш. *Документаль повесть.* № 2.
Фәтхуллин Н. Россиядә җинаятьчелекне җиңеп булырмы? *(социологик уйланулар).* № 8.
Әхмәтҗан Мәхмүт. Галәм. Мәхәббәт. Ганлә. Балалар. № 3.

## ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

Шәмси С. Галиҗәнаб китап зарлары. № 2.

## КЕШЕ ҺӘМ ХОКУК

Вәгыйзов Р. Татарстанда җинаятьчелеккә каршы көрәш чаралары. № 7.

## АЧЫКТАН-АЧЫК СӨЙЛӘШҮ

«Мәгариф» — биш яшьлек аксакал *(«Мәгариф» нәшрияты директоры Мөдәррис Вәлиев белән әңгәмә).* № 2.

## МӘДӘНИ МИРАС

Исхакый Г. Бугазлар. № 10.
Миңнегулов Х. Нинди төскә керсә дә, асылы бер... № 10.
Әйди Т. Муса Акъегет Төркиядә. № 4.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Вәли М. Каргышлы еллар. № 8.
Галимуллин Ф. Таза орлыклар. № 2.
Гайнетдин М. Татар шәҗәрәләре. № 8.
Нәҗми Н. Шагыйрь гомере. № 8.
Саяпова А. «Кемгә тансык бу замана?» № 8.
Фәтхерахманов Р. Тормыштан килгән геройлар. № 10.
Шабаев М. Сандугач язмышлы шагыйрь. № 5.
Әшрәфҗанов Х. Язучы һәм тарих. № 12.

## ХӘТЕР

Батулла Р. Акчарлакның сагышы. *(Рәйит Әхмәтҗанга мәрсия).* № 1.
Батулла Р. Әбрар Сәгыйди. № 8.
Мөбарәков Т. Мөхәммәт Мәһдиев турында истәлекләрем. № 3.
Мостафин Ш. Әманәткә тугрылык. № 2.
Сафина Н. Ә сүз бирмиләр. № 9.
Харис Р. Тавышсыз җыр. № 6.
Хәмидуллин Л. Ике дәвер кешесе. № 6.
Шабаев М. Сагындыра... *(Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәкимнең вафатына ун ел).* № 7.

## ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

Низамиев Р. Мин дә кеше ләбаса! *Юмореска.* № 9.
Риан Р. Бил кузгалу. *Юмористик хикәя.* № 6.
Сафиуллин Ә. Әллә нишләде бу халык! № 3.

## ӘЗ-МӘЗ ГЕНӘ МӘЗӘК

Маннап Ш. Мәзәкләр. №№ 1, 8.
Нәҗмиев Т. Мәзәк хәлләр. № 5.
Яһудин Ә. Күргәннәр, белгәннәр, ишеткәннәр, баштан кичкәннәр. № 6.

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Алмазова Т. Музыка сүзлеге. № 7.
Вәли М. Сатира батыры. № 4.
Галимуллин Ф. Язмышлар язылганда. № 9.
Лаисов Н. Сибгатуллина Ә. Төркиядән бүләк. № 7.
Поварисов С. Ил йөрәгендә тамырлансын. № 4.
Әхмәтҗанов М. Татар тарихы буенча яңа дәреслек. № 4.

## ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

Т. Галиуллинның «Тәүбә» романына карата укучылар фикере. № 9.

## ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫННАН

Әйди Т. Бу нинди бәйрәм? *(Күренекле тарихчы, Татарстан Фәннәр академиясе академигы Миркасыйм Госманов белән әңгәмә).* № 8.

## МӘДӘНИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Абдуллин Я. Садри Максуди — олуг галим. № 1.
Госманов М. Тагын бер әдәби ачыш. № 10.
Колый М. Берекәннәр сыйфаты. № 10.
Мәрданов Р. Гасый Җафи Мәүла Колый сүзли, дуслар. № 10.

## ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Гариф Н. Борынгы Чаллы. № 3.
Хужин Ф. Борынгы Казан: кичәге һәм бүгенге археологик ачышлар. № 6.
Хәмидуллин Б. Татарларның этник тарихы турында уйланулар. № 4.

## КҮРЕНЕКЛЕ ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

Ибраһимова Ф. Фаҗигале язмыш. № 2.
Малышева С. Фуад Туктаров. № 5.
Солтанбәк Б. Тапталмас исем. № 5.

## ОНЫТЫЛГАН ИСЕМНӘР

Солтанбәк Б. Әскәр Али улы Шәех-Али. № 1.

## ХАЛЫК ИҖАТЫ

Исхакова-Вамба Р. Мишәр татарларының халык җырлары. № 4.

## ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮҢЕЛ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Сирматов И. Бер дәфтәр моң... № 10.

## СӘНГАТЬ

Хәмидуллин И. Игелекле талант. № 11.
Хөсәенов Ш. Газап диңгезен эчеп. № 8.
Әхмәтова-Урманче Ф. Меңнәр арасыннан бер йөз эш. № 11.

## ЮБИЛЕЙЛАР

### Һ. АТЛАСИНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

Алишев С., Галләмов Р. Ут эчендә калган күгәрчен кебек. № 12.

### Г. ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Фәйзуллин Р. Үлемсезлек символы. № 4.
Тукайга чәчәкләр: С. Хәким, М. Львов, Х. Туфан, М. Кәрим, М. Мәүлеков, Ә. Фәйзи, Г. Афзал, Ш. Галиев, Р. Гаташ, М. Әгъләмов шигырьләре. № 4.
Алиева Ә. Тукай гомереннән бер елы. 1912 ел. № 4.
Рәми З. Тукайның ачык һәм яшерен имзалары. № 4.
Низаметдинов Ә. Габдулла Тукайның мәхәббәте. № 4.

### М. ГАЛӘҮНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Даутов Р. Әдипнең фаҗигасе. № 9.

### Ф. ӘМИРХАННЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Бәкхан Ф. Казаннан. № 1.
Укмасый хәтерендә Әмирхан. № 1.
Фатих Әмирхан турында истәлекләр. № 1.
Әмирхан Р. Шомлы еллар кайтавазы. № 1.

### СИРИННЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Мостафин Р. «Кыш сайрамый сандугач...» № 12.

### Һ. ТАКТАШНЫҢ ТУУЫНА 95 ЕЛ

Бәйрәмова Ф. Атылган йолдыз. *Драма.* № 1.

### М. ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Җәлил М. Серле йомгак. *Шигырь.* № 2.
Фәйзуллин Р. Ә горурлык хисе һаман шул... № 2.
Каһарман шагыйрьгә — чәчәкләр: С. Хәким, Н. Нәҗми, М. Дудин, С. Данилов, Җ. Җаббаров, Н. Арслан, И. Юзеев, Зөлфәт шигырьләре. № 2.

### С. САДЫЙКОВАНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Онытылмас олуг зат. *(Г. Бәширов, Г. Зәйнашева, Х. Гайнуллин, Р. Харитонов, З. Сөнгатуллина, Л. Любовский, Р. Исмәгыйлев, Ә. Айдарская, Ә. Хәсәеновларның истәлекләре).* № 11.

### З. НУРИНЫҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ

Ихсанова Л. Урман шавы. № 12.
Зәки Нури хатлары. № 12.

### С. СӨЛӘЙМАНОВАНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Ихсанова Л. Дустымның уң хаты. № 10.
Сөләйманова С. Шигырьләреннән кайбер үрнәкләр. № 10.

Р. РӨКЫЙПОВНЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Гаташ Р. Җыр белән түләнгән әҗәт. № 11.
Рәкыйпов Р. Җыр кайтарам. Шигырьләр. № 11.

«СӨЕМБИКӘ» ЖУРНАЛЫНА 70 ЕЛ

Хатын-кызның серле дөньясы *(«Сөембикә» журналының баш мөхәррире Р. Туфитуллова белән әңгәмә).*

Г. АФЗАЛГА 75 ЯШЬ

Афзал Г. Ян, йолдызым, ян... *Шигырьләр.* № 5.

Ә. МАЛИКОВКА 75 ЯШЬ

Маликов Ә. Төрле еллардан. *Шигырьләр.* № 8.

Г. ШӨРӨФИГӘ 70 ЯШЬ

Утлы юлларны узып. № 7.

Ә. ГАБИДИГӘ 70 ЯШЬ

Гаташ Р. Ихласлык — шагыйрьлек тә... № 10.
Габиди Ә. Аккошлар китә. *Шигырьләр.* № 10.

Х. КАМАЛОВКА 70 ЯШЬ

Әҗәлне җиңгән әдип. № 4.
Камалов Х. Сугышта устав юк... *Фронт истәлеге...* № 4.

Ш. МАКСУДОВАГА 70 ЯШЬ

Низамиев Р. Тынгысыз сабырлык. № 11.
Гөлшәһидә. Моңнарымда — җиде кыл. *Шигырьләр.* № 11.

И. НИЗАМОВКА 60 ЯШЬ

Низамов И. Парчалар. № 7.

К. БУЛАТОВАГА 60 ЯШЬ

Гаташ Р. Ничәдә син, йөрәк? № 3.
Булатова К. Безнең гомер сирпелгән җир... *Шигырьләр.* № 3.

Р. КУТУЙГА 60 ЯШЬ

Әгъләмов М. Кутуй — үзе бер дөнья ул. № 11.
Кутуй Р. Килеп чыгышым. *Шигырьләр.* № 11.
Кутуй Р. Ир кешеләр. *Хикәя.* № 11.

Ә. РӨШИТКӘ 60 ЯШЬ

Әгъләм М. Хакыйкать эзләп. № 3.
Рәшит Ә. Карлар ява. *Шигырьләр.* № 3.

Ә. САФИУЛЛИНГА 60 ЯШЬ

Үзем турында үзем. № 12.
Сафиуллин Ә. Гаҗәп серләр. *Хикәяләр.* № 12.

Ф. УРМАНЧЕГА 60 ЯШЬ

Урманче Ф. Чыңгыз хан һәм аның эпик биографиясе. № 5.

И. ГЫЙЛӘҖЕВКӘ 50 ЯШЬ

Фәйзуллин Р. Болай гына гади күренә ул... № 1.
Гыйләҗев И. Кемдә гаеп? *Шигырьләр.* № 1.

М. ГАЛИЕВКӘ 50 ЯШЬ

Низамиев Р. Тауга күтәрелү. № 9.
Галиев М. Догалы еллар. *Эссе.* № 9.

М. ӘГЪЛӘМОВКА 50 ЯШЬ

Әгъләм М. Төрле еллардан. *Шигырьләр.* № 10.

Н. ӘХМӘДИЕВКӘ 50 ЯШЬ

Гамбәров Н. Каеннар яктысында. № 12.
Әхмәдиев Н. Кыяр-кыймас кояш байый. *Шигырьләр.* № 12.

Р. СИБАТКА 50 ЯШЬ

Зөлфәт. Сер. № 10.
Сибат Р. Өчтомлыкны укыгач өч сүз. № 10.

Х. ӘЮПКӘ 50 ЯШЬ

Зөлфәт. Тыелгысыз кош сере. № 8.
Әюп Х. Хәтер тауларыннан. *Шигырьләр.* № 8.

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Госман Бакирның тууына 100 ел. № 3.
Идрис Туктарның тууына 100 ел. № 9.
Абдулла Гомәрнең тууына 90 ел № 6.
Габдрахман Минскийның тууына 90 ел. № 9.
Демьян Фәтхинең тууына 90 ел. № 10.
Кәшфи Басыйровның тууына 90 ел. № 4.
Ләбиб Гыйльминең тууына 90 ел. № 6.
Әсгать Айдарның тууына 90 ел. № 6.
Гамир Насрыйның тууына 80 ел. № 1.
Зыя Мансурның тууына 80 ел. № 12.
Әхмәт Юнысның тууына 80 ел. № 10.
«Казан утлары» архивыннан № 5, 8.

Укучы сүзе №№ 1, 5, 10.

## ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Булычева К. Чиксез манзара — чиксез күңел. № 1.
Булычева К. Пәйгамбәрнең уе. № 2.
Гамбәр Н. Иҗат ул — тәкъдир эшедер!.. № 9.
Миңлебаев К. Ак ат. № 6.
Шаһиева Р. Кырыгынчы көн... № 7.
Шаһиева Р. Хансәвәр ишан шәмаиле. № 8.

## ЯҢА КИТАПЛАР

№№ 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9, 10, 11, 12.
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан №№ 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9, 10, 11, 12.

## ТАТАРСТАН ДЕЛЕГАЦИЯСЕ — ИРАНДА

18—20 ноябрь көннәрендә Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев җитәкчелегендәге рәсми делегация эш визиты белән Иран Ислам Республикасында булды. Визит барышында Җөмһүриятебез Илбашы Иран Ислам Республикасы Президенты Али Әкбәр Хашими Рафсанҗани һәм Мәҗлес (Парламент) Рәисе Али Әкбәр Натег Нури белән очрашты. Очрашуда ике ил арасында элемтәләрне ныгыту турында сүз барды. Али Әкбәр Натег Нури әфәнде Казан дәүләт университетына болгар галимнәренең Иран китапханәләрендә саклана торган кульязмаларының күчермәләрен бүләк итте.

## ПОЛЬША ВӘКИЛЛӘРЕ — КАЗАНДА

14 ноябрьдә Татарстанга рәсми визит белән Польша Республикасы Премьер-министры Влодзимеж Цимошевич килде. Югары дәрәҗәле кунакны Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев, ТР Премьер-министры Ф. Мөхәммәтшин кабул итте. Үзара дуслык шартларында үткән сөйләшүләр барышында Польша — Татарстан хезмәттәшлеген тагын да киңәйтү һәм тирәнәйтү мәсьәләләре хәл ителде.

Польша Премьер-министры җитәкләгән делегация составындагы министрлар һәм эшкуарлар Татарстан Республикасының җитәкче даирәләре һәм инициативалы, күренекле эшкуарлары белән «түгәрәк өстәл» янында фикер алыштылар.

## ГАЛИМНӘРГӘ — ДӘҮЛӘТ БҮЛӘКЛӘРЕ

Гуманитар, табигать һәм техник фәннәрне үстерүгә зур өлеш керткән, принципиаль яңа технологияләр эшләгән һәм гамәлгә ашырган, фән һәм техника казанышларын киң күләмдә куллану нигезендә производствода зур нәтиҗәләргә ирешкән өчен, ТР Президенты М. Шәймиев Указы нигезендә, бер төркем галимнәргә фән һәм техника өлкәсендә 1996 ел өчен Татарстан Республикасының Дәүләт бүләкләре тапшырылды. Бүләкләнүчеләр арасында Татарстан Фәннәр академиясе һәм Россия Мәгариф академиясе академигы Мирза Мәхмүтов, Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе ректоры, академик Газим Идрисов, ТР Сәламәтлек саклау министры Камил Зыятдинов һ. б. бар.

## М. ФИЗУЛИ КУНАК ҖЫЯ

Бакуда бөек әзәрбайҗан шагыйре — атаклы «Ләйлә һәм Мәҗнүн» исемле романтик поэманың авторы Мөхәммәд Физулинең тууына 500 ел тулуга багышланган юбилей тантаналары булып үтте. Анда Татарстан Республикасы вәкилләре — ТР Мәдәният министры М. Таишев, ТР Дәүләт Советы әгъзасы, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясе рәисе, шагыйрь Р. Миңнуллин да катнашты.

Татарстан кунакларын Әзәрбайҗан Президенты Г. Алиев кабул итте. Очрашуда Татарстан Республикасының Әзәрбайҗандагы даими вәкиле Р. Ильязов та катнашты. Ул Әзәрбайҗан Президентына Татарстан Президентының хатын тапшырды.

## ВӘКИЛЛЕКТӘ ОЧРАШУ

Татарстан Җөмһүриятенең Россия Федерациясендәге даими вәкиллегендә танылган татар тарихчысы һәм публицист, тарих фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең почетлы әгъзасы, Россия дәүләт гуманитар университеты профессоры, «Казан утлары» журналының даими авторы Әгъдәс Борһанов белән иҗади очрашу үткәрелде. Биредә аның яңа гына дөнья күргән «Каян һәм кая барасың, Россия?» дип исемләнгән яңа китабын тәгъдир итү булды. Кичәне Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге даими вәкиле Ф. Мөхәммәтшин, «Туган тел» җәмгыяте вәкиле Н. Гарипов алып барды.

## ПЕДУНИВЕРСИТЕТ БӘЙРӘМЕ

15 ноябрьдә Казан дәүләт педагогия университеты 120 еллык юбилеен билгеләп үтте. Бәйрәмгә биредә төрле елларда белем алган мөхтәрәм академиклар, профессорлар, педагоглар килде.

Тантанада катнашучыларны Татарстан Республикасының Дәүләт Советы Рәисе В. Лихачев һәм шушы югары уку йортын тәмамлаган дәүләт эшлеклеләре — ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, шагыйрь Р. Харисов һәм ТР Премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин тәбрикләде.

## ТӨБӘКТӘГЕ КИҢӘШМӘЛӘР

Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы, Журналистлар берлеге, «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе һәм Казан дәүләт университеты район-шәһәр газеталары мөхәррирләре, ти-

пография директорлары һәм хакимият башлыклары урынбасарлары катнашында Балык Бистәсендә һәм Буада төбәк киңәшмәләрен үткәрде. Аларның һәр икесендә дә ТР Мәгълүмат һәм матбугат министры И. Әхмәтҗанов һәм «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Р. Фәйзуллин катнашты һәм чыгыш ясады.

## КОЛ ШӘРИФ МӘЧЕТЕ ТӨЗЕЛӘ БАШЛАДЫ

1 ноябрьдә Казан Кремлендә Кол Шәриф мәчетен яңадан торгызу буенча төзелеш эшләре башланды. Бу мөһим төзелешне Төркиянең «ИЛЬК УМУТ» фирмасы алып бара. Әлеге фирма Татарстанда 1994 елдан бирле эшли. Төркиядә, Сәгуд Гарәбстанында мәчетләр салуда бай тәҗрибә туплаган бу фирма төзүчеләре Кол Шәриф мәчетенең монолит стеналарын 10 ай эчендә торгызырга ниятлиләр.

## ДУСЛЫК КҮПЕРЕ

6 ноябрь көнне Казан—Мәскәү автострадасында Зөя елгасы аша 378 метр озынлыгындагы яңа күпер ачылды. Әлеге күпер Татарстанны Чуашстан һәм Россия Федерациясе өлкәләре белән бәйләде, Европа һәм Азия илләренә туры юл ачты, Казан белән Мәскәү арасын якынайтты.

Зөя күперен рәсми тәстә ачу тантанасында Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев, ТР Премьер-министры урынбасары В. Швецов катнашты.

## АТИЛЛА РАСИХНЫ ИСКӘ АЛУ

13 ноябрьдә Татарстан язучыларының Г. Тукай исемендәге клубында күренекле язучы-галим Атилла Расихны искә алу кичәсе булды. Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булган әлеге фронтовик-әдип турында ТР Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, Татарстанның халык язучысы Г. Ахунов, СССРның һәм Татарстанның халык рәссамы Х. Якупов, әдәби тәнкыйтьче Ф. Галимуллин, Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе профессоры, шагыйрь Р. Җамал (Корбанов) һәм мәрхүм язучының хатыны З. Рәсүлева үзләренең истәлекләре белән уртаклаштылар.

## АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВКӘ ХӨРМӘТ

Моннан берничә ел элек Зәйдә район хакимияте, Татар иҗтимагый үзәге белән берлектә, язучы Сөббух Рафиков исемендәге премия булдырган иде. Быел бу бүләккә Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев, Зәй районында яшәүче шагыйрь Мөнир Талипов һәм район мәдәнияте бүлеге хезмәткәре, баянчы Хәтфир Җиһаншин лаек булды.

Тантанада район хакимияте башлыгы Р. Хәмәдиев язучы А. Гыйләҗевкә Зәйдә төзелгән яңа коттеджның ачкычын тапшырды. Шулай итеп, аксакал әдибебез хәзер гаиләсе белән туган төбәге Зәйдә яши башлады.

## Ф. КӘРИМ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

23—24 октябрь көннәрендә Башкортстан Республикасында өч тугандаш республика — Башкортстан, Татарстан һәм Чуашстан әдәбиятлары дуслыгы фестивале булды. Биредә Фатих Кәрим исемендәге халыкара премиянең беренче лауреатлары игълан ителде. Быел ул берьюлы өч кешегә — татар шагыйре Ренат Хариска, чуаш шагыйре Виталий Енешкә һәм башкорт язучысы Таһир Таһировка бирелде.

## ЯҢАВЫЛДА — ЯҢА КҮРГӘЗМӘ

Танылган рәссам-график, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Э. Зарипов үзенең авылдашы һәм дусты — Татарстанның халык шагыйре И. Юзеев иҗатына һәм тормышына багышланган күргәзмәсен быел җәй айларында Казан тамашачыларына Г. Тукай музеенда күрсәткән иде инде. Шушы елның 18 октябрендә әлеге күргәзмә рәссам белән шагыйрьнең туган ягына — Башкортстанның Яңавыл шәһәренә кайтты.

Күргәзмәне ачу тантанасында Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, шагыйрьләрдән Ш. Галиев, И. Юзеев, Р. Миннуллин, Яңавыл шәһәре һәм районы хакимияте башлыгы Н. Зыязов һ. б. чыгыш ясадылар. Залдагылар рәсеме күргәзмәгә куелган, күптән түгел арабыздан киткән зур галим һәм язучы Нил Юзиевны (И. Юзеевның бертуган абыйсы) хөрмәт белән искә алдылар.

---


## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Әнвәр Сәйфетдиновның «Гаҗәпләнү мизгеле» картинасыннан фотокүчермә.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган шагыйрь, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире Зиннур Мансуров.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Ренат ХАРИС. **Хисемнең исеме.** *Шигырьләр, поэмалар.*—Казан: Татар. кит. нәшр., 1996.—255 бит.




Бу китапка күренекле татар шагыйре һәм җәмәгать эшлеклесе Ренат Харисның (ул—Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, «Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы) яңа шигырьләре, поэмалары, җырлары тупланган. Җыентык «Татар иле», «Көмеш нур», «Өченче фәрештә» дип исемләнгән өч бүлектән тора. Беренче бүлектә татар әдәбияты һәм сәнгатенең мәшһүр шәхесләре—Бакый Урманче, Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Әмирхан Еники, Рөстәм Яхин, Александр Ключарев, Сара Садыйкова һәм тагын кайберәүләргә багышланган шигырьләр бар. «Татарлар», «Җирсү» дип аталган кечкенә күләмле поэмалар да шул бүлектә урын алган. Ә өченче бүлектә исә—тоташ мәхәббәт шигырьләре. Шагыйрьнең кайбер шигырьләре үз вакытында безнең журналыбызда да басылган иде.

НАСЫЙБУЛЛИН М. Н. **Кайтаваз:** *Педагогик язмалар һәм кыйссалар.*—Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 1996.—223 бит.


Язучы Мәгъсүм Насыйбуллин укучыларга «Телсез шаһитлар», «Төнге ату», «Яшерен касса», «Алтын алка», «Йөрәк таш түгел» һәм башка мажаралы китаплары буенча таныш.

Һөнәре белән хокукчы һәм мөгаллим М. Насыйбуллинның бу җыентыгына педагогика белән юриспруденциягә бәйләнешле, алар өчен уртак мәсьәләләрне чагылдырган, милиция, суд, прокуратура тормышыннан алып язылган «Җинаять сәбәпсез булмый», «Мәкерлек һәм мәмилек», «Сугышканда хәлвә өләшмиләр» кебек исемнәре белән үк укучылар игътибарын җәлеп итә торган гыйбрәтле язма, кыйссалар тупланган. Автор тасвирлаганча, хокук белемнәре борынгы төрки бабаларыбыз заманыннан ук иҗтимагый-педагогик фикер белән бергә үрелеп үстерелгән.

Яшь буынны тәрбияләүгә багышланган бу җыентык укучыларны, ата-аналарны, барлык китап сөючеләрне битараф калдырмас.



Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)